КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Эльмира ҖӘЛИЛОВА. Гомернең төш кенә булуы ихтимал... *Шигырьләр.* 3
Рифә РАХМАН. Татар кызы. *Роман.* 8
Мөхәммәт МИРЗА. Адәм баласы. *Бишьюллыклар.* 70
Амур ХАН. Сабакташлар. *Хикәя.* 74
Ләбиб ЛЕРОН. Күңелемә шигырь оялады... *Шигырьләр.* 84
Гөл МИРҺАДИ. Гитара. *Хикәя.* 88
Алинә ХИСАМИЕВА. Ак кәгазьдән нәни очкыч ясыйм... *Шигырьләр.* 93

«КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Милләтнең әдәби авазы. 96

«КАЗАН УТЛАРЫ» – МИНЕМ ЯЗМЫШЫМДА

Марат ӘМИРХАНОВ. «Мичкәдә дары бетмәгән әле». 99

ЯҢА ИСЕМНӘР

Илшат БИЛАЛОВ. Мәдинә тавы. *Повесть.* 101

«АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Халисә РӘЙХАН. Прасковья. *Хикәя.* 147

Юбилейга барышлый: фотоархив. 156

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Бәхетне эзләп табалар... 158
Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА. «Чүп базары»нда яңгыраган шагыйрь тавышында нинди аһәңнәр ишетелә?.. 166

Ерактагы утлар: Альбина ХӘЛИУЛЛИНА. Өзелгән кыллар моңы. 170

Кардәш халыклар әдәбияты: Борис УКАЧИН, Бронтой БЕДЮРОВ, Кулер ТЕПУКОВ *шигырьләре (алтайчадан Разил ВӘЛИЕВ, Рафис КОРБАН тәрҗемәләре).* 175

«Чолбон» журналына – 95: Рафис КОРБАН. Саха кардәшләребезнең таң йолдызы. 180

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Милли музыкаль драманың атасы. *(Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 130 ел).* 182
Күңелдән җуелмас моң иясе. *(Мәрьям Рахманкулованың тууына 120 ел).*
Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара. 183

Фән: Дания ЗАҺИДУЛЛИНА.Татарның фән йолдызлары. 184

«Казан утлары» архивыннан. 157
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 190

КАЗАН УТЛАРЫ
№ 11 (1189) 2021

БАШ МӨХӘРРИР –
Рөстәм Госман улы
ГАЛИУЛЛИН

ИДАРӘ:
Ирада Әюпова
Разил Вәлиев
Рәдиф Гаташ
Искәндәр Гыйләҗев
Айрат Зарипов
Дания Заһидуллина
Ркаил Зәйдулла
Илгиз Зәйниев
Илфак Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Газинур Морат
Рүзәл Мөхәммәтшин
Айдар Сәлимгәрәев
Равил Фәйзуллин
Илсур Һадиуллин
Данис Шакиров
Ленар Шәех

Баш мөхәррир урынбасары: **Вакыйф Нуриев.**
Җаваплы сәркатип: **Ландыш Әбүдәрова.**
Бүлек мөхәррирләре: **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан, Рамил Ханнанов.**
Мөхәррирләр: **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Илгизә Сабирова.**
Сайт мөхәррире: **Ләйсән Зарипова.**
Исәп-хисап бүлеге: **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер).
Машина йөртүче: **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).
Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).
Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).
Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.10.2021, график буенча 29.10.2021, басылып чыгу вакыты 03.11.2021.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-3555. Тираж 8937.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2021 ел

Эльмира
Җәлилова

ГОМЕРНЕҢ ТӨШ КЕНӘ БУЛУЫ ИХТИМАЛ...

***

Кая калды соң ул керфек какмый,
икәү төнгә таң ярәшкән көннәр?!.
Аһ!..
Җитәр микән йөрәк җегәрләрем,
сине бүген «шундый боек», диләр...
...Йөз елга бер күрешәбез хәзер –
сусау бетми, мизгел ярым күреп,
имәнепләр китәм.
Дөнья сыйган караш –
суы кибеп барган кое кебек.
Эле-е-ек!
Син бит башка идең!
Ни үзгәрде?!
Сулык-сулык килә чигә, уйлый-уйлый.
...Булмый!
Беләм, пыску үлемгә тиң. Безнең өчен.
Җаның утсыз – утсыз янып булмый...
Мин... хәлеңне сорарга да кыймыйм
(сорасам да, әйтмәсеңне тоям).
Кирәк бит, ә! Җаннар тәңгәллеге –
син бар яклап никтер минем сыман.
Әйтергәме-әйтмәскәме?! Белмим.
(Син бит минем үзәгемнән өзелгән үз кешем!)
Башкасына исем китмәс иде... –
Үз-үзеңне югалтырсың төсле...
Дәшү – авыр, дәшмәү – газап. Нишлим?!.
Каян табыйм шыксызлыктан ышык?!
...Дөньясыннан яшерердәй булам –
кочаклыйсым килә сине!
Кысып-кысып!..

Эльмира ҖӘЛИЛОВА (1979) – *шагыйрә; «Кыз күңеле», «Икебезгә бер гомер», «Яратулы еллар» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Сары яфрак булып, җиргә ятып,
җылый-җылый җан биргәндә быелгы көз,
ноябрьдә үләрмендер кебек.
(ә без һаман «син»гә күчәлми(без).

Исәнме(сез)! Хәлне сорама(гыз)!..
Кара төнне соры көнгә күмәм.
Кәеф көйлим. Каһвә белән. Ят шәһәрдә.
Ноябрьне сөймим, шуңа күрә.

Томан, томан, томан... пыскак яңгыр.
Күпме сорау бу дөньяга. Бар да ачык.
Качып котылырлык түгел төссезлектән.
Әйдә,
ноябрьне календарьдән сызып ташлыйк?!

Яши башлыйк гел яңача, ноябрьсез.
Әйтерсең лә үзебездә түгел сәбәп.
Ялангач – көз.
Һәм саксыз сүз җан сүрүен җыртып тула.
Гел түз дә түз.

Шул чагымда чара-дәва табалмагач
без беркайчан «син»гә күчәлмәбез.

***

Бүген иң соңгы мәртәбә
сиңа дип талпынган хисләрне тугарам.
Таныйм да тын алам:
бу җиргә син мине сагынып тумаган.
Үпкәне гел үпкә тутырган.
Суламый түз дә түз...
Картайган җәйдә без.
Бер көн көз
сагыну төсенә манар да дөньяны,
исеңә төшерер кайдадыр мин барны.
Әлегә
мин сиңа буявы тутыккан төш кенә.
Ни диим?!
Кайчандыр шулкадә-ә-әр кадерле кешегә:

...Җәйге төн суынды. Өшемә!

***

Шундый авыр булып калды сине күрү:
әллә үле инде, әллә тере.
Бүген апрель ноябрьгә охшагандай –
син бөтенләй башка. Үзең түгел.
Сүзем. Сиңа гына дигән мең-мең сүзем
дәшәлмәүдән буа бугазымны.

Беләм:
минем язгы боздай чатнап яргалану
сиңа берни түгел, буп-буш ыгы-зыгы.
Битлегеңне ватамын да, мин арчалап,
әрчим, әрчим җан кабыгың.
Кубаруга яңа битлек калкып чыга –
юк, танымыйм.
Табылмыйсың... Инде сиңа ят шәүләләр,
ят мәгънәләр йога.
(Һәм коточкыч!) сине күргән саен
ышанычым җуям. Яратуга.
Тик алай да тыңла, ишет, яме,
белеп булмый алдан дөнья хәлен:
бер көн дертләп уянуга уеныңнан
һәм болытлар куерудан ят офыкта,
йөз чөерсә әгәр бөтен Галәм.
(Сине беркем үз итмәсә. Минем кадәр!)
үз җанымнан чыра телеп,
сине тергезерлек мин бар!
(Мин каядыр бар)
Син онытма...

***

Җил ега аяктан.
Кай яктан китә боз?!
Тыз да быз, выж да выж
җил бәрә. Җилгәрә,
шашынып,
кыш буе асфальтка сибелгән
шакшыны.
Бу – апрель (газабы)
азагы...
Буылып,
авыру тузанын йотамын Казанның.

Азамы яз саен төзәлмәс өянәк:
чыгаммы чиксезлек чигеннән?!
Дөньяга ябышып торамын
җанымның
тик сиңа береккән җиреннән.
(Югыйсә
очармын шикелле кан тарткан тарафка
үзәккә үтәрлек җил белән).

Һава юк. Мин сине сулыймын.
Кисәрдәй шыр исәр җил исә.
Һәм кинәт исертә –
хушбуең йога да бу кичкә.

Чәч төбемә батырасың бармакларың:
«мин беркайчан, мин беркемне
болай яратмадым!»

***

Бу салкынга күнегүдән куркам,
сүрелүдән куркам сиңа – синсез.
Кырау төшкән иртәләрен кояш
иркәли. Тик
җиле җелекләргә үтә.
Казанда көз!
Үз идек без,
үзәкләргә үтәрлек үз идек бит!
Читләшкәндә, җанны кысып учка,
(сиңа башка күзләр кадерлерәк
күренүдән куркам)
һаман
фасылара халәт әле тышта.
Көздән кышка.
Көннәр төннән кыска.
Күңел тула никтер,
бер дә юктан.
Куркам.
Һәр минутта хәзер, һәр минутта...

Синсезлеккә күнегүдән куркам.

***

Бер артык сорау да кирәкми:
«моңарчы?», «моннан соң?»
Белергә теләмим. Берни дә.
Быел яз акылдан язарлык.
Азарлык –
утлы сут яшәүнең иренендә.

Яланөс. Яланбаш. Гел кояш!
Кан кайный.
Кымырҗый җүләрлек.
Яшеллек яп-яшь мәл.
Үләннең
чыкларын иелеп үбәрлек.

Үләрлек!
Яратып үләрлек!
Тик менә
парадокс туп-тулы күләмдә:
яшәргә курыккан бәндәләр
шулкадәр куркалар үләргә...

Ә миңа көләргә булсын гел,
янарга, көяргә,
җә янып сүнәргә,
бер көндә мең туып үләргә...

Һәм шуңа күрә дә
мин дәва эзләмим үземнең «чиремә».

Читтәрәк корам да тирмәмне –
тирбәләм.
Бәхет гел кыргыйлык чигендә.

Син генә (башкалар – шәмәхә!).
Син генә яшәргә, үләргә
курыкма – ян да ян!
Тоеп кал
тамырда яшәүнең яшьнәвен –

гомернең
        төш кенә
                булуы
                        ихтимал!..

***

Һәм мин сиңа сүзләр таба алмыйм.
Чирек гасыр учлам-учлам җыйган
һәрбер иҗек җуйган бөтен гамен.
Ә син
әле кичә генә хушлашкандай:
«Ничек хәлең?!» – дисең. Ничек хәлем?!

Бар дөньяның яздан язган мәле.
Комлы, тозлы пычрак җеби…
Хәл сорашу шуңа мәгънәсездер.
Исеңдәме? Юл ярата идем.
Бүген: көн-таң атса юлдан-юлга.
Уйдан-уйга...
Тик әйтергә сүзләр таба алмыйм.
Авыр тынлык тынны буар төсле.
Синең өчен күк күкрәтеп йолдыз койган
чакны сөйләр идем. Артык төче.
Һәм хакыйкать чыңлый җанны ярып:
без шулкадәр... ике чип-чит кеше...
«Нихәл» ише сүзләр белән,
беләм, ялгап-ямап булмый...

Димәк, «җир йөзендә
Син булганга гына исән, –
дигән сүзләреңә, – исәр йөрәк».
Сүзләрем юк.
Һәм тып та тып нидер эри.
Гомер эреп югалгандай.
Гел тыз да быз.
Очрашканбыз.
Чирек гасырдан соң.
Сиңа баккан (Син яраткан)
күзләремдә күк төсендә
Зәп-зәңгәр ике боз.

Рифә Рахман

ТАТАР КЫЗЫ

РОМАН*

Бишенче бүлек

Сөйгәнеңне сөйрәп ал

1

Рәгыйдәнең, авырлыкларны күбрәк күргән саен бәхет бер дә бер көнне ишелеп килер, тормышның рәхәте алдадыр, дигән уйлары сөрсегән тукыма кебек таралды да китте. Яшьлеге сугыш елларына туры килгән кызда, дус-ишләрендәгечә, кемгәдер гашыйк булырмын да кияүгә чыгармын, өй тутырып, балалар үстерермен, дигән хыяллар бөтенләй юк иде. Ул барысын үзе булдыра, ат кебек эшли, белгәндә көче җитәрлек, ирсез йортны ялгызы диярлек алып бара, әнисен өрмәгән урынга да утыртмый. Шулай икән, нәрсәгә аңа ир исемен йөрткән мәшәкать?! Әле энесе Галинурны укытасы, эшкә урнаштырасы, тормышын корып җибәрергә булышасы бар.

Кыз бервакыт кичен иптәшләре белән капка төбендә утырганда, яр сайлау, өйләнешү кебек нәрсәләр турында сүз киткәч:

– Сез ни, әбиләрегезнең әйткәнен яхшылап истә калдыргансыз, утыз улың булганчы, у...к ирең булсачы, дип уйлыйсыз. Алайса, Муллагалигә баруыгыздан да яхшысы юк, ул әнә сәгать саен пырт итә, – дип көлде.

– Аның каравы… Әнисе шундый әйбәт. Сыерлары бар! – диде шушындый чакта акыллы сүз таба алмаган Шәмсия. Рәгыйдәнең егетне яратмавына сөенеп, шуның аркасында үземә кала дип өметләнә иде ул, тик моны Муллагали генә белмәде.

– Аларның мунча тәрәзәләре дә зур, абзарлары да ишекле… – дип тезде Рәгыйдә, сүзне шаяруга борып. – Миңа сыер белән дә, тәрәзә белән дә яшисе түгел. Мин көн итәрлек кешегә генә чыгам! Ирләрнең матурлыгына карамаска куша иде мәрхүм әтәй дә.

– Үзе әнә патшабикәләр кебек затлы, төскә-биткә чибәр Зәмнихаттәйне эләктергән. Бөтенләй башка авылдан алган. Бер күреп белмәгән кызны, – диде Майтап, тешләренә начар ябыштырылган укаларын рәтли-рәтли.

– Алтын тешең төште мәллә? – дип көлештеләр кызлар. Көмеш-алтын тешләрнең модага кереп барган чагы иде. Акчалары булгач, Гөлзиннәт белән Рәгыйдә, Мамадышка барып, шундыйны сәламәт тешләре урынына

---

* Журнал варианты.

Ахыры. Башы 9, 10 нчы саннарда.

куйдырып кайтты. Майтап, әле чыгым көткән җирләр күп дип, бу эшне соңракка калдырган, яндагы ике тешенә кәнфит эчлеге генә ябыштырып йөри иде. Тешемне күрсеннәр дигәндәй, үзе гел елмаерга гына тора.

– И-е, – дигән булды ул, авызын киң ачар өчен җай чыкканга сөенеп.

Муллагали кызларның, бигрәк тә Рәгыйдәнең таза-сау тешләрен алдырып атуларын бер дә аңлый алмады. Ул кәкрәешеп утырган тешләрен дә кызгана, чери башламасалар ярар иде дип куркып тора. Берсен алдырсаң, калганнары артыннан ишелә бара, ди әнисе.

Муллагали Рәгыйдә турында уйлап, капка төпләрендә утырды да, кызларның күпер янындагы уенлыкка төшмичә, инеш буена киткәннәрен аңлагач, урам уртасына чыкты. Юлның үр башында да, түбәнендә дә беркем юк иде. Тегеләйгә-болайга карангалап торды да, нәрсә эшләргә белмәгәч, өенә кереп китте.

Уйламыйм дип, үз-үзенә күпме сүзләр бирсә дә, Рәгыйдәне уйлаудан туктамаган иде Муллагали. Якында гына үскән кызга кечкенәдән үк гашыйк, чикләвеккә барганда, аңа ияреп, Сабантуйда аның янына басып йөгерә, каз бибиен дә аның янәшәсендә сакларга тырыша иде ул. Әле егет булгач та, печәнгә төшсәләр, Рәгыйдә артыннан калмаска тырышып чапты. Ындыр ачылса, аның бригадасына язылды. Булган да, чибәр дә Рәгыйдәне яраттыра алмагач, күрше кызлары урам иңләп култыклашып, җырлап клубка төшеп киткәндә, Муллагали әбисе сырып биргән юрган эчендә мышык-мышык кала торганга әйләнде. Ничек мышкылдап йокыга китсә, Рәгыйдәне күргән төшеннән шулай мышкылдап уянды да. Кайвакыт ул бөтенләй йокламыйча ята һәм, менә клубтан кайтырга чыгарлар, иркен сулыш белән җырлаган кызның моңлы тавышы марля тарттырылган тәрәзәләре аша үтәр дә аның болай да әрнегән йөрәгенә тоз салыр дип, алдан ук калтырый башлый иде.

Кызның малаена карамыйча, борын чөюенә ачуы чыккан Шәмсенисаның хәтере калды. Иртәнчәк урам буйлап көтү җыеп төшкән Рәгыйдәне каршысына чыгып туктатты да шул турыда бик тә аңлашылырлык итеп әйтте. Аның моңа исе китмәде:

– Бергә уйнап үскән малайларга егет итеп карамыйм мин, Шәмсениса апа!

– Алай барысын да кага торсаң, ир күрмәвең дә бар, кызый.

– Өскебашта чын ирләр бетсә... Авылдан китеп барам да җылы як кешесенә чыгам мин. Мондагы салкыннарда катканчы. Дөнья зур, ирләр калгандыр әле.

Бу сүзләрне Рәгыйдә болай гына, теленә һич уйламастан килгәнгә генә әйтте. Аның өстендә гаиләсе – әнисе, энесе иде.

Озак та узмады, Муллагали Исламнурларның, Минзифа апаларының сеңлесе Миңлебануга өйләнде. Шуннан соң үпкәләр онытылды, күрше егет белән кызның үзара яратушуга әверелеп китә алмаган дуслыклары тагын да ныгыды, Шәмсениса апалары тумачи булды да китте.

Чынлыкта, Рәгыйдәнең авыл егетләренә чыгарга теләмәвенең сәбәбе бөтенләй башкада. Ул мәктәптә укыганда ук, зәңгәр күзле, бөдрә чәчле Хафизны якын итте. Бала вакытта бөтенләй дус түгел иде алар. Югары классларга җиткәндә, борчаклары пешә башлады. Җидене тәмамлауга мәҗбүриләп, колхоз эшенә куймасалар, бергәләп авылдан чыгып китәсе, дөньяның иң матур җирендә йорт салып, моңарчы күрмәгән рәхәтлекләр кичереп, авылга күчтәнәч арты күчтәнәч салып яшәмәкче иде Хафиз.

Рәгыйдәне бу хыяллар үсендермәде. Тормышны, әнисен энесе җилкәсенә генә калдыра алмый иде ул.

Бервакыт күрше авылдан узганда, кыргыз булган бер адәмнең думбра чиртеп әйткән җырын исе китеп тыңлады Рәгыйдә:

Катындардан калпып ал,
Кыз балдардан – кымтып ал.
Келиндерден кетип ал,
Сүйгөнүңдү сүйрәп ал,
Каалаганың кармап ал.

– Бигрәк сүзләре безнеңчә! Ничек оста әйтте дә бирде!

– Тышкысыннан битәр, эчке мәгънәсе тирән аның. Хатын-кызның иң өстәгесен – яхшысын сайла, кызларны алдап, үзеңнеке ит, киленнәрне умырып ярат, сөйгәнеңне сорамый да ал, теләгәнеңнең барын эләктер, дигәнне аңлата ул, – диде кыргыз ирен авылга ияртеп кайткан хатын.

– Җырны яратканыңны үзеңнеке ит дип аңласаң җитә. Сез әйткәне тормышның ямьсез яклары, хатын-кызга тупас мөнәсәбәт турында да уйлата.

Шулай диде дә Рәгыйдә юлын дәвам итте. Күңеленнән кыргыз җыры китмәде. Бу җыр аның турында кебек тоелды...

Ул яраткан, аның белән мәңге бергә булырга дигән Хафиз Төньяк океандагы утрауларның берсенә – Шпицбергенга эшкә ялланган иде. Халыкара күмер чыгару концессия шахталары ул, дип мактанып сөйләп торды. Кукмара-Мамадыш ягы халкы аеруча күп язылган, имеш. Рәгыйдә, егет аны үзе белән алырга теләсә дә, әнисен калдыра алмады. Ул моңа үч итеп, егетләр белән йөри дип даны чыккан кыз белән китеп барды да инде бер фатирда яшәп тә ята иде...

Бу хакта ишетмәгәндер, белмидер дип уйлаган Хафиз Рәгыйдәгә баштарак хат та язган иде. Норвегиянең ак аюлар хуҗа булган, җәйләрен дә биш градустан да артыгракка җылынмаган төньягы бу, үзләре Свальбард дип атыйлар, үзәге – Лонгйир, дигән, мин СССР шведлардан сатып алган җирләрдәге Гурмант посёлогына эләктем. Сугыш чорында җимерелгән бистәне торгызасылар да, шахтада эшләп калачаклар, имеш. Рәгыйдә Хафизның хатына җавап язып тормады. Танышлары арасында сугышка кадәр дә Баренцбург белән Гурмант шахталарына киткәннәре бар иде. Аларның туганнары аша ул бу хәлләрне инде ишетеп белгән һәм Хафизның үз тормышы турындагы ялганнарына, чынны яшерүләренә таң калган, башка үпкәсе дә зур иде.

Әнә шундый күңел борчуларың өстенә яңалары да өелә, тегенди-мондый хәлләре дә булгалап тора бит аның. Бер ай чамасы элек кичкерәк якта абзарга керсә, сыер янында төлке йөренә. Тегесенең нишләптер артык исе китми. Рәгыйдәне күрүе булды, төлке абзар почмагына сыенып утырды. Сыерга зыян да сала алмаган булыр иде, тавыкларга ияләнеп китмәсен дип курыкты Рәгыйдә. Тотты да кулындагы сәнәге белән төлкегә китереп тә кадады. Төлке шунда ук җан бирде. Кыз болай да аннан бик шүрләгән иде, бар нәрсәне онытып, шунда ук абзардан чыгып качты. Баскыч төбенә җиткәч, артына борылып карады, сыер да ишегалдында. Ишекнең ачык калуын күргәч, бер аңгыралык белән генә чыкканмы? Мал булып, малның да үләксә янында торасы килмәгәнме? Күзләрен мөлдерәтеп, Рәгыйдәгә карап тора. Куып кертте дә ишекне ныклап япты, төлкене алып атырга кушарга әниләре янына керде. Бу хәл күңеленә авыр килде, укшытты, ашый-эчә алмады, урынга барып ятты.

Төлкене әрәм итмәгәннәр, абзардан энесе чыгып алган да, тиресен тунагач, кичтән үк иләүчегә илткән, итен каядыр күмгән.

– Уф, миңа калмаган икән, эшен бетереп куйгансыз, – диде боларны ишеткән Рәгыйдә.

Әнисе сары-җирән тиредән бер дигән яка тектереп кайтты. Үзе үтергән төлкенең тиресе булса да, ул кыз күңеленә инде кибет әйберсе кебек тоела башлады. Шуннан соң гына Рәгыйдәнең төлкене кызгануы бераз басылды.

Бер төлке вакыйгасы гына, имансыз Хафиз исеме генә идемени Рәгыйдә күңелендә?! Әнәй дип, авылда калып ялгышты бугай ул. Әнә бит, Хәлимәбикә апалары бер киттеләр, бер кайттылар. Кайда гына барып чыксалар да, һәрвакыт торырга урыннары булды. Соңгы кайтуларында җизнәсенең Шәмәрдәндәге эше дә начар түгел иде – урман җибәреп ятты. Барыбер бөтенләйгә яшәп калмадылар. Авылда мәңге рәхәт күрмәячәкләрен, эштән башканы белмәячәкләрен аңлагач, анда ачык шахталар икән дип, Кизел якларына барып төпләнделәр.

Бу язда бакча башындагы буага күп итеп юкә батырганнар иде. Мунчаласын алгач, кабыкларын Газизҗан җизнәсе белән абзар түбәләренә яптылар.

– Тактадан итик мәллә? – дигән иде Галинур, җизнәсе кирәксенмәде:

– Ун елга чыдый әле ул, алга таба сыер тотарсызмы-юкмы, кем белгән. Тотсагыз, карарбыз.

Җизнәсе хак булган. Зәмниха карчык белән авылдан китәргә дип киңәшкәч, сыерны бетерделәр, сарык белән тавыкларны гына калдырдылар. Бер сөтле кәҗә алып җибәрделәр. Аннан Галинур белән икәүләп китеп тә бардылар. Әниләрен ялгызын калдыру авыр булса да, Ямьбикә апалары янда гына яшәгәч, ярдәмнәреннән ташламас әле дип уйлады Рәгыйдә.

– Акча эшләсәк, аңа да файдабыз тияр, күбрәк мая тупласак, йә үз яныбызга алдырырбыз, йә кайтып яшәрбез, – диде Галинур.

Әхмәтгали абыйлары эшкә чакырып торса да, аның хәле дә хәл иде. Көтмәгәндә-уйламаганда, мәңге терелмәс кебек хастаны аякка бастырган Аннасы үлеп китте. Бу аның авыруларын тагын көчәйтеп җибәргәндәй булды.

Тора-бара кәҗәнең файдасы үзләре уйлаганнан да күбрәк тиде. Суд хөкеме җиңеләйтелгән Әхмәтгали ил буйлап йөрергә рөхсәт алган һәм әнисе янына кайтып килгән, үпкәмне шуның сөтен эчеп кенә дәвалый алам – файдасы бар дип ышана иде.

– Балакаем, нинди зур урыннарда утырасың, өйдәгене аркылыдан буйлыга да алып куярга ярамыйсың, – диде аңа икенче кайтканында Зәмниха.

– Үпкә кысыла бит минем, әнәй. Кышкы салкында юеш кием белән, анда да ярымшәрә, яланаяк пленнан качуларның зарары инде.

– Шул килеш тә шахтага төшәргә, тузан суларга туры килә икән үзеңә.

– Булышмыйсың, дисең. Монда да эшләп йөрсәм, рәхәтләнеп минем белән сөйләшеп утыра алыр идеңмени, әнәй? – дип көлгән булды Әхмәтгали.

– Болай гына әйтүем. Калдырган акчаңа эшләтер кешесе табылыр.

– Табылыр.

– Ялгыз яшәвеңә дә борчылам. Менә Нәүбәһар әле дә үзеңне ярата бит...

– Арттан йөрүчеләр җитәрлек. Акчалы, урындагы кешегә кызыгамы алар, башкасынамы... үзем дә аптыраган.

– Шуларның берсен сайла инде.

– Рәгыйнә дигәненең Газимҗан исемле малае күңелемә якын, тик үзен бер дә яратмыйм. Ал да ал, дип аптырата ул да. Сиңа гына җибәрим әле, әнәй? Тегендә күңеле ятмый.

Аннаны яратканмы-юкмы, Зәмнихага бер дә сөйләмәде Әхмәтгалие. Үзен кайгыртканын, тәртипле хатын икәнлеген, бер-берсен санлап яшәгәннәрен күрә иде. Ничә ел торып, иремнән бер авыр сүз ишеткәнем юк, дигән соңгы хатында Аннасы. Ничек шундый итеп үстерә адыгыз сез аны, дип сораган. Кем белән дә бер дигән яши ала ул Әхмәтгали.

– Кемне дә яратмагач, Рәгыйнәгә өйләнәсең дә торасың мәллә? Аш-суга да оста, дисең.

– Шаккатырасың, әнәй.

Шулай дигән Әхмәтгали үзе шаккатырса да шаккатырды: шаяртып кына әйтә кебек иде, кунак булуына күп тә узмады, малаен җитәкләп, Рәгыйнә килеп керде. Үз өенә – бер яшәп киткән җиренә кайткандай, ишекне каерып ачып, бусагадан узды да Зәмниха карчыктан бөтенләй кыенсынмыйча, ике куллап күреште:

– Исәннәр генә торасыңмы, энкәй?

– Аллага шөкер. Әхмәтгалием, өйләндем, димәгән иде диюен. Алай, энкәй, дип торгач, уз әйдә, – диде Зәмниха, аның җавабын да көтмичә, малаеның костюмын салдырып, чаршау астына элеп торган Рәгыйнәгә.

Килен булып кергән хатынны бер дә начар дип әйтә алмады Зәмниха. Өйне ялт иттереп җыештырып куя, ризыгын пешерә, малаен карый, кәҗәсен сава, бакчасында эшли. Көн буе рәхәтләнеп сөйләшеп, чәй эчәләр, Әхмәтгалине искә алып утыралар. Беркем дә колхоз эшенә йөрмәгәч, олыгаеп килгән Зәмнихага өч кешене тарту, тамакларын туйдыру гына кыен иде. Аксыбыда сыендырырга теләүче туганы табылмадымы, көн итүләренең авырлыгын күрсә дә, карчыктан чыгарга уйламады Рәгыйнә. Ахырда түзмәде Зәмниха, аңа Келәвештә бәрәңге киптерү эшен сөйләшеп кайтты. Әле дә ярый «килене» моңа карышмыйча, рәхмәтен әйтеп, шунда күченде. Алар киткәч, бер утырып, ух Аллам, диде Зәмниха.

Көн итәргә бар ягы да килгән Рәгыйнәне алырга теләмәсә дә, барыбер өйләнде Әхмәтгали. Ир кешегә, авырган кешегә ялгыз яшәүнең кыенлыгын ныклап аңлагач, кайдандыр шул тирәдән Аннасының ераграк туганы Варвара Семёновнаны алып кайтты. Марҗага иялэнгән идеме, Аннага охшаган дип, күңеле тарттымы, балалары янына чит кеше китермим, дигәндерме... Карап торучы табиб кирәклеге шулай куша идеме... Мондагы кызлар, башкаларга яраган татар кызлары нигә килешмәде соң аңа, дип аптырады Зәмниха алай да. Инде дә йөз төрле халык арасында эшләгән Рәгыйдә белән Галинур кемгә өйләнер дә өйләнешкәне белән бәхетле булырмы дип, ут йота иде ул.

Йотасы утлары соңрак кабынырга көткән икән. Китүенә озак та үтмәде, Галинур үз якларыннан чыккан бер кызга өйләнеп җибәрде. Күрше Алгайдан куылган кулак кызы иде ул. Авылларына кайтып яшәр җире юк икән. Ярты җирләрен, торып торырга мунчаларын калдырып, калган бар каралтыларын сүтеп алып киткәннәр. Шул мунча дигәне бик матур бакча эчендә тора икән, дип язган Галинуры.

Соңыннан Зәмниха белеште. Әтиләре, бар әйбере тартып алынып авылдан куылгач, балаларына көн итү авырга килгән. Байлыкта иркәләнеп

үскән төпчек кыз Минзада ни бакчасын юньләп карый алмаган, ни башка эшкә кулы бармаган. Мунчада кысылып яшәүне дә кимсенгән. Йорт эшләрен белгән апасы кияүдә икән инде, артык ярдәмләшә алмаган. Авыл тормышыннан тәмам күңеле кайткан Минзада, мине монда берни тотмый дип, Кизелга киткән дә барган.

Халык авылдан куды дип рәнҗемичә, үпкә сакламыйча, кулакның үзе белән киткән Нурания исемле кызы яшәгән җиреннән Сабантуйга инәҗеп, тоз, галуш кебек бүләкләр җибәреп ята икән әле дә. Үзеңә нинди авырлыклар китергән туган ягыңны, авыл кешеләрен шулкадәр ярату булыр икән, дип уйлады Зәмниха. Яратумы, мондагы тормышның авырлыгын белеп кызганумы бу? Эчке бер миһербанлыкмы?

Зәмниханы сөендереп, бер хатында, малаебыз туды, Камил исеме куштык, дип язган иде Минзада. Көне буе очынып кына йөрде, зиратка төшеп, догасын да укып кайтты ул, туган-тумачаларына кереп, мактанып та чыккан иде. Ул да булмады, хатын баланы карарга теләми, өйдә утыру күңелсез дип саный, алайса улымны яслегә биреп, эшкә кер, дим, анысына да риза түгел дип, баласын күтәреп кайтып төште Галинуры.

– Улым, май чүлмәгенең тышыннан билгеле, диләр. Нәрсәләр карап кына аңа өйләндең соң? – дип сорады Зәмниха.

– Кулак баласы булгач та, апаларына карап та, бу да шулар кебек акыллыдыр, тырыштыр дип уйлаган идем, ул иргә буйсынып торуны яратмый булып чыкты. Авызыңны гына ачасың, талашырга тотына.

– Бер үзгәрер, түзәр идең әле.

– Ир башым, шушы гәүдәм белән өйгә курка-курка кайтам, әнәй. Ишектән керүгә үк берәр нәрсә эшләп атмаса ярый, дип уйлыйм.

– Ярар, улым, Ходай язмаган булмас.

– Нигә безгә генә яза соң ул авырлык өстенә авырлык? Мин мин инде... Менә сиңа нигә яза?

– Барысына шөкерана мин, алай димә, улым, әҗерләрен җәннәткә калдыргандыр.

– Баланы карый алырсыңмы, әнәй?

– Әле аңа гына көчем җитәр, тик картаям инде, унбиш яшьләренә булса да илтеп җиткерә алсамчы.

Зәмниха хәзер ян яктагы тәрәзәләргә карамый диярлек. Кеше шакыса гына, кем дип, шуннан баскыч төбенә күз ташлап алгалый. Ялгызы көн итә башлагач, беркем нәрсәдер эшләп йөрмәгән, чирәм баса башлаган ишегалды күңелендәге моңсулыгын арттыра кебек. Дөньяның үз көенә һаман барганын тоясы килсә, түр тәрәзә төбендә утырып, урам якны күзәтә ул. Галинурны еракта ук күреп алып, каршысына киткән иде. Зәмниха урамга чыгарга өлгергәнче, улы пар наратларга җитеп тукталган булып чыкты.

– Әнәй, бераз әтәй утырткан наратларның исләрен сулыйк әле, – диде Галинур, кул биреп сәламләшкәч. – Бала да йоклый. Мин ул мышкылдаганда хәлләремне сөйләрмен.

– Алар да өскә күтәрелде инде, исләрен кошлар суласа гына...

Бу наратларда хәсрәт минекеннән бер дә ким түгел, дип уйлады Зәмниха, улына карап, шундагы утыргычта хәл алганда. Галинур белән булган авырлыкларның да шаһиты алар, башкаларныкының да. Наратлар

торган саен югарыракка үрли. Ул биеклектән аларга бик күп нәрсәләр күренәдер. Зәмниха менә көннән-көн җиргә ныграк якыная... Ул сөйләгән серләр ябалдашларга кадәр инде ишетелмидер дә. Әхмәтгалим утыртканда Зәмниханың тезләреннән генә иде үсентеләр.

Самавыр куярга дип, карчыкның алъяпкычына бераз күркә җыйдылар да өйгә кереп киттеләр.

Тыныч... Үзләре монда чагында шаулап торган йортның икенчеләнүе Галинурның күңелен йомшатты. Ул турыда уйламаска тырышты.

– Бик йончытты. Үзең беләсең, ике айлык бала белән ир кешегә озын юлның нинди леген, – диде ул, караватка кертеп салган Камилне биләвеннән арындыра-арындыра.

– Сиңа читен, аңа синнән дә читенрәк булгандыр, – диде Зәмниха. – Хәзер үк җылы сөт савып керәм. Балаң еламаса, чәйне куя тор.

Камил елак бала түгел иде. Зур күзләрен ачып, аларны күзәтеп ята. Нинди җиргә килеп эләктем мин? Янымда бөтерелеп йөргән әбекәй миңа кем, ди торгандыр инде...

Тамак ялгап алганнан соң, Камилне ашаткач, аны кайда ничек йоклату турында уйлаша башладылар. Зәмниха чормадан балаларыннан калган бишекне алып төште. Галинур түшәмгә асты.

– Бишеккә кадәр саклагансың икән, әнәй.

– Аны буыннан буынга күчерергә кирәк. Оныкларың булмаса да, сатасы түгел, кемгәдер бүләк итеп бирергә генә ярый. Бу йоланы бозсаң, нәселең корый, диләр.

– Бер дә ишеткән юк иде.

– Мин дә йола үтим дип кенә эшләмәгән инде аны. Оныклар белән кайтсагыз, кирәге чыгуы бар дип калдырган.

– Камилемә насыйп икән алайса.

Малай атасы кебек озын торыклы, калын сөякле булырга охшаган. Моңа сөенде Зәмниха. Аның нәселенә тартым кыяфәт иде Камилдә. Шушы уенның артыннан ук, бала чагыннан йөк атына әйләнгән Галинурны кызганды. Күзенә яшь килде. Сөенече, кызгануы бергә кушылды...

– Бу бишектә озак ята алмассың, улым, тиз чыгар кырыеннан аякларың. Баһадир булмагаең. Сиңа икенче кайтуымда караватясатып китәрмен, – диде Галинур.

...Көтмәгәндә кайтып кергән Галинурны ныклап күрергә, тоеп калырга да өлгерә алмады, атылган уктай юкка да чыкты. Шахтасына тиз әйләнеп килергә кушканнар, вәгъдәсенә ышанып кына җибәргәннәр икән.

Олыгайдым, кулымнан эш бөтенләйгә китеп бара, ди иде Зәмниха, эшнең зурысы белән, әле тиз генә бушап булмаслыгы белән ялгызы диярлек торып калды... Кирәк чагында калдырып торырга инде янында кыз оныклары да юк, елларга гына кайтып йөриләр иде. Ямьбикәсе үзе дә тагын бергә авырлы.

Авылда да кызы бар иде Галинурның. Сугышка озатып калган кебек хушлашкан иде. Балалары эшкә дип, еракларга чыгып киткәннән соң, нарат төбендәге утыргычта ни вакыт елап утырды. Зәмниха түзмәде. Чыкты.

– Кызым, бар, өегезгә кайт инде, ата-анаң борчылып көтәдер, – диде.

Ул тагын да ныграк, сүзләрен дә юньләп әйтә алмыйча үксергә тотынды:

– Бөтенләй югалтырмын кебек мин аны.

– Егетләр бетмәс. Галинур китсә, башкасы табылыр. Каты еларга кушмыйлар, туганнарсыз калырсың, диләр. Елама. Әти-әниең исән-сау, алга таба да алар белән яшәргә язсын. Тормыш авылдан кумасын. Рәхәттән китми кеше.

Кыз аны тыңларга да уйламады.

– Авыр югалтулардан хәбәр булмасын бу елау, – диде кабат Зәмниха.

Тынычландырыр өчен генә шулай дигән иде ул. Аннан үзе дә әллә нишләп китте, сүзен башкачага үзгәртте:

– Нинди югалту?! Кайчаннан бирле шундый дус булып йөрисез. Бер-берегезне яратышып.

– Галинурны син яратып, диген. Мин яратам да бит. Аныкына менә ышанып бетмим. Бөтен кеше кызыгып карап торган егет бит ул. Бәясен белә. Кызлар дип, әллә ни исе китми. Мине дә дус кына иткән шикелле.

Кәҗәдә икән хикмәт! Хатын-кызның берсенә дә ярату җитми! Кеше күңеленнән кайларга качкан ул? Үзенә ошамаганны ул мине ярата дип кенә яратырга тиешмени соң ир-ат?!

– Керик, чәй эчик әле, кызым, – диде карчык. – Чәй артында икесенең дә борчулары кимегән кебек булды.

Галинур китү белән шул кыз, кайтканын ишетеп, тагын йөгереп менгән.

– Китте, балакаем, – диде каршына чыккан Зәмниха, кызның күрәм дигән өметләрен кисеп.

– Күрмичә дә калдым.

– Аны күрү нигә кирәк?! Хатыны, баласы бар бит инде.

– Булса да...

– Яратмый дигәннәрең хак булган, кызым.

– Нигә генә кайткан иде соң, Зәмнихатти?

– Менә миңа баласын калдырып китте. Чормадан бишек төшереп куйдык. Йоклый әле.

Кыз Зәмниха карчыкка ияреп, өйгә керергә, баланы карарга булды.

– Нәкъ Галинур! – диде ул елмаеп, инде өстеннән таулар ишелгән кебек. – Охшаса да охшар икән! Аны күргән кебек булдым.

Шушы хәлләрдән соң күп тә узмады, Варварадан хат килеп төште. Киленегезнең холкы бик авыр, эшкә кулы ятмый, дигән. Көндезен урамда бала күтәреп, кәнфит суырып, лач-лоч сагыз чәйнәп йөри, ни ашарга хәзерләп көтми, алар эштән кайткач, баланы Галинур кулына тоттыра да дусларына китеп бара икән. Китмәсә, капка төбендә шарт та шорт көнбагыш яра.

Нинди хәл инде бу, имчәк баласын шулай тилмертергә ярыймы соң, дип сораган Варвара. Сорамыйдыр инде. Гаҗизләнеп әйтәдер. Марҗа килен алып биргән әйберләрне санга да сукмагач, баласына юып та кидермәгәч, бер чиләккә җыеп, тагын алырлар әле дип, чүплеккә чыгарып баргач, ни дисен?..

Күршеләре Минзаданың бу эшен күрә дә:

– Ник ташлыйсың аларны? – дип сорый.

– Җирәнәм. Буклы булганга, – дип җавап бирә Минзада.

Тегенең күзләренә яшь килә.

– Мондый авыр заманда исраф итмә. Буклыларын миңа булса да бир әле, болай эшләгән кешене бер дә бер көнне Ходай орыр, – ди. Килененең бу сүзгә дә исе китми.

Минзада бер китүендә бик озак кайтмаган. Таныш-белешләрендә дә күренмәгәч, милициягә хәбәр иткәннәр. Алар унбиш көн буена беркайдан таба алмаган. Үзен эзләүләрен ишеткән Минзада, инде эзләү тукталгач, Галинурның эштә чагын туры китереп, Варвара Семёновналарга күренеп киткән, тик кире кайтмаячагын әйтергә генә килүе булган.

Анысы бер хәл. Озак та үтмәгән, маржа килен эштән кайтса, баскыч төбендә ниндидер тавышлар чыгарып, зур гына төргәк ята, ди. Мәче баласын китереп ташлаганнар мәллә, дип уйлаган. Чүпрәк-чапракларны чишеп җибәрсә, эчендә Камил икән. Ике айлык имчәк баласын әнисе баскыч төпләренә ташлап киткән. Әле дә ярый бер-бер хәл булмаган.

Минзаданың кайда качып ятканлыгын белеп, янына барганнар, тик Камилне үзенә алырга да, торган җиренә кайтырга да теләмәгән. Миннән башка гына бала карап тилмерсен әле Галинур, ничек авыр икәнлеген белер, дигән. Баланы апалары белән чиратлашып, эштән калып караганнар да, болай күпме мөмкин дип, авылга кайтарырга булганнар. Галинур сөйләгәннәрнең барысы да хак алайса...

Татар хатыннарының мондые да була икән хәзер. Яхшы ата-анадан да баланың ниндие тумый икән. Ник соң нәкъ шундые аның Галинурына туры килгән?! Зәмниха бик аптырады, бик аптырады. Картлык көнемдә ничек кеше итәрмен аның баласын ялгызым, дип тә кайгырды. Әле дә ярый кәҗәсе бар. Сыекласаң, кәҗә сөте әни кешенеке кебек ул. Шуңа бик сөенде. Камилгә сөт булыр, әни җылысы җитмәсә дә, яраткан әбисенең җылысы булыр.

Килен кеше берничә айдан кайтты. Бу хәлләрне, Галинурны бик яратканга гына шулай эшләдем, шахтасына чыгып киткәч, аны күрмичә торуыма түзә алмадым, аннан башка бала карау бик авырга килде миңа, дигәнрәк сүзләр белән аңлатты. Бәйләнчек Варвара Семёновнага да, иренә дә, баланы каратып, үз хәлен аңлатырга уйлаган, имеш. Галинур аңа боларны кичермәгән. Баласын үзе белән алып китмәвенең, урамда калдыруларының да сәбәбе бар икән. Минзада иренең, үзем генә карый алмыйм, синнән башка да яши алмыйм, кайт инде, дип ялварып килүенә өметләнгән, аннан бик тә, бик тә кадерләнәсе килгән.

– И-и кызым, и-и кызым, ирне шулай яраттырып буламыни соң?! Бик әйбәт хатыннардан да сүрелә аларның күңеле. Ашамаган, эшләмәгән җәмәгатен авылда җир сөреп, тормыш йөге тартып үскән, әнисенең, апаларының ниндилеген күргән ир бала яратырмы?

Минзада такмаклый-такмаклый елап ук җибәрде:

– Соң үзем яратам бит мин аны! Аннан да яхшырак кеше бармы?!

– Шулай икәнен белгәч, аннан тапкан балаңны ничек авырсынып карарга кирәк, ә?..

Шундый сүзләр әйтсә дә, эченнән киленен бик кызганды Зәмниха. И-и, бу яшьләрнең акылсызлыгы, ирен эштән дә көтеп ала белмәгән, инде гомер буе көтәр, кире китерә алмас, дип кызганды.

Хушлашып китеп барганда, идәндә уйнап утырган балага карап торды да, Минзада:

– Әнкәй, инде Галинурым кире кайтмас, төсе итеп үстерермен, бир миңа Камилне! – диде.

Зәмниха, елап шешенеп беткән киленен җәлләсә дә, малаен кулына тоттырып җибәрмәде. Ул ике ут арасында калган иде. Киленнең карыйсына ышанып бетмәде, малае сүзен тотмыйча да булдыра алмады. Галинур, Камилне елап сораса да, бирмә, бирсәң, мине рәнҗетәсең, барыбер карыйсы юк аның, дип киткән иде.

Шушы сорап кайтуыннан соң Минзада башка күренмәде, икенче кешегә кияүгә чыкканлыгы, моңа кадәр һичнәрсәдә гаме булмаган хатынның ирләргә дә авыр җиргә – тимер юлга эшкә урнашканлыгы ишетелде. Вакыт-вакыт, ни галәмәт, барыбер Галинурымны бик яратам, дигән сүзләре килгәли иде. Яраткач, үзеңне дә яраттырырлык итеп торалар лабаса! Юләрлек баштан бер китә, узган көннәреңне һичничек кайтарып ала алмыйсың. Аңлатып карады бит килененә, аңлатып карады. Дөнья акылны керткән икән...

Минзада Сәлимҗаннар турын үткәнче, тагын бер сөйләшеп карамакчы булып, артыннан да йөгергән иде Зәмниха, тик килен инде, үпкәләгән сыман, аның сүзләренә игътибар итмәде. Утка очкан күбәләк шикелле, ни өчендер түбән якка түгел, чишмә буена алып төшә торган тыкрыкка таба чапты.

Камилне соңыннан да алып китә алган булыр иде әнисе... Кайтмады, күренмәде. Алар аерылышуга озак та үтмәстән, баланы бөтенләй ятим иткән хәбәр – Галинур вафатыннан телеграмма килеп төште. Моңа ышанып та җитмәгән, ышанырга да теләмәгән, нишләргә белмичә югалып калган иде Зәмниха, ул да булмады, улының үле гәүдәсен алып кайтып, ишегалдына керттеләр...

Чыдаса да чыдый икән адәм баласы. Сынаса да сыный икән аны язмыш дигәннәре, дип уйлады соңыннан Зәмниха, әлеге хәлләрне кайтып-кайтып исенә төшергәндә.

Шахтаның данлыклы эшчесенә әверелгән ирне хәрби кешеләргә булган хөрмәт белән озаттылар. Әллә гаепле якның үз өстендәге кара тапны төшерү өчен генә тырышулары иде микән?.. Бу хәлләрне күреп, күзәтеп торды, ни йөрәге, ни акылы аркылы уздыра алмады Зәмниха. Аңкы-миңке кыяфәттә, үз-үзен белештермичә, кем белән дә сөйләшмичә, кемгә дә хәсрәтен түкмичә, яшәмәүле яшәгән чагы иде аның.

Озакламый Зәмниханы, суд эшләре кузгатылды дип, сорау алу өчен Кизелга чакырдылар. Улын тиктомалга – бер милиционерның сәбәпсез атуы аркасында югалтудан йөрәге бик авыртса да, ни кылырга, кемнән дөрес киңәш алырга белми аптырады башта. Уйларга көннәр санаулы, тиз арада юл хәстәрен күрергә кирәк, ул инде олыгайган иде. Ни тикшерүчеләр каршына, ни хөкем итүчеләр алдына бармаска булды, әйләнеп кайта алырына ышанмады. Үтерүченең язмышын хәл итүне хөкем кылучыларга калдырдым, дисә дә, Зәмниха улыннан мәхрүм итүченең шулардан берсе икәнлекне бик яхшы аңлый иде. Үз-үзен, минем әле Галинурның баласы, Камиле өчен яшисем бар, дип тынычландырды.

Кайгы килгән вакытында гына авыр, әкренләп онытыла, йөрәк басыла диләр дә, бик алай түгел, хәтереңнең бер почмагына кереп урнаша да, еллар узгач та, менә-менә яшеңне агызырга җай чыкканны гына көтеп ята. Бераздан әнисенең хәлен җиңеләйтергә дип кайткан Рәгыйдәсе сөйләгәннәрне дә көч-хәл белән генә тыңлады Зәмниха.

– Галинур шимбә-якшәмбеләрдә иптәшләре белән ресторанда ашарга гадәтләнгән. Ул бик гәүдәле, күрекле иде бит. Кесәсе тулы акча. Кемнедер эзләп кергән милиционер моннан тиктомалдан шикләнгән, бәйләнә башлаган.

– Мин фәлән-фәлән кеше, фәлән шахтада эшлим, – ди икән Галинур. Ресторан телефонынннан шахтага шалтыраткан милиционер. Каравылдагылар алмаганмы, исемлекне белүче булмаганмы, шуннан соң, сез анда эшләмисез, кеше талап йөрисез дип, ныграк та бәйләнә башлаган.

Әзмәвердәй гәүдәле булса да, Галинур иптәшләренә:

– Бер дә юньле бетәргә охшамаган. Моннан китү ягын карыйк без, – дигән.

Акчаларын түләп, бөтенесе дә чыгып, машиналарына утырганнар. Теге милиционерның Галинурларны болай гына калдырасы, кайтарып җибәрәсе килмәгән. Гаепле булганга качалар дип уйладым, дигән судта. Шуннан, китеп бармасыннар дип, рульдәге иптәшләренең кулына аткан, имеш. Ул, машинасын кузгатып маташканда, моның юньләп төби алмаганын күргән дә, башыма эләкмәгәе дип, рулена иелгән. Пуля янында утырган Галинурның чигәсенә килеп кергән.

Милиционер судта туктаусыз:

– Шофёрның кулына гына атмакчы идем, – дип кабатлаган.

– Нигә атарга иде соң аңа? – дип сораган тикшерүче.

– Озын буйлысыннан шикләндем.

– Бер сәбәпсезгә шикләнгән бөтен кешене ата башласак, дөньяда кем калыр соң? – дип сораган тикшерүче.

– Милиционер булгач, нәрсәдер эшләргә тиештер бит инде мин?

– Тиеш. Җинаятьчеләрне тотарга тиеш!

– Ул совет хакимияте сагында торган, – дигән яклаучы. – Шуның кануннары белән эш иткән. Аның күңелендә шик уятыр сәбәпләр барында атарга хокукы да бар.

– Нинди сәбәпләр соң ул? – дип сораган тикшерүче.

– Алар милиционер яныннан качып китеп барганнар бит.

Сүз әнә шулай һаман бер тирәдә әйләнә икән.

Рәгыйдә елап җибәргән.

– Синең көчең-буең, акчалы булуың, тыныч яшәвең, дусларың барлык, хокук сагындагылар белән тавышка кермәскә тырышуың шул законнар белән тыела микәнни? Без белмәгән нинди законнар ул? – дип сораган. Җавапсыз калдырганнар.

Үтерүче вак-төяк җәза белән котылган...

– Кануннар төрле кешегә төрлечә языла икән, әнәй. Безгә берсен тукыйлар, башкалар без белмәгәнен куллана.

– Инде Галинурымны бер нәрсә кире кайтара алмый. Тырышсам, барган да булыр идем. Кем белә, Ходай көч бирсә, әллә әйләнеп тә кайтыр идем. Сүз бирсәләр, улымны яклап сөйләр дә идем, тик кемнән, нидән яклап? Иң кирәк чагында мин аның янында булмаганмын бит инде...

– Синең сүз дә берни үзгәртмәс иде шул, әнәй.

– Чынында, кызым, шул милиционерны үстергән әнисен кызгандым. Башка карар кешесе булмаса, күпкә утыртып куйсалар, кем кулларына калыр, дидем.

2

Кара дулкын чәчле, шомырт күзле кыргыз егетен Рәгыйдә бер күрүдә ошатты. Иң тәүдә тавышына таң калды. Кыз, рәсемгә төшим әле дип, танышы эшләгән «Фотография»гә керсә, башына киез калпак кигән кыргыз егете диванга аякларын бөкләп утырган да думбра чиртеп җырлый, шунда эшләүчеләр исләре китеп тыңлый иде. Рәгыйдәне күргәч, Буранбай уйнавыннан туктады, клиент бар, дигән булды. Аны сырып алган барысы, тагын берне, тагын бер җырла инде, дип ялынырга тотынды.

– Менә бу кыз ни әйтә бит? – диде Буранбай, кызга карап.

– Җырлагыз, үзем дә исем китеп торам әле, – дип, Рәгыйдә көтәргә авырсынмаганлыгын аңлатты. Буранбай ялындырмады:

Атка салган дилдейсиң,
Ачылган кызыл гүлдейсиң,
Бир күнү оору, бир күн соо,
Алымкан, азабың тартсам, билбейсиң.

– Бигрәк матур җыр инде, – диде, думбрачы уйнаудан туктагач, Нәкыйп абыйсы. – Көе дә, сүзе дә безнең күңелгә ятышлы. Атка салган иярдәйсең, ачылган кызыл гөлдәйсең, бер көн авырыйм, бер көн сау, синең өчен газапланганымны белмисең, дисеңме?..

– Шулай аңлашылса да, бик җиткән. Токтогул акынның Алымкан исемле асыл кызга мәхәббәтен сөйләдем мин. Без җыр җырлап, фотога төшерәбез, матурым. Сервисыбыз шундый. Телисеңме, мин сиңа көтүчеләр җырын да җырлыйм, – дип, Буранбай Рәгыйдәгә саф татарча эндәште.

– Боларның сүзләре килеште, – дип көлештеләр дә таралыштылар. Нәкыйп абыйсы фото ясау бүлмәсенә кереп китте.

Буранбайның кинәнеп җырлаганы Айкүл, Куйкүл, Күркүл, Эенсай кебек сулыклар, шулар тирәсендәге утлаулар, маллар турында иде. Рәгыйдә:

– Таудан, малдан, судан башканы данламыйсың, ахрысы, – дип көлде.

– Тарихыбыз белән горурланып җырладым бит башта! Монысында да йолдызларны-кондызларны, калканнарны-калпакларны да атадым.

– Барысы да бер үк нәрсәләр турында кебек нигәдер.

– Шулайдыр. Без тарихи Ватан, торган җир белән бик береккән. Көтүчесе дә шуны җырлый, башкасы да. Эенсай дип сөйләгәнем – Енисей, Күркүле Ыссык-Көл аның. Угызханның углы Кыргызхан, аның нәселен дәвам иткән Далган би, Далган бинең улы Долон би балалары без, кыргызлар.

Кыз егетнең сөйләгәнен икенчегә борып:

– Безнеңчә яхшы сөйләшәсез дә инде, – дип куйды. Аңа каршы Буранбай:

– Әнием ягыннан кардәшләрем татар мөгаллимнәреннән белем алган, тегеләр язуны татар сүзләре белән өйрәткән, – дип җавап бирде. – Мин хәрефне татарча укыган апамнан өйрәндем, үземне ярымтатар саныйм.

Рәгыйдә егетнең шаяртыбрак әйткән бу сүзләренә елмайды:

– Миңа татар булуың ошый.

– Монда килгәч, татарчам бөтенләй яхшырды. Нәкыйп абый белән башка телдә сөйләшмибез диярлек.

– Карточкага төшүчесе дә безнең халык булгач.

– Якындагы шахталарда алар күп шул. Әзер эшләрне карап чыксаң,

авылдашларыңны да табарсың әле, – дип, Буранбай фотолар салынган тартманы бирде, әмма анда Рәгыйдәнең танышлары очрамады.

– Без фотога паспортка кирәк булганда гына төшәбез, ахрысы, – диде ул. – Гел авыл, әти-әни, аларга ярдәм турында уйлыйбыз. Фотога төшүең алар өлешенә керү кебек, аңа акча кызганабыз.

– Бушка эшләүче шәхси фотографың булырмын, – дип көлде Буранбай.

– Ә нигә апаңнан? – дип сорады Рәгыйдә, кыенсынып кына.

– Мине ул тәрбия кылды. Әни мине тапканнан соң аз яшәгән.

– Әтиең?

– Ул мине агасы кулына тапшырган да тауларга китеп барган. Аннан инде сугышка алганнар. Ул арада агасы, әби-бабай да үлеп киткән.

– Олыларның аяк арасында чуалып йөрер яшькә җиткәч, җиңгәмә артыклыгымны сиздем. Тоттым да апама күчендем. Әти сугыштан исән дә кайтты... Чирле иде, ул да озак яшәмәде.

– Әнәй исән әле, аллага шөкер,– дип куйды үзалдына Рәгыйдә.

– Бездә мәргән турында бер хикәят бар, мин шуның улы булам, – дип, сүзне уенгарак күчерде Буранбай. – Тыңла. Үткән заманда Ала тауның бавырында мәргәнче көн иткән. Аның пистон мылтыгы, хатыны, Буранбай атлы баласыннан башка нәрсәсе юк икән. Киек ите ашап, тиресеннән төрле әйбер, кием ясап җан асраган. Берзаман авырып, түшәккә егылган. Инде киектән мәхрүм, көн итәренә көчкә генә таба икән. Кечкенә Буранбай аның пистон мылтыгы белән көртлек, чил, фазан атып кайтырга керешкән.

– Синнән бер хикмәтле сүз көтәм тагын.

– Тормышым шушы хикәяткә сыеп беткән, димәкче идем. Кечкенә аучының исемен дә юри үземнекенә үзгәрттем.

Буранбайның шаянрак сүзләре Рәгыйдәнең күңелен күтәреп җибәрде:

– Әллә чынын сөйлисең, әллә шаяртасың – кайчак аңлау да кыен.

– Кыргызда тапкыр сүз, матур сүз мактала, акыллылык билгесе санала. Әңгәмәдәшләр гел мәкаль-әйтем кыстырырга тырышыр.

– Кыргызның бөтенесе җырлый, дип тә җибәрсәң.

– Шулай да ул. Кыргыз-кайсакта үз җыры булмаган адәм юктыр.

– Алайса мәргәнче улы түгелдер син, тел батырыдыр, бездә андыйларны «тел бете» диләр дә диюен, – дип көлсә дә, егет кыз сүзенә үртәлмәде:

– Мин дә әтине киек атып, итен ашатып сөендердем. Аның трофей мылтыгы белән бик эрактан ала торган разведка биноклен һаман саклыйм.

Салонда фотоальбомнар күп иде. Рәгыйдә, Буранбай сөйләнә-сөйләнә аппаратын көйләгәндә, шуларны караштырырга тотынды. Берничәсе Ала-Тау рәсемнәре булып чыкты. Кыз аларын аеруча игътибар белән карады.

– Кулга төшкән киекләрне, бозыласы җирләрен алгач, яхшылап киптерәм дә эчләренә мамык тутырам. Чыннан аерылмый да. Шуларның рәсемнәрен күрсәтермен әле бер, үзем дә килсәң.

– Сез кайда яшисез соң?

– Менин жаткан жерим көченүн башындагы чоң сарайда, – диде Буранбай, кыргыз теленә күчеп.

Рәгыйдә, үзенең дә аларча аңлаганлыгын сиздерергә, шуның белән егетнең күңелен ныграк яуларга булды:

– И-и, безнең әби урам башына төшкәндә, күргән-сораганга, күчә

башына чыгуым, ди торган иде. Син урам башындагы соңгы йортта яшисеңмени? Мин дә шул тирәдә генә торам.

– Алайса кич кереп чыгыйм?

– Нәрсәгә керәсең? – дип, күзләрен шарлатты Рәгыйдә.

Кыз буйдак егетләрнең, гашыйкка салынып, кызларга ашарга йөрүләре турында күп ишеткән иде. Әллә Буранбай да шулар сортыннан инде?!

– Курсагым ачка, ошон үчүн, – дип көлде моны сизеп алган фотограф. – Кешедә ашау гадәте юк безнең, кафе аркылы кайтабыз.

– Алайса куркыттың.

– Сиңа ник Буранбай дип аталуымны да сөйлим әле.

– Буран кебек көчле булсын, дигәннәрдер.

– Чын исемем Бешә минем. Кыргызда исем сайлау йоласы бар. Бала тууга, тышка йөгереп чыгалар: сөенче хәбәрчесенең күзенә ни күренсә, сабыйның аты шул булыр. Мин кыштакта ком бураны күтәрелгәндә туганмын. Кендек әбисе шуңа Буранбай дип атаган. Әни белән этинең бик тә Бешә итәсе килгән, анысын соңрак Казан мулласы колагыма кычкырган.

Рәгыйдә егетнең Буранбай икәнлегенә ияләнгән иде, Бешә чит кешенең исеме кебек тоелды:

– Мин сиңа Буранбай дип кенә дәшәрмен, яме! Бигрәк ошый!

– Тегесен дә әйткәлә. Онытылып ук бетмәсен.

– Мулла кушкан исем белән атамасаң, кешенең язмышы үзгәрә, чирли, диючеләр дә бар.

– Син андый ырымнарга ышанма. Үзем дә йолалар, ырымнар иленнән татар-урыс арасына качтым.

– Бездә туганнар кызларны Җиләк апа, Чәчәк апа, Май апа дип йөртәләр.

– Кызык икән. Ә ирләрне?

– Ирләргә матур сүз батмый, – дип елмайды Рәгыйдә. – Җиләк абый... Көлке дә инде. Күрше малайлары туганнарына Бети абый, Кечти абый, Төпчи абый дип торганнарые. Әйтә белмәгән чакларыннан калгандыр.

– Тимер абый, Булат абый, Таш абый дисәләр, бик тә буласы икән дә...

– Тимер-булатлар күгәреп беткәннәр... Бездә дә бар ие анда бер Ыржайганбулат... мич башында... – дип сөйли башлаган иде, Рәгыйдә телен тешләде – авылда капка төбендә теләсә нәрсә сөйләшеп утырганда барган сүз монда килешмәс кебек тоелды.

– Алайса кич кереп чыгыйм? – дип кабат сорады Буранбай.

– Чыкма!

– Керсәң чыкма, дисеңме?

– Кич чыкма, дим!

Егет кызга, мине чакырмасаң, үзең килсәң дә була, дисә дә, Рәгыйдә ишетмәгәндәй кыланды. Ул арада Буранбай кызны тегеләй дә, болай да утыртып төшерде, анысын-монысын ошатмаганга салынып, вакыт сузды.

– Кайчан фотоларны аласын әйтегез дә, мин китим, – диде Рәгыйдә, ишеккә таба атлап, инде эш беткәнне күргәч. Буранбай аннан:

– Сен бизге келесинби? – дип сорады.

– Юк!

– Мен бир сааттан келем? Макулбу?

– Киләсең килгәч, бер сәгатьтәнме, бер көннәнме, кил соң. Бик мәгъкуль, – диде Рәгыйдә, ә аннан алай тиз ризалашуыннан шүрләп калды.

Егет ни сәбәптәндер килмәде, шуңа да соңрак бу сөйләшүне Рәгыйдә мут егетләргә хас бер шаяруга гына алды. Инде аны бер дә күрмәс кебек иде. Атна узгач, салонга барса, әзер эшләрне бирүче каядыр киткән, аны Буранбай алмаштырган булып чыкты. Кыз моңа эченнән сөенде, әмма узгандагы кебек ачылып китәргә ашыкмады. Иң башта, сорый гына алса да, фотолар картотекасын өстәлгә алып, үз исемен эзләде, тапмагач, башкарылмаган заказлар арасыннан караштыргандай итте. Егет Рәгыйдәнең бу эшләрен читтән күзәтеп тора иде. Бераздан ул эчтәге бүлмәдән ниндидер тартма тотып чыкты һәм, шуннан алып, кыз кулына бик матур конверт сузды:

– Мә, бак!

Буранбай иренмәгән – аклы-каралыга гына түләнгән булса да, фотоның төрлесен һәм күпләп ясаган. Рәгыйдә аларны бик ошатты. Рәхмәтләрен әйтеп, рәсемнәрне салыр өчен өстәлдә яткан конвертка үрелгән иде, Буранбай кулыннан эләктереп алмасынмы:

– Ошол убактан бери ойлондум: сени өзүмө алыйм![1]

– Фотоны бирегез дә, мин китим, – диде кыз.

– Мага тиги фотони бериңизчи, деп айт[2].

– Әйе, әйе: мага тиги фотони бериңизчи.

– Рәгыйдә! Карап туруп ойлондум: сени өзүмө алыйм![3]

Кыз Буранбайның сүзе һаман бер тирәдәгелектән ялыккан кебек кыяфәттә күзенә текәлде, әмма егет тагын-тагын кабатлагач, җавабын тапты:

– Мин сезнең: туруп-туруп ойлондум, сабак алдым өзүмө, дип әйткәнегезне көткән идем...

– Корутундум бар: аялга күйөөгө чыккандык – жакшы. Балдарымдын апасы болорсуң[4], – диде бу юлы инәлгәндәйрәк Буранбай.

– Апасы? – Рәгыйдә әллә нишләп китте.

– Сезнеңчә әни була. Ризамы?

– Тапкан сүз! Кыргызга кыргыз беткән шикелле... Юк балаңа әни эзләгән кебек. Бер тапкыр күргән килеш. Әле дә бүлмәдәшләрем, Буранбай исемле бер егет эшли «Фотография»дә, күзләрен гел татар кызларына гына майландырып утыра, дип калды. Минем кияүгә чыкмыйм дигән сүзем бар! – дип тезде Рәгыйдә.

– Ошондо жамандаганга айтар сөзүм бар: жамандаган кишисин жалганчы ооз жактырбайт[5].

– Алдыңны-артыңны карап торма, бар да кочагына кер, дип әйтмәсләр инде, – дип көлде кыз. – Татарга татар бетмәс! Минем кияүгә чыгуны әнәй генә хәл итә, ул бик ерак. Эзләп табарга иренерсең. Тапсаң да, синдәйгә бирмәс! Безнең өйгә җир җимертердәй эш аты кирәк, думбрачы түгел!

Рәгыйдә шулай дисә дә, асылда бу дөреслеккә туры килми иде. Кизелда татар гына түгел, кыргыз да күп. Араларында түрә булганнары да юк түгел. Күптән түгел шундыйларның берсе иптәш кызын яучылаган. Эш кешесе

[1] Теге вакыттан бирле уйландым: сине үземә алыйм!
[2] Миңа теге фотоны бирегезче, дип әйт.
[3] Карадым да сине үземә алам, дидем!
[4] Минемчә (нәтиҗәм бар): хатын-кызга кияүгә чыгу яхшы. Балаларымның әнисе булырсың.
[5] Шулай яманлаучыга әйтер сүзем бар: яманлаган кешесен ялганчы авыз ошатмый.

инде, тырыш, дигән була. Алмышны күреп тә, аның турында ишетеп тә белә иде Рәгыйдә, тәкъдимен кире какты:

– Исемен ошатам, үзен юк, дип әйтерсең.

– Ничек алай җавап бирим инде? – дип ухылдады ахирие.

– Алайса, теләсәң ни әйт, чыкмаслыгымны гына аңласын.

Бер аралашмаган Алмышка түгел, татар абыйларына да чыкмады әле ул. Үзеннән олыларга бер дә күңеле ятмый иде. Күрер күзгә матур булса да, олы тоелды Рәгыйдәгә Алмыш. Буранбай соң?.. Анысы үзеннән яшьрәккә охшаган.

Икенче күрүендә үк беркем дә сиңа барам, дип, авызын ерып ризалык биреп тормас. Егет моны белә иде. Ул бит башына күктән төшкән кебек җөмләне үзе дә сүз башлар өчен генә әйтте. Әйтте дә шунда ук уйламастан әйткәненә сөенде, сүзендә калырга булды. Өйләнгәнче хәл итәсе әйберләре күп иде аның. Тулай торактагы егетләр бүлмәсендә генә тора. Хатыныңны каядыр алып кайтырга кирәк. Гаиләсе булса, фатир бирерләр ул бирүен... Күрер кыяфәткә юаш, йомшак кебек тоелса да, Буранбай кыз кебек үк тимерне кызуында сугучы егет иде. Шул көннән Рәгыйдә йорты яныннан китми торганга әйләнде.

– Йөрмә инде янымда, Буранбай, – диде Рәгыйдә бервакыт, кертмәс өчен ишек тоткасын тотып торган егеткә ялынып.

– Ничек каршы торсаң да, барыбер үземнеке итәм!

– Әле миңа гаилә корырга иртәрәк.

– Шушы яшьтәме?

– Әнине карыйсы бар. Галинур энемнең улын үстерәсе, укытасы... Үз борчу-мәшәкатьләремне кеше сыртына салырга яратмыйм.

– Минем сыртны үзеңнеке дип сана да син дә менеп кунакла, – дип көлде Буранбай, сүзнең җитдилегеннән качарга тырышып.

– Булды, Буранбай, керим. Уйлыйм әле.

Рәгыйдәгә инде уйларга урын калдырмастан, билетлар алып, икенче көнне тагын килеп җитмәсенме Буранбай.

– Чыксаң чыгасың, чыкмасаң үпкәләмим. Инде соңгы тапкыр сорыйм.

– Кая чыгам?

– Аңламамышка салышма инде, Рәгыйдә. Менә миңа. Кияүгә!

– Шулай диген.

– Эшеңнән рөхсәт ал да, әниең белән сөйләшеп килик.

Рәгыйдә үзе дә сизмәстән, ярар, диде. Буранбай киткәч, әнисенә ял алуын, ялгыз гына кайтмавын, шуның сәбәпләрен тәфсилләп хат язды. Ул барып җитүгә, әнисе апа-җизниләре белән киңәшләшеп алуга, без дә килеп төшәрбез, дип планлаштырды. Шулай булып чыкты да.

Шахтада эшләгәч, Рәгыйдәнең акчасы шактый гына җыелган иде, егетнеке аныкыннан да күбрәк икән. Әллә никадәр тоттылар. Чемоданнарга тутырган бүләкләре, күчтәнәчләре, нәселгә, күршеләргә генә түгел, бөтен авылга алынгандай булды.

Буранбай белән поездда кайту үзе бер рәхәт иде. Сөйләсә сүзе бетмәс, көлдерсә – көлкесе. Һәркемне авызына каратып тотучан бу егет, икесе генә калганда, безнекеләр белән күрешкәнче ныграк таныш дигәндәй, Рәгыйдәгә гел нәселләренең тарихын сөйләде. Ул – сугышчан, үз эчендә күп тармакларга бүленгән һәм бик борынгы сарыбагышлар токымыннан, имеш.

Сарыбагыш манапларыннан Ормон, Торогелды үзләре күчмәнлек кылган Ыссык-Көл буйларының бөтен сәүдә юлларын күзәтүдә тоткан, айыллары аша бер генә кәрванны да туктатмыйча, бүләкләр алмыйча һәм кунак та итмичә уздырмаган. Бу ырулар шундый зур булган ки, аларның кышлаулары Күрмәт елгасыннан алып Көнгәй иңкүлекләренә, күлнең көнбатышындагы Көтүмалды чикләренә кадәр сузылган. Җәйләрен алар биек тау түбәләренәчә, Каскәлән, Корт, Чу елгаларының башларына кадәр барып чыкканнар. Элек бу нәсел Чон-Кимән, Кече-Кимән, Нарын һәм Ат-башы җирләренә дә хуҗа булган. Бугу токымы белән гомер бакый көрәшеп яшәгән сарыбагышлылар бик күп кабиләләрне эченә алса да, хәзер халык аларның күбрәк исәнгул-булат, черикчи-темир, надырбәк һәм атәкә-тынай кебек төп токымнарын гына белә икән. Шул ук вакытта ун мең йортлы илдән таралып, бик ишәйгән сарыбагышлылар аерым-аерым айыл-кыштактарда яшәгәндә дә, үз кан-кардәшләрен онытмыйлар, туен да, бәйрәмнәрен дә күмәкләшеп уздыралар, бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән, имеш.

– Мин сине киләсе җәен, Алла кушса, Ала-Тоо итәкләрендә, Ыссык-Көл буйларында йөртәм әле! Барысын да шунда аңларсың! – диде Буранбай.

– Без анда юртада торырбызмы?

– Юрта – урысчалашкан сүз ул, безнеңчә – йорт. Сезнең «йорт»ыгыз да шул ук киез өйләрнең электәге атамасыннан килә инде ул. Кыргыз тирмәсендә көн салкынча, төн җылы, хәшәрәт юк...

– Ир кеше барында хәшәрәт кирәкми... – дип төрттерде Рәгыйдә. – Булмый да – бөтенесе үлеп бетә.

Буранбай рәхәтләнеп көлде.

– Без кемнәргә барып төшәрбез соң? Бертуганнарың булмагач...

– Кыргызда нәселеңнең һәркеме якын итә. Безнекеләр бик ишле ул. Көчле токым. Фамилиямне кара. Усубалиев! Турдакун Усубалиевнең... хатыны... чүт татар димәдем!– дип көлде Буранбай.– Уйгур бит әле.

Буранбай шулкадәр дәрәҗәле урында утырган адәм белән карендәш түгелдер, кызык ясап әйтәдер.

– Кайвакыт татар белән уйгурны бутау бар, – дип куйган булды кыз.

– Исеме татарныкы түгел. Алай да башлыкларның татардан кыз алуы гадәти инде ул.

– Син менә башлык та түгел.

Буранбайга тагын шаяртырга җай чыкты:

– Үзем кадәр биеклектә башлык кигәч, тагын кем булырмын икән мин?! Татарны түрә булганчы алалар аны, хатын киңәше белән өскә күтәрелеп булмасмы дип. Балаларын тәрбияле, белемле итәр дип өметләнеп.

– Син мисал белән сөйләш.

– Күп инде алар. Утызынчы елларда Торекул Айтматов исемле бер коммунист зур түрә булып торган. Кайчандыр кыргыз җиренә туганнары белән барып чыккан татар баеның кызына өйләнгән.

– Хәмзә абзый белән бер бабам белешкән минем. Бездә аларның тамырлары калган әле. Үтәмишевләр. Бу нәсел кайчандыр Кукмара-Малмыж якларында үз акчаларына мәчетләр тоткан, ар-чирмешне ислам диненә күчерергә тырышкан, – диде мактанасы килеп киткән Рәгыйдә.

Аның моны белүенә бик аптырады Буранбай.

– Аның нәрсәсенә аптырыйсың?! Әтәй дә алыш-бирешле, шул нәсел белән

дә аралашкан кеше иде. Алар турында Нәкыйп абый да беләдер әле! Ул бит күрше авылдан гына. Сора әнә. Ниндидер ятимә тумачалары Үтәмишевләрдә хезмәттә булган. Башта ерак бер шәһәрдә урысларда торган ул. Белемле, дини икәнен күреп, үзләренә сорап алганнар, урыс арасында тилмермәсен дигәннәр. Бай абзый соңыннан егетнең шәбен сайлап, туйлап кияүгә биргән.

– Соң... ни... минем эти дә яшьлегендә Зөһрә исемле татар кызына кызыккан. Аңа гына өйләнәм дип, бабама әйтергә курыккан.

– Инде син гадәт артыннан кумакчымы?

– Юк, кайчан кайда өйләнсәм дә, яраткан кызымны гына алам. Аны әле менә татар булмагае дип торам.

Буранбай белән сөйләшеп узган юл сиздермәде дә. Кукмара вокзалына килеп төшкәндә, көн бозылып китте, яңгыр ява башлар сыман иде.

– Сабантуйда яңгыр яумыйча калмый. Бездә моңа аптырамыйлар, тик менә урамны аркылы чыга алмау гына йөдәтә. Аягыңда да лаклы-чүпрәкле ботинка,– диде Рәгыйдә. Буранбай шаяртып җавап кайтарды:

– Кияүләп йөргәндә, модный булырга тырыштым.

Район үзәгенең иң озын урамын гизгәннән соң, автобустан почта янында төшеп калып, җәяүләп кенә Туешка киттеләр. Авылга кайтасы юл Кукмарага кушылган шул бистә аша уза иде. Машинаны озак көтәсе булмады. Сөтен бушатып, авылга ашыккан шофёр Рәгыйдәне ерактан ук танып алган да, кул күтәргәнен дә көтмәстән, яннарына килеп туктады. Буранбайга ерак араны, машинада түгел, ишәктә үтү дә гадәти иде. Автобус йөрмәгәнгә аптырамады. Чемоданнарны кузовка ыргытты да, Рәгыйдә кабинага утыргач, үзе өскә – зур сөт багының ян-ягында тар гына калган бушлыкка менеп басты.

Көн дә ничек тиз бозылып китсә, шулай ук тиз генә ачылды да. Саф һавалы җил рәхәт кенә, йомшак кына исә иде. Буранбайның тагын җырлыйсы килә башлады. Кыргызда шундый гадәт: эшкә барасыңмы син, кунаккамы, һәрвакыт кумызың яныңда булыр, әле бер җырны башларсың, әле икенчесен. Монда килешә микән, дип кенә уйлаган иде, каршы килгән машина арбасындагы кызларның да җырлап узганын ишетте.

3

Кукмара яклары бик матур булып чыкты. Монда җәйләрен саргаеп киткән даланың ялыктыргыч төсе карашны әллә кайларга алып китми, кар түбәле таулар булмаса да, менеп, башларыннан бөтен дөньяга аваз салырдай, итәкләренәчә наратлык каплаган калкулыклар җитәрлек. Су буйларына, болыннарга, башка печәнле ачыклыкларга арканланган малларның туклыгы, симезлеге күренеп тора. Аларны күзәтеп бару шушындый матур дөньяда яшәвеңнән күңелдә рәхәтлек хисе уята.

Авыллар аша узганда, машина арбасына тагын берничә юлчы алдылар. Алда урын эләкмәгәннәр ян-якларга – тар гына калган арага кысылып, тезләнеп утырды. Авыл ерак булса, болай барырга риза булмаслар, башка машина көтәрләр иде, дип уйлады Буранбай. Өскебашка кайтып җиткәнче коелып та беттеләр.

Калтыр-колтыр машина, сәгать ярым дигәндә, авылга кайтарып та җиткерде. Чыннан да, урамнары яңгырлар аркасында бик тигезсезләнгән, баткакланган икән. Тегендә-монда, аркылыга ничек чыгыйк, дип аптырашкан кешеләр күренеп калды. Машина тавышын ишеткәч, чәчрәтмәсен тагын дигәндәй, һәркайсы тиз генә читкә чыгып калырга тырыша иде. Сазның

нәкъ уртасында туктарбызмы дип курыккан иде Буранбай, шофёр аларны казлар чемченеп йөргән сары чәчәкле чирәмлек буенда төшереп калдырды.

Чирәмлекнең сул ягында – койма белән әйләндереп алынган бәрәңге бакчасы. Димәк, юл кырыенда кайчандыр йортлар булган... Алар сүтелгәннән соң, ас урам төп урамның эчкә кергән бер ягы сыман калган. Чирәмлектә кәлтә тай[6] уйнаклап йөри. Әнкәсе бести атка[7] охшаган. Татарларда ат исемнәрен ни тешенә, ни яшенә карап юньләп белмиләр икән инде.

Татар инде урысча уйлауга, яшәүгә күчә баргандай. Татар иптәшләре нәрсәгәдер ачуы чыккан базар үзбәгенеңме, башка берәүнеңме үзләренә, озын җиңле чучка дип төрттерүенә кабынырга торсалар да, бу сүздә хаклык бар. Җиңең озын калса да, урыс була барасың, агай-эне, дип әйтә бит алар. Рәгыйдә, ничә гасыр урыс эчендә яшә дә үзең генә булып калып кара, ди. Анда да дөреслек бар кебек. Ятлар тегермәнендә тартыла ул татар...

Рәгыйдәләрнең өе түбәндәрәк, иңкү яткан чирәмлекнең теге башында икән. Чирәмлекнең бу ягында утыргыч белән тоташтырылган пар нарат үсеп утыра.

– Бу агачлар яшь чакта кырларында эскәмия иде, – дип куйды Рәгыйдә. – Инде менә бер-берсенә тотынышканнар...

– Бу җиргә ямь биреп утыралар икән.

– Әти истәлеге...

– Юньле кешедән истәлекнең матуры гына кала, – диде үз алдына уйланып Буранбай. Ул йортка карап төшә иде, Рәгыйдәнең сүзен эләктереп алып китәргә өлгермәде, түр тәрәздә бик матур карчыкның, баш сузып, аларны күзәткәнлеген күрде. Менә ул югалды. Шул арада, җемелдәп елмаеп, өйдән дә килеп чыкты. Карчык иң элек – Буранбай, аннан Рәгыйдә белән ике куллап күреште. Татарларда кочышып күрешүләр, үбешүләр авыл кешесенә дә чит дип, тагын нәтиҗә ясады булачак кияү. Тыйнак халык та инде: ничек сагынганнары күзләреннән үк күренеп тора, аналары белән дә ят кешеләр кебек кулны кулга алып кына күрешәләр. Итагатьлек микән әллә бу? Ананы артыгын санлау-хөрмәтләүме?

Ишегалдына уздылар. Яхшы бүрәнәләрдән, такталардан корылган булса да, кайры түбәле абзарлар манзарасы ачылды. Артында – алма, карлыган, бәрәңге бакчасыдыр. Рәгыйдәнең элек ян-якта да мунчалы, ял итү урынлы бакча бар иде, дип сөйләгәне исендә. Ул җир күршеләрендә икән хәзер.

– Бизим адам жашай турган турак үйдө терезеби бак жакты, карду тоолор жакты карап тура[8], – диде үз телен, илен сагынып куйган Буранбай.

Киң итеп ачып куелган урыс капка артында өем-өем ярка биеклеге киселгән агачлар. Аргы ягында шуларны ярып яткан кечкенә генә бер малай, кунаклар кыргызчалы-татарчалы сөйләшә-сөйләшә үзләренә килүне күргәч, соңгы пүкәнгә куелган яркасын җиңел генә як-якка очып китәрлек ярды да билләрен турайтты. Эшем кешесе кебек, фуражкасын салып, шуның белән генә тирләгән маңгаен сөртте. Аннан йөзенә, инде керәсе була, яру да туктала икән дигән сымаграк ризасыз бер кыяфәт чыгарып, янындагы ботаклы түмәрләргә карап алгач, балтасын шапылдатып, шуларның берсенә батырды.

Малайның күзе иң элек ишегалдына алданрак узган Буранбайга төште. Ике зур чемодан күтәргән кунакның, олы кеше санап, каршысына барырга

[6] Кәлтә тай – ике яшьлек тай.
[7] Бести ат – дүрт-биш яшьлек ат.
[8] Безнең кеше яши торган торак-өйдә тәрәзәләр бакча ягында, карлы тауларга карап тора.

ашыкмады. Кем әйтмешли, кияү кисәгенең ни эшләячәген көтте. Кече капканы ябып, артыннан Рәгыйдә кергәч кенә, аңа таба атылды:

– Исәнме, төтү!

– И-и, яным, ничек үсеп беткәнсең, – диде апа кеше. – Буранбай абыең белән дә күреш.

Буйга әле кечкенә булса да, эре сөякле беләкләреннән, озын бармаклы кулларыннан, какча йөзеннән, зур туры борыныннан бик токымлы күренә, үскәч, гәүдәле, көчле бер егет булачак кебек иде Рәгыйдәгә эне тиешле Камил. Ул, олыларча кыланып, Буранбайның бармакларын нык итеп кысарга тырышты. Авырттырмаса да, кунак абыйсы:

– Кумыз чиртергә калдыр. Минем балта тоткан кулмыни! – дип, көчен таныганлыгын сиздертте.

– Минем әбигә, кумызчы түгел, утын яручы, печән китерүче кирәк.

– Анысына син дә бар икән, зур малай булып үскәнсең бит, Камил!

Буранбай көлде, ул үзе дә сабый вакытыннан эшнең төрлесен эшләде. Атка атланып, тауларда көтүен дә көтеште, арыгын да буды, суын да ерды... Тик менә әнисенә охшап, бик зәгыйфь буынлы, артык йомшак күңелле.

Барысы да өйгә уздылар. Җәй, һава бетә, бүлмәләр эсселәнә, дип тормаганнар, олы мичне якканнар. Йортка камыр ризыкларының хуш исе таралган. Буранбай аны ишегалдында ук сизгән иде. Өстәлдә ялтырап торган самавыр җырлап утыра. Зәңгәр борчаклы чынаяклар, шикәр, варенье савытлары. Татарлар нигәдер шундый чынаяк ярата икән, дип аптырады Буранбай. Рәгыйдәләрнең Кизелдагы бүлмәләрендә дә ак борчак рәсемле куе зәңгәр савытлар иде. Үзләре белән бүләккә кытай чынаягы – чөйчек алып кайтмаганнар лабаса! Анда чәй гел бер төсле җылылыкта тора. Аңа салынган чәй азлыгыннан сиңа хуҗаның хөрмәте беленер.

– Инде утырып, йортка дога кылыйк, – диде Зәмниха карчык.

Буранбай бисмилладан артыгын белмәсә дә, мич буендагы скамьяга утырды да кулларын кушучлады. Аңа юлдагылар кайтканнан соң укыла торган дога нигәдер озын тоелды. Ниһаять, карчык:

– Амин, – дип, аны тәмамлады. – Ничекләр генә кайттыгыз? Юлыгыз бик авырга килмәдеме?

– Юк, әнәй, – дип җавап бирде Рәгыйдә.

– Минем белән бернинди юл да авыр түгел, – дип шаяртты Буранбай.

Зәмниха көлемсерәде. Ул кызының ниндидер бер егетне мактап утыруына гадәтләнмәгән, аларның тырнак астыннан кер генә эзли дип уйлый иде. Сигез ел йөргән Хафизын мәңге гафу итмәскә антлар эчте, инде онытырлык вакытлар узса да, кичерә алмады ул. Үзенә баш-аяк гашыйк Муллагалине җебегән, пыртлаган ис килеп тора, дип яратмады. Болай булгач, аңлашылды – кара чутыр башлы кыргызга исе киткән дә киткән. Ул тегенди-мондый гына адәмне яратмас. Сөйкемле сөяге бар кебек, әллә кайдан үзенә тарта бу егет. Бирәм, дисәң дә, бирмим, дисәң дә, барачак аңа ул.

Рәгыйдә, кайтуга ук өйләнешү хакта сүз кузгалырмы инде, дип шүрләгән иде, кузгалды, әмма карчык сорау арты сорау яудырып аптыратмады, ничек яшәрсез, кайда торырсыз, нинди акчага, дип төпченмәде. Үзегезнекен үзегез беләсез, мин инде олыгайган, дип кенә әйтте. Эченнән, Әхмәтгалимем исән булса, яхшы булыр иде дә бит, дип уйлады, кияүгә үгет-нәсихәт бирсә дә,

килешер, үз янында торырга чакырса да, гаепкә алынмас иде. Аңа менә артык сүз куерту әдәпсезлек булыр.

Буранбай, иркенләп ашап-эчеп алгач, эш соңына калдырылган ботаклы пүләннәрне ярырга дип, ишегалдына чыкты. Аңа Камил дә иярде.

Йортта олы мал асрамаганнары, ишле гаилә яшәмәгәне күренә иде. Абзар бүлеменең ачыклыгын яртылаш кына каплаган рәшәткә ишектән ап-ак кәҗә башын сузган.

– Сәйнәкме? – дип сорады Буранбай.

– Сәйнәк?

– Ике яшь тирәсендәге кәҗәгә шулай дип әйтәләр бездә.

– Алайса шулай.

– Нигә көтүдә түгел?

– Аягы җәрәхәтләнгән иде. Чыгармадык, бозылыбрак тора.

– Үлән төтене белән төтәргә кирәк аны.

– Бездә мал врачы бар. Нәрсә эшлисен үзе белер.

Буранбай ишегалдын тагын бер күздән кичерде. Бар җирне чирәм баскан. Әлеге дә баягы олы мал юклыктан, хатын-кыз гына тормыш иткән йорт булгангадыр инде ул. Абзар буенда читән белән киртәләнгән, өстенә тилгән-мазардан саклар өчен дипме, ямаулы киндер капчыклардан тегелгән япма тарттырылган бер урында чебеш анасы гаиләсе белән матавыклана. Чебиләре артык зур булмасалар да, рәтләре көн яктысы узарлык итеп үрелгән чыбыклар арасыннан чыгарлык түгел. Әле йомшак, сап-сары чакларында кулына алырга ярата чебиләрне дә, каз-үрдәк бәбкәләрен дә Буранбай. Аларга авызы белән берәр нәрсә каптырган булып шаяра. Хәзер дә берәрсен тотып карыйсы иткән иде дә, кире уйлады. Тавыкны бөтенләй куркытырмын дип, читәнне күтәреп тормады.

Буранбай кабат урам якка борылды. Төшкә тамак ялгарга кайткан казларның, кунак бармыни дигәндәй, әле анасы, әле атасы башын сузып, кече капка астыннан карый. Керәм дисәләр, янындагы зур капка шыр ачык. Нигә керсен инде алар? Утын түмәрләре, яркалары аша йөрсеннәрме? Буранбайны күрер өченме? Алар да тикшерә, сыный торгандыр әле. Сәламләвен көтәләрдер. Буранбай кошлар, маллар белән сөйләшергә, уйнарга, алар турында сөйләнергә ярата инде ул.

– Әссәламегаләйкүм, ата каз, – диде Буранбай, үзенә муенын сузып, ысылдап-ысылдап куйган кошка. Аннан Камилгә дәште:

– Кукмарадан Нәкыйп исемле бер кеше белән эшлим. Муеным катып калгач, ата казга сәлам бирергә кирәк, дигән иде, соң булса да уң булсын: бирәм, алга таба файдасы тимәсме?!

Камил көлде:

– Сиңа мин Кызык Җизни дип дәшәрмен, яме!

Эштегеләр Шаян Кыргыз диләр иде. Инде Камил дә исемне хәл иткән икән. Элек Буранбай кешегә ничек кушамат тагарга була инде, дип аптырый иде. Моны дин дә гаепли, йола да. Кушамат шул икенче исемең бит ул, халык, чынын кабул итмәгәнгә, тапкыр таптым дип санап биргән исемең дип уйлый хәзер. Кайчан – тапкыр, ә кайчан ачудан, көнләшүдән, үчләшеп, кешегә исем чыгарып, шуны таратып уйнаучылар да бар. Буранбай артыннан бер дә калмаган малайга карады: ул нәрсә уйлап тора икән?

Камил апасын бик ярата иде. Кияүгә китеп барса, әнисе ташлаган, әтисе

үлгән малайга бер дә рәхәт буласы түгел. Әллә җизни буласы кешенең үзеннән сорарга инде?

– Сез Кыргызстанга күченмисездер бит? – диде ул нигәдер аңа текәлеп карап торган Буранбайга.

– Әлегә төгәл генә белгән юк.

– Мин мәктәп бетергәнче, төтүгә кияүгә чыкмаса була иде инде...

– Ничәнчене бетердең соң, үскәнем?

– Бергә барам!

Буранбай көлемсерәде. Апасын картайтып кына бирәсе икән егет...

– Кара син аны! Нинди зур түмәрләрне яргансың.

– Әби дә булышкалый миңа. Зурракларын ул яра.

– Барыбер. Маладис икәнсең.

Балаларга үзләре яшәгән далада, көтүлекләрдә генә эш күп, анда гына аларны кырыслык белән үстерәләр дип саный иде Буранбай. Бергә, ди... Буена карасаң, һич тә алай дип уйламассың. Ничек җир җимертеп, утын ярып ята! Нәрсә дип җавап бирергә соң аңа?

– Конокто жакшы болгону менен үйдөгүгө жетпейт, ди кыргыз. Кунакта яхшы булса да, өйдәгегә җитми. Татарчасы шулай дөресрәк булыр, энем. Мин бит Кизелга гомер яшәргә килмәдем.

– Сагынсаң, үзең безнең янга барырсың, – дип сүзгә кысылды өйдән чыгып килгән Рәгыйдә. – Менә бераз үс тә барырсың.

– Әбине калдырыпмы?

Зәмниха Рәгыйдәне кырык тирәсендә генә тапты. Хәзер җитмешнең теге ягында. Ялгыз гына көн итү түгел, төн куну да рәхәт түгел инде аңа. Нужа балаларының кайсын кайда йөртә. Күзгә күренми торган дошман кебек ул. Үзеңә зыян салган кешеләргә ничек тә каршы торырга, бирешмәскә тырышасың, моңа – юк. Камил белән Буранбайның сөйләшкәнен өйалды ишегеннән тыңлап торган карчык шулай уйлады, әмма:

– Әле аягымда бит, улым, майабыстаңнар да ярдәмнәреннән калдырмас. Габделкасыйм кияү бик игелекле кеше, – дияргә булды. – Ул якка баручы табылса, шуларга ияреп, карап килерсең. Хәлимәбикә апаңнар бармасмы әле?

Бу баланы тынычландыру, өметләндерү кебегрәк кенә әйтелгән сүзләр иде. Зәмниха карчык аны озынга сузасы итмәде:

– Эшегезне бетерүгә үк, майабыстаңнарга чәйгә менәрсез. Бәлешлесе-мунчалысы иртәгә булыр, монысы бер күрешү өчен генә дип хәбәр салганнарые, – диде.

Икәүләшеп тырышкач, түмәрләрдән берни калмады. Буранбай ярып, Камил ташып, Рәгыйдә өеп торды. Аннан бераз тын алдылар да, җыенып, Малиха карчыкның олы кызларына – Ямьбикәләргә менеп киттеләр. Машина туктаган урынның каршы ягында аларның өйләре булган икән. Чиккән пәрдәле, шау чәчәкле-гөлле бер йорт иде ул. Ишегалдының сул ягында курчакныкы кебек җыйнак, пөхтәләп салынган икенчесе тора. Монысы ак өй, ахрысы, дип уйлады Буранбай. Татарларда да кунак йә җәй өчен махсус йортлар бар дип белми иде. Ак келәт, ак мунча булгач, ак өй дә була торгандыр, ахрысы. Танышкач-күрешкәч, күчтәнәчләрне биргәч, хәл белешкәч, табыннан өстен булмыйк, диешкәләп, чәй эчеп алдылар да Рәгыйдәләргә кайттылар.

Кырыс тормыш үзен дә, телен дә чарлаган Рәгыйдә әниләре, туганнары

янында гел икенчеләнеп китте. Җизнәләренә менгәч, кирәгеннән тыш сабыр, тыенкы, әдәпле күренде Буранбайга. Җизнәсенең шаяртуларына да көлеп кенә тора, кара-каршыга да шаяртмый. Олылар янында, кара, үзен ничек тота икән, дип сокланды аңа егет.

Аштан соң барысы намазга хәзерләнә башлады. Рәгыйдә дини йортта үскәндер, укый беләдер дип, башына да китерми иде Буранбай. Аптырап китте. Яшермичә дин тотудан бер дә курыкмый микәнни соң болар? Рәгыйдә, җизнәбез мулла безнең, ди иде. Хак икән. Төрмәсе дә, сугышы да чыгармаган икән аннан иманны.

Буранбайның икенче йортны яхшылап күрәсе килгән иде, ялгыз калгач, җай чыкты. Касыйм абыйсына ияреп, шунда керде. Татарлар бай да, чиста да, җиһазлы да яши икән. Рәгыйдә юл буена үз якларында көн итүнең чиктән тыш авырлыгын сөйләде, ничек яшәвебезне гаепкә алма инде, дип әйтә килде. Бар нәрсәләрен алып бетерсәләр дә, яңадан тормышны матур гына корган икән апалары. Мондый йортларда үскән кыз тире йортларда яшәргә теләмәс... Теләсә дә, яши алмас. Рәгыйдә сораса, инде монда яшәп калырга да әзер иде ул, тик кызга ул хакта әйтергә батырчылык итмәде.

Өйдә һава иркен итеп суларлык иде. Агач бүрәнәләрне алдагы көндә генә юып чыгарганнар бугай. Сабантуйга өйләрне түрдән ишеккәчә җыештыралар, дигән иде Рәгыйдә. Юан нарат бүрәнәләренең исе борыннарны ярып керә. Әллә чәернеке генә түгел, шул бүрәнәләрне сафландырган сулар да бирә микән бу хуш исне?..

Паласлар җәелгән түр бүлмә өстәленең уртасында матур вазада кибет чәчәкләре утыра. Уң почмакта – дүрт тәпиенә баскан радиоалгыч. Сулда – чәчәкле тышлыкларга киенгән мендәрләрдән авыраеп торгандай тимер карават. Савыт-саба шкафының өстендә – самавыр. Янында – аның кебек үк челтәрле күлмәк ябындырылган гармун. Кемдер уйныймы анда, уйнаганмы?

Рәгыйдәнең җизнәсе сүзгә аннан да шаянрак, ахрысы. Буранбай намазын тәмамлаган Касыйм абыйсыннан, гармун кемнеке, күрекләрен тарткалыйсыз мәллә, дип сорагач, минекен яшьлегемдә муллалар кәнфискәцияләде – мәчет астында яптылар, үземне кызгандылармы – бераздан чыгардылар, дип көлде, монысы – малайныкы. Хәзер мулла урынына йөрсә дә, заманында гармунын да уйнаткан, җырын да җырлаган, шуның өчен картлардан җәзасын да алган, имеш. Әллә, гадәтенчә, шаярта гынамы? Ямьбикәсенә кашларын сикертеп алды да, бик җитдигә салынып:

– Инде карчык акылга утыртты, намаз карты ясады, – диде ул.

Буранбай да шулай бервакыт торып-торып намаз укыган, бисмилласын авызыннан төшермәгән бер ир булыр микән?! Габделкасыйм аннан әллә ни олы түгел ләбаса! Әнә бит, совет кушмый дип тормый – эшенә дә бара, намазын да калдырмый. Сугыштан да дога гына исән кайтарды, ди.

Татар авылының иң күңелле вакыты кич икән. Рәгыйдә, аптырама, төн безнеке, рәхәтләнеп җырларбыз, беркем сүз әйтмәс дип, алдан ук искәртеп куйган иде. Буранбай, үзеннән һич калдырмый торган кубызын алып, наратлар янына барып утырды. Бераздан аның янына Рәгыйдә дә чыкты. Берсе уйнап, берсе җырлап җибәргәннәр иде, алар янына тирә-яктан халык агыла башлады.

– Кичке уенлык монда гына булыр инде, – диештеләр, Буранбайның йөгерек бармакларына, чит көйләргә, Рәгыйдәнең тавышына таң калган кешеләр.

Берзаман яшьләр таралды. Буранбайның кирәсе килмәде. Көнбагыш чиртеп, күкне күзәтеп, ишегалларында эт өргәнне, су буйларында бакалар кычкырганны тыңлап, төн буе капка төбендә утырырга әзер иде.

– Буранбай, кайдан алдың син бу тәмле эре көнбагышларны? – дип сорады Рәгыйдә, аларны бер-бер артлы теш арасында чертләтеп.

–Уйлап тап! – диде Буранбай.

Рәгыйдә җавап бирмәде. Хәтеренә әллә кайчангы вакыйга килеп төште.

Шулай бервакыт Рәгыйдә, иптәшләре колхоз өчен урманга печәнгә киттеләр. Араларында Хафиз да бар иде. Ул кайдандыр көнбагыш эләктергән дә, беркемгә бирмичә, үзе генә ашап бара.

– Бик тәмләп ашыйсың, – диде аңа Рәгыйдә.

– Өлгереп үк бетмәгән әле ул.

– Булсын. Бер башын бирче.

Хафиз өлгермәгән дип алдаган гына, орлыклар эре иде инде.

– Тугаерга иртәрәк, дип уйлап йөрим тагын. Үзебезнекен карыйсы калган. Әллә аларның да кабыкларында йомшак мәмәй генә түгелдер инде.

– Борчылма, үзегезнеке кебек аша, – диде Хафиз. – Бар бит. Җитә.

Кичен эштән кайтканда, тук микән, карыйм әле дип, бакча аркылы узарга булды Рәгыйдә. Әле генә авыр башларын иеп утырган көнбагышларның берсе дә калмаган иде. Хафиз әйткән сүзләр шунда гына башына барып җитте: бурлыкка еракка йөрми икән... Колхоз абзарларыннан аларга гына төшкән дә барысын җыеп чыккан. Күптәнге вакыйганың күңеленә килүе Рәгыйдәнең кәефен төшерде.

– Керик булмаса, – диде ул. – Әллә нинди шомлы, күңелсез бүген төн.

Кузгалдылар. Башка вакыттагыдан артык аерылмаган төн кебек иде Буранбайга. Рәгыйдәсенең сүзләренә бик гаҗәпләнде. Алай да нәрсәдер җитми бит бу төнгә. Сәер тынлык урнашкан түгелме?!

– Рәгыйдә, кошлар җырлаганы бер дә ишетелми.

– Июльгә күбесе бала чыгаралар. Алар бит май урталарында ук киләләр. Сандугачлар июль башында сайраудан бөтенләй туктый. Бер айга иртәрәк кайтсаң, аланнарда җырлары чигәңне тишәр иде. Башта гына хозурланасың, аннан кайчак ялыгасың, бераздан, эшкә бирелеп китсәң, ишетми үк башлыйсың аларны урманда. Авылда минем аларны игътибарга да алган юк. Зират яныннан узганда, коры елгаларда сайрауларын ишеткән бар. Аларга да тыныч, бөҗәкләргә дә оя булган куе үләнле урыннар кирәктер.

– Безнең якларга булбул[9] апрельдә үк килә. Мин башка кошлар да сайрамаганга аптырадым.

– Инеш буендагы тирәктә мәче башлы ябалак кычкырса гына инде. Әтәй, әниегез белән танышкан көнне шулар белән киңәштем, аларның хәер-фатихасы белән өйләндем, дип шаяртырга ярата иде. Син дә минә күңелең белән кош эзлисең.

– Ата сандугачлар мәхәббәт аңлатып, ары бала чыгарганда, күңелен күреп сайрый. Сине үземә алар кебек каратыйм әле: «Бүл-бүл-бүл-бүл... Клә-клә-клә-клә... Трррррррр... Плән-плән-плән-плән...Һо-һо-һо-һо...Түй!»

– Синең сайравың да җыр кебек, Буранбай.

– Бөтен дөньясын онытып, тәүлекләр буе ни турындадыр сөйләгән

[9] Булбул – былбыл.

сандугачны беркем дә кабатлый алмый. Үзебезнең якныкыларның көйләрен чыгарып күрсәтергә тырыштым да бит. Сайраганым әллә сезнең былбылларныкына да охшаштыр. Әтием менә былбыл тавышыннан кайсы якныкы икәнен аера иде. Алар бит кеше кебек: җырларга остаздан өйрәнә.

– Син сагышлы да, шаян да җырлаучыдан өйрәнгән былбыл алайса!

– Икенче тапкыр озаккарак, иртәрәк кайтсак, Чок-Талдагыча сайрарга өйрәтәм мин сезнең сандугачларны!

– «Урыс сандугачы» дисәләр дә, алар монда болай да арча да, татарча да җырлый. Берәрсен кыргызныкыларга остазлыкка алып кит. Анда татарча да сайраган кошларны тыңлыйсым килер минем.

– Әллә бер үк төсләдер әле аларның җырлары.

Икенче көнне Тәкәнештә Сабантуй буласы икән. Җыен күрше-күлән, туган-тумача – йөк арбасында шунда киттеләр. Камилне дә алдылар.

– Кыдагый, – диде Буранбай, китәр алдыннан Әнфисә күршеләренә кергәч.

– Бирермен мин сиңа кыдагыеңны, кодагый диген!

– Кыдагый, – дип, тагын үзенчә башлады Буранбай. – Өскебашында синең белән мин яраткан мәчегез генә кала. Үпкәләмәсен, аның белән минем өчен уйный тор.

– Сиңа, Буранбай, шукланырга булсын. Килен каенанасына охшап килә, диләр. Зәмниха белән Әхмәтгалимнең киресенчә – кияүләре үзләренә охшаган.

– Рәгыйдә, тач Галинур инде син, ди. Белеп әйтми ул, име, кыдагый, – диде Буранбай, Әнфисә апасын котыртып.

– Шулай булмыйча. Ул Зәмнихәттиләрнең биек өендә дә баш иеп йөри башлаган иде инде, синең башың ишек киергесенә дә тимидер.

– Кемгә охшасам да ярый, барыгыз да минем кебек матур, – дип көлде Буранбай. – Песи белән икегезне бергә карточкага төшереп китим. Рәсем астына, «Тәкәнешкә Сабантуйга бармаучылар», дип язарбыз да район газетасына бирербез.

Сабантуйдан алар гына түгел, Хәлимәбикә апаларының Фәнисе дә калды. Берсе дә уята алмады. Йокыдан торгач:

– Анай, анай, дип татарчалап елагансың икән, – дип шаяртты Габделкасыйм җизнәләре бәйрәмнән кайтучыларны авыз бүлтәйтеп каршы алган шәһәр малаен. – Көтеп торсаң, туктамасаң, бергә елаган булыр идек. Мин тагын да матуррак кычкырам. Сине дә уздырамдыр әле.

– Үзем генә елыйм, – диде тынычлана башлаган малай. – Син Тәкәнешкә бардың бит. Нәрсәгә еламакчы буласың?

– Кил, алайса кочаклыйм әле үзеңне, – диде Габделкасыйм. – Миңа эшкә үсүче малайларны яратам мин. Анаеңа әйт: кайткач, тәмле әйберләрне күп итеп ашатсын, тагын да тизрәк үсәрсең. Урманга гел синең белән генә йөрермен.

– Кунакка – сез, эшкә мин икән, – диде Фәнис, борын мышкылдатып. Барысына да аларның сөйләшүеннән кызык булып китте. Җитмәсә, Сабантуйга баруына, катнашып, балалайка алуына да бик сөенгән иде Буранбай. Кыргызчаны җиңелдән аңлаган, дәртле көйләр уйнавын яраткан халык аны уртага кат-кат чакырды, тамагы карлыкканчы җырлатты.

Матур башланган кунак көннәре тиз генә узды да китте. Никах туйлары да артта калды, кияүләп, туган-тумача белән танышып йөрешләр дә. Татар авылындагы бар нәрсә, бар кеше ошады Буранбайга. Яллар бетеп килә,

кунакның вакыты вакытлы, кузгалырга кирәк иде. Чемоданнар кайтканда, ничек шыплап тутырылган булса, киткәндә дә, буш урыннары калмады.

Буранбай Кизелда калырга да, хәтта кыз ягында яшәргә дә риза иде, тик Рәгыйдәсенең иренә «кияүгә чыккан» даны күтәртәсе килмәвен сизде. Ул аңа, һавасының үпкәсенә зарарын белсә дә, син кайда яшәргә уйласаң, мин – шунда: телисең – шахтада эшләп калам; теләмисең икән, сезгә китәбез, башка бер якларга күченсәк тә, каршы түгелмен, диде. Буранбай, Рәгыйдәнең туган җирен күргәч, үз ягын бераз сагына да башлаган иде. Уйлый торгач, эш урыннарында исәп-хисап ясап, Кыргызстанга күченүне хуп күрде.

Алар Кизелга җомга көнне иртәнге якта кайтып төште. Шахталар да, бухгалтерияләр дә эшли иде. Яшь парларга тоткарлык ясамадылар, атна көтегез, ай көтегез дип тормадылар, шунда ук тиярен кызның кулына тоттырдылар. Моны алар, күмер чыгарудан файда кимегәч, кайчандыр төрле җирләрдән җыелган халыкның инде артыкка калуына бәйләде. Әкренләп, барыбер кешеләрне таратып бетерәчәкләр, китәсе булгач, иртәрәк китеп котылуың яхшырактыр да әле ул, дип уйлады Рәгыйдә. Аңа, никадәр гомере вагонеткада күмер ташып узган шахта белән хушлашудан битәр, шушы тирәдәге посёлокларда яшәгән туган-тумачаларын калдыру авыр иде. Җиңе белән яшьләрен сөртеп алды. Коридорга чыккач, кеше күрмәсен тагын, тынычланыйм әле дип, стенадагы язуларны карап тора башлады. Ике норма эшләүче хезмәт батырлары арасында никадәр татар икән! Татарлар мондагы шахталарда унөч-унбиш процентган артмый, дип язалар югыйсә. Беркем дә алай димәсә дә, башкалардан узып эшлиләр алайса...

Китәсе алай да. Чираттагы җидееллык планны вакытыннан алда үтәсәләр, күп орден-медальләр таратылачак, дисәләр дә китәсе. Кизел үсәр, төзелер, дип тә өметләндерсәләр дә. Шахталары әкренләп, яңача эшли башлыйсы, автоматлаштырыласы ди. Эшче кешенең ул чагында кирәге калмый да калмый инде. Никадәр иртәрәк китсәң, күңелеңә шуның кадәргә авырлык кимрәк килер. Рәгыйдә бүген чыгып китсә дә, риза!

– Жакшы, – дигән булды ул, өйгә кайткач, кыргызчалап. – Эртең – ишемби. Бүгүн болбосо, эртеңкиге калсын, же жәкшембкә[10] . Атна башын көтәсе юк.

– Эртең же бүрсүгүну[11], – дип килеште Буранбай.

Кич буе дус ишләре, якын туганнары белән хушлашып йөрделәр, сораганнарына адресларын бирделәр, төн буе җыендылар да, Аллага тапшырып, шимбә көнне Кыргызстанга китеп бардылар. Рәгыйдә алдан болай моңсу булыр дип уйламаган да иде, китә башлагач, күңел үзгәрә икән. Үзен гашыйк иткән, яраткан Буранбай хакына бик күп нәрсәләрне монда да калдырганлыгын аңлады ул. Йөрәге өченче кисәккә бүленгән кебек булды. Аның бер өлеше әнисе белән хушлашканда, әтисе утырткан пар наратлар янында өзелгән иде инде.

Алтынчы бүлек

Бәхет бәрхеттә булса...

1

Рәгыйдәләр, эшләрендә исәп-хисап ясалгач, монда нишләп ятабыз инде, дигәндәй китеп барырга ашыктылар. Алдан заказ бирелмәгәч, билетның ниндиенә дә риза иделәр. Свердлауга кадәр барсагыз, анда Фрунзегача

[10] Яхшы. /.../ Иртәгә – шимбә. Бүген булмаса, иртәнгегә калсын йә якшәмбегә.
[11] Иртәгә йә берсекөнгә.

урын булмый калмас әле, диде билет биргәндә кассир ханым, Буранбайга елмаеп. Рәгыйдә, касса яныннан киткәч, нигә сиңа шулай елмая ул дип, иреннәрен бүлтәйтте. Буранбайның сәбәпсез көнчелеккә исе китмәде, бу елмаюның паспорттагы күчтәнәчкә рәхмәт йөзеннән икәнлеген белә иде.

Поезд Свердлауга таң алдыннан китереп җиткерде. Перронда салкынча иде. Вокзалга уздылар. Саклау камерасы эшли икән. Акчаларын Рәгыйдәнең кечкенә сумкасына салдылар да, әйберләрен шунда тапшыргач, кассага бастылар. Билет монда да юк икән. Инде нишләргә белмичә торганда, кире тапшыручылар табылды. Башкаларга күбрәк урын кирәк булып чыкты да, бәхетләренә, Рәгыйдәләргә эләкте. Шулай, кемдер – ишле гаилә белән, кемдер – ялгызы. Рәгыйдә менә – парлы. Иргә таянып яшәү бөтенләй башка икән. Юлын Буранбай кайгырта, әйберләрен аңа күтәртми диярлек. Мондый бәхетне күргән кыз идемени соң?!

Кызны вокзалның зурлыгы, кешенең күплеге, һәркайсының үз юлында булуы, төрле якка баручы поездларга шыплап тулулары шаккатырды. Уйгур-казакъка, башкасына тартымы да, татары-урысы да җитәрлек икән монда. Әйтерсең, дөньяның кендеге иде Свердлау. Юллар төйнәлгән урын, шуңа халык мыжгып тора, диде Буранбай.

Рәгыйдә бу як кешеләренең, Уралның баш шәһәрендә яшибез, дип мактанганын ишеткәне бар иде. Бер көннәре шуның урамнары буйлап каңгырып йөреп узды. Тегендә барган булдылар, монда, әллә ни карарлык нәрсә дә тапмадылар, эсседән әлсерәп беттеләр. Кич җиткәч кенә, чемоданнарын саклау камераларыннан алып, Фрунзе поездына утырдылар. Әйберләрен куйгач, пычрак, каралмаган, сатырга, күчтәнәчкә алынган җиләк-җимеш, яшелчә исе килгән плацкарт вагоннары аша ресторанга уздылар. Кузгалмаган поездның рестораны ачык булырмы?! Ишеген тартып-тартып карагач, кичке ашка барыбер барасы дип, үз купеларына кайттылар.

Фрунзега юл бик озын икән. Рәгыйдә баштарак куркып калган иде дә, билетлар купедан табылгач, көн эссесе алай ук җәфаламас әле дип сөенде. Юл авырлыкларыннан, бер транспорттан төшеп, икенчесенә, өченчесенә утырулардан, дала аша узган поездның акрынлыкларыннан ялыккан яшь хатынга машинистлар һәр карбыз сатучыга, һәр әйрәнче-кымызчыга сәлам бирәләр шикелле тоелды. Балхаш күлен узганда, поезд бөтенләй үк туктады. Ишек ачарга чыгып барган проводница, кемнең су керәнәсе килә, сәгать ярымлап ял итеп алабыз, дип белдерде. Башка пассажирлар бу гадәтне белә иде, ахрысы: ирләрнең күпчелеге киемнәрен алдан ук алмаштырган булып чыкты. Вакытны аңа уздырмыйча, шактый кеше поезд юлына терәлеп диярлек җәелгән Балхаш күленә кереп китте. Рәгыйдә моның кадәр халык арасында су коенырга уңайсызланды, Буранбайга иярмәде. Алай да, вакыт узар дип, тышка чыкты. Якындагы бар сатучы, калта тотып, поезд баскычыннан җиргә сикергән пассажирга атылды. Рәгыйдә, башкалар кебек сатулашмый-нитми генә, берсеннән ысланган балык алды да, базарчылардан көчкә ычкынып, вагонына керде.

Ул да булмады, поезд, күл яныннан кычкырта-кычкырта китеп, алга таба юл алды. Рәгыйдә тәрәзә ачыгыннан, башын сузып, тышка карады. Вакытны онытып җибәргән уйсызларның, йөгереп барып, соңгы вагонга гына эләккәннәрен күрде. Буранбай үзләренекенә өлгергән иде.

Яшь ир белән хатын, кыргыз белән татар баласы, кайчандыр үз халыкларының бабалары хуҗа булган, утлы уклар күкләрне кисеп узган Дәште-Кыпчак буйлап бардылар да бардылар. Рәгыйдәнең төрки халыкларның ватаны зур икәнлеге хакында ишеткәне бар иде, әмма шундый киңлекләрдә яшәгәннәрдер дип, һичбервакыт уена китермәде. Бу иркенлек аның башын әйләндерде, дала эссесе аның бугазын яндырды, шул дала өстеннән челләдә дә очып узган, ташлар өстендә басып калган бөркетләр, шоңкарлар яшь хатын күңеленә күкләрнең генә түгел, әлеге дә баягы җәйрәп яткан җирнең дә бүгенге хуҗаларыдыр кебек тоелды.

Җиле, корылыгы, эссесе бергә буталган далада анда-санда балчык-тизәк измәсеннән ясалган өйләр юл буйлап махсус сибелгән, диярсең. Йөзләре кара-кучкыл, чәчләре кылдай малайлар, кысык кара күзләрен каш астыннан текәп, борыннарын җыерып, аларга кул болгап калгалый иде. Рәгыйдә дә, купедан чыгып, вагон коридорында барганда, тәрәзәне төшереп, бала-чагага өрфия косынкасын җилфердәткәндәй итте. Малайларның күңеле булса да, өй тирәсендә кипкән печән ашап торган ишәкләрнең дә, күләгәдә ял иткән дөяләрнең дә татар кызына исе китмәгәндер – башларын күтәреп тә, борылып та карамадылар.

Кеше чыдаса да чыдый икән! Бу эсседә, бу коргаксыган туфраклы җирләрдә гомер бакый яшәү түгел, алар аша бер көнлек юл узарга да түземлек кирәк, дигән фикергә килде бара торгач Рәгыйдә. Ә бит монда яшәргә кызыга да башлаган иде ул! Кемгәдер бу ашсыз җирләр дә – кадерле Ватан! Җәйләрен кибүчән коелар да, үләксә эзләп чапкан шакаллар да, бер-бер ваграк нәрсә кыймылдаганны эзләп очкан кошлар да, Рәгыйдә моңарчы ишетеп-күреп белмәгән нәрсәләрнең барысы-барысы – аларныкы.

Кызны бернинди авыл булмаган җирләрдә курганнарның, мазарстаннарның күплеге аптырашка калдырды. Әллә кайлардан диварлары белән калкып утырган каберлекләрне барып карыйсы, ташлар астына басылып яткан адәми затларга догасын ирештерәсе килде. Комнардан, кызыл балчыктан гына ясалган һәйкәлләрнең моңа кадәр җилләрдән, яңгырлардан ничек ишелмәгәнлегенә шаккатты.

Рәгыйдә Буранбайга, татарга хас булмаганча, башка төркиләрнең шундый зур каберлекләр коруларына аптыравын әйтте.

– Нәрсәсенә аптырыйсың,– диде Буранбай.– Әллә син күргән борынгы каберлекләр эчендә үз нәселең әрвахлары да ятадыр. Сиңа кул болгап калган малайларда синең бабаларыңнан да тамчы гына булса да кан агадыр. Сез еракка күчкән, сез үзгәргән... Ә монда – уртак Ватандыр.

Хәер, Рәгыйдә дә шулай уйлый. Институт бетермәдем, әнисез үстем, ди Буранбай. Тормышны гына түгел, Рәгыйдә китаплардан да тапмаганны, һич ишетмәгән тарихны да ничек яхшы белә ул! Кыргызлар өчен аны хәтерләү шулкадәр мөһим микәнни?

Буранбай үзенә күрә бер горурлык белән:

– Бездә якын кешене булдыра алганча кадерлиләр, үлгәч тә онытмыйлар, зурлап күмәләр, – диде. – Мин, ата-анасын җирләп килгәннән соң, инде анда һичкемем калмады дип, туган җиренә кайтмаган татарларны беләм.

– Бердер, икедер инде ул.

– Бере дә яман. Зират исәндә, һичкем калмаган була, димени?

– Синеңчә, үлгән кешегә мондый йортлар кирәкме соң?

– Үлеп карамагач, әйтәлмим, – диде Буранбай. – Исламның тыенкылыкны яклаганын да беләм. Электән килгән күмү йолаларын дин генә халык хәтереннән сызып атарлык түгел.

– Әрвахлар догага гына мохтаҗ.

– Син дә хаклы. Безгә ислам сездәге кадәр кермәгән. Үзебезне мөселман дисәк тә, башкачарак – ыруглык гадәтләре беләнрәк яшибез, алар туган җир шартлары белән сыналган дип уйлыйбыз. Әйтик, мәетне җиргә, бигрәк тә өскә генә күмеп калдырсаң, һични белән уратып алмасаң, чүл буйлап азык эзләп чапкан ач шакаллар бервакыт казып алып ашамасмы? Өстендәге комнары давыллар вакытында күчеп китеп, мәетләрнең гасырлар буе яткан сөякләрен өскә чыгармасмы?

Кыргызда борынгыдан килгән гадәтләр гел башка икән: мәрхүмнең кабер ташына узган гомеренең картинасы ясалса йә янына тормышта кирәкле әйберләр салынса, үтә кадерлеләре төрбәсенә куелса, теге дөньяда да мондагыча яшәр. Булмаганны! Кыз авызын ачты да калды. Алар авылында картлар каберлекләргә фото да куйдыртмыйлар, батырчылык итеп, кемдер ясатса, рәсемгә корым сөртергә дә күп сорап тормыйлар.

– Мин үлгәч, этемне, мылтыгымны тотып, атта ауга барганны ясатырсың, яме! – диде кинәттән Буранбай. – Үзеңне ясатма!

– Анысы нинди сүз тагын?

– Син миннән соң да яшәргә тиеш! Исәнне янәшәңә ясату – начар фал.

Кызга әллә ничек булып китте:

– Һәрберебезнең гомере Ходай кулында. Кайчан үләсен берәү дә белмәс!

– Белмәсәң дә, алдан әйтеп куюың яхшы. Әкренләп гадәтләребез белән дә таныш.

– Безнеңчә булмагач, өркетә. Миңа бит анда яшәп каласы...

– Безнең анда яшәп китәсебез бар, диген! Минем кочакта авыр булмас!

– Ышан ирләргә,– дигән булды Рәгыйдә сүз өчен генә.

– Сине берәр вакыт тау башларындагы мәгарәләргә, ташлыкларга алып барырмын әле. Аларда борынгылар ясаган шундый рәсемнәр бар! Әллә ничә гасырлык рәсемнәр!

– Син дә картинада гасыр кичәсеңә ышанасың инде алайса?

– Үземнән соң нәрсә дә булса, кемне дә булса калдырасым килә минем. Сурәтем булса да калмасмыни, Рәгыйдә?! Тик ул рәсемгә, тагын бер әйтәм, үзеңне ясатмассың, яме! Синең миннән соң да бик озак вакытлар бу күкләрне күрүеңне, бу һаваларны сулавыңны телим. Миңа догачы булуыңны.

Рәгыйдәнең керфекләре дерелдәп китте. Ул менә-менә елап җибәрер шикелле иде. Буранбай күрмәсен дип, поезд тәрәзәсенә башын терәде дә бите буйлап тәгәрәгән яшьләрен җилдә җилфердәгән кисия пәрдәләргә сеңдерде.

Буранбайның кайтып керәсе Чок-Талы Ыссык Күлнең төньяк ярындагы Фрунзе шәһәреннән ике йөз утыз биш чакрым ераклыкта, имеш. Кыргызлар башкалаларын Бишкек дип йөртә, әле дә якташларының исеме белән атарга теләми икән. Исемен югалткан – тарихын югалткан, ди Буранбай. Аңа гел сөйләргә булсын:

– Чок Тал артында борынгы курганнар күренеп тора. Аларда ау, күмү,

бәйрәм, йола рәсемнәре тулып ята. Алтынчы-сигезенче гасырлардан ук килгән таш балбаллар да табыла икән әле дә.

– Авылың янындагы тауларга менгәч, без дә берәр ташка уеп кына рәсем ясап төшәрбез дә, килер буыннар кайсы гасырныкы дип, баш ватар, – дип көлгән булды Рәгыйдә.

– Була ул! Үзебездән соң, үземнән соң нәрсәдер калдырасым килә, дидем бит, рәсем калдырырбыз алайса.

– Кайтуга ук табигатькә чыгарбыз әле, Буранбай, яме! Син матурлап сөйләгән йөгерек арык суларының салкынында җанны басарга иде...

– Туган авылыңны онытырга икән исәбең.

– Юк! Инде хәзер үк үз ягыбызны сагына башладым кебек. Синең йортыңа да ияләшергә тиешмендер бит. Шунда яшисе дә булгач.

– Мин янында килеш тә сагынасыңмыни? Гомереңдә беренче тапкыр дөньяның иң матур җирләрен күрәчәкмен дип сөен!

– Мин анда синең белән яшәү өчен генә барам. Күпме генә сүксәң дә, туган якны бер җир дә алмаштыра алмас.

– Мин юләр сездә яшәргә дә риза идем, – дип көлемсерәде Буранбай.– Борчылма, минем белән үзеңә ошаганча яшәрсең. Телисең – җилкәнле көймәләрдә йөрербез, катамараннарда яр буйларын айкарбыз, телисең икән – давыллы көндә яшен астында икәүдән-икәү калып, дулкын өсләрендә чайкалырбыз – язмыш белән уйнарбыз.

– Куркытмале!

– Яшен, дулкын белән үчләшергә яратам мин!

Поезддан Чуда кичкә таба төшсәләр дә, якты иде әле. Монда автобуслар төнен дә йөри икән. Сәгать тугыз тирәсендәгесенә утырып, туп-туры Чок-Талга таба киттеләр. Буранбайның туп-туры дигәне әлеге дә баягы биек таулар арасыннан, итәгеннән узган бормалы-бормалы юллар икән.

Автобус тауларга карап барганда, Рәгыйдәнең йөрәге кысылгандай булды. Ул һава җитмәгән шикелле күлмәк изүенең сәдәфләрен чишеп җибәрде. Тирән ермаклар, төпкелләр-упкыннар яныннан узганда, аска түгел, күккә карарга да курыкты. Төнен дә башкалар кебек йокламады, ятлаган догаларын укып барды. Тарлавыкларны кичкәнне аңлагач, инде таң беленгәндә, анда да ташларга баскан һәйкәл-кәҗәләрне, боланнарны карар өчен генә, автобус тәрәзәсенең пәрдәсен җыерды.

Чок-Талга җитәрәк Буранбай уйланып торды-торды да әйдә булмаса, без башта Чолпон-Атага юл тотыйк, андагы туганнарга тукталыйк әле, диде. Монда яңадан әйләнеп килербез. Анда баргач, безгә эш табуы җиңелрәк булмасмы? Калган ара өчен өстәвен бирделәр дә алга таба киттеләр.

Буранбай, Ефәк Юлын су юллары белән төрле тарафларга тоташтырган Чолпон-Ата[12] безнең гасыргача ук салынган, ди. Шәһәрнең борынгылыгы, кәрван-сарайларның күплеге күзгә ташлана шул. Мондагы Төбәк музеенда Ыссык-күл төбеннән табылган әллә ни кадәр хани заман ядкарьләре саклана, имеш.

Чолпон-Ата Йолдызлар Атасы кебегрәк аңлашыла. Кыргызларда «Ата» сүзе белән күпме исем бар! Без таң атканда, Чулпан йолдызны эзлибез, аңа карап, җырлар җырлыйбыз, сагышланабыз, аны – гүзәл кызга, гүзәл

[12] Чолпон-Ата – Чулпан-Ата.

кызны аның үзенә тиңлибез. Бу атама башта бик үк ошамады Рәгыйдәгә. Бераздан ул фикереннән кире кайтты, Йолдызларның йолдызы дип тә аңларга була бит аны, дип уйлады. Рәгыйдә Буранбай белән танышканнан соң, кыргызның һәрнәрсәсен – татарныкына, урысныкына янәшә куярга гадәтләнде, бигрәк тә сүзләрне.

Буранбай, борынгы ташлар Чолпон-Ата янында да бик күп, ди. Сугыш, бәйрәм, хайван рәсемнәре төшерелгән кырык ике таштан торган урынны «Ташлар бакчасы» дип йөртәләр икән.

– Бездә гөлләр, алмагач бакчасы була торган иде, сездә ташларныкы икән, – диде аңа Рәгыйдә.

– Ташлар бакчасында һәрвакыт башлар бакчасы...

Хак сүз.

Чолпон-Атага алар, юлда туктый-туктый барып, сәгать унберләр тирәсендә генә килеп җиттеләр. Автобустан төшкәннән соң, Рәгыйдә бөтенләй ят якларга яшәп калырга килгәнен ныклап торып аңлады. Якын да, ерак та кебек иде аңа мондагы йөзләре җилләрдән ярылган, кояштан каралган кешеләр. Кыргызлар аңа үзләренә караганда акрынрак яшиләрдер, ашыкмый-кабаланмыйдыр кебек тоелды. Менә алар Буранбай белән кызу-кызу атлап бара торгач, яхшы гына хуҗалык каршында туктадылар.

Буранбай белән Рәгыйдә каршында, капкадан керүгә үк, бик матур манзара ачылды. Йөзем тәлгәшләре белән уратып алынган беседка, өрек, шәфталу, алма агачлары, карлыган куаклары... Алар яныннан агып узган чиста сулы арык. Буранбай аны ярык дип атый. Рәгыйдә элек әлеге сүз ары китүне аңлата дип уйлый иде, хәзер ничек килеп чыкканлыгын белде. Борынгылык нык сакланган кыргыз теле бик күп сүзләрнең килеп чыгышын аңларга ярдәм итте аңа.

Арык буендагы беседкада ял итүләре үзе бер күңелледер. Аңа якын гына тандыр. Тирә-юнендәге скамьяларга, өстәлләргә чиләге, казаны каплап куелган, киң яссы табакларга яшелчәләр юып киптерелергә салынган. Читән белән бүленгән җирдә күркәләр гөр-гөр килә. Аларының башы гына күренә. Якынрак килеп карады: сосар белән үрдәкләрнең караватсиртмәләрен тарттырып ясалган йортларында ризык ашаган чаклары.

Өй ягына борылды. Стеналары акшарланган йортның тәрәзәләреннән яхшы җиһазлар күренеп тора. Монысы әллә кунак өеме? Яшелчә, җиләк-җимеш үстерсәләр дә, шәһәрчә, заманча яшиләр, ахрысы. Йөзем ботаклары өлгергән тәлгәшләр болдыр түбәсеннән матур итеп асылынырлык үрелдерелгән. Баскыч төбендәге савытларда роза чәчәкләре утыра. Аларны якындагы гына куаклыктан кискәннәрдер – чәчәкләре шуныкына охшаган.

Рәгыйдә, иң әчкәрге йорт ишегенә Буранбай артыннан әкрен генә атлый-атлый, һаман ишегалдын күзәтте. Әллә ишегалды, әллә бакча, әллә ял итә торган дача кебегрәк бер җир иде бу. Кыргызларның шәһәрдәгеләре нинди яхшы өйләрдә тора икән.

Рәгыйдә, тукталып, артына карап, ишегалды күренешләренә сокланып торганда, Буранбай тавышы килде:

– Ананайын![13]

Борылды. Йорттан башына үзләренчәрәк итеп, ак яулык ураган бер хатын чыккан иде. Башта үзләренчә Буранбай белән күрешкәч, иң көткән кешесен күргәндәй, шуңа бик сөенгәндәй, Рәгыйдәгә елмайды:

[13] Ананайын – бик яраткан кешегә «кадерлем минем» рәвешендәге эндәшү сүзе.

– Кандайча келип калдыңыз? Аман-эсенбе, киленүн?[14]

Хатын Рәгыйдәнең яңакларына үз битләрен тидереп алып кочаклагандай итте. Яшь килен бик кыенсынды, ул ике куллап, әссәламегаләйкемләп күрешергә гадәтләнгән. Буранбай олылар янында тыйнаклык сакларга, алар ни эшләсә, син шуңа риза булып торырга кирәклеген кисәткән иде.

Рәгыйдә йорттан чыгып, биткә бит куеп исәнләшкән хатынга, сөендерер өчен, булдырган кадәрле кыргызча җавап бирде:

– Абдан жакшы. Саламатсыздарбы? Кандай турасыз?[15]

– Кудайга шүгүр, эптеп кыбырап жүрөмүн![16]

– Абай кандай тура? Асылбубуда иштер кандай?[17] – дип, сүзгә катышты Буранбай.

– Асылбубу – сонун. Абай ар дайым эле оору...[18]

– Куйчы! Бигрәк озак авырды инде, җәйгә чыксам, терелер идем, дип калган иде, – дигән булды Буранбай, Рәгыйдәгә дә сөйләшү җиңелрәк булсын өчен.

– Кандай аракет кылса да, баарыбир эч нерсе чыкпай жатат. Киленүн, бир туугандарың барбы?[19]

– Алла хәрәкәт иткәнгә бәрәкәт бирермен, дигән, бер терелми калмас, – дип тынычландыргандай итенде Рәгыйдә. – Апа-сеңелләрем, абыем бар. Килә алмадылар. Ерак бит. Баарысы салам айттырды[20].

Хатын, ишекне киң ачып, йортка чакырды. Түренә күп итеп түшәкләр-ястыклар өелгән бер бүлмәгә килеп керделәр. Әйберләрен шунда куйдылар да икенчесенә уздылар. Монда зур итеп табын әзерләнгән, әмма ул табын кырында һичкем юк иде. Димәк, әле барысы да – эштә. Рәгыйдә, сүзсез тормас өчен:

– Чолпон-Атада абдан ысык экен! Жамгыр эмгиче жок. Каным катып суусадым[21], – дигән булды.

– Мындай күнбе ысык? Аба ырайы уламдан-улам жакшы[22].

Буранбай көлде. Рәгыйдә өчен генә эссе иде мондый җәй. Апасы әнә, һава торган саен яхшыра, ди. Бәхеткә инде бу көннәрнең матур торуы, яңа пар бәхетенә. Иртәгә Буранбай рәхәтләнеп, туйганчы Ыссык-Көлдә су коеныр йә яшь бичәсе белән тауларга киек атарга китәр...

Рәгыйдә кыргыз якларына шултиклем дә ияләнермен дип уйламаган иде. Ай дигәндә, авыррак, читрәк сүзләрне исендә калдырмаса да, көн дә ишеткәннәрен кушып, гел аларча аралаша башлады. Кыргызча белү аңа бик кирәк иде, кайда да булса эшкә урнашыйм, дисәң, урысча аңлаучы аз, үз телләрендә сөйләшүеңне телиләр.

Буранбай белән тормышлары авыр барырга охшамаган. Аның болай да тауларда маллары булган. Карап торучысы да бар икән. Терлекнең саны туйдан соң тагын да артты. Апалары, үзегез теләмәгәч, «уйлонуу туй» ясамасак та, гадәтен китерик дигән булып, кечерәк кенә мәҗлес оештырдылар. Туганнары үзара берләшеп, һәрберсен тугыздан – атын да, сыерын да, сарыгын да тиешенчә бирделәр, Рәгыйдәгә алтын муенса, алка

[14] Ничек килдегез? Иминлек-исәнлекме, килен?
[15] Бик яхшы. Исәнмесез? Ничек яшисез?
[16] Ходайга шөкер, әкренгә кыбыртап йөрим.
[17] Абай ничек тора? Асылбубуның эшләре ничек?
[18] Асылбубуның бер дигән. Абай һәрдаим авырый гына...
[19] Ничек кенә тырышса да, барыбер һичнәрсә килеп чыкмый. Килен, бертуганнарың бармы?
[20] Барысы сәлам әйтергә кушты.
[21] Чулпан-Атада бик эссе икән. Яңгыр яуганы юк. Каным катып сусадым.
[22] Мондый көн эссеме? Һава торышы яхшырганнан-яхшыра.

кебек нәрсәләр бүләк иттеләр. Ул бу ерак арага артык әйбер күтәреп йөрмәде, йорт хуҗаларына бирердәйләрен, якынракларга таратырдайларын гына алды. Үзләрендә аның төрледән-төрле әйбере дә юк, кибет киштәләре буш иде. Яшәп китә алсак, берсеннән дә бүләкне кызганмам дип, күңеленә беркетте.

Буранбайның Чолпон-Атада таныш кибетчеләре күп булып чыкты. Килен бүләген тегендә-монда кунакка барыр алдыннан шулардан сатып алдылар. Әле дә ярый, Рәгыйдә әнисенә җибәреп торса да, үзенә дә кирәк кадәресе мая туплаган иде. Татарстанда гомер ахырынача җитәр кебек акча ыру-карендәш күңелен күрүгә китте дә бетте.

Яшь кияү белән киленнең бу җәйләре-көзләре кунакка,ауга, балыкка йөреп узар кебек. Бүләккә китерелгән малларны көтүгә кушарга барганда, Буранбай аны үзе белән алды. Тау елгаларын, тарлавыкларны югарыдан күрерсең, диде. Атка атланып, Чон-Кәмин елгаларына кадәр барып җиттеләр. Буранбай хатынының яшьрәк чагында атта йөргәнен белми иде. Гаҗәпләнде дә, сөенде дә.

– Атларга бер кеше җиңелрәк килер, югыйсә сине кочагымда алып барырга уйлаган идем,– диде.

Кыргыз ягы бик тә ошаган иде Рәгыйдәгә. Торырга урыннары да булгач, мәңге шунда гына яшәрләр кебек иде. Тауларга менеп, суларда йөзеп. Кайтуларына озак та булмады, Буранбай авырый башлады. Шахта корымына да чыдаган үпкәсе тауның сирәк һавасына түзмәде. Рәгыйдәгә дә юньле эш табылмады. Ул монда да авыл кешесе тормышының җиңел түгеллеген, һаман кысынкылык белән яшәвен аңлады. Әллә тагын бәхетне бер сынап карыйкмы, дип, Чиләбегә вербовка белән язылып китәргә булдылар.

Рәгыйдә тиз арада юлга хәзерләнә башлады. Буранбай ул якта әйбер табу кыен булганга, әллә никадәр кием сатып алган. Рәгыйдәгә дигәннәре арасында бәрхет, панбәрхет күлмәкләр дә бар.

– Их Бешәм, Буранбаем, хатын-кызның бәхете бәрхеттә генә булса, бүген миннән дә бәхетле кеше булмас иде, – диде Рәгыйдә.

– Син минем белән бәхетсезмени соң?!

– Юк анысы. Сәламәтлегең өчен кайгырам. Чиләбесендә дә заводта эшлисе бит аның. Үзе дә тимер-томыр кебек соры, җылы кирәктә – салкын, салкын теләгәндә – мунчадай кызучан шәһәр.

– Шахтага төшәсе түгел. Без эшлисе заводның яхшы атлары бар икән. Мин фермасына ат караучы булып керергә уйлап торам.

Рәгыйдәләр Чиләбедә озак яши алмады. Буранбае мал арасында гына йөрсә дә, үпкәләре андагы һавага да чыдарлык түгел иде. Аптыраганнан, танышлар, туганнар шунда күп калды дип, Кизелга да барып чыктылар. Монда эшләү шартлары бик кирегә киткән иде, җитмәсә, шәһәре дә бу юлы чит, шыксыз тоелды. Күңелләре, күзләре дала хөрлекләренә, тау биеклекләренә, әле тыныч, әле дулкынланып яткан Ыссык-күлгә иямләнгән иде. Алар яңадан кайчан гына башка кайтмас кебек хушлашкан туфракка юл тоттылар. Инде, киләчәккә планнар корып, баш ватып та тормадылар. Буранбай кайтуга аучылыгына кереште, Рәгыйдә колхозда эшли башлады.

Тормышлары бер алган эздән генә барса да, начар түгел, яхшы гына буласы иде. Финанс министрлыгының әллә төп башлыгы, әллә шуның ярдәмчесе татар икән. Буранбайның танышлыгы бар, имеш. Аның янына дип киткән иде, шул кеше аларга Чолпон-Атадан йорт алырга, инде дә дуслар-туганнар Чок-Талда

дисәләр, «Нур» пансионатына эшкә урнашырга киңәш иткән. Чәчәкләр үстерүче агроном кирәк, бик матур йорты да бар, дигән. Рәгыйдәгә бу тәкъдим ошады. Әтисе, яманнар кулыннан тартып алганчы, бакчачылык белән шөгыльләнде, бу аның эшен дәвам итү кебек тоелды да, шунда ук ризалык бирде. Ул соңга калдым дип тә тормыйча, Кыргызстанга килгәч, авыл хуҗалыгы техникумында читтән торып белем алган иде, катыргыларны файдаланырга да җай чыкты, дип сөенде.

Агрономга ял йортында эш җитәрлек икән. Бакчаны кышка әзерлисе, язда утыртасы чәчәкләрнең орлыкларын, суганчаларын, тамырларын алдан ук кайгыртасы, ял йорты урнашкан территорияне ныклап өйрәнәсе бар иде Рәгыйдәнең. Ул эшне пансионат бакчасының схемасын төзүдән, түтәлләр урнашкан тәртипне өйрәнүдән, алардагы чәчәк төрләрен барлаудан башлады. Их, «Нур»ны күңеле яткан гөлләр иленә әверелдерсә!

Көзгә авышкан чак ялның бәрхет чоры икән. Ыссык-Күлнең сулары әле җылы, кояшы эссе, яр буйларын, пляжларны кеше йокыдан торганчы ук җылытып куя. Ыссык-күлгә кереп торган бер пирс бар. Кичләрен, эшен тәмамлагач, Рәгыйдә анда барып, диңгез өстен күзәтә. Әйе, әйе, аңа ул күл буенда түгелдер, тирән сулы, дөньяның башка якларына да алып чыга торган диңгез буйларында басып торадыр шикелле. Шунысы хак: бу сулар, тауларның түбәсеннән төрле якларга карап аккан кар елгалары аны беркайчан да туган якларына илтә алмый. Якын булса да торган җир, сагындыра туган җир, дигәннәре шушы була торгандыр. Ул, шул каршы як ярлары да күренмәгән күл офыгына карап, һаман бер җыр суза:

Йөгереп китәрдәй булам да,
Кайтып җитәрдәй булам.

Буранбай кыргыз ягына әйләнеп кайткач та, беркая эшкә урнашмады. Пансионат тирәсендә кешеләрне фотога төшереп көн күрүне сайлады. Аның гел янында булуы Рәгыйдәгә дә ошый иде. Вакыт-вакыт һаман даауга чыккалый иде әле Буранбай. Беркөнне ялгыз ядрәгә уникe борчун күтәреп кайтып кергәч, Рәгыйдә үз күзләренә үзе ышанмады.

– Чәрдәкләнә торган пуля белән аттым, – диде Буранбай. – Моның өчен очып барган кыр үрдәкләренең нәкъ уртасына төбәргә кирәк.

Бәлки, ул кошлар аның туган ягыннан килгәннәрдер... Алай да Рәгыйдә бу фикеренә күңелендә урын бирергә тырышмады. Әнисе, малны кызгансаң, ите харамнан китә, дип әйтә торган иде... Алар Буранбай тапкан киек итен бик тә яратып ашыйлар бит. Уф... Аеруча кояш баешларында дулкыннар тигезләнә башлаган күлнең пирсы өстендә моңаеп торганда-утырганда гына шушылай уйлата ул. Үз кардәшең, үз кавемдәшең янында булмаганда, туган ягыңда бала чыгарган, тән үстергән үрдәк тә ырудашыңа әйләнә.

Рәгыйдә үз күңелен ышандырырга теләгәндәй, берничә мәртәбә:

– Мында мага жакшы. Мында мага жакшы. Монда миңа яхшы, – дип кабатлады.

2

Рәгыйдә тора-бара кыргызның гадәтләренә дә, теленә дә тәмам күнде, инде үзен гомер бакый таулар илендә яшәгән кебек хис итә башлады, туган ягына хатларны да атна саен язмады, сирәгәйтте, кайчандыр конвертка тулмастай битләрнең дә санын киметте.

Көннәрнең берендә, Буранбай гадәттәгедән дә шатрак күңел белән кайтып

керде. Тиз уйлаучан да кеше инде үзе! Көтмәгәндә-нитмәгәндә, Фрунзега барган җиреннән, Рәгыйдәнең туганнарын күреп килергә дип, сорап-нитеп, киңәшеп тә тормыйча, билетлар сатып алган. Аптырабрак калган хатынына:

– Көзен йә кышын да алып кайтмасам, җәй бармыйбыз да бармыйбыз бит анда. Син китсәң, яңа утырткан чәчәкләрең нишләр? Инде болай да бакчаң рәткә килгәнче, ни көттек, түздек, – диде.

Чыннан да, эш арасында сагынуыңның җетелеге кимесә дә, онытылгандай булса да, җырлый башласаң, шул яклар хакында телевизордан кино карасаң, йөрәкне әчеттерми калмый. Буранбай да, барып килик, дип торганда, нигә әле ризалашмаска?! Рәгыйдә шул көнне үк әйберләрен төйни башлады. Пансионатта бәрхет сезоны тәмамланып килә иде инде. Хәзер Буранбай белән Рәгыйдәдән башка Ыссык-Күлдә су коенган кеше дә юк. Октябрьның көндезге җылылары төнгә кергәч тарала да бетә. Бакча агачларында җимеш калмаган, үләннәр саргаешкан, бар нәрсәгә көз төсе кергән. Чәчәкләрне кышка әзерләрлек вакыт алда бар әле.

Буранбай кайтыйк-кайтыйк, дисә дә, әйберләр җыелып беткәч, кичкә таба күңелсезләнеп калды, алай да моны сиздермәскә тырышты сымак. Чемоданнарын китәргә хәзерләп йөргән хатынын күзәтеп торды-торды да, билдәмчәсен[23] чишеп торган чагында артыннан килеп, сөякләрен кузгатырдай кочты. Нидер аңлатырга теләп, бик яратканлыгын белдереп кочу кебек иде бу, әмма ул һични әйтмәде, киресенчә, әйтер сүзем юк, дигәндәй, Рәгыйдәнең җилкәсенә ияге белән терәлде. Хатын, шаярып кузгалып киткән иде, моны көтмәгән Буранбай чүт кенә егылмый калды. Шулчак апалары фатиха билгесе итеп яптырган ак шарф башыннан сыпырылып төште дә, Рәгыйдәнең кап-кара чәчләре көн яктысына чыкты.

Буранбай ул өс-башын рәтләгәндә, тагын бер читкә китте, тагын томырылып, аңа карап тора башлады. Матур да иде соң аның бишәсе[24], татар хатыны! Нечкә билле, төз аяклы, туры тотышлы гәүдәле. Билдән толымнарын баш түбәсенә өеп куйган да үзе, яшь кыргыз киленнәредәй, шарфны кат-кат урап, очларын маңгай якта бәйләгән.

Ул турыда кычкырып әйтмәсә дә, хатынының туган җиренә баргач, күңеле үзгәрер дә, калам дип әйтер дип курка иде Буранбай. Мондый чибәркәйгә, уңганга, ир хатыны булган дип тормаслар, татар арасында да мең егет табылыр. Инде үз илендә тормышлары җайланды дип кенә торганда, хатынны югалтасы килми иде ирнең.

Әле бит Рәгыйдәнең бала булмауны сылтау итеп тә анасы йортында калуы бар... Буранбайның бу уе тагын йөрәген китереп кысты. Күпме тапкыр нәзерләр итеп – угыл димәм, кыз димәм, дөньяга китерешкән Киндик-энегә дә, баланы исән-имин саклап калган Җир Алиһәсе Умай-энегә дә бүләкне мулдан бирермен, дигәне бар... Буранбай, шаяртканга гына салынып, Рәгыйдәнең кармак бавын тартты:

– Син минем белән кире кайтырга исәп тотасыңдыр бит, кызый?

– Мин сине никадәр көттем, көтә-көтә көтек булдым, инде тапкач кына, ташлап калдырыр, башкаларга бирер, дисеңме?!

– Рәхмә-ә-әт.

– Тагын бер җанны эретә торган сүз әйт әле, Буранбай.

[23] Билдәмчә – билбау.
[24] Бишә – бичә.

– Менин сүйгөн шабдалым сен!

– Син менә шәфталу сөясең икән, ә мин алма яратам. Әчкелтем тәмлесен, сусылын, теләсә кемнең теше үтә алмаганын.

Буранбай хатынын кочагына алды да тын калды. Аңа болай бер-берләренә сыенышып торудан бик рәхәт иде. Рәгыйдә дә дәшмәде. Алар икесе дә шул көнге тормышларын уйлый иде бугай.

Буранбай белән көн итү җиңел иде. Әнә бит матур сүзне дә кызганмый: сөекле шәфталуым дип кенә тора. Кыргызның теле үзенчәрәк, бу якның һава торышы кебегрәк: кирәк чагында кырыс, икенче бер вакытта – татлы. Үзе белән яшәгән өчен генә кайсы татар ире рәхмәтен әйтер?! Буранбай менә көн дә әйтә. Шулай ди дә Рәгыйдә, татар белән яшәп карамаган бит әле. Әтисе, әнә, бик йомшак кеше иде, авыр сүзне түгел, ныгын да кирәк чагында да чит-ятларга үткәзеп әйтергә кыенсына торган. Әнисенә дә, туганнарына да чырае һәрчак якты иде аның. Хикмәт милләттә генә түгелдер. Кешене авырлыклар кырыслата, сүзсез итә, хәсрәтен йөзенә чыгара. Кемнедер сындыра. Кемнедер явызлата йә ялагай итә. Татар соң тормышның җиңелен күргәнме?..

Буранбай белән бик яхшы. Нигә соң, михнәттә яшәтсә дә, авылы шулкадәрле сагындыра? Тора да анда калган әнисе, туганнары турында уйлый ул. Бер рәхәтләнеп, алар белән татарча сөйләшәсе, татар арасында буласы килә аның. Атнага бер сәгать, айга бер көн...

Тауларны кичүләр, поездда барулар Рәгыйдәдә узган көннәрне, яшьлек хатирәләрен бөтен җетелеге белән яңартты, гаиләгә бәйле хыялларын исенә төшерде. Шунда ук, балабыз юк, дигән уй күңелен сыкратып алды. Тормышны алып барса да, кыргыз иренең бәхете ир балада, дигән Буранбай бервакытта да әти буласы түгел микәнни соң?! Әллә шәһәргә барып, тикшеренеп, табиблардан шуны белгәч, күңелемне басармын дип, аның якларына кунакка кайтырга дигән фикергә килдеме ул?

Рәгыйдәгә иптәш кызы, Хафиз да авылга кайтты, дип язган иде. Буранбайның кискән тырнагына да тормаган ир кирәкмени аңа?! Төкерә ул дөнья бозыкларына! Хафиз, төньяк утрауларында үләргә ярамый, җир каты, кешене казып күмү – мөмкин булмас бер эш, үләр өчен генә кайттым, дип шаярткан булып йөргән, имеш. Чынлыкта авылдашлары эшләгән шахта ябылган инде. Бергә торыйк әле дип, ирле хатынга, җитмәсә, кеше аркылы әйттереп, тагын рәнҗетте Рәгыйдәне Хафиз... Оныттым дигән саен, үзен искә төшерергә тырышкан бер үҗәт булды ул да. Колхоз тормышын уйласа да, болай да күңеленә килми калмый бит ул аның!

Соңгы вакытларда Буранбай тагын да күбрәк җырлый, күбрәк моңая башлады. Өйләрендә инде кумызның ничә төре булса да, теге агачтан ясап карый, монысыннан, һичкайсының тавышын ошатмый. Мин әле үземнеке дип әйтерлекне ясамадым, үз тавышымны да тапмадым, мин әле үземнән соң башка бер нәрсә дә калдырмадым, ди. Нигәдер, аткан кыргавылларын[25] җиренә җиткереп киптереп, карачкы ясаудан туктады, ауга йөрүен дә сирәгәйтте. Кошларны кызганам, кызгансаң, ите хәрәмнән китә, дисең бит, дип акланырга гадәтләнде. Эте Кызыл Тайлак белән кайвакыт кырларны, тауларны болай гына әйләнгәлиләр. Кулына тау чәчәкләре тотып кайта:

– Монысы син үстергәннәрдән дә матуррак, синең кебек гүзәл.

Матур. Аларын саклап кына булмый. Тауларның салкынына, җиленә,

[25] Кыргавыл – фазан.

даланың эссесенә чыдаган гөлләр вазага салуга шиңә. Икенче көнне үк чыгарып ташлыйсы була. Озаграк торганнары сирәк.

– Су эчендә дә үскән гөлләр бар, өйдә бер көндә матурлыклары югала, – ди Буранбай.

– Туфракларыннан өзелгәнгә ул, җаным.

– Су гөленең – суда, тауныкының тауда үсүе яхшы шул.

– Вазадагы чәчәкне соңгы сулышларын алган кешегә охшатам. Якыннарының яшәтәсе килә, ни генә эшләмиләр. Ул инде өзелгәнлеген, барыбер күзләрен йомасын аңлый.

– Чагыштырсаң чагыштырасың инде.

– Ә син ничек уйлыйсың?

Буранбай җавап бирмәде. Рәгыйдәсен туган туфрагыннан, тамырыннан өзеп алып киткәндәй хис итте ул үзен. Ничек моңарчы шулай икәнлеге башына да килмәгән? Кайда яшәүләрен Рәгыйдә ирегенә куйган иде ул. Җылы якта да яшәп карыйсым килә, диде хатыны. Чын күңелдән әйтте микән? Әллә аңа ярарга тырышып, аны кайгыртып кынамы? Рәгыйдә һаман этне уйлый икән әле:

– Кызыл да аучылыгын онытып бетерерме инде, Буранбай?

– Бетермәс, кечкенәдән өйрәтсәң, хайванның канына сеңә ул.

Рәгыйдә этне үзләренчә, кыскартып, Кызыл дип кенә йөртә. Аның, тайлагы да шул ук ау эте – тайган дигән сүз. Этне эт дип атау бу, дип аптыраганына каршы Буранбай шундыйрак бер хикәят сөйләде Рәгыйдәгә.

Кыргыз халкы, риваятьләргә караганда, кызыл тайлактан килеп чыккан. Бу турыда «Кырык кыз»да язылган икән. Аны инде Буранбае яттан белә. Хан кызы иптәшләре белән Ыссык-Күл буенда йөргәндә, ярдан ак күбекне татып караганнар да көмәнле булганнар, имеш. Ак көбөк дигәне ак этне белдерә икән. Рәгыйдә шунда ук татарларның «Ак Бүре» әкиятен исенә төшерде, чынлыкта никадәр уртак әйбер бар безнең, уртак ышанулар, дип сөенде. Шулай, төс-кыяфәт белән генә бераз аерылган бер үк халыктыр инде ул – нугае да, казагы да... Салкын якларда яшәгән татары да, үз җирләрен һаман да атта кичкән, тауларны өе иткән кыргызы да...

Кыргызстанга барганда да, болай ук ялыктырмаган кебек иде, Кукмарага кайтып җиткәнче, Рәгыйдә тәмам йончыды. Шунысы яхшы булды: Туеш тукталышында төнгә кадәр тормадылар. Ишегенә «Таң» дип язылган машина кибет янына туктагач, Рәгыйдә шунда таба бара башлауга ук, шофёры үзе каршысына атлады. Килеп җитеп исәнләшкәч, әйберләрегез янына бара торыгыз, хәзер чыгам дип, кибеткә кереп китте. Бераздан аның сеткада берничә ипи күтәреп килгәне күренде. Шофёр кабинасына утырды да, машинасын борып, олы юлга чыгарды һәм аларның сумкалары өелеп торган җиргә үк китереп туктатты. Ул да булмады, чыгып, әйберләрен кузовка атарга тотынды:

– Зәмнихатти сөенер инде, – диде. – Хәлләрегез ничек, Буранбай агай, Рәгыйдә апа?

Кара син бу яшь кенә шофёрны, Буранбай аны бер дә хәтерләми, ул менә таный булып чыкты. Сәгать буе авыл хәлләрен сөйләшеп кайттылар. Вакыт узганы сизелмәде дә. Авылның урта тирәсендәрәк, ындыр турына җиткәч, басу юлында төшеп калдылар да колхоз абзарлары янына чыгарылган тирес өемнәре өстеннән Рәгыйдәнең апаларына таба юнәлделәр. Әллә ничә ел яткан саламлы-тизәкле ат тиресе булса да, батып китүең дә ихтимал иде.

Туры юл дип, әйбер күтәреп, болай азапланып барганнарына Буранбай бик аптырады. Рәгыйдә, монысы кияү сынау, дип көлде.

Агач коймалар белән әйләндереп алынган зур бакча киртәсеннән узып, сукмак буйлап абзар артына төшеп киттеләр. Бакчаларда бәрәңге алынган, печәннәр чабылган, сукмакларда тигезләп өеп куелган бәрәңге сабаклары гына бар. Искесен түккәч, яңа тирес астына салырга дип калдырганнар бугай, дип уйлады Рәгыйдә.

Күктән көтмәгәндә төшкән кебек кунаклар инде күпертеп, йомшатып куелган түтәллекләрне үткәч, кышкы йорт чоланының бакча ягындагы ишегенә килделәр. Ул эчтән бикләнмәгән иде, һичкем ишетмәсен, бер сюрприз булыйк, дигәндәй, әйберләрен бер кырыйга куйганнан соң, әкрен генә басып, өйалдына керделәр, өйгә – кеше юк иде. Уеннары барып чыкмады.

Барысы да икенче өйдә чәй өстәле артына җыйналышкан икән. Тәрәзәдән Рәгыйдә белән Буранбайның ишегалдында йөргәннәрен күреп, атылышып чыктылар да ай-вайлап, табынга дәшә башладылар. Буынга төшеп кыстасалар да, кунаклар кереп тормады. Рәгыйдә, әниләрен күрмичә, майабыстайларында ашап-эчеп утыру килешмәс дип уйлады. Сәламләшкәннән соң, Буранбай белән, әйберләрен күтәреп, Түбән урамга киттеләр.

Көзнең матур көннәре иде. Әбиләр чуагы. Урам тутырып, пәрәвез оча. Кояш әллә нинди бер ярсу белән җылыткандай. Югыйсә соң гына чыккан, җирне озаклап кына җылыткан инде ул, әмма бер кыздыра башлагач кыздыра! Ноябрь җиткәндә, мондый көннәр торуы яхшы инде ул. Җылы көздә бәрәңгесен дә вакытында аласың, ашлыгың да киптерелеп, амбарларга керә, каз-үрдәкләрең дә салкыннаргача симереп өлгерә.

Зәмниха карчык та, Камил дә, бәхетләренә, өйдә булып чыкты. Камил һаман утын яруда икән, дип көлемсерәде Буранбай ишегалдына узганда, кырыйда яткан ярылып бетмәгән утын өеменә карап. Рәгыйдә иртәрәк эштән китә алса, бакчалар казылганчы кайтасы да югыйсә. Пансионатта ял итүчеләр күп чакта аны кем җибәрсен... Буранбай, өйалды ишеген ачып, Рәгыйдәне алдан уздыруы булды, Камил йөгереп чыгып, апасын да узып, аның муенына атылды:

– Исәнме, Кызык Җизни!

Ул арада әнкә кеше дә чыккан. Яулык почмагын җыеп, дулкынлангандай бөтерә-бөтерә, ялгыш күренәләр мәллә дигәндәй, кызы белән киявенә карап тора.

Рәгыйдә сабырлык белән генә:

– Исәнме, әнәй, – дип, ике куллап күреште дә Буранбайга юл бирде. – Әйдә, инде син исәнләш.

Малайны муеныннан төшермәгән килеш кенә, Буранбай әбисе белән күреште. И-и, бу татарларны, шушы кыланышларына һич кенә дә ияләнерлек түгел, дип фикер йөртте ул эченнән беренче кайткандагы кебек, әнкә белән кызның икесенең дә күзендә яшь тора, тыныч кына елмаешып карашкан булалар. Нинди тыйнаклык бу?! Әллә соң сөтен имезеп үстергән анага изге зат итеп карауммы?

Зәмниха карчык, аңына килгән кебек булгач:

– Улым, төш җизнәңнән, күреш апаң белән, әйдәгез, өйгә узыйк. Бик вакытлы кайттыгыз әле, самавырны яңарткан гына чагым, – диде.

Кар кебек акшарланган мич буенда, озын муенын үзенә махсус ясалган төнлеккә сузып, самавыр җырлап утыра. Янындагы кәрҗиннәрдә, ягылырга чират көтеп, эп-эре нарат күркәләре ята.

– Әнәй, син һаман күркә чәе генә эчәсең икән, – дип куйды Рәгыйдә.

– Мин аны шундый сагындым! Тамагыма карлы тау башларыннан агып төшкән елгаларның сулары үтми башлаган иде инде.

Кара син аны, Рәгыйдәне! Чәй эчә башласалар, чынаяк санын белмиләр, монда кайткач, ни дип тора?! Шулкадәр дә сагынгач, әйдә кайтыйк, бәгърем, дип кенә әйтәсе югыйсә...

– Ие шул. Күркә чәе үзенчә тәмдә була. Күмер белән кайнатканы үзенчә. Бәләкәй чәйнектә пешергән белән зур чәйнектә пешергән кара чәй дә аерыла бит, шуңа күрә самавыр башына уймак шикеллесен генә куям. Менә, кайтырыгызны белгән шикелле, хушисле сәйлүнскине салдым, Әхмәтгали абыең Донбасстан җибәргәнне.

– Аның хәлләре ничек, әнәй?

– Ничек булсын? Авырый инде, авырый.

– Һаман да авырыр микәнни?

– Кырык градуслык суыкта эчке күлмәк-ыштаннан концлагерь дигән дошман өтермәненнән кач та. Шул чакта аяклары беткән дә инде аның. Берзаман күреп алып, артыннан немечләр атып килә, ди, безнекеләр ягына чыктым, дигәндә, алары атарга тотынган. Аннан, тегеләреннән дә, боларыннан да кача-чаба торгач, аңсызланып егылган. Рубеж дигәннәре нәрсәдер, шуннан табып алдылар, дип сөйләде әле соңгы кайткач та. Алай да исән калган балакаем.

– Ие, абый күрәсен күрде инде...

– Туган илендә яшәмәскә дип, закунын чыгарганнар, шул илгә эшләргә ярамый, дигәнен юк, кияүкәем. Авыру дип тә тормыйча, аягыннан тәмам егылганчы иң кыен, җаваплы урыннарда хезмәт итте. Инде менә, мыскыллаган кебек, бер дә гаебең булмаган икән, дигәннәр. Үз аягында кайта да алмый торган хәлгә килгәч, яшәргә кайтырга да ярый, имеш...

– Никадәр бала үстерсәң дә, берсе дә үзеңнеке булмый, ахрысы. Ирнеке була, мирнеке була. Үлгәннәренә бер төсле кайгырасың, исән калганнары өчен икенче төсле. Нимес концлагеры да бетерә алмаган баламны сәвит закуны бетерде...

– Алай ук хафаланма әле, әнәй...

– Ничек хафаланмыйсың, гөрнәдир кебек ике улымны бирдем бит мин сәвит дигән аждаһага. Берсен милиционерлар бер сәбәпсез атып үтерде – баласы ятим калды, икенчесенә, мылтык атып, үз җирен яклаганына, аяксыз килеш тә илендә яшәргә рөхсәт итмәделәр.

– Тормышы алай начар түгел бит Әхмәтгали абыйның.

– Караватта ятуның тормышлыгы инде аның! Ичмасам, үзе телендә дә сөйләшә алмый бит ул анда! Хатыны – марҗа, малае – урыс...

– Хатыны белән сөйләшә, – диде Рәгыйдә.

– Сөйләшә. «Чәй яса» да «ашарга бир»не әйтә белә...

– Малае ничек урыс? – дип аптырады Буранбай.

– Татарча сөйләшмәгәч, аның татар язылуыннан ни мәгънә? Син кыргыз башың белән кирәк чагында рәхәтләнеп үзебезчә аңлашасың!

– Өйрәнер әле ул да!

– Ай-һай... Әле дә ярый – рәхмәт үзләренә – улымны карыйлар. Аларның монда гаебе юк. Гаеп ул һәрвакыт – өстәгеләрдә.

– Хатлары килеп торадыр бит, әнәй?

– Анысы килә. Посылкасын да ай саен булмаса да, елына әллә ничә

сала. Хат язса, дәфтәр битен тутыра. Ичмасам, рәхәтләнеп бер татарча сөйләшкән кебек була, ди.

– Алла боерса, Камил үссә, шунда җибәреп кайтарыр идем дә бит.

– Тормышларыбыз көйләнеп китте, үзебез бер барып килербез әле, әнәй. Әле моңарчы сезне күрергә дә җай чыкмады.

– Рәхмәт төтүләреңә – елын елга кайтып торалар.

Төтү дигәне Рәгыйдәнең Кизелда яшәп калган уртанчы апасы Хәлимәбану иде.

– Аларның хәлләре ничек? Болай без дә хатлар алышабыз да алышуын.

– Яхшы. Ире әйбәт. Балалары тәртипле. Аныкылар ичмасам татарча сөйләшеп үсә, җәй саен авылга кунакка кайта. Менә Камилгә дә күңелле булып кала.

– Шулай.

– Әхмәтгалиемне сугышка җибәргәндә, исән калса да, фәлән кадәр гомер күрмәссең дисәләр, ышаныр идемме? Алай дигән кешенең башын кулымдагы таяк белән генә ярасы. Инде бит үлгәнче күрәчәгемә дә өмет юк...

– Варвара Семёновна малай белән булса да, күзләренә бер күренеп китәрмен, дип хат язган безгә,– диде Рәгыйдә.

– Нәрсә сөйләшербез аның үзебезчә бер кәлимә җавап кайтармаган Барие белән?! Үзе белән?! Русчаны бөтенләй белмим, дип тә әйтмим, колакка ятышмый хәзер, ишетсәм, аңышмый торам.

– Шулай дигән буласың да, Барие да йөрәк парәсе бит аның.

– Баланың баласы балдан татлы дигәннәре хак анысы. Янымда Камил булганга сөенеп бетә алмыйм. Ул да әнисез, әтисез калмаса, бер оныгымны да сөя аласы түгелмен икән мин картлык көнемдә.

Кинәт карчык туктады, әле кайтып кермәдегез, мин нәрсә сөйләп торам, дип, өстәл тирәсендә кайнаша башлады. Бераздан:

– Пәтәч! Без дога кылырга да оныттык түгелме? – дип сорады.

Соң булса да, уң булсын, дигәндәй, кайсы кая утырыштылар. Зәмниха карчык йортка доганы кычкырып кылды, калганнар эчләреннән кабатлап утырды. Камил дә ике кулы белән йөзен сыпырды да:

– Йә, кая кучтәнәчләрегез? Эссе күл җимешләре, салкын тау чикләвекләре? – диде. – Сез сүз белән генә сыйларга кайткансыз бугай мине!

Барысы да рәхәтләнеп көлде. Бу табында, бу өйдә иң зур кунак Камил иде. Әнисе ташлап калдырган ятим дә булгач, кызганып та, яратып та, бүләкнең иң кыйммәтлесен, киемнең иң матурын, кучтәнәчнең иң тәмлесен аңа алып кайталар. Ул моны бик тиз аңлады һәм кунакны түземсезлек белән көтеп ала башлады.

– Энем, сиңа бер нәрсә дә жәл түгел, – диде Рәгыйдә апасы, аның алдындагы чынаяк тәлинкәсенә дә, өстәл уртасындагы зуррак савытларга да тәм-томнар тезә-тезә. – Менә чәй генә эчик тә, мәктәпкә йөрергә дигән яңа кәчтүм-күлмәкләреңне киеп күрсәтерсең. Җизнәң кыргыз эшләпәсе алып кайткан үзеңә. Җәйге пәлтәң белән икесен бергә кисәң, артыңнан бер кыз да калмый инде!

– Кирәк ие, ди, миңа кызлар. Минем алар белән йөрергә вакыт юк – әбигә булышасым бар.

– И-и, рәхмәт инде, улым! – дип, Зәмнихатти Камилнең башыннан сыпырды. – Син булмасаң, ул утыннарны кем ярыр иде дә, кем миңа чишмә сулары алып кайтыр иде...

– Миңа җизнинең эшләпәсе катырак ошый, – диде бераздан үзенекен карап туйган, салып, чөйгә элгән Камил. – Киеп карыйм әле?

– Мондый биек эшләпәне дәрәҗәле кешеләр генә кия бездә, – дип бирмичә торды Буранбай. – Әле синең зур кеше буласың бар. Шуннан соң таулар кебек биеген алып бирермен үзеңә. Аннан, бөтенләй картайгач, бакал калпак[26] киярсең. Сарыкның койрыгын ашарсың. Яхшы кеше, акыллы кеше, дип сөйләрләр үзең турында.

– Сарык койрыгын яратмыйм мин. Киеп карыйм инде...

– Бала белән бала булма әле, Буранбай, кисен. Койрыкны, мәртәбәле кунак дип, өлкәннәргә бирәләр аны, – диде Рәгыйдә.

– Аңа алайса башын тоттырырлар.

– Баш та ашамыйм мин. Телен генә яратам. Киеп кенә карыйм инде.

Буранбай Камилнең шулай ялынуына түзмәде, салып, малайга бирде:

– Апаң сораса, тыңламас идем, сиңа ярар инде, – дигән булды. – Шуның өчен күзең төшкән кызның исемен әйтерсең.

– Юк, дим бит.

– Бездә аны борын кысып әйттерәләр, – дип көлде Буранбай.

– Борын кыссаң, кунак кызлары чыгар да шуннан танып алырсың, – диде аңа Рәгыйдә.

Малайга эшләпә ошады.

– Нигә кеше калпагын кияргә ярамый, җизни? – дип сорады ул, аны кулында әйләндерә-әйләндерә бизәкләрен карап.

– Эркектин баш кийимин аял кийбейт, ирләрнең баш киемен хатыннар кими, диләр бездә, юкса тормышының бөтен авырлыгын үзенә алачак.

Рәгыйдә әллә нишләп китте. Буранбае яңа калпак сатып алып кайткач, ничектер бер кызыгып китеп, ул өйдә югында киеп, көзгедән карап торган иде үзенә. Килешә иде бик. Бу ышану турында бөтенләй уйламаган да. Тормышы үзенә генә каласы булса, Аллам сакласын.

– Курыкма, Камил, малайларга дигән ырымын белмим, – диде Буранбай, Рәгыйдә йөзенең үзгәргәнен күргәч, энесе өчен борчылганга санап. Биек калпак Камилгә тагын да ныграк килеште. Буранбай уенча, ул, әбисенә охшап, бик матур иде. Җизнәсе аны Рәгыйдәне ратканы өчен дә үз итте.

– Татар балалары барысы да сөйкемле була мәллә, – дип сорады ул Рәгыйдәдән, икенче бер авылдагы кардәшләренә кунакка баргач, яше дә тулмаган сабыйларын күрде дә.

– Ие, бездә кешегә су килешә, – дип үртисе итте Рәгыйдә. – Бездә су тауларның өстеннән туфрак белән, пычрак белән кушылып акмый, астыннан, таш ярып, көмеш төслегә әйләнеп чыга.

Буранбайга тау эшләпәләреннән эрегән су да тәмле. Әллә кайлардан алып килеп, болытлар калдырган бит ул карларны. Кояш эреткән, җилләр этеп төшерергә, таратырга-туздырырга тырышкан, төнге салкыннар саклап калырга маташкан. Югарырак менгән саен, салкынлыгы, бозлыгы арткан суларда Өске елгасыннан парга әйләнгән тамчыларның өлеше дә бардыр. Тауларны яшәртеп, үләннәрне терелтеп аккан сулар, төчерәк тоелса да, ничек тәмсез булсын?! Таулар – әлегә җирдә иң чиста җирләрдер. Тау асларыннан чыкканы да ошый суларның Буранбайга. Һәрберсенең үз тәме. Сусаган чагында суның кайсы да татлы. Кешегә, яшәү өчен, һава белән судан да кирәгрәк ни бар?!

[26] Бакай калпак – алтын җеп белән чигешле, аксакаллар, хөрмәтле кешеләр калпагы.

Җиденче бүлек

Һаваларда гына ла җиз үрдәк

1

Буранбайның күңеле китәр көннәр җитәрәк үзгәрде. Аңа Рәгыйдәнең туганнары арасында рәхәт иде. Бу якның һавасы да үпкәсенә яхшырак килә. Янында Камил бөтерелеп йөри, җизни дә җизни, ди. Бер баласыз үз илеңдә каңгыраганчы, балалар белән чыркылдашып, чит җирдә яшәвең дә яхшырак түгел микән?.. Әллә калырга гына инде?.. Бакча артына чыгып, каршы як тауларына карап уйланып торганнан соң, үзен дә гаҗәпләндереп, кинәттән, калырга, дигән ныклы карарга килде. Өйдәгеләрнең иртәнге чәй эчәргә әзерләнеп йөргән чаклары иде. Өстәл янына утыра-утырышка:

– Калыйк булмаса без монда, Рәгыйдә! – дип әйтә куйды.

Бик тә көтелмәгәнчә килеп чыкты. Көтелмәгәнчә дисә дә, Рәгыйдәнең эченнән генә, Буранбай яңадан монда яшәү турында сүз башласа, ике дә уйламыйм, дип йөргән чаклары иде. Шулай да ул, әйе, дип, кистереп кенә әйтмәде, монда сиңа кыен булмасмы соң, дип сорады.

– Булмас.

– Кышлары да салкын, карлы.

– Кыргызстанда да кыш җылы түгел. Тауларда җәен дә – кыш, түбәләрендә кар ята, төннәрен үзәгеңә төшеп туңдыра.

– Яраткан эшең табылырмы? Пансионатта әле фотога төшерсәң була. Кышын ауга йөрисең.

– Башкача да яшәп карарга исәп! Ауга йөрсәң, монда да төлке белән куян тулган! Хәзер үк мылтыкларның барысын да алып кайтып йөрисе булмас. Аннан күз күрер.

– Ияләнеп китә алсаң. Башка халык гадәтләренә күнегү җиңел, димәс идем.

– Миңа татарныкы ошый.

Буранбайларның авылда калуына иң сөенгәне Камил булгандыр.

– Мине әтисез-әнисез дип кимсеткән малайларның кирәген бирерсең, җизни! – диде ул, шулай буласына нык ышанып.

– Мондый буйлы егетне кем кимсетсен?! – дип аптырады Буранбай.

– Кыйнатып тормыйм ла мин. Үртәгән, көлгән малайларны, дим.

– Аларга да берни әйттермәскә өйрән.

– Барыбер якларсың мине, җизни, яме.

Классташ малайлары, әбисе әйтмешли, көне-төне тырай типкәндә, ул һаман – өй эшендә. Җизнәсе инде аларны Камилгә кушмас, үзе тиз генә эшләп куяр. Җитмәсә:

– Без монда калгач, Камилне үзебезнең карауга гына алырбыз, малаебыз итеп яздырырбыз, – дип тора.

Әти булмаса да, җизни – җизни инде ул! Апасы гел үзенеке!

– Бик яздырыр идең дә, әнисе исән килеш аны кем сиңа бирә?! – диде Рәгыйдә.

– Әби кулына тоттырганнар бит әле.

– Кем тоттырсын, шулай әтисе авылга кайтарган җиреннән яшәп калган инде ул.

Буранбай моңа чиктән тыш гаҗәпләнде. Ул Камилне бөтенләй ятим калганнан соң Зәмниха карчык белән үсә дип уйлый иде. Ни дияргә белмәде.

Сабыйның язмышына һичкем кызыгырлык түгел, сөйләсәң, күздән яшь китерерлек. Рәгыйдә аның хакында шуңа күрә һичкемгә сөйләми дә иде. Инде яраларының әчеттерүе кими генә, дисең, тагын яңарырга җай чыга да тора. Алай да:

– Сен бул жөнүндө уккан жоксуңбу? – дип әйткән булды. Аннан әнисе өчен тәрҗемә итте:– Син бу турыда белми идеңмени соң?

Энесе Галинур, Әхмәтгали абый янында җиңелрәк булыр, эшен дә табар дип, башта Донбасс, Донецк шәһәрләрендә яшәде. Инде әнисе янына кайткач, авылда тормыш итүнең тагын да авыррак икәнлеген күреп, яңадан китәргә булды. Рәгыйдә белән бергәләп Кизел тирәсенә – читкә алдарак чыгып киткән Хәлимәбикә апалары янына барып урнаштылар алар. Баская станциясе тирәсендәге Гремячинск исемле бер шәһәр иде ул. Рәгыйдәнең анда күңеле һич кенә дә ятмады. Бер караңгы тормыштан икенчесенә килеп эләккәндәй булды.

– Бездә бик тырышлар гына яхшы эшли, акчасын да шәп ала, – дигән иде аңа кадрлар бүлегендә документлар кабул итеп утырган кыз. Кайда башкача соң, дип уйлады Рәгыйдә – бөтен җирдә эш атлары кирәк, күпме түләгәннәрен алгач күрербез инде.

Сугыштан соң немец пленныйларын шул якларга китереп тутырганнар, яңа гына ГУЛАГтан котылган үз тоткыннарыбыз да бик күп булган анда. Менә шулардан төзелгән шахтёрлар каласы икән. Моны да белгәч, каядыр куылган кеше, әсирлектә кебек хис итте Рәгыйдә үзен. Авылдан беренче тапкыр чыгып китү авыр ул, аннан читтә яшәүгә ияләнәсең, миңа монда яхшырак, ди иде Галинур. Дөресен сөйләде микән? Апасын тынычландырыр өчен генәме? Ничек кенә булмасын, ул үзен монда килгәч, башкачарак тоткандай, бәхетлерәк сизгәндәй, авылны артык уйламагандай күренде. Ә менә Рәгыйдә пар наратлы Түбән урамны, инеш буйларын, әнисен, аның күркә җылысында кайнаган чәен, бергәләп, уенлыкка йөргән дус-ишләрен бик нык сагынды. Гел шулай булыр дип курка иде, эшкә ныклап кереп киткәч, күңеле басылды, әмма Гремячинскига барыбер ятмады.

Кизелы да сөргендәгеләр, төрмә кешеләре аркасында шәһәргә әйләнгән бер җир иде аның. Кеп-кечкенә шәһәрдә һаман да ундүрт меңгә якын әсир бар, дип сөйлиләр. Алар барып урнашканда, ике тапкыр күбрәк булган ул. Башка посёлокларын да тоткыннар төзегән, имеш. Төрмәләр илендә яшәгән икән Рәгыйдә. Күмер табу кими башлагач, ераклардан килүчеләр әкренләп тарала башлады. Исән булса, Галинурлар да күченеп китәрләр иде аннан...

Әбисе алып калганда, Камил ике айлык кына булганлыгына гаҗәпләнде дә инде Буранбай.

– Нишләгән соң абыең? – дип сорады Рәгыйдәдән Буранбай. – Әйбәтләп сөйләп бир дә, башка аптыратмам.

– Хатыны ир санларга да, бала карарга да теләмәгән аның. Ул эштә вакытта Камилне баскыч төбенә ташлап киткән. Ярый күреп алганнар, исән калган. Абыйның бит эшлисе, улын яшәтәсе бар.

Рәгыйдә сөйлисе килмичәрәк тукталды.

– Шуннан?

– Иртәгесен күтәреп, шахтага килә, авылга булса да кайтарыйм дип, ял сорый. Башта көт әле, хатының табылыр, диләр. Табылмагач, тагын бала

белән килә. Гел кешедән карата алмый бит инде. Эшнең кызуында аңа кем озакка ял бирсен?! Планның да кыскан чагы икән. Ничек тә җаен табарсың әле дип, өч-дүрт көнгә җибәргәннәр.

– Нәрсә ашаткан инде ул аңа юлда?

– Базардан кәҗә сөте сатып алып, аны су белән сыеклата да шешәләргә тутыра, аннан Пермьгә китә. Анда килеп төшсә, Казан ягына билетлар бөтенләй юк икән. Баланы алып кайтмассызмы, түләр идем дип, әле бу, әле теге кешегә әйтеп карый, һичкем алмый. Көне кыса. Кире килеп өлгермәм дип курка. Ахырда товар поездының машинистына бара. Биләүсәдәге баланы кызгангандыр инде, безне алай тикшерү юк дип, буш такта вагонга алырга ризалаша. Кукмарада күмер бушатачакбыз, шунда төшәрсез, ди.

– Кирәген биреп тә караган икән дөнья Галинурның. Камилнең дә.

– Ходай гомереңне алмаса, яшисең. Аллага шөкер, ул менә исән-сау. Әбисе янында кәҗә сөтен эчеп, исән калган сабыйдан тәки кул арасына керерлек кеше булып килә.

Минзада, каты күңелле булса да, барыбер кызганыч иде Рәгыйдәгә. Берничә ай узгач, баласын сагынып, ире яшәгән йортка тагын килүен әйткән иде аңа Варвара түтәе. Дуслашыйк, яхшы иптәш, әни булырмын, дип, соңыннан Галинурның үз янына да барып караган, тик аның күңеле катып өлгергән була инде. Ишеген япкан да кереп киткән.

– Әбигә кайтса, биреп тә җибәргән булыр иде инде.

– Кайткан ул. Аның, килен, ул бала сиңа нәрсәгә кирәк, дигән соравына каршы, «Камил янымда булса, Галинурым яңадан минем белән яшәр иде», дип җавап биргән.

– Ир кирәксә, икенчегә чык, малай кирәксә, ал, дигән әнәй, Галинур бирмәскә ныгытып әйткән булса да.

– Минзада барыбер кызганыч, – диде Буранбай.

– Әнәй кызганыч түгелме? Ул аңа икенче төрлерәк тә әйтеп караган. Бер җавабын да ошатмаган. Баланы карыйсына ышанычы беткән.

– Барыбер кызганыч.

– Беркайда эшләмәгән, торыр җире булмаган килеш, Минзада Камилне ничек аякка бастырыр иде, әйт? Әни янында яшисе килмәгән. Авылның авыр эшләренә күңеле ятмаган.

– Алай да кызганыч, – диде Буранбай әллә ничәнче кат.

– Кызганыч. Озак та тормыйча, башка кешегә чыккан ул, Камилне бөтенләй оныткан, бер дә килеп карамаган.

– Алайса кызганыч түгел.

– Менә мин абыйны аннан да катырак җәллим. Хатыны белән яшәсә, кафе-рестораннарда ашап йөрер идемени ул?! Ялларын өйдә уздырыр иде. Баласын карашып. Исән дә калыр иде. Әзмәвер кадәр ир чыпчык кадәрле милиционер аткан пулядан үлсен әле! Әнәйгә нинди хәсрәт.

2

...Буранбай татар илендә яшәүләре шулкадәр үк авыр булыр дип уйламаган иде. Бик теләп, ашкынып кайтты бит ул хатыны авылына. Ыругдашлык гадәтләре бездә юк, дигән Рәгыйдә үзе дә аптырап калды. Акчалы эшкә дә, җиңеленә дә туган-тумачага гына әйтәләр булып

чыкты. Яхшысы, урынлысы рәискә йә бер-бер башка җитәкчегә ярарга тырышучыларга тия. Техникум белемең булуга түгел, институт бетерүеңә дә беркемнең исе китми. Ә бит кайчандыр әтисен яраткан хезмәтеннән, кулыңда катыргың юк, дип аерганнар иде. Шуннан чирләп кенә китеп барды... Авыр елларда үзенә эш өстенә эш өйгән колхоз бит бу...

Түтәл ясап, гөл утыртып, шуның белән пансионатыңны бизәүнең үз рәхәте булган икән. Матурлык яздан көзгә таба артканнан-арта барган, күңелеңә хушлык китергән. Чүп утаудан, бәрәңге чүпләүдән, малга җилкәсендә ризык ташудан кеше нинди тәм тапсын?! Бигрәк тә яшең барганда, җиңел түгел бу эшләр.

Малсыз яшәү авылда кызыксыз, өстәлең дә такыррак була дип, мүкләк кенә бер сыер алып җибәргәннәр иде, җәйдән әзерләп куйганы булмагач, ашатырына таба алмый интектеләр дә ахырдан сатып ук җибәрделәр. Җайлашып алгач, тагын булдырырбыз әле дип,үзләрен тынычландырдылар. Вак-төяк нәрсәләр – сарыгы, казы-тавыгы җитәрлек иде.

Җәй җитсә, җиләгенә йөрербез, балыгына барырсың, дигән иде Рәгыйдә, укулар бетүгә үк, Буранбай, әйдә, кире китик, ди башлады. Камилне балалыкка гына аласы да китеп барасы кебек иде аңа. Безнең белән генә яшәсен, дигәннәренә, сагынырмын, дип, башта нык каршы торса да, соңыннан, яныңда кызың-киявең, аларның балалары бар бит, дигәч, Зәмниха карчык ризалашкандай тоелды, әмма районда рәтен белешә башлагач, малайны үзләренеке итеп булмаслык аңлашылды. Ул һаман да әнисенеке булып исәпләнә, аларның түгел, әбисенең дә балага хакы юк булып чыкты.

Минзада судтан ерак түгел генә бер йортта тора икән. Тыштан караганда ук, тормышларының муллыгы күзгә ташлана. Капка төбендә – мотоцикл. Комлыкта бала-чага уйнаганнан калган әйбер – чиләк, машина ише нәрсәләр. Капка келәсенә үрелүләре булды, ишегалдыннан ярсып, эт өрә башлады. Бераздан, чолан ишегеннән булса кирәк, кемнеңдер кырыс кына:

– Кайсыгыз йөри анда? – дип сораганы ишетелде.

– Җиңги тавышына охшаган, – диде Рәгыйдә. Аннан кычкырыбрак: – Җиңги, ач әле, капка аратагыз этелгән, ахры, бу мин, Рәгыйдә, – диде.

Менә капканың артында шалтыр-шолтыр килделәр һәм аннан үтә дә чибәр бер хатын күренде:

– Яным, синмени?

Матур итеп ендәшсә дә, Минзаданың, бер сүз ишетмәстән үк нидер сизенгәндәй, йөзләре агарып китте:

– Әллә Камилне үзегезгә алмакчы булып килдегезме сез?

Ничек сүз башларбыз дип курыкканнар иде, башлап торасы да булмады.

– Юк инде, яным, беренче баламны чит кешеләргә бирер хәлем юк.

– Алайса ник кайтып та карамыйсыз? – дип, сүзгә кушылды Буранбай.

– Карыйммы-карамыйммы – минем малай. Безнең нәселдә кысырлар юк!

Җиңгәләренең дорфа төрттерүе Буранбайны үтерде. Ул аның баладан баш тартмаячагын алдан ук фаразлый иде, әмма болай тупас сөйләшер дип, һич кенә дә башына китермәде. Җавап итеп, анда да кыргызча:

– Баланы жетимсиретпей жакшы[27], – дип кенә әйтә алды. Бераздан тынычланды. Минзада апасының төрттергәнен ишетмәгәндәй, ягымлы гына:

[27] Баланы ятим итмәү яхшы.

– Сиксәнгә барган карчык белән яши, аның үзенә дә авыр бит, алайса бераз карашыгыз, күргәләгез инде, – дип өстәде.

– Малаеның пенсиясе әллә никадәр. Үзенә дә, Камилемә дә җитәр, – дип, җиңгәләре ишеккә таба борылды. Аннан дөресен әйтим инде дигәндәй:

– Болай бит мин биш балалы хатын булам, стаж күп кирәк түгел, илле яшькәчә генә эшлисе. Алып китсәгез китегез, ул миннән инде өзелгән, тик үз исемемнән генә төшермәгез, – дип өстәде.

Буранбайда ниндидер өмет кабынды. Кара син аны, монда килеп йөрмәгән булсалар, һичкем Камилнең алар белән киткәнлеген дә беләсе булмаган. Алай да проблемалар, ул уйлаганча, җиңел хәл ителмәде.

– Хәзер сугыш чоры закуннары да, сугыштан соңгылары да йөрми, – диде директор. – Баланы үзеңнеке итүнең әллә нинди таләпләре бар. Авылдагы һәр бала өчен мин җаваплы, өстемә андый эшне ала алмыйм. Әбисендә яшәгән килеш яшәсен. Монда бит тикшерү килсә дә, әнисен таптырып йә сәбәбен аңлатып була. Әле һичкем белми: анда кадәр аның белән ничек барырсыз да укырга кая урнаштырырсыз...

Буранбай атылган киек хәлендә иде. Мәктәптән башын кыңгыр салып, хәсрәтле кыяфәттә кайтып керде. Керде дә тагын, үрсәләнгән бала кебек, әйдә китик, әйдә китик, ди башлады. Аңа монда яшәү ничек авыр булса, әбисен, инде үз малаена әйләнгән Камилне калдыру да авыр иде югыйсә. Шулай да, башка чактагыча, уйларына килгән көнне үк чыгып китмәделәр: керешкән эшләрен бетереп, аралтыны тәмам төзекләндергәч, малайга укырга барырга кирәк-яракларны хәстәрләгәч, киләчәктә үзләре белән алып китәргә вәгъдәләр биреп кенә, юлга кузгалдылар. Капка янына озата чыккан карчыкка Буранбай, кыргызча бик үк яхшы төшенмәгәнен дә онытып:

– Оозу чайга күйгөн айранды үйлөп ичет. Көп нерседен жалкып калдым. Ырасын айтканда, менин санаам бир аз тынып калды. Балким, бул мага эң эле көптүк кылат, – диде.

– Әнәй, авызың чәйгә пешсә, әйрәнне дә өреп эчәсең. Буранбай, йөрәгем бераз тынычланды, бу мин күтәрә алмаслык йөктер, ди. Алга таба Камилгә нык ияләнермен дип курка ул. Әллә китүебез яхшырак тадыр, оныта алмаса, авыр булыр, – дип, үзенчәрәк шәрехләде Рәгыйдә аның сүзләрен.

– Шул инде, – дигән булды Камил янында калганга сөенгән дә, кызы белән киявен кызганган да әнисе. – Исән булырга, яңадан күрешергә язсын.

– Әни, өйдә юл догасын укыгач, наратларыбыз төбендә тагын бер иңгәиң терәлеп утырыйк әле, – диде Рәгыйдә. – Йөрәк әллә нишләп тора.

– Төне буе эшләдегез бит, кысылгандыр, кызым, – дигән булды Зәмниха карчык. Аның да күз төпләрендә яшенең мимылдаган чагы иде.

Буранбай, яныгызга сыймым, дип, әбисе белән хатынының каршысына басты. Нинди көчле ике кадерле кешесе иде утыргычта. Нинди йомшак ике кадерлесе... Бер сүзсез генә утырдылар алар. Бер сүзсез генә хушлаштылар. Рәгыйдә торды. Карчык кузгалмады.

Киттеләр... Олы юлга менеп җиткәч, машина көткәндә, Рәгыйдә тагын наратларга борылып карады. Әнисе арты белән утыра. Таягын утыргычка терәгән. Аңа үзләренә борылып карарга авырлыгын аңлады. Еламас өчен Камил чыгып ук тормаган иде.

Менә машина килеп туктады. Буранбай чемоданнарын арбасына ташлады да башта Рәгыйдәгә менәргә булышты, аннан үзе күтәрелде.

Кузгалдылар. Рәгыйдә тагын наратлар ягына күз салды. Әнисе шунда иде әле. Күрмәсен белсә дә, ул күзеннән югалганчы, кулын болгагандай итте.

3

Зәмниха карчык, балалары кайткан саен саулыкта-исәнлектә күрешергә теләп хушлашса да, һаман да шулай булырга язмаган икән. Алтмыш җиденең җәендә Рәгыйдә белән Буранбайга, әниегез авырый, тизрәк кайтыгыз, дигән телеграмма килеп төште. Әниләренең юкка-барга борчу гадәте юк иде. Үлем чире белән түшәккә егылмаса, аларны шушындый ерак юлга чыгарырга кемнең башына килсен.

Шулвакыт әнисенең һаман да:

– Камилемне унбиш яшькә кадәр булса да үстерә алсамчы, – дип әйткәләгәне исенә төште. Алдагыны чамалавын белә иде, йөрәге жу итеп китте: малайга унбиш тулган, бераз узып та киткән бит.

Мондый чакта алдын-артын карау юк икән. Әйберләрен дә юньләп җыйнамадылар, акча булса, бар да була дигәндәй, күбрәк итеп алдылар да атылып-бәрелеп, поездга чыгып йөгерделәр. Пансионат директоры җибәргән машина артларыннан басуда куып тоткач кына, башлары эшләмәгәнлекне аңладылар. Юлда автобус көтеп торганчы, озатып куюлары яхшырак иде, әлбәттә.

Ыссык-Күл буйларында ялның иң кызган чагы. Юлда торсаң, автобуслары тулып килә, туктамый. Башкалада еракка билет алыйм, дисәң, һәрвакыт диярлек сатылып беткән булыр. Әле дә ярый бу юлы Казан ягына алып китә торганнары калган булып чыкты.

– Безнең бәхеткә инде, – дип сөенде Буранбай. – Кире кайтасы билетларга баруга ук заказ бирергә кирәк.

Күңеле борчуда, бик сөйләшәсе килми иде Рәгыйдәнең.

– Алдан ук кайгырма әле. Алла боерса, терелер, без кайтканчы ук терелер,– дип тынычландыргандай итенде аны Буранбай. Үзе эченнән, терелерлек булса, чакыртмыйлар инде аларны, дип уйлады.

Бер уң килсә килә ул алай да. Кайчак курыккан эш тә хәерле булып куя. Беркайда берни көтмичә, бер җирдә озакка тукталмыйча, башка чактагылардан да кызурак кайтып җиттеләр. Җиттеләр... Зәмниха карчыкның вафатына гына өлгерә алмадылар. Теләге кабул булган: өч көннән дә артык авырмасам ярар иде, дигән сүзе дә бар иде әниләренең. Шулкадәр генә авырып яткан да. Бәхетләренә, әле күмелмәгән, җыелышкан туганнар ике күз белән Рәгыйдәләрне көткән.

Әхмәтгали генә кайталмый инде, дип өзгәләнде Рәгыйдә, сугышка киткәннән соң әнисен юньләп күрмәгән, кайтып йөрергә рөхсәт алгач кына, бөтенләй урынга калган абыйсын кызганып. Әле дә ярый берничә тапкыр булса да күрештеләр. Патша малае булса, самолётта кайтарып, бакча артындагы болынлыкка ук төшерерләр иде дә бит.

Өлкән улы иде Әхмәтгали Зәмниха карчыкның. Әхмәтгалиме белән тормышларының башында гына туган улы. Эне-сеңелләренә ата урынына калган баласы. Алай да, үзеннән битәр, туып-үскән урамнарын сугышка алынганнан бирле бер генә тапкыр да әйләнмәгән Әхмәтгали бик кызганыч иде әнисенә. Баштарак хатларында, аякларым рәтләнер дә, әле урманнарга

да менәрбез, күрше авылларга да барырбыз, туганнарны да күрербез, ди иде ул. Язмаган икән... Тау асты чишмәләреннән иелеп су эчмичә, ул да бер заман аның артыннан китеп барыр микәнни?..

Әле дә ярый яннарында баласы бар, дип сөенә иде Зәмниха карчык. Барины да туйганчы сөеп кала алмагандыр. Үсә төшкәч, бөтенләй кайтмады.

– Әби, татарин мин, Бари! – дип килеп кергән иде беренче тапкырында әбисе йортына. Таягын читкә алып куеп, аякларыннан кочып алган иде... Рәгыйдәләрнең күренеп киткәненә әле озак түгел, Камилем янымда, башка кызларым, оныкларым кайтып, күренгәләп торды, сөйлисе сүзләрем сөйләнеп бетелгәндер инде аларга, дип уйлаган иде үлем түшәгендә ятканда Зәмниха. Ничә дистә еллар буена туплаган уйларны китәр көнеңә генә калдырырга ярамый, иң әйтеләсе дигәне барыбер кала икән.

Тыштан тыныч кына үлемен көткән кебек тоелса да, йөрәген бимазалаган нәрсәләр, чыннан да, калган иде әле. Әхмәтгалиенең менә-менә шушы көннәрдә хаты килеп җитәргә тиеш. Ходайдан шуны көтеп алу өчен, ялварып, нибары өч көн сорады ул. Иртә-кич хәлен белергә кергән күршесе почтада эшләгән Минзифадан гел Әхмәтгалидән хат юкмы, дип белеште. Анысы кергән саен баш чайкады. Бер дә ялгышмый торган иде Зәмниханың күңеле. Бу юлы ялгышты микәнни?.. Беренче көне дә узды, икенчесе дә, өченчесе дә. Инде шарт-шорт килеп өзелә башлаган кан тамырлары аның озак яшәмәячәген хәбәр итәләр иде.

Күрше фельдшерны чакырдылар. Ул авыруның караваты янына барып утырды. Йөрәген тыңлап карады. Берни дәшмәде. Алдагы көнне кергәнендә үк ничек тын аладыр һаман да, ныклык икән үзендә, дип аптыраган иде. Зәмниха карчык өзелде. Күбәләкнең канат җилпүе дә ишетелерлек тынлык урнашты. Менә-менә барысының бугазында торган төен ерылыр, күзләренә бөялгән яшь битләреннән юл алыр кебек иде. Нәкъ шундый мизгелдә, Әхмәтгали салган посылканы тотып, ишектә Минзифа күренде. Күчтәнәчләре, эчендәге хаты нәкъ өч көн буе почта складында яткан иде...

Шул ук көнне Рәгыйдәләр кайтып төште. Алар, өйдәгеләрне тыныч кына сәламләгәннән соң, бүлмә уртасына мәет өчен дөресләп борылган карават янына килделәр. Рәгыйдә, яшьләрен көчкә тыеп, әнисе йөзенә ябылган яулыкны күтәреп карады: матурлыгы әле китмәгән, исән сыман, елмайганрак сурәттә ята. Бала чагындагыдай, кулларын тотты. Бик салкын иделәр. Бу тойгы үләнлегенә бераз ышандырды. Өстенә ябылган җәймәне рәтләгәннән соң, берничә мәртәбә гәүдәсен сыпырып алды да түр буйлап тезеп куелган урындыкларның бушына килеп утырды. Рәгыйдә майабыстаеннан ым белән генә тәсбих сорап алды. Аннан әллә аңлап, әллә башкаларга ияреп, бармакларын бертуктаусыз төймәләр буйлап йөгертергә тотынды. Кайвакыт буташты, еламсырагандай итте, кайвакыт онытылды, дисбе тартуыннан туктап, кайдалыгын аңларга теләгәндәй, өйне күзәтергә тотынды.

Бар нәрсәгә – йортка, аның пәрдә-мичләренә, шунда утыручыларның җаннарына – авыр бер тынычлык иңгән кебек иде. Кыргызда мондый вакытта, илерә-илерә еларга дип, сыктаучылар килә, ә монда һәркем Алла белән, үз күңеле белән, хәтта телсез калган мәет белән сөйләшкәндәй. Өйнең һәр почмагыннан шыбыр-шыбыр, пыш-пыш дога укыганнары гына ишетелә.

Балаларның, туганнарның барысы да кайтып беткән иде, күмүне шул көннән дә калдырмаска булдылар. Кешенең вафаты – авыр бер

хәл, хушлашуы аннан да авыррак. Әнисе чыгып киткән өйнең капка баганаларына, чирәмлек каршындагы наратларга кадәр елый күк тоелды Рәгыйдәгә. Тәрәзәләргә карады. Әллә өйдәге һава белән селкенде инде пәрдәләр. Әнисе кулы белән ачып караган да кире ябып куйган кебек тоелды Рәгыйдәгә. Йөрәге дерт итеп китте. Алып киттеләр бит инде аны, алып киттеләр! Үз-үзен ышандырыр өчен, эченнән шушы сүзләрне кат-кат кабатлады. Тагын тәрәзәгә карады. Пәрдәләр инде селкенми иде.

Камил дә олылар белән зиратка төшеп китте. Буранбай әбисенең яраткан мәчесен дә үзе белән алган. Ни дисең инде аңа?

– Орышма, барсын, ул бит аны башка күрмәячәк! – диде Буранбай.

– Барсын...

Рәгыйдә болай да көчкә чыдап тора башлаган иде, бу сүзләрдән элеккедән дә катырак елый башлады. Ул да, апалары да, абыйсы да, Камил дә башка күрә алмый бит инде аны!

Ирләр зиратка киткәч, бар нәрсә җыелды, юылды, тәртипкә китерелде. Ул арада күршеләр ашарга, йокларга чакырып керде. Рәгыйдәнең ашамый да тамагы тук иде. Күрше хакын хаклап кына, кереп тамак ялгаган булды. Мәет чыккан йортны ялгыз калдыру ярамый иде. Төн буе аның рухына дога укылды, теләкләр теләнде.

Кәҗәне саварга, мәчене булса да ашатырга кирәк иде. Башка бер вакытта көтүдән туп-туры үзе кайтып кергән кәҗә ишегалдына таба курка-курка гына, анда да эткәч-төрткәч кенә атлады, абзарга кергәч, бер почмакка елышып калтырарга тотынды. Элек тә сава иде аны Рәгыйдә. Бүген аңа имчәкләрен бирергә теләмәде. Савып бетердем дигәндә, кечкенә чиләгенә тибеп чайпалдыртты да күпме сөтен түкте. Мәче савыты баскыч тирәсендә генә тора, ул Зәмниха карчыкның абзардан чыкканын шуның янында тыныч кына көтеп утыра торган иде. Бүген күренмәде.

– Зиратта кулымнан төште дә югалды, – дигән иде шул Буранбай. – Адашмый алар. Кайтыр әле.

Мәче кайтмады да кайтмады. Әллә мәет чыккан йортка аягы тартмыймы? Апаларына менәргә дә ярата иде. Әллә шунда гынадыр.

Йортта Буранбайның да юклыгын күреп, төн үтәр-үтмәстә Рәгыйдә, бер тын алыйм дигәндәй, бакча буйлап инеш буасына төшеп китте. Сукмактан уйлана-уйлана барганда, колагына әкрен искән җил белән ниндидер сагышлы көй килгән кебек булды. Төшә-төшә, Рәгыйдә аңлады. Бакча башында, түбәндә аккан суларга карап, Буранбае моңлана иде:

... Келгендеги кошогу
Башка салса Кудайым...[28]

Рәгыйдә ире янына җиткәч, өстендәге калын кофтасын җиргә җәйде дә, җилкәсенә терәлеп, янәшәсенә утырды. Шул исенә төште: аларның бабаларыннан калган кечкенә генә, берничә битле китапчыклары бар иде. шунда сыктау җырлары кыргызча да, русча да язылган. Казаннан алып кайткан булган Әхмәтхәсән бабасы аны. Югалмаган булса, чормадагы тартмаларда ятмый микән? Ничек моңа кадәр онытып торган соң Рәгыйдә?..

Кыргыз кумызчыларының җырларын сагынган, болай да бозылган

[28] Килгәндәге сыктауны
Башка салса Ходаем...

йөрәген тагын да ныграк әрнетеп, шуларны тыңларга, кушылып җырларга тели иде ул. Буранбайның тукталып калганын күргәч, икенче берсен үзе дәвам итте. Шушы ук җырны татарча да җырлый ала иде Рәгыйдә, алай эшләмәде. Кайчандыр ата-бабалары җиңел аңлаган бу телне туган ягының таллары, кошлары да тыңласын, аңларга тырышсыннар дип хыялланды.

Рәгыйдә белән Буранбай сөйләшми генә, һәрберсе үз уенда таң аттырды. Өйгә менәсе дә килми иде. Анда туганнары бар, әмма авылының күрке булган Зәмниха карчыкның җәсәде дә юк инде. Анда сөннәтче әбинең догалы тавышы өзелгән... Бакча сукмагыннан өйгә таба күтәрелгәндә, Буранбай татарча үзе чыгарган бер җырны, кешеләр ишетмәсен, аңламаслар, гаепкә алырлар, дигән кебек борын эченнән генә әвәләде:

Һаваларда оча җиз үрдәк,
Эзли мәллә төшәр күлләрне?
Сөйгән ярны күктән эзләдем,
Арасыннан таптым гөлләрнең.

Кайгы килсә дә, шатланса да, кумызын чиртә башлый Буранбай. Сүзләр килеп кенә тора, көйләр кайлардандыр агып кына керә кебек күңеленә. Кичтән, хәсрәтләрен эчләреннән кичереп тә, нарат төбендә әниләренең, Әхмәтгалимемнеке, дип яраткан утыргычында Буранбай белән бик озак хәл алды алар. Рәгыйдәнең шул чагында ян-ягында күркәләр таралып ятканга исе китте. Әле өлгереп тә бетмәгән күркәләрнең өзелүе-коелуы гаҗәп иде. Күтәрелеп агачка карады. Аның урта тирәсендәге киң ылыслы бер ботагына козгын килеп кунган да наратның яшькелт җимешләрен чукый да җиргә ыргыта, чукый да җиргә ыргыта. Сөннәтче әби булмагач, күркәләрнең дә кирәге калмады инде, диме бу мәет кошы? Өлгермәгән күркәләр җиргә тәгәрәшкән.

Рәгыйдә нарат күләгәсендә ял итеп утырганда:

– Әтәй, нигә дип мондый агач утырттың син урамга? – дип сораган иде кайчандыр. – Ә нигә чыршы түгел?

– Чыршы астында ял итә алыр идекме соң, кызым? – диде әтисе. – Наратның ябалдашлары әнә нинди киң. Түбәндә ботаклары бөтенләй юк. Чыршынықылар җиргә таяна.

– Аның караве кәүсәсе озын, төз аның.

– Чыршы биеклегенә җитмәсә дә, наратның да илле метрлыларын күргәнем булды минем. Хәзер урманнар таланды, агачлар сирәгәйде, картлары калмады диярлек.

– Ә нигә алар икәү? Берсе дә җитәр иде бит.

– Әниең белән үзем кебек күз алдында тоттым мин аларны. Аркага-арка терәп үссеннәр, корымасыннар, дидем. Ә син беләсеңме: нарат күркәләренең дә әнисе, әтисе була. Тормышта балаларга да әти дә, әни дә кирәк.

Рәгыйдәнең менә берсе дә калмады. Күпне белгән әтисе дә, тормышны һәрвакыт җай алып барырга, иренә ярарга тырышкан, авылга хезмәт иткән әнисе дә.

Рәгыйдә белән Буранбай бер-берсен шулкадәр яраткач, нигә бала бирмәгән аларга Ходай? Ник менә Галинурның бердәнбер баласын ятим иткән? Болай уйлау дөрес түгел, дияр иде әтисе. Димәк, сезнең бурычыгыз башкада, дияр иде. Ялгызы калгач, ничек яшәргә тиешлеген сорарга да өлгермәгән. Алар кебек, игелек кылып кына икәнлеген белә ул, әмма кайда, ничек, кемнәр белән

тормыш итүе җиңелрәк булыр хасталыгы көннән-көн көчәйгән Буранбайга, аны яраткан Рәгыйдәсенә? Монда гына күчеп кайтыргамы? Камилне үзләре белән алыргамы? Баланы, никадәр сәбәп табып, директор җибәртүгә каршы төшкән иде. Ходай Камил бәхетенә баласыз итте микән әллә аны?

Энесе сигезенчене бетерде. Аттестаты – кулында. Моңарчы Казанга бер-бер техникумга укырга китәргә чамалап торган. Артыгын ирексезләми генә, безнең якта укы, дип әйтәсе булыр. Казанда укыйм дип, үзенекен алга куйса, акчасын җибәрерләр, ялларына чакырырлар. Ямьбикә апалары да ташламас. Әбиең картая инде, дип, бу кышта Минзада да үз янына дәшеп килгән. Аның белән китәргә теләмәгән, миңа монда яхшы, дигән.

Эшләр болайга киткәч, Буранбай белән Рәгыйдә Камилне иң башта үзләре белән яшәргә күндерергә булдылар.

– Бездә дә бер дигән институтлар, техникумнар бар, кайсы-берсендә танышларым да укыта, – диде Бешә.

Камил дәшмәде. Әле уйлый иде.

– Сөйләшербез-киңәшербез дә, күңелеңә ятканына урнашырсың. Тугызга барам, унны бетергәч, институтта укыйм, дисәң дә, риза без.

– Анысына әле керәсе бар аның.

– Керерсең. Ятим балага ташламалар да каралмаган микән әле, – диде Буранбай. – Бар нәрсә үзеңнән генә тора. Иң элек ни теләгәнеңне ачык бел.

– Әни бар бит... ятим түгел...

Рәгыйдә, шул сөйләшүне уйлый-уйлый, бакчадан лапас аркылы чыгып, болдырга таба атлады. Ишегалдына кергәч, ачык капкадан пар нарат утыргычындагы Камилне күреп алды. Ул да йокламый икән. Янына барды. Камил, бер чарасыз калган адәм шикелле, җилкәсен дерелдәтеп, тын гына, яшьсез генә елый иде.

Малай тынычлансын, игътибарын башкага күчерсен өчен Рәгыйдә:

– Өйдә кеше калгандыр бит? – дип сорады.

Камил баш селкеп кенә җавап бирде.

– Моңаймале, энем, – диде Рәгыйдә. Улым, дип әйтергә теләгән иде дә, тукталды. Малай әнисен белә, әбисен әни урынына күрә иде. Бер кешенең өч әнкәсе буламыни, дип уйлады.

– Моңаймале, яным, – диде ул яңадан. – Без бит икебез дә кичә иң кадерле кешебезне югалттык. Бер-беребезгә тагын да кирәгрәк булып калдык. Өчләрен-җиделәрен уздыргач, әйберләреңне җыйный тор, үзебез белән алып китәрбез.

Малай, чыннан да, тынычланды, апасын кочаклап ук алды. Әйе, эчәр чәйләребез калган икән әле, дип уйлады Рәгыйдә, мин ашны әнәй вафат булган өйдә генә уздырасы икәнлеген башымнан чыгарып җибәргәнмен. Алар өйгә кергәндә, алдагы ашка әзерләнү эше башланган иде инде.

Газизәбану сеңлесе – апасының кызы кай арада төшеп җиткән. Ул бакча башында булып, күрми калгандыр инде. Кичә ул да тиз генә күңелендәгесен сөйләп алды.

Газизәбануның, авырып яткан әбисе белән хушлашырга килгәч, күзе яңа гына агартылган мичкә төтенлеген кыңгыр салып утырган самавырга төшкән. Якын әбисе янында кунакта булып кайтканнан соң, кызы, әбием, инде икенче килүеңә мин булмам, күркәләрне бер еллык итеп кенә әзерлә, миннән соң нарат

чәе эчәргә теләүче табылмас дип сөйләнгәли, яңадан күрмәс кебек кочаклап бик нык аркамнан сөйде, дигән икән аңа. Газизәбану шул вакытта әле яшенә күрә нык карчыкның ел дигәндә китеп барасына бөтенләй ышанмаган. Хәзер менә, бөтен тормышын елга агышларыдай гел белеп, сизеп торган икән безнең әби, ди.

Газизә, узган җәйдә кызы Рәүфә күп итеп җыеп калдырган күркәләрдән самавыр тергезим дип, чоланга чыккан. Алар салынган кәрҗингә карагач, имәнеп үк киткән: кәрҗин төбендә нибарысы биш-алты тапкыр чәй кайнатырлык күркә тәгәрәп ята, ди. Җитсә дә, өч көннән артыкка җитмәс, моның кадәр кунак төшкән өйгә, дип уйлаган. Кызына кат-кат:

– Киләсе җәйгә, киләсе җәйгә... – дигәне әллә чын ук булыр микән, дип коты очкан. Шунда кылт итеп әбисенең намаз укыганда калдырмый торган, өч көннән артык урын өсләрендә яткырмасаңчы, Ходаем, әҗәл чирләренең шул өч көненә чыдарлык түземнәр бирсәңче, дигән теләге күңеленә килгән. Бу әйберләрнең туры килүенә шаккаткан.

Учлап, күкрәгенә кыскан күркәләрнең берсе кире кәрҗингә төшеп киткән дә почмакта җыелышып яткан ишләре янына тәгәрәгән. Газизә аны шунда калдырган. Күркәләрне озагракка житкерсә, әбисе дә артыграк яшәр кебек тоелган аңа. Язмышны алдарга теләгәндәй, бер күркәне үзе үк кире кәрҗингә ыргыткан, алдый гына алмаган...

Сеңлесен тыңлау да елыйсын гына китерә иде Рәгыйдәнең. «Бала чагыбызда, нарат янындагы чирәмлектә мәш килгәндә, күркәләрне утырган җиреннән генә, каз бәбкәләрен саклаган, уйнаткан кебек, таяк белән төрткәләп җыярга, хәрәкәткә китерергә ярата иде ул», – ди. Аннан йомшак бәбкә үләне өстендә изрәп, кояшта кызынып яткан күркәләрне бергәләп җыялар да чәй эчәргә кереп китәләр икән. Каз йомышлаганчы, кеше аягы басканчы алып калыгыз инде, балалар, ди торган булган Зәмниха әбиләре, самавыр эченә тутырылган күркәләрдән ят, зарарлы исләр килүен, самавырның нәҗесләнүен теләмәгәндәй.

Зәмниха карчыкның бер-бер артлы өче, җидесе узып китте. Кырыгына кадәр көтеп булырлык түгел, Камилне кая да булса урнаштыруны хәл итәргә кирәк иде. Йортны болай да биктә озакка калдырып булмый.

Киттеләр. Өйне бикләп, ачкычын апаларына биреп, бер нәрсәгә тимичә диярлек, әнисе исән чагындагы килеш калдырып киттеләр. Камилнең әтисеннән калган катыргы чемоданы бар икән. Ул аңа җыен юк-бар тутырган идеме? Күтәреп карагач, Рәгыйдәнең коты очты:

– Яным, син моңа нәрсәләр салдың соң?

– Китап. Мин моннан бернәрсә дә алмыйм. Миңа китап булса, җитә. Үскәндә эш күп булды, гел укып утырырга кызыктым.

– Ярар соң, – диде Рәгыйдә апасы. – Киемне без аны үзебез дә табарбыз. Җизнәң кайтырга чыкканда ук авырыбрак торган иде, аңа күтәртмәбез.

– Ярар. Миңа ул әллә ни авыр түгел. Андыйны гына күтәрмәгән!

Рәгыйдә сумкасына кипкән җиләк, мәтрүшкә ише җиңел әйберләрдән башкасын салмады. Бераз уйланып торганнан соң, безнең якның миллеге, мунчаласы белән чабынасым килә дип, сарайдан каен себеркесен алып керде дә, гәҗиткә төреп, шулар янына тыкты. Аның бу эшенә:

– Әйтерсең, бездә каен үсми, – дип аптырады Буранбай.

– Гаепләмә инде. Безнең якның каены да хуш ислерәк, яфрагы ботагында

да ныграк тора, – дип җавап кайтарды Рәгыйдә. – Әле икене тыксаң да, ярыйсы да бит, синең кычкырып көлүең бар... Бу юлы урманга да бара алмадым, ичмасам, бер шунда барган кебек булыр.

Келәт матчасына киптерелгән казлар эленгән иде. Буранбай бигрәк тә шуңа кызыкты. Кәгазеннән майлары тамып торган берсен аның сумкасына тыктылар. Йорт истәлеге булыр дип, берничә канат алган булдылар. Әтисеннән калган бер кием чабата бар иде, чормага менеп, Рәгыйдә шуны алып төште дә әнисенең килен бүләгенә бирелгән алкаларын, чәчүргечләрен шулар эченә салды. Ул эшләгән эшләренә үзе дә аптырап куйды. Чабата белән көмеш тәңкәле чәчүргечләр, уртасына зәңгәр таш утырткан ай колаксалар аңа әти-әнисенең элекке тормышын сөйли кебек иде.

Рәгыйдә яңадан өйгә керде. Алар кайтканлыктан, туганнары иптәшкә төн кунганлыктан, кеше тыны сизелә икән. Ул киткәч, инде бу йорт бөтенләй бушап калачак. Бусагасын кем дә атлап кермәс, ишегалдындагы йомшак чирәмнәренә кем дә аяк басмас. Соңгы ашта ук инде үзләре дә, төтүләре дә булмас. Ятим бала белән бер икән бу әнисез калган йорт.

...Озатырга кеше күп килгән иде. Сүз һаман Зәмниха карчык, Камил турындарак барды. Әнисе бу хәлләрне ишеттеме соң, диючеләргә Рәгыйдә җавап биреп тормады. Биш балалы ана инде пенсия яшенә җитеп килә торгандыр, бар хыялы шул иде кебек, дип уйлап, борынын гына җыерды.

Камил авылдан китүгә борчылдымы-юкмы – белә алмады. Ул да ике арада иде бугай. Туган җирен калдырып чыгып китү никадәр авыр булса, малай дөм ятимлек ачысыннан да, ялгызлыктан да шулкадәр курка иде кебек.

Сөт машинасы озак көттермәде – килде. Кабинага хатыны белән Камилне утыртканнан соң, Буранбай яңа сауган сөт исләре аңкып торган цистерна янына менеп басты. Хәтеренә, шушы машинага охшаган искерәгенә утырып, кыз сорарга кайтканы төште. Риза булмас, Рәгыйдәне бирмәс, дип бик шүрләгән иде ул Кыргызстанда чагында. Зәмниха карчык кирегә ләм-мим бер сүз әйтмәде. Каршы килсә, әнисеннән һичбер вакыт узмаган Рәгыйдә аңа кияүгә чыгар иде микән?..

4

Камилгә җизнәләрендә бик ошады. Җәй буе аның белән ауга йөрде, балык тотты, су керде, апасы пешергән мантыйларга, пылауларга сөенеп бетә алмады, әмма ул иң татлы, иң кадерле бала булырга күнеккән иде һәм яшенә күрә кешене олылыклаган кыргыз гадәтләрен яратмады. Егет моңарчы Рәгыйдә апаларының заманча йортында искелек калдыкларына урын бардыр дип, һич кенә дә башына китермәде.

Камилнең хәтерен тәү тапкыр өстәл янына утырганда калдырдылар. Йомшак мендәрле түр урындыкны үзенә тартуы булды, апасы шунда ук кисәтте:

– Анысы әти кешенеке, яным.

– Җизни – әти түгел ул, – диде Камил.

– Ул – олы кеше дә, ир кеше дә, әтиең урынына калган кеше дә. Син аның уң ягына утырырсың, ә минем урыным моннан соң сулында булыр.

Рәгыйдә киң төпле зур савытта алып кергән пылауны, кечерәкләренә бүлеп, шул ук тәртиптә һәр кеше алдына куеп чыкты. Әгәр ул өлкән хатын – байбичә булса, өстәл кырында тик кенә утырып торыр иде, боларны яшьрәк хатыннар эшләр иде, бәхетемә, бу гадәтләр үткән инде, күпхатынлы

гаиләләр очраса да, бик ерак авылларда гына, анда да картлар арасында сирәк кенә очрыйдыр, әмма күренгәне юк, дип уйлады.

Икенчегә күп итеп тагын бер бизәкле савытта ит керде. Кулына коштабаклар тоткан килеш, ит белән нишлим дип торган шикелле, Рәгыйдә, Камил дә бераз күнегә торсын дип, кыргызчалы-татарчалы дәште:

– Куу өрдөк– җиз канатлы үрдәк. Кыргызча бер ышаныч бар: кем шушы кошның итен ашаса, дөнья беткәнче яшәр, имеш. Жез канаттуу өрдөктүн этин жеген өлбөйт – деп, ушул дүйнө бүткөнчө, аркы жайды көрбөйт. Аша, яме, яным, озак яшәрсең. Җизнәңә аучы булганы өчен башын бирербез, калган җирен үзе сайлап алыр.

Боларга рәхмәт әйтсә дә, үзен әбисе өендә бердәнбер ир заты итеп яшәгән Камилгә җизнәсе янында гел икенчегә калу авыр иде, кәефе киткәнлек йөзенә чыкты.

Үпкәләтерлек сәбәп, эзләп утырсаң, табыла да тора. Әкренләп, шуларга хәтере калган Камил өй эшләреннән дә бизә башлады. Аңа далада, тауларда, үзәннәрдә йөрү кызыграк булса да, уку вакыты килеп җитә, һәм үзен кая да булса урныштырачаклар иде. Камил техникумга китмәскә, мәктәпкә генә барырга теләвен әйтте, бер күрмәгән кешеләр арасына, башкалага чыгып китәргә курыкты булса кирәк. Сайлавын үзе сайласа да, документлар илтергә барган җиреннән үк кәефе кырылып кайтты.

Авылның иң күрекле бер йорты булып торган зур һәм яңа салынган мәктәптә алар барганда, директордан кала һичкем юк иде. Буранбай, исәнләшеп керде дә, Камилгә ишарәләп:

– Мен өтүнүч менен кайрылгым келет.

Камил моны якынча аңлады. Җизнәсе үтенеч белән килгәннәрен әйтте булса кирәк. Калганын ул тыңлап та тормады. Директор чит сүзләр кыстырырга яратса да, русчаны юньләп аңламый диярлек һәм кыргызча гына сөйли иде. Ул, җизнәсе белән сөйләшкәннән соң, Камилгә, телен ачарга тырышкандай, бер-бер артлы сораулар яудырды:

– Шкулда Сизге жактыбы? Кай улуу? Сиздин атыңыз ким? Фамилияңыз кандай жазылат?

Бер көн укымаган мәктәп турында ни дисен? Фамилиясе дә, исеме дә, аларның язылышы да, калган сорауларга да җавапларның барысы метрикә кәгазьләрендә, мәктәптән алынган документларда да бар иде бит инде. Ахмак директор белән түбәнчелекле сөйләшкән җизнәсенә дә ачуы килде аның. Алай да киткәндә, татарчагарак охшаганга, берничә белгән сүзе бар иде, җизнәсе моңарчы төксе торганына орышыр дипме, кыргызчалап хушлашты:

– Көрүшкөнчө.

– Баары жакшы болсун. Анан жоголуп кетпеңиз[29], – диде директор.

– Яхшы булсын, дигәнегезгә рәхмәт. Юк, ничек югалыйк, әйеме, Камил, безгә инде монда укырга киләсе, – диде Буранбай, шуның белән егетнең дә күңелен күрергә теләп. Юлда кайтканда, тынычландырыр өчен генә:

– Безнең кышлак мәктәпләрендә русча укытмыйлар диярлек. Рус теле дәресләре дә кыргызча бара аның, – дип аңлата башлаган иде, Камил сүзен кырт өзде:

– Бездә дә татарча аңлаталар, русча сөйләшә беләм бит әле!

– Мин сине үзебез белән Кошчак исемле рус теле укытучысына кунакка

[29] Бары да яхшы булсын. Югалып ук китмәгез.

алып барырмын. Күрерсең, ул да синең русча әйткәнеңне һич төшенмәс... Белүе ипилек-тозлык кына.

– Алайса мин сезнең мәктәбегезгә бармыйм да! Мин кыргыз булырга теләмим! Миңа татар булу да бик җиткән!

– Үзеңә кара, анда ошамаса, иртәгә үк документларыңны кире барып алам да техникумга илтербез, интернаты да бар, русча да укыталар.

Камил монысына ризалашкан кебек булды. Җизнәсенең күзәтүеннән котыла икән алайса. Юл буе директорны көлеп искә алгалап кайтты. Аның мәктәбендә укысам, надан калырмын, дигән булды. Пансионатка җитәрәк егетнең кәефе кинәттән тагын үзгәрде.

Рәгыйдә болай да борчылып көтеп торган иде, Буранбай белән Камилнең сөмсерләре коелып кайтып кергәнне күргәч, ни булды, дип сорады. Буранбай егет ишетсә ишетер, аңласа аңлар, ишетмәсә, аңламаса – бәхете, дигәндәй, ярымпышылдап кына әйтә куйды:

– Атасына караганда, ал көбүнчө энесине окшош – таарынат, ачууланат[30].

– Абый да, әнисе бик үпкәчел, көйсез, дип әйтә торган иде, чыны шул икән, – диде кичен йокларга ятканда Рәгыйдә.

Камил бүлмәсендә әле ут яна, һичшиксез, ул китаплар укуда иде. Менә монысы Рәгыйдәгә ошый. Тикмәгә тырай тибеп йөргәнче, китап укуы күп яхшы.

Тора-бара Камил мәктәпкә барырга да, техникумга керергә дә теләмәде, берәр һөнәр бирә торган училищега илтегез, урта белем алгач, калганын үзем карармын, диде. Уйлаштылар-киңәштеләр дә килештеләр. Буранбай, баланың кәефе алдан ук кырылмасын дип, бу юлы документларны үзе генә биреп килде. Сентябрь җиткәч, кием-салымнарын, ризыкларын җыеп, аны шәһәргә илтергә әзерләнде. Озатырга дип чакыртылган машинага Камил әлеге дә баягы иске чемодан белән чыккан иде.

– Куй инде, яным, чемоданыңны, үзебездә генә калсын. Анда китапларыңнан башка да әйбер бармыни соң? – дип сорады Рәгыйдә.

Малай җавап бирмәде, чемоданны да апасына тоттырып калдырмады, машина багажнигына салды. Беренче атнада сагынып, әйберләр пешереп көткәннәр иде, егет күренмәде. Юлга җитәрлек тә, ашарлык та акчасын тыктык бит, дип уйлады җизни кеше, хәер, аны анда бушка ашаталар да бит әле. Бу безне сагындыртырга, борчырга тели, ахрысы, дип үзенчә фаразлады апасы. Камил исә училищега баргач, монда да күбрәк кыргыз балаларының укыганлыгын күргән һәм башка беркем белән дә аралашмаска, бүлмәсенә бикләнеп, китап укып кына яшәргә карар кылган иде. Ул юри, инде бөтен кеше урнашып беткәч кенә, ялгызы яшәр өчен, начаррак булса да, иң соңгы бүлмәгә керде.

Камил өчен кыргыз арасында русча уку авыр булмады, яхшы билгеләр генә алды, әмма һичбер чараларга катнашмады, кеше арасында күренеп йөрмәде, укытучыларның күзенә чалынмаска тырышты.

Өченче атна ахырында энеләренең Чолпон-Атага кайтасына өметләре киселгән Буранбай үзе калага китте. Ул башта аның төркеменә дә, яшәгән бүлмәсенә дә кермәде, директор янына сугылды. Буранбайның килеп чыгуы яхшы булган, югыйсә директор үзе дә аны чакыртырга торган икән.

– Бу бала әллә ничегрәк, мин әле аны аңлый алмыйм, – диде ул.

– Ятим үскәнгәдер инде, – дип, әллә хуплады, әллә акланырга теләде Буранбай. – Ятимнең күңеле нечкә була бит, бик еш үпкәли, һәрчак бәхетсез,

[30] Ул этисенә караганда әнисенә күбрәк охшаш, үпкәчел, ачулы.

ялгыз хис итә. Ни сөйлим, үзем дә – шундыйларның бер сыңары. Әллә дәрескә йөрмиме?

– Дәрескә дә йөри...

– Укуы начармыни?

– Анысы барысыныкыннан яхшы.

– Соң?

– Һичкем белән аралашмый, сөйләшми ул – аерым хуҗалык кешесе кебек үз эченә бикләнгән.

– Анысы бераз бар инде.

– Кайчан карасаң, китап укуда. Егет кешегә бераз хәрәкәте дә, кызлар белән, дуслар белән аралашуы да кирәк.

– Кыргызча аңламаганга, шулайрак кылана торгандыр.

– Ул бит бүлмәгә рус балалары белән дә урнаша ала иде. Алар әнә бернинди тарлык сизми. Сезнең малайның кыргызчаны төшенгәне күренеп тора югыйсә, ә барыбер аңламамышка салына.

Буранбайның кәефе кырылды. Теләсә ничек яшәвенә риза булсаң, Камилне авылда гына да калдырып китәргә булыр иде. Шәһәр укуыннан соң, ичмасам, институтына да җиңелрәк керер дип уйлыйсың. Үзенең дә китәсе килде бит инде.

– Тәрбияләп үстергән балагыз булмагач, сүз әйтүе дә кыендыр, – дип хушлашты директор. – Алай да бер сөйләшеп карагыз әле.

Буранбай баш какты, ә үзе тулай торак бүлмәсенә кергәч, ничек сүз башларга белми торды. Егет тә ачылып китәргә ашыкмый иде.

– Килеп йөрмәсәң дә була. Мине монда ашаталар. Кием дә бирделәр, – диде. – Укып бетерәсе китабым да күп әле...

– И улым, – диде Буранбай, гомерендә беренче мәртәбә шулай эндәшсәм, бала күңеле үзгәрмәсме дип уйлап. – И улым, китап уку белән генә дә кеше булып булмый, иптәшләр, дуслар табарга кирәк. Әле синең туйганчы уен да күргәнең юк, бергәләп туп тип, башкаларның уеннарына катыш.

Камил дәшмәде. Нинди эти булсын инде аңа бу кеше? Рәгыйдә апасының бераз анда хакы да бардыр, әмма ул үзе аларның берсенә дә бернәрсә дә тиеш түгел! Тиеш кешесе әбисе бар иде, ул хәзер юк! Нәрсәгә дип минем белән маташалардыр болар?! Үзләренең балалары булса, Камил барлыгын белмәсләр дә иде әле...

– Апаң бик борчылып калды, – диде киткәндә Буранбай. – Ялга кайтырга тырыш. Киемнәреңне дә юып-үтүкләп җибәрергә кирәк, өй ризыгы ашарсың.

Камил тыңлады – кайтты. Китаплары янына киемнәрен дә салып кайтты-китте, кайтты-китте... Тик көннәрнең берендә тагын югалды. Училище директорыннан аның атна буе күренмәве турында хат килеп төшкән иде. Буранбай анда чапты, монда, һичкайдан таба алмады, ахырда тау үзәнендәге табыннан көтүче хәбәре килеп иреште. Ул аның юртасына чемоданын күтәреп барып җиткән дә әлеге дә баягы китапларын укып тик ята, имеш. Буранбай, атта барып, Камилне үзләренә алып кайтты.

Ормадылар, сукмадылар, һичбер сүз әйтмәделәр. Ашарына пешереп ашаттылар, мунчасын керендерттеләр дә, йокласаң дип, урынын җәеп куйдылар. Малай ни көндез, ни кичен һичбер нәрсә сөйләшмәде. Олылар белән утырып телевизор да карамады, пансионат буйлап ял итеп тә йөрмәде. Ул һаман нәрсәдер укый, нәрсәдер сызгалый-бозгалый яза иде.

Камил йокыга ныклап киткән бер чакта апасы, бүлмәсенә кереп, чемоданын ачып карады. Ни генә юк икән анда! Китап янында – киеме дә, ризыгы да, әйтерсең, бала дөнья беткәнгә әзерләнә, ялгызы яшәргә генә хыяллана. Рәгыйдә әйберләренә тимәде. Чемоданның капкачын ябам, дигәндә, күзе кесәсеннән чыгып торган бер фото почмагына төште. Кулына алып карады. Минзаданың кыз чагында төшкән бик матур бер рәсеме иде. Фотоның артын әйләндерде. Камил куллары белән:

– Әни, син дөньяда – иң яхшы кеше! – дип язып куелган иде.

Үз балаңны да бу кадәр карамассың, көйләмәссең, ул барыбер күңелендә икенче кешегә – имезмәгән, бакмаган, барлыгын да белмәгән, сабый чагында ук баш тарткан әнисенә табына икән. Аның акчасына кадәр үзенә тоткан анага мәхәббәтле булып калу мөмкин микәнни соң?! Дөрес алып килделәрме алар үзләре белән Камилне, юкмы – аңламады. Минзада, минем белән торсын, дисә, бу юлы һичбер каршы төшәселәр түгел иде югыйсә.

Рәгыйдә чемоданны япты, бүлмәдән чыкты. Ишек сыкраганга Камил уянган һәм, уяу икәнлеген сиздермәскә тырышып, апа нишләп минем бүлмәгә кергән икән, дип уйланып ята иде. Юк, ул үзенчә яшәргә тели, ул апасы кебек кеше гадәтләренә буйсынырга теләми. Рәгыйдә апасыннан кыргыз колы ясагач та, аннан ясый алмаслар! Теләсәм, үзем сезне кубызыма биетәм мин! Тугызны бетергән булса да, сабыйлык акылы белән сөйләшә иде әле Камил.

Иртәнге ашка дәшеп, егет бүлмәсен шакыганда, ул инде әллә кайчан, чемоданын күтәреп, пансионаттан качкан иде. Буранбай, ерак китмәгәндер әле, дип уйлады да кырга чыгып чапты. Ишәктә печән алып кайтучы бер кыргыз нindidер малайның Ыссык-Күл буйлап Чолпон-Ата ягына таба китеп барганлыгын күрдем, дип әйткәч, җан-фәрманга шунда таба йөгерде. Куып җитте, егетне туктатты, тик кире кайтара алмады. Яр буйлап юка киемнән чапканда туңуы гына җитмәгән, абынып китеп, салкын суга килеп төшкән, шактый гына чыланган иде. Кинәт күкрәге кысылгандай булды, өзлексез йөткерергә тотынды, егылды, тагын торды, тагын егылды. Җизнәсенең авызыннан канлы күбек килгәнне күргән егет каушап калды.

– Үлмә, җизни, мин хәзер, мин хәзер, сине күтәреп үк алып кайтам! – дип өзгәләнеп кычкырырга тотынды.

Камил, чемодан кесәсеннән нindidер фоторәсемне алып, күкрәк кесәсенә тыкты да, башка әйберләрен ташлап калдырып, җизнәсен күтәреп, пансионатка таба китте. Кайларда гына югалды дип, ут йоткан Рәгыйдә, инде хәлсезләнеп егылган ирен күргәч, тынсыз калды. Буранбай шул егылуыннан яңадан аякка басмады. Ул Камилгә элеккечә йомшак булып калды, үпкәләмәде, орышмады. Рәтләрәк бер көнендә, мин булмасам, апаңны тыңла, ташлама, укуыңны да бетерә күр, дип кенә әйтте.

Малай, ниһаять, сүзләрен тыңлап, Чолпон-Атага китеп баргач, бик борчылган бер кыяфәттә:

– Жетемакы деп...[31] – дип, нәрсәдер әйтә башлаган иде, кире уйлады булса кирәк, авыр итеп сулау белән канәгатьләнде. Шул сулышны күтәрә алмаган шикелле тагын ютәлләргә тотынды.

– Ятим хакы да, әни хакы да, абый хакы да инде... – дип тезде Рәгыйдә. – Менә безнең хакны гына кем хаклар... Яшь чакта, Муллагали дигән бер

[31] Җитте...

егетне үз итмичә көлеп йөргәндә, кызлар, утыз улың булганчы, у...к ирең булсачы, диләр иде, хак икән...

– Авылда чакта бик акыллы күренгән бер малай иде...

– Ул чагында әле аны кем генә белгән соң? Ул безнең белән яшәмәде бит, әбисенең иркә гөле булып үсте. Дөрес, эшен бик эшләште, шуңа күрә орышырга телем дә бармый үзен. Төскә-биткә әнисенә охшаган, диләр иде, холкы да шуңа тарта, ахрысы...

Буранбай кире аякка басмады. Язга чыксам, исән калырмын кебек, ди иде. Беренче саф җете-яшел үләннәргә сөенеп, баскыч төбендә бер утырып алды да яңадан тышка чыгаруны да сорамады.

Хәсрәт арты хәсрәт килгәнгә аптырамый башлаган иде инде Рәгыйдә, гадәтләнә генә алмады. Шул авыр көннәрендә Варвара Семёновнадан хат килеп төште. Барие, яше җитеп, паспорт алган. Үзен – урыска, исемен Бориска алмаштырып кайткан. Әтисенә мактанып күрсәтүе булды, Әхмәтгали йөрәген тотты да егылды, дигән. Күмгәннәр икән инде... Әле дә ярый боларны әнәй ишетмәде, диде Рәгыйдә. Качып кына бер елады да, абыйсының хәсрәтен күңел төбенә күмеп, яшь түгүеннән туктады. Аны алда зур мәшәкатьләр көтә иде.

Рәгыйдә бөтен эшен ташлап, Буранбайны дәвалауга кереште. Табибларын да тапты, даруларын да. Ире шактый тиз генә тернәкләнә дә башлады, шулай булса да, Рәгыйдә хәл белергә килгән саен:

– Исән калсам, сине татарларың янына алып кайтам, – ди иде. – Ялгыш кире килгәнбез без. Иләнгән булыр идем әле. Колхоздагы хәлләрдән күңел кайтты да... Ашыктым... Исән калсам...

– Юкны сөйләмәле.

– Үз илең гадәтләре белән тор. Аннан үлеп-нитеп китсәм дә, җаным синең өчен тынычрак булыр.

– Юкны сөйләмә әле, дим бит, Бешә, рәхәтләнеп яшәп ятканда. Болай гына авыргалаганың булды инде, гел уңайлана килдең.

Рәгыйдә сүзләренең дөреслеген раслагандай, Буранбай йөзенә тиздән чын-чынлап матур төс узды, тәннәренә ит куна башлады. Менә-менә аягына ныклап басар кебек иде ул. Әмма... Беркөнне Буранбай бүлмәсенә ниндидер ят тавыш ишетеп керсә, Рәгыйдәнең коты очты: ире идәндә тәгәрәп ята. Тиз генә күршеләрен дәште дә ашыгыч ярдәм чакырттылар. Буранбай, йөрәгем авырта, дип кенә аңлата алды.

Рәгыйдә бу көнне бик озак реанимация бүлмәсендә утырды. Аннан Буранбайны, хәле артык куркыныч түгел дип, гомуми палатага күчерделәр.

Буранбай, чыннан да, уңайлангандай кебек иде. Бераз сөйләшкәләп утырдылар. Ахырда, йөрәген тотып кына, тагын гадәтенә кереп барган сүзләрне кабатлады:

– Исән кала алсам, туганнарыңа илтеп тапшырам.

– Нинди сүз бу һаман?! Җитте, булды.

– Ярар, ярар, – диде аны тынычландырып Буранбай. – Әле терелермен дә кебек. Син яңа суйган тавыктан үзегезчә аш та пешереп китерсәң.

– Калдырырга куркам, Буранбай.

– Нәрсәсеннән? Терелеп килә́м бит инде.

Шулчак ишектә укол савыты тоткан медсестра күренде.

– Сеңлем, нәрсә кадарга уйлыйсыз?

– Сезнең ни эшегез бар? – диде яшь кыргыз кызы.

– Иремнең үпкәсе хаста, бронхиаль астмасы да бар, аларны исәпкә алып кына дәвалагызчы.

– Сезнең минем нәрсә кадавымда ни эшегез бар? – диде кыз тагын.

– Кайбер антибиотиклар иремә аллергия бирә. Исемлеге – врачта.

– Мин врач кадарга кушканны гына кадыйм да! Юлыгызда булыгыз.

– Сеңлем, дозагыз да зурга охшаган. Врачның минем язып биргәннәрне укымаган булуы бар, беразын гына кадагыз инде, – дип ялварып сорады Рәгыйдә. Ул медсестра кулындагы дарулы энәгә карады. Күңелендә шомның чиге юк иде.

– Борчылма, тиеш түгелне кадамыйлардыр, – диде Буранбай. – Кайт инде, иртәнге аш вакытына килерсең.

Теләмәсә дә, Рәгыйдә китте. Буранбайның тавык шулпасын бик нык ашыйсы килгәнлеге күренеп тора иде.

Иртән килде дә киемнәрен салып, бүлмәсенә узарга дип торганда, вахтада туктаттылар:

– Сез кемгә?

– Бешә Муса углы Усубалиевка. Алтынчы бүлмәдә ята.

Вахтёр алдындагы исемлекне карады да:

– Үлде бит инде ул! – диде.

Вахта кырыннан ире белән бер палатада яткан кыргыз узып бара иде.

– Рәгыйдә эже, Буранбай агайның йөрәге китүегезгә үк туктады. Уколлар ярамадымы, буыла башлады да берничә минут эчендә китеп тә барды.

Әллә тыңлады боларны Рәгыйдә, әллә юк, вахтёрны этеп кенә төртте дә врач бүлмәсенә йөгерде. Ул килеп кергәндә, ирен дәвалаган табиб медсестра кыз белән нәрсә хакындадыр киңәшеп тора иде. Рәгыйдә икесенә берьюлы:

– Ник үтердегез минем иремне?! – дип, бар көченә кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. – Судка бирәм мин сезне! Бирмәсәм, берегезне дә бу җир өстендә йөртмим.

Суд булды. Врачларны утырту түгел, эшкә салкын караучылар дигән сүз белән, штрафка да тартмадылар. Рәгыйдәнең кат-кат кабатлавына да карамастан:

– Авыру кеше үзенә ярамаган дарулар хакында алдан кисәтмәгән, табибларның аның үлемендә гаебе юк, – дигән карар чыгардылар. Гаебе юкның – җәзасы да юк.

Рәгыйдә хәсрәтенең беренче көннәрендә аларны үзе үк үтерер кебек иде, күмү мәшәкатьләре белән йөри торгач сабырланды. Ул шул вакытта иренең нигә кыргыз арасында калдырырга теләмәвен аңлады. Монда кануннар бөтенләй юк, дуслык-әшнәлек бар нәрсәдән йола иде.

Камил, тыштан караганда, бик тыныч кебек күренсә дә, эченнән кайгырды, бу хәлләрдә, бу хәсрәтләрдә үзен дә күпмедер гаепле сизде, тик ул моны теле белән апасына әйтмәде. Аны инде борчымыйчарак яшәргә, сүзләрен тыңларга тырышты.

Рәгыйдәне үлем хәсрәте генә түгел, күмү хәстәрләре дә тәмам аяктан екты. Кыргыз гадәтләрен яратам, дисә дә, барысын да кабул итеп бетерерлек түгел икән. Үз башыңа төшмәсә, белмисең генә. Кешенең бар туена да ыру җыеша, диләр дә. Алганыннан биргәне күбрәк булды. Үлем хәбәрен ишетеп, авыллардан җыелган туганнар ул бүләкне сорады, бу бүләкне. Мәҗлесләрдә ризык су кебек акты. Калым бүләгеннән үрчегән көтүләр дә калмады,

алтыннар да таралып бетте. Буранбайның киемнәренә дә урын чыкты. Ярар, үзе дә тапкан мал, савап булып барсын, урынын җәннәттә итсен дип, ризалыгын сиздереп куйса да, Буранбайдан бер истәлексез дә калу авыр иде. Ул ире киптергән берничә кош карачкысын, ау мылтыгы белән биноколен пансионат складына илтеп яшерде. Күзләренә күренмәсә, сорарга башларына килмәс, дип уйлады. Иренең аларны һичкемгә бирмә дигән сүзе дә бар иде.

Фазанын да, башкасын да һичбер кеше искә алмады, әмма ау мылтыгына-биноклена өметләнгәннәр, барлыгын истә тотканнар күп булып чыкты. Рәгыйдә үзендә каршы торыр көч тапты, алары – малайга, җизнәсе истәлеге, диде. Сүз шуның белән өзелгән кебек булган иде, Рәгыйдә ялгышкан икән. Туганнарның иң олысы булган бер карт, үлем түшәгенә егылгач, әлеге дә баягы мылтыкны соратып алды. Имеш, бер атуда әллә ничәшәр киеккә тидергән мылтыкны тотып карамыйча, бинокль аша тауларга күз салмыйча, дөньядан китәсе килми. Рәгыйдәнең пансионатта эшләре бик тыгыз көннәр иде. Җитмәсә, өйдә дә кунак арты кунак, мылтыкны да, биноклые дә кеше аркылы гына җибәртте.

Ай узды, картның үлгән хәбәре килеп иреште, әйберләрне генә кире китереп бирүче табылмады. Рәгыйдә түзмәде, үзе эзләп китте. Аны ишегалдында картның олы оныгы каршы алды. Күзләреннән ялганлаганы күренеп торса да, бабай, мылтык белән биноклыне каберенә салырга кушты, ул анда ауга йөрермен дип ышанды, очраса, Буранбай аганың үзенә бирер әле, диде. Мондый оста ялган ишетермен дип Рәгыйдә башына да китермәгән иде. Шулар өчен нинди озын юл үткән булса да, йортка да кереп тормыйча, кыргыз гадәтләренчә күрешмичә-хушлашмыйча да, күз яшьләрен сөртә-сөртә, җәяүләп Чок-Талга кайтып китте. Юлында танып туктаган кешеләргә дә кул гына селтәде, тукталышта көтеп торган автобуска да утырмады. Аңа ничек тә җанын басарга кирәк иде.

Язмышның шаккатырган хәлләре тезелеп кенә килде Рәгыйдәгә. Пансионатка кайтса, Буранбаеның ау эте баскыч төбендә ята. Дәшеп, селкетеп карады – үлгән. Бер җире авыртмаган, моңа кадәр хуҗасы артыннан койрык безләтеп чабып йөргән тайганның шулай кинәттән җан тәслим кылуы йөрәген хәлсезләндерде. Көч-хәл белән стенага тотынып, таш баскычка утырды. Әти артыннан этләре дә китте, дигән иде Буранбай. Этләре дә, башка маллары да... Кызыл Тайлакка да чират җиткән... Көтүләрен саклаган никадәр эт булгандыр. Берсен дә аның кадәр яратмады Буранбай. Бабамнар заманыннан килгән, токымын чиста саклаган тайган ул, ди иде. Тугач та, башка бәйрәмнәрдә дә аңа бүләккә көчекләр бирә торган булганнар. Буранбай калыккач, тәпи киткәч, менә шушысының бабасын – шаянын, үзе белән йөгерергә яратканын, куышканын сайлаган.

Хайван иясенә охшый, диләр. Эшкә, кеше арасында кызурак булса да, өйдә бик тыныч, үзен сабыр тотучан, Рәгыйдәне бик кайгыртучан, ялгызлыкны сөймәүчән иде Буранбай. Кызыл Тайлак та – нәкъ шундый. Хуҗасын якларга кирәк булса, бүрене дә ботарлап кына атар иде ул. Һичкемгә, һичнәрсәгә – көтүдәге малларына да, кешегә дә зыян салмас.

Рәгыйдә Кызыл Тайлакны кадерләп, затлы бер чүпрәккә төрде дә мазарстанга якын гына калкулык тирәсенә илтеп күмде. Буранбай, теге дөньяда нәкъ мондагыча яшәренә ышана иде. Шулай була-нитә калса, эте якындарак йокласын. Үлеп карамыйча, анда ни көткәнен кем белә?..

Рәгыйдә икенче көнне үк Фрунзега рәссам эзләргә китеп барды. Кабердәге

ташлар нык урнашкан, һәйкәл өчен махсус корылган диварга Буранбайның Кызыл Тайган белән ауга барганын ясатырга кирәк иде. Аның өчен сызмаларны Камил төн буе ясады. Кулы килә иде егетнең. Рәсемне үзе төшергәндә дә буласы. Рәссам ныграк ошатсынга, Буранбайның ауда йөргән бер фотосын да салдылар. Рәгыйдә, син миннән соң яшәргә тиеш, үзеңне минем янәшәмдә ясатма, дигән сүзләрен хәтеренә китерде. Әйе, ул догачы булып яшәргә тиеш иде әле. Бергә төшкән рәсемнәрен аерып, иң матур альбомга – кызыл бәрхет тышлысына тезеп чыкты. Бәхете бәрхеткә төренде... Еракка алып куелды...

Су буенда ялгызың яшәп ятмассың, шәһәрдәге өегезгә күчәрсең, дигән иде танышлары, Рәгыйдә алай итмәде. Анда китеп нишлисең?.. Ичмасам, пансионатта эше бар, җәен өе тулы – ял итәргә килгән кунак. Барысының күңеле шат: гөрләшәләр, шаулашалар. Рәгыйдә күңелендә яшәү акрынайгандай, элекке мәгънәсен югалткандай тоелса да, кемдер үлгән аркасында гына, башкаларның тормышы ашыктырып, ашкындырып агудан туктамый.

Килем-төшемгә һаман да ачык чырай күрсәтсә дә, Рәгыйдәгә, кеше арасында булуга караганда, үзе үстергән бакчада, гөлләре, абзарындагы маллары янында рәхәтрәк иде. Шулар белән сөйләшүдән ямь-тәм тапты. Алаен алай да, Буранбайны юксынуын барыбер һични баса алмады. Торды да ире йөргән юллардан тауларга китте, торды да мазарстанга барды.

...Кечкенә бер шәһәрчек кебек кыргыз зиратында быел калкып чыккан каберләрнең җанына кадерлесенә таң арты таң кояш төшәр, җылысын бирер, дип уйлады Рәгыйдә, кабер өстенә куелган һәйкәлне карарга, останың эшен бәяләргә килгәч. Төнен аңа йолдызлар карлы тау башлары яктысын сирпер. Үземнән соң бернәрсә дә, беркем дә калмас микәнни, дигән Буранбай хәзер рәсемнәргә күчте. Рәгыйдәнең – татар хатынының күңелендә урын алды. Аның урыны анда болай да бар иде инде! Их, әгәр исән булса... Әгәр исән булса, җаннарны айкаган үз җырын җырлар иде ул аңа, аның исемен язып ясаган кубызында күңел кылларын тибрәтерлек көй чиртер иде.

Буранбай беренче кайтканнарында Өскебаш кыры күгеннән очып узган үрдәкләрне атарга ярата иде. Аларны эшкәртеп, чистартып, каклап үзләренә алып китә. Күршеләренә дә өлеш чыгара. Зәмниха карчыкка да, туганнарына да. Бервакыт Буранбай: «Куу өрдөк – җиз канатлы үрдәк. Кыргызча бер ышаныч бар: кем шушы кошның итен ашаса, дөнья беткәнче яшәр, имеш», – диде. Үз куллары белән, бу сүзләрне кат-кат исләренә төшерә-төшерә, никадәр сыйлады ул ирен табында гомерләре дәвамында. Буранбайны әнә шундый гасырлык ышанычлар да саклап кала алмады...

...Буранбай вафатыннан соң ел арты ел уза торды. Рәгыйдәгә ялгыз түгеллеген күрсәтергә теләгәндәй, туганнары сирәк-мирәк булса да килгәли башлады. Кайда да тормыш яхшырган, кеше акчалы иде инде. Буранбайны юксыну өстенә, туган ягын сагыну хисе дә артканнан-артты гына. Рәгыйдә, һичшиксез, Буранбайның теләген үтәргә – үз иленә кайтып китәргә, үз гадәт-йолалары белән яшәргә тиеш иде. Тиз генә булдыра алмады.

Яшьлегендә дә эштән башканы белмәгән иде Рәгыйдә, хәзер дә бар юанычны шуннан, Камилдән тапты. Укып бетергән егетне армиягә алдылар да кыргыз илендә дөм ялгызы калгандай булды ул. Аралашкан кешеләре дә, ир ягының туганнары да кимемәде, әмма һаман да беркем дә, берни дә аның ялгызлык хисен басарлык түгел иде.

Йөрәге хәсрәтләренә чыдамаган, күрәсең: көннәрнең берендә Рәгыйдә, аңсызланып егылып, больницага эләкте. Тагын чыкты, тагын керде, тагын, тагын... Йөрәген, монда калсам, дигән курку басты. Хәле бераз гына яхшыруга, күченергә хәзерләнә башлады. Юлда ялгызы кайтырлык көче юк иде. Апасының кызы килде дә, бергәләп кайтып киттеләр. Йорт әйберләрен контейнер белән генә җибәрделәр.

Күңеле юкка ашкынмаган икән Рәгыйдәнең. Кукмарага урнашуының беренче аенда ук яңадан хастаханәгә ятты.

– Апа, сезне үзегездә нәрсәдән дәваладылар? Кәгазьләрегездә йөрәктән дип язылган. Күп кенә җирләрегездә хасталык бар, йөрәгегез әле ярыйсы гына.

– Йөрәктән, – диде аптырап калган Рәгыйдә.

– Шикәрегезне тикшерткәннәре булдымы?

– Юк.

– Егермегә җиткән бит! Бездә иң элек шуны тикшерәләр хәзер.

– Беренче ишетәм.

– Анысы да борчылганнан аның, апа. Тынычрак яшәргә тырышыгыз. Ялгызрак, бала-чага чыр-чуын ишетмичәрәк.

Рәгыйдәгә нәкъ менә шул ялгызлык авыр иде дә! Буранбайсыз гомер итү авыр иде. Ире исән булса, инәгә тагылган күндәм җеп кебек, ияреп йөрер иде ул аңа. Кыргызы да, татары да бердәй якын булып, җырлап-көлешеп яшәрләр иде. Таулар иленнән күңеле бер кайткандай булса да, ярата иде ул аны барыбер! Торган җире итеп, үзен хөрмәтләгән җир, иренең Ватаны итеп ярата иде!

Туган җирен тагын да ныграк ярата Рәгыйдә алай да. Аныңча, Буранбай бер дә кыргызга охшамаган. Күзләре татарныкы кебек зур, битләрендә бәхет чокыры бар, абыйларыныкына тартым куе кара чәчләре бөдрәләнеп тора, тулы иреннәре гел елмаюда. Йөзендә салкын дымлы җилләр, даланың эссе кояшы салган эзләр дә юк. Йокларга дип, керфекләрен йомдымы, шул сурәтендә килә дә баса, килә дә баса, татар сылуым, ананайым, дип сөйгән Буранбай.

Бигрәк матур да иде Бешәсе! Аның янына кайтуын ешайтты. Чакыра. Кабат бергә булыйк, ди. Бүген Рәгыйдәнең әнисе белән әтисен дә иялртеп килгән. Барысы да ризалар. Апасы да, җизнәсе дә... Элек тә каршы төшмәгән иде. Хәзер дә, үзеңә кара, вакыт җиткән санасаң, диләр. Җитте микән?

– Алар үлде бит инде, – диде караваты янында утырып торган Хәлимәбикә апасы, аның туганнарына дәшкәнен ишетеп алып. – Оныттың мәллә?

– Юк. Монда күршеләр дә килгән әле... Бусагагыз янында тукталганнар.

Онытмады. Белә. Акылында. Шулар белән сөйләшкәләгәнен сиздермәсә дә була иде. Аларның кайдадыр барлыгын аңлатасы, аларны да шуңа ышандырасы килде бугай. Пышылдап кына да әйтә ала иде. Әйтә ала иде...

Муллагалигә туганнары арасында ни калган? Хафизга бигрәк тә. Кичерү сорап килгән. Ул бар кешене күптән кичерде инде. Үзенекеләрне, Буранбаен гына көтә. Ул да Рәгыйдәне көтә. Җавап бирмәде әле. Алып китәргә, диләр бит. Китәргә...

– Китте... – диде кинәттән тетрәнгән Мәрүә сеңлесе. – Җаны якты шәүлә кебек өзелеп очты...

Ярый яннарына кайтырга, аларны да күрергә өлгерде...

Мөхәммәт
Мирза

АДӘМ БАЛАСЫ

***

Кар төшә дә эри: –
Пары оча күккә...
Адәм баласының
Гомере – бер тамчы,
Бер карлы бөртектәй.

***

Яуланган кыры бар,
Бар яуланыласы...
Адәм баласының
Җилләр хөкемендә
Кылганлы даласы.

***

Шик-шөбһәсез үтмәс
Яшәлгән бер көне...
Адәм баласына
Җан дусты чыгарыр
Яшерен хөкемен.

***

Юрганына карап
Аягын сузалган
Адәм баласы җир
Шарын җиде кабат
Әйләнеп узалган.

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Биш томлык «Сайланма әсәрләр», «Киек каз юлында», «Тере су», «Адәм баласы» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Түбәсен коруга
Килеп кояр яңгыр.
Адәм баласының:
– Иртәгә, – дигәне
Бер елга соңарыр.

***

– Бу дөнья – өч көнлек, –
дип әйтүен әйткән...
Адәм баласы ник
Гомере чикләрен
Тәмам кичерәйткән?..

***

«Сүз куертып кына,
Май төшмәс», дигәнне
Адәм баласының
Туа-тумышыннан
Аңлыйсы килмәде.

***

Юк җил күтәрмәгән,
Үтелмәгән ара...
Адәм баласының
Уңайга торганын
Җил җәһәтрәк ала.

***

Үрчетеп аера
Корт анасы күчен...
Адәм баласының
Мөстәкыйльлегенә
Үрнәк булсын өчен...

***

Болын, кыр, даласы
Тояк тоймас булды.
Адәм баласының
Йорты-курасына
Елан кереп тулды.

***

Мәгънәле вәгазен
Тыңлап, тынып торыр...
Адәм баласының
Күп белдеклесеннән
Колак тонып торыр.

***

Иң әүвәл сүз булган! –
Инкяр итмәс кем дә.
Адәм баласының
Теле ачылырмы
Җавап тотар көндә?

***

Көлке куып килер,
Китмәс ары узып...
Адәм баласының
Кимсетеп көлгәнен
Калдырыр тузгытып.

***

Шат йөзе – бәхетле
Сәгате, мизгеле...
Адәм баласының
Шул хәлен күпсенеп,
Күңелен биздермик.

***

Иртәдән торганы
Килерен киметмәс.
Адәм баласының
Юрганы япканын
Күтәрер көч җитмәс.

***

Күргәннең – күзе юк,
Ишетми – ишеткән.
Адәм баласы үз
Туганыннан бизеп
Иблисне иш иткән.

***

Хәсрәтле хәленнән
Хәбәрдарларыннан
Адәм баласының
Котылыры булмас –
Гаепләү әреннән.

***

Кемне кем узган да,
Кем кемнән калышкан?
Адәм баласының
бизенмәс хыялы
Комарлы табыштан.

***

Сан җитмәс хәзинә
Шыплап тулган җиргә.
Адәм баласына
Хәрамын – хәләлен
Танырга җай бирә...

***

Эт мәчене куа –
Белеп тоталмасын.
Адәм баласының
Кысыр селтәнүе –
Көлкегә калмасын.

***

Куркаклык – мескенлек,
Батырлык – юләрлек.
Адәм баласының
Мескен батырлыгы –
Тилереп үләрлек...

***

Исәбе, хисабы
Үзгәрә көн саен...
Адәм баласының
Базары ябыла
Табалганчы җаен.

***

Чакрымнар арасын
Бер тында үтәлгән
Адәм баласының
Оныгын иңендә
Ташбака күтәргән...

***

Ишеге, тәрәзе –
Аркылы такталы...
Адәм баласының
Ятим йорт түбәсен
Елап, җил каккалый.

***

Үчен алмый калмас
Кыерсытылганы:
Адәм баласының
Турысын әйткәнгә
Үте сытылганы.

***

Ябынган юрганы
Ябалган табанын...
Адәм баласының
Атлы-сукалысы
Табалган тәгамен.

***

Күңеле пәрдәсен
Күтәрәлмәдисә,
Адәм баласының
Көннәрен телгәләп
Көя-телә кисә...

***

Тырмасына басып
Маңгаен канаткан
Адәм баласының
Мәңгелек бабасы –
Маймыл шаклар каткан.

***

Кемгә, кайчан, кайда? –
Сан җитмәс сораулар...
Адәм баласының
Тәне туфрак булыр –
Җаныннан сорарлар.

***

Дөньяны яулаган
Иярләгәч атын...
Адәм баласының
Нишләтер дөньясын
Баетылган Атом?

***

Таяну ноктасы
Табанында ласа...
Адәм баласының
Җайланыр дөньясы
Катлауландырмаса...

***

Илетеп биргәндә
Ияреп кайтканы...
Адәм баласының
Гомер базарында
Табып югалтканы...

***

Шөкерана кылып,
Бәхеткә кинәнгән
Адәм баласының
Йөземе, хөрмәсе –
Юкәдә, имәндә...

***

Айдан-айга сузып,
Җиткерә тапканын...
Адәм баласының
Күрсәтәсе килмәс
Качырып капканын.

***

Бердәмлеген тойса,
Көч-кодрәте артыр...
Адәм баласының
– Берүзем, – дигәне...
Тик телендә батыр.

***

Чигенер чире дә,
Җитдисә тәкате...
Адәм баласын гел
Чиргә сабыштырыр
Үтмәс бер гадәте.

***

Көнозын – ызанда,
Төн озын – кысанда.
Адәм баласының
Үзгәрмәс ил-көне
Кыйбласын борсаң да.

***

Җир, су – шәхси милек,
Болын, кыр – хосусый...
Адәм баласының
Нәфесе азганы
Кайчан бер косыр соң?

***

Сорап килгәне бар,
Биреп җибәргәне...
Адәм баласының
Бар гомере буе
Читтән имәлгәне...

***

Бирмәс борын тартып
Алсалар аласын...
Адәм баласы үз
Яныннан ук алмас
Арада каласын.

***

Чиллә көн уртасы –
Карлы яңгыр яуды...
Адәм баласының
Битараф чырае
Йокылы-уяулы...

***

Ач-ялангач булмас,
Кулы корал тоткан...
Адәм баласының
Эшлексезлегенең
Һушын йокы йоткан.

***

Бар чамасын тоеп,
Нәфесен тыйганы...
Адәм баласының
Бәрәкәтен табар
Бөртекләп җыйганы...

***

Басып бәхәсләшер
Төшенми төшенә,
Адәм баласының,
Баксаң, чыкмагандыр
Бер акыл теше дә...

***

Алтыдан – алтмышка
Тугыздан – туксанга...
Адәм баласының
Азынмас этлеге:
– Чәбә, – дип кусаң да.

***

Киерелеп тарткан,
Аткан ук, сөңгесен.
Адәм баласының
Куәтен арттырган
Ияр өзәңгесе...

***

Күзен дә йоммас ул:
Әйтер күрәчәген –
Адәм баласының
Кайчан да булса бер
Ятып үләчәген...

***

Гомере юллары
Ел араларында –
Адәм баласының
Барып җитәр җире
Күк карамагында.

Амур Хан

САБАКТАШЛАР

хикәя

Җәй сәеррәк килде быел. Корылык. «Их, бер тамчы яңгыр яуса иде...» дип, күк йөзендә сирәк кенә күренеп киткән уч төбе кадәр генә болыт кисәгенә дә зур өметләр белән караган бер мәлне, барча җан ияләрен куандырып, көннәрдән бер көнне яңгыр яварга тотынды. Шәп яуды. Бар халык урамда – бала-чага, карт-коры, эт-мәчеләр, кош-корт... Бар җирдә шат авазлар, уен-көлке. Сабан туе, диярсең...

Ул да булмады, баштарак тәннәрне иркәләп талгын гына искән җил, тора-бара көчәйгәннән-көчәя барып, күз ачкысыз давылга әверелде. Тирә-юньне яп-якты итеп, якында гына яшен ялтырап куйды. Бер мизгелдән, кешеләрнең колакларын тондырып, күк күкрәде. Әле генә яңгыр ява башлавына чиксез куанган халык, чыр-чу килеп, мизгел эчендә кайсы кая таралышып та бетте. Һәм бик вакытлы, чөнки чама хисен элеп тә бирмәгән җил-давыл, тагын да көчәя төшеп, балалар мәйданчыгындагы «гөмбәчек»не бер почмакка илтеп ыргытты, андагы ком өемен туздырып атты, ничәмә-ничә дистә еллар буе үз көенә тыныч кына үсеп утырган карт өрәңге, тупыл агачларын төбе-тамыры белән йолкырга тотынды. Агач тирәләрендә кешеләрнең затлы-затлы машиналары тезелеп торуына да игътибар итмичә, үз эшен дәвам итте. Урамга аяк басарлык та түгел. Кайбер кешеләргә, сүгенә-сүгенә, озак еллар тир түгеп туплаган акчасына сатып алган машинасы өстенә агач кәүсәсе ауганын тәрәзә аша карап торудан башка чара калмады...

Шулай... Айлар буе корылыктан гаҗиз булып, инде яңгыр ява башлагач, иркен сулап куйган адәмнәрне Аллаһы Тәгалә, янә бер кат, бу юлы инде давыл-гарасат белән сынарга булды. Сынарга. Күрәсең, гөнаһларыбыз артык күп җыелгандыр инде...

Амур ХАН (Амур ФӘЛӘХОВ) (1965) – *язучы, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Шәйхи Маннур һәм Риза Шәфи исемендәге әдәби премияләр иясе. «Зимагур», «Төнге кунак», «Мизгелләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Гөнаһ дигәннән, адәми затлар гөнаһ кылмый яши алмыйдыр да инде ул. Бигрәк тә аянычы – кайвакыт иртәгәсе көн турында уйлап та карамыйча, чама хисен бөтенләй онытып җибәрәләр...

Иртән иртүк техник хезмәт күрсәтү станциясе янына затлы чит ил машинасы килеп туктады. Кичәге гарасат үзенекен иткән – яңгыр яуганчы яңа сауган сөт кебек ап-ак төстә булган, ялтырап торган «Лексус» шактый пычранган. Аннан текә костюм кигән яшь ир-ат чыкты. Кыяфәте үк кычкырып тора: бик биектән оча торган кош! Һәм көтеп торырга өйрәнмәгән – барысы да бик тиз кирәк!

– Әй, кем бар анда? Күпме көтәргә була?! – дип җикерде ул.

Автосалоннан, ашыга-кабалана, машина юучы чыкты. Автомобиль хуҗасы аңа күтәрелеп тә карамады, шундый ук текә телефонына төбәлгән килеш, тупас кына:

– Минем чибәркәйне рәткә китер, ялтырап торсын! – дип боерды.

Машина юучы үз эшенә кереште, ә теге ир-ат телефонында актарынуын белде. Ниһаять, башын күтәреп, эшчегә карап куйды да берара тын гына торды.

– Ба! Кемне күрәм мин! Чанга, синме бу?!

«Чанга» сүзен ишеткәч, машина юучы бу ир-атның үзен күптән, мәктәп елларыннан ук белгән кеше булуын аңлап алды. Берәр нәрсә турында сөйләгәндә, кулларын селти торган гадәте булганга, сыйныфташлары аны «Чунга-Чанга» дип үчекли иде.

Ә текә клиент сүзен дәвам итте:

– Хәзер күңелем тыныч – машина чиста булачак! «Бишле»гә генә укыган кеше үз куллары белән югач, минем чибәркәй чынлап та тәртиптә булачак! – диде ул мыскыллы көлемсерәп һәм машина юучыга якынрак килеп басты.

Алмаз да, башын күтәреп, аңа карап куйды. Таныды.

– Хәерле иртә, Хәмит. Әйе, чиста булыр, – диде ул тыныч кына.

– Юк, болай булмый, моны төшереп алырга кирәк. Тарих өчен! – Автомобиль хуҗасы мыскыллавын яшереп тә тормады, машина юучыны видеога төшерергә кереште.

Шулай итеп, техник хезмәт күрсәтү станциясендә ике сыйныфташ очрашты. Берсе «Лексус»та килде. Икенчесе аны юды. Менә шундый әкәмәт. Үзенең кәттә машинасын юарга китергән ир-ат шулай фикерләде.

Видео төшерүдән туйгач, Хәмит машинаның сазга баткан тәгәрмәчләрен юып торган сыйныфташының янына ук килеп басты.

– Шәп булды әле бу. Димәк, шимбә көнне сыйныфташлар очрашуына буш кул белән килмим булып чыга. Гел «бишле»гә генә укыган яшьтиебезнең ничек эшләвен күрсәтәм!.. Мәктәптә укыганда, киләчәккә нинди планнар коруыңны искә төшерсәм... Хәтерлисеңме, синең хыялларыңнан без көлә идек. Машина юучы булып эшләүдән башкага сәләте булмаган кешенең малаена шундый ук язмыштан башкасы тәтемәячәген ул чакта ук аңлый идек. Ә син тыпырчынган булдың, имеш, юкка гына тырышып укымыйсың, киләчәктә һичшиксез үз эшеңне ачачаксың... Кыскасы, ачтыңмы үз бизнесыңны? Ә, Чанга? Шушылай чит кеше машиналарын юумы инде бизнесың?.. – «Лексус» хуҗасы шаркылдап көләргә тотынды. – Юк, очрашуда моны бөтенесе дә күрергә тиеш. Синең казанышларыңны

барысына да күрсәтәчәкмен. Көлсеннәр әле бер рәхәтләнеп! Тик син үзең дә кил, яме. Хуҗаң җибәрерме? Үзем кереп сөйләшимме әллә? Ни генә әйтсәң дә, сыйныфташлар очрашуы бит. Яхшылап аңлатырмын.

– Кирәкми. Җибәрер дип уйлыйм, – диде машина юучы тыныч кына. – Килермен, шимбә турында әйттеләр инде миңа.

– Юк, Чанга, син миңа шуны әйт әле. Нишләп шулай килеп чыкты? Менә мин мәктәптә «өчкә – көчкә» генә укыдым дияргә була, дәреслекләр, контроль эшләр дип, баш ватканым булмады. Бер сүз белән әйтсәк, күңелле укыдым. Һәм бүген кайда мин? Ә син кем, «отличник»?

Алмазга тиешле сумманы тоттырып, сыйныфташы чиста, ялтырап торган «Лексус»ына утырып, китеп барды.

...Шимбә көнне ресторанның ачык террасасына сыйныфташлар җыелды. Сәбәбе, инде әйтелгәнчә, мәгънәле: мәктәпне тәмамлаганга ун ел үткән! Яшьтәшләрнең тышкы кыяфәтләрендә әлегә әллә ни үзгәрешләр сизелми. Кочаклашып күрештеләр. Очрашуга барысы да чиксез шат: ничек кенә булмасын, сагынылган. Үткән дистә ел югарылыгыннан караганда, укытучыларның да начарлыгы, усаллыгы хәтердән юылып беткән. Беркемгә дә начарлык эшләргә уйламаган, бары тик төпле белем бирергә тырышкан гади укытучылар гына алар бүген. Ачыкланганча, сыйныфташлар барысы да диярлек гаиләле икән инде. Хәтта аерылып өлгергәннәре дә бар. Укыганда, сыйныф старостасы булган Миләүшә балалары булганнарның кулларын күтәрүләрен сорагач, берничә көн элек кенә Алмазга машинасын юдырган әлеге дә баягы Хәмит кенә кулын күтәрмәде.

– Мин яшь бит әле! Бераз үзем өчен яшәп каласым килә, – дигән булды ул, сыйныфташларының тел очына эленеп калган «Нишләп?» дигән сорауга җавап итеп.

Аннары сүз кемнең нинди югарылыкларга ирешүе, кайда эшләве турында китте. Сыйныфташларның тормышы ярыйсы гына килеп чыккан: яртысы югары белем алган, үз белгечлеге буенча хезмәт итә. Кемдер ныклы адымнар белән бизнес өлкәсенә кереп бара. Арада хәрбиләр дә бар: бер майор, ике өлкән лейтенант.

– Ой, кордашлар! Онытып торам! – дип, «шук телле» Хәмит сикереп торды. – Безнең арада иң текә кеше кем икәнен беләсезме? Иманым камил, берегезнең дә башына килмәячәк! Хәзер күрсәтәм...

Хәмит бер читтә аларны күзәтеп торучы ресторан хезмәткәре янына килде дә пышылдап кына нәрсәдер хакында серләшеп алды. Ә берничә минуттан зур плазма экранында видеоролик пәйда булды. Барысы да танып алды – тагын бер сыйныфташлары, мәктәптә «бишле» билгеләренә генә укыган «Чанга»! Укытучылар киләчәктә фән өлкәсендә зур югарылыкларга күтәрелергә тиеш дип исәпләгән тырыш Алмаз! Сүз уңаеннан, егет үзе дә ышана иде моңа. Сыйныфташлары мыскыллап көлгән вакытларда да: «Борчылмагыз, барыбер үз дигәнемә ирешәчәкмен!» – дип кенә әйтеп килде. Ләкин, ни кызганыч, видеороликта барысы да нәкъ киресе: Алмаз кеше машинасын юа!..

Әлбәттә, бу хәл беркемне дә битараф калдырмады. Кемдер шаркылдап көлде, кайберәүләр Алмазны кызгануын яшермәде.

– Юк, болай гадел түгел! Ул бит бик сәләтле кеше...

– Әтиең кебек кеше машинасын юудан узмаячаксың дип әйткәнгә, ачуы килә иде бит әле...

– Ә нишләп бүген монда килмәгән соң әле үзе? Әйтүче булмаганмы әллә?

– Аңа да әйтелде әйтелүен. Ояла торгандыр инде, мескен...

Шулвакыт терраса янына бер зур машина килеп туктады. Джип. «Митсубиси Паджеро». Бу кәттә автомобильне күрми калу мөмкин түгел иде. Ир-атларның игътибары мизгел эчендә шул тарафка күчте. Кемдер сызгырып ук куйды. Билгеле, елкылдап торган кап-кара джип мул тормыш турында хыялланучы хатын-кызларда да кызыксыну уятмый калмады. Ә берничә мизгелдән барысын да шок хәлендә калдырган вакыйгага булды. Джип эченнән сыйныфташларның барысына да бик таныш тоелган йөзле яшь кеше чыкты. Затлы киемнән. Күн туфлиләре белән бик кыйммәтле икәнлеге күренеп торган галстугы бер-берсен тулыландырып тора, дисәң дә була. Бер сүз белән әйткәндә, игътибар белән карамасаң да, киенә белә торган бай кеше икәнлеге әллә кайдан кычкырып тора. Әле генә алар көлешә-көлешә видеороликтан караган, майга баткан кием кигән сыйныфташлары – машина юучы «Чанга» иде бу.

Алмаз килешенгән вакытка килеп җитә алмавы өчен гафу үтенде, барысы белән дә кул бирешеп күрешеп чыкты. Видеоролик авторына чират җиткәч, Хәмит янә үз роленә керде:

– Менә бит, килеп тә җиттең! Булдыргансың! Хуҗаң җибәрде, димәк? Джипны берәр клиентыңнан алып тордыңмы? Хәзер ел буе бушка юарсыңмы инде? Ә кыяфәте! Кыяфәтен карагыз әле! Шә-ә-әп! – дигән булды ул, үз уйларының дөреслегенә үзе дә ышаныр-ышанмас кына. – Хәзер мондый костюмнарны прокатка алу күпмегә төшә инде?

Алмаз аның төртмәле сүзләренә җавап кайтаруны кирәк тапмады, ихлас елмаеп торуында булды. Ә бу исә Хәмитнең җенен котыртты.

– «Штрафной» җиффәргәндә, «бишле»гә генә укыган кешенең хыяллары ничек итеп челпәрәмә килгәнен сөйләрсең әле. Синең белән шулай килеп чыкты бит, әйеме?

– Әйе, шулайрак булды шул, – диде Алмаз тыныч кына. – Аның каравы синең барысы да шәптер? Машинаңны күрдем инде. Ә калган яктан?

– Борчылма, яшьти, – дип, Хәмит тәкәббер генә башын күтәрде. – Синекеннән яхшырак.

Өстәл янына утырышыр вакыт җитте. Ләкин сыйныфташлар аракы эчү белән бик мавыкмады. Күбрәк аралашу, бер-берсенең хәлен сораштыру кызыграк иде. Дүрт сыйныфташның очрашуга килмәве турында сүз чыккач, староста Миләүшә Маратның бәлагә тарыганлыгын әйтте. МЧСта хезмәт итүче Марат фаҗига булган урынга баргач, бик каты янган. Янгын сүндерүчеләрне көткән арада бер иптәше белән салым инспекциясе бинасындагы кешеләрне коткарганнар, ләкин үзләре ут эчендә калганнар һәм бик нык зыян күргәннәр. Марат хәзер үзәк хастаханәдә икән. Хәле яхшырып килә, ләкин инде алга таба яраткан эшендә МЧСта хезмәт итү тәтемәячәк, дигәннәр.

Маратның сәламәтлеге өчен күтәреп куйдылар. Аны барысы да ярата. Шуңа күрә Маратның тизрәк савыгуын теләп әйтелгән сүзләр барысы да ихлас иде.

Аннары «Яшел Баш»ның да очрашуга килмәвен искәрделәр. Зур күзле Нәсимәне икенче сыйныфны тәмамлаганнан бирле шулай дип йөртәләр. Беренче сентябрь алдыннан гына, өченче сыйныфка барырга тиешле Нәсимә ишегалдындагы таганда атынган вакытта кулы ычкынып китеп, егылып төшә. Нәкъ бер тимер кисәгенә эләгә. Бик катлаулы операция кичерергә туры килә аңа. Ярты башына җөй салалар. Матур көдрә чәчләрен дә кыркыйлар. Менә шуннан соң Нәсимә мәктәпкә яшел төстәге берет киеп йөри башлады. Яшьтәшләре аңа шундук «Яшел Баш» дип исем кушты. Дөрес, күпмедер вакыттан соң Нәсимәнең чәчләре үсте, тик «Яшел Баш» кушаматы бүгенгәчә сакланып калды.

– Кайсыгыз белә, нишләп бүген «Яшел Баш» килмәде икән? – диде кайсыдыр.

– Мин беләм. – Алмаз әйткән сүздән сискәнеп киттеләр. – Командировкада ул.

– Опа! – Игътибар үзәгендә кабат Хәмит. – Миңа кемдер «Яшел Баш»ның медицина университетына кергәндә, имтихан тапшыра алмавын әйткән иде. Беләсезме, ул кая эшкә урнашкан? Хастаханәгә, санитарка булып! Безнең чебен тимәс чер итәр чибәркәебезне кулына швабра, чүпрәк, авырулар астыннан чыгарып түгә торган «утка» тоткан килеш күз алдына китерәсезме? Һәм шул санитаркага нинди командировка булырга мөмкин инде? Күрәсең, безнең күзгә күренергә оялгандыр. Кыскасы, үзегез дә күреп торасыз, электән үк әйтеп килдем, хәзер дә кабатлыйм – мәктәптә яхшы билгеләргә генә уку әле киләчәгең якты, тормышың мул булыр дигән сүз түгел. Киресенчә, андыйларга тормышта иң арттан сөйрәлергә туры килә.

Бу сүзләр әллә ни тәэсир итмәде. Әллә Хәмитне хуплап, әллә сүзнең нәрсә хакында барганын аңлап бетермәгән Наил исемле егет кенә хихылдап куйды. Алмаз «шук телле»гә игътибар белән карады. Шулвакыт аны Миләүшә читкә әйдәкләде.

– Әле генә башыма барып җитте, Алмаз. Нәсимә – синең хатының бит, әйеме? Балалар хирургымы? Ике ел элек минем малайны өлкә хастаханәсенә консультациягә җибәргәннәр иде. Анда бик яхшы балалар хирургы эшли, диделәр. Ул чагында мин үзем анда бара алмадым, эштән җибәрмәделәр. Ирем китте. Кайткач, шул хирургның фамилиясен әйтте, бик яшь, сөйкемле ханым, дип сөйләде. Ләкин ул мин белгән Нәсимәнең фамилиясен әйтмәде... Хәзер аңладым, димәк, синең бүгенге фамилияңне әйткән? Һәм, аңлат әле, нинди командировка ул?

– Нәсимәне Казакъстанга чакырдылар, республика балалар клиникасына. Бер ай шунда инде. Катлаулы операцияләр үткәрә, коллегаларын өйрәтә.

Миләүшә Алмазны кочаклап алды.

– Мөмкинлегегез булса, безгә кунакка килегез! Шунда ук яшибез. Тик... эти-әнием юк инде... Ә синекеләр исән-саумы?

– Рәхмәт, Миләүшә. Нәсимә дә сине күрергә шат булыр, дип уйлыйм, – диде Алмаз. – Ә минекеләр исән, Аллага шөкер. Әни байтактан пенсиядә инде. Әтине дә СТОдагы эшеннән көчләп диярлек чыгардым. Җитте, әнә, оныклары кирәген бирә хәзер.

– Балаларыгыз да бармыни? – диде Миләүшә, ихлас елмаеп. – Ничәү?

– Ике кыз. Игезәкләр. Дүрт яшь инде. Икесенең дә эчендә мотор – бер тик тормыйлар, – дип елмайды Алмаз. – Синең дә, аңлавымча, балаларың бар?

– Бар. Бер бөртек. Бик еш авырый торган. – Миләүшә моңсу гына елмаеп куйды. – Ә авырмаган чакларында ул да моторлы. Балаларны бер-берсе белән таныштырганда, начар булмас иде.

– Менә Нәсимә кайтсын инде, таныштырырбыз, боерган булса, – дип вәгъдә бирде Алмаз.

Соңрак барысын да истәлек өчен күмәк фотога төшәргә чакырдылар. Тырыштылар, кысылыштылар, бөтенесенең дә бер кадрга керәселәре килде. Билгеле инде, безнең «шук телле» егет монда да үзен күрсәтми калмады – беренче рәттә торучыларны эткәләп-төрткәләп, уртага кереп басты. Ә нәрсә? Үзәктә аннан башка кем булсын инде?! Очрашу истәлеген мәңгеләштерү официант җилкәсенә төште. Кирәге була калса дип, берничә тапкыр төшерде. Күмәк фото шунда ук һәрберсенең телефонына җибәрелде. Тагын ун елдан соң очрашканда көлешеп искә алырга менә дигән сәбәп. Хушлашканда, тагын очрашырга вәгъдәләр бирешеп таралыштылар, бер-берләренә уңышлар теләделәр. Хәмит тә үзенекен әйтми калмады:

– Минеке кебек күп акча телим барыгызга да!..

...Алмаз очрашудан кайтканда, руль артына үзе утырырга базмады, күршедә яшәүче дустын чакыртып китерде. Ни дисәң дә, ике бокал шампан шәрабы эчте бит. Ә юл йөрү мәсьәләсенә ул кечкенәдән җитди һәм аеруча сак карады. Әтисенең мәктәбе. «Авариядә үзем генә зыян күрсәм, бер хәл, – дип әйтә торган иде аның әтисе. – Бернинди гаебе булмаган башка берәүнең тормышын куркыныч астына куйсам, яки гарип калдырсам – монысы бөтенләй башка, гафу ителмәслек нәрсә...»

Алмаз үз йорты янына кайтып җиткәч тә керергә ашыкмады. Капка янындагы эскәмиягә чүгәләп, әле генә үткән очрашуның кызыклы мизгелләрен исенә төшереп утырды. Сыйныфташларын кабат күрүенә ихлас шат иде ул. Нәсимәнең генә очрашуда катнаша алмавына үкенде. Нәсимә, Нәсимә... Аңа кирәкле бердәнбер хатын-кыз. Аның хатыны. Кызларының әнисе. Нәсимәнең теге вакытта аның белән киногa барырга ризалашуына әле һаман да аптырый Алмаз. Нинди кино карадылар соң әле? Мөһим түгел, ул бит экранга карамады, сеанс тәмамланганчы күз алдында бары тик «Яшел Баш» кына булды. Очрашулары да очраклы гына килеп чыкты. Эш урынында кадакка эләгеп җәрәхәтләнгән кулын бәйләтергә дип хастаханәгә барган иде. Шунда күреп алды Нәсимәне. Әйе, ул чагында кыз санитарка булып эшли иде. Үзенең дә инде, киләчәген әлегә әтисе эшли торган техник хезмәт күрсәтү станциясеннән башка күзалламаган чагы. Дөрес, мәктәпне тәмамлагач ук, институтның читтән торып уку бүлегенә керде ул. Әти-әнисенең үгетләвенә каршы, әлегә көндезге бүлеккә күчәсе килмәвен әйтте. «Ни өчен? Аңлат!», – дип таләп итте әтисе. «Мин әлегә үземне тапмадым, – диде Алмаз. – Ярыймы шундый җавап?»

Икенче елны исә, берничә имтиханны уңышлы гына тапшырып, көндезге бүлеккә күчте, логистика өлкәсен сайлады. «Нәрсә соң ул логистика, нәрсә белән ашыйлар аны?» – дип кызыксынды әтисе. Улының аңлатмаларын тыңлаганнан соң, бераз уйланып утырды да үз фикерен әйтте: «Ә нәрсә, син хаклы, улым!»

Логистиканың ни икәнлеге турында Нәсимә дә сорады. Беренче тапкыр шул көнне кинотеатрдан кайтышлый алар киләчәк турында, еллар буе күңелдә йөрткән хыялларны ничек итеп тормышка ашыру турында сөйләштеләр. Алмазның шиге юк иде – Нәсимә барысына да ирешәчәк!

– Сәер кеше син, Алмазик!

Нәсимә авызыннан әйтелгән бу сүз егеткә ничектер тылсымлы тәэсир итте.

– Минем сәерлегем нәрсәдә инде?

– Миңа үземә караганда да күбрәк ышанасың, – диде Нәсимә, ихлас елмаеп.

– Чөнки мин сине яхшы беләм, – диде дә, тагын нәрсәдер өстәргә җыенып авызын ачты, тик монысына егетнең кыюлыгы җитмәде.

– Беләсең? Соң син бит мәктәптә минем якка бөтенләй борылып та карамадың.

Нәсимәнең тавышында беркадәр үпкә сиземләнде.

– Менә сиңа мә! – дип каршы төште Алмаз ихластан гаҗәпләнгән кыяфәт белән. – Мин ун ел буе синнән күземне алмадым, бик беләсең килсә.

Һәм сагаеп калды – менә хәзер Нәсимә фыркылдап китеп барачак. Кыз дөрестән дә фыркылдап куйды. Ләкин Алмаз уйлаганча түгел:

– Ә син калын тиреле икәнсең, Алмазик! Менә мин ул синнән күземне алмадым! – Нәсимә дә бу сүзләрне әйтермен дип уйламаган иде бугай...

Шушы мизгелдән алар бер-берсеннән берни дә яшермәс булдылар. Инде менә тугыз ел шулай дәвам итә. Карьераны да параллель рәвештә кордылар. Сүз дә юк, Нәсимәгә авырракка туры килде: балага узу, аны тугыз ай буе карынында йөртү, бәләкәчләр тугач, ярты ел алар белән мәш килү. Алмазның әнисе: «Бар инде, кызым, укуыңны тәмамла. Күреп торам бит, синдә менә дигән хирург утыра. Ә оныклар... Бабалары белән икәүләп ничек тә җаен табарбыз», – дигәнче. Рәхмәт аларга, әти-әнигә.

Нәсимә әле интерн вакытында ук берсеннән-берсе катлаулырак операцияләрдә катнашып килде. Яшьтән үк сиземләве яхшы булды аның, куллары алтын. Хәзер инде аның җитәкчелегендә операция ясау өчен, кем әйтмешли, чират торалар. Менә хәзер Казакъстанга ук чакырылды.

Алмазның да эше җайлы гына барды. Әйе, ул да хезмәт юлын әтисе эшләгән авторемонт салонында башлап җибәрде. Ләкин логистика бүлегендә юкка гына укымаган булып чыкты. Аны аңладылар, теләктәшлек күрсәттеләр. Әтисенә дә, бергә эшләгән иптәшләренә рәхмәтле ул. Ә бүгенге техник хезмәт күрсәтү станцияләре челтәренең уңышлары әтисенең – «барлык эшләрдә дә беренче чиратта хокук, законнан тайпылмау, икенче урында тизлек һәм сыйфат булырга тиеш» дигән тәгълиматына тугрылыкка бәйле булды. Бүген Алмаз бу сүзләрнең мөһимлеген үзе дә аңлый. Бер-береңә булышу, кеше хәленә керү кебек сыйфатлары да – әтисенең тәрбиясе. Аның компаниясендәге кешеләр эш урыннарының кадерен белә. Ләкин тормышта төрле хәлләр була бит. Кеше чирләп китәргә, бәлагә тарырга, гаиләсендә кичектергесез мәшәкатьләр килеп туарга мөмкин. Алмазның компаниясендә андыйларны алыштырып торырдайлар һәрвакыт табыла. Кайвакыт үзе дә «кара» эштән чирканмый. Теге вакытта сыйныфташы «Лексус» белән килеп туктаган көнне дә бер хезмәткәре төнлә сукыр эчәгесе ялкынсынып эшкә килә алмагач, машина юарга үзе алынды. Беразга гына,

берәр слесарь үз эшеннән бушаганчы. Нәкъ шул вакытта төртмә телле сыйныфташы күзенә эләкте дә инде. Ә нәрсә булган? Алмаз, гомумән, бер эштән дә тартынып тормады. Урынбасарлары да. Нәсимә аларны лаеклы рәвештә универсаллар дип атый. Аның үзенә дә катлаулы вазгыятьләрдә терапевт та, инфекционист та, хирург та булырга туры килә...

...Тагын бер эш атнасы үтеп китте. Иртәгә җомга. Аннары? Ике ял көне. Исенә төште – кызларын ипподромга алып барырга сүз бирде бит. Бер тапкыр барганнар иде, атларны, кечкенә пониларны күзәттеләр. Инде менә тагын алып бар әле, дип ялыналар.

Җомга көнне иртән Алмаз үз кабинетына керде, видеокүзәтү камераларын эшләтеп җибәрде дә заявка тутыра башлады: диагностика үткәрә торган яңа җайланма сатып алып, сынап карарга кирәк. Күз чите белән генә экранга карап куйган иде, якын дусты, аягында нык басып торучы эшмәкәр Андрей килгәнен күреп алды. «Лексус»та килгән. Тукта! Ул бит күптән түгел генә бу машинаны үзе юды! Тик ул чагында аның хуҗасы сыйныфташы Хәмит иде. Алмаз, Андрей белән исәнләшергә дип, кабинетыннан чыкты. Чыкты да шундый күренешнең шаһиты булды. «Лексус» янына тыны кысылган, манма тиргә баткан Хәмит – затлы машинаның теге вакыттагы «хуҗасы» килеп җитте. Еларга җитеп, Андрейга ялына, соңга калуы өчен кичерүен үтенә, «Андрей Владимирович» дип дәшә.

«Пик сәгате, маршруткага керерлек түгел, көчкә такси яллап килдем артыгыздан...» – дип аклана.

– Берәр яңа төрле сылтау табар идең ичмасам. Көн дә бер сүз. Булды, туйдым! Бүген миңа иртүк машина кирәк икәнен белдең бит. Белдеңме? Нигә карап куймадың? Нигә двигателе шакылдый? Нигә мин аны үзем ремонтларга тиеш? Кыскасы, осталар әйбәтләп карасын, юдырып, офис янына китереп куй да гариза яз. Иртәгәдән миндә эшләмисең! Аңладыңмы?

Хәмит кызарынды, бүртенде, елап җибәрер дәрәҗәгә җитте.

– Андрей Владимирович! Гафу итегез инде, соңгы тапкыр.

Андрейның бу сүзне беренче генә ишетүе түгел иде, күрәсең. Ачуы кабарды. Түземлеген җуеп:

– Җитте, шыңшыма! Такси чакыр миңа! – дип җикерде.

Алмаз алар янына килде. Андрей, үз кул астында эшләүче Хәмитне онытып, техник хезмәт күрсәтү станциясе хуҗасы белән кочаклашып күреште.

– Алмаз! Ничек хәлләр, дускай? Сине күрүемә бик шат. Ничек, Нәсимә кайттымы әле? Юкса минем хатын: «Нәсимә белән игезәк кызларын күрәсем килә!» – дип, бөтен колак итләремне ашап бетерде инде.

– Андрюха, аптыраган инде, үзем дә көтә-көтә көтек булдым, – диде Алмаз, елмаеп. – Ларисага әйт, Нәсимә, кайткач та, иң беренче аңа шалтыратачак, диген. Ә бездә ни йомыш соң?

– Әй, минем бүген уникедә чит ил партнёрлары белән очрашу. Аңынчы ательега кереп чыкмакчы идем. Чалбар балагын кыскартырга бирдем. Үзең беләсең, ул европалылар бик нәзберек халык. Менә шул. Ә минем машина шакылдый башлаган. Минем булдыксыз йөртүче кичә тикшермәгән. Бүген бөтенләй эшкә соңга калды. Әй, ярар ла! Иртәгә икенче кеше алам. Ә монысын бүген үк эштән куам, – дип аңлатты Андрей.

Ниһаять, Андрейның йөртүчесе дә Алмазга карады. Оятыннан җир тишегенә керер дәрәҗәгә җитүнең нәрсә икәнен шул мизгелдә аңлады Алмаз. Аның сыйныфташы, берничә көн элек, юк, әле мәктәптә укыганда ук, Алмаздан көлгән, аңа хәерче, «кара эшче» язмышы фаразлаган төртмә телле сыйныфташы Хәмит хәзер үзе нәкъ шушы хәлдә. Аның үз күзләренә ышана алмыйча газаплануын, башында төрле уйлар бөтерелүен Алмаз ачык тоемлады. «Димәк, хуҗа – Чанганың, машина юучы Алмазның танышы? Ә бәлки, якын дустыдыр да? Ә бу Алмаз бөтенләй дә машина юучы түгел. Димәк, ул босс! Әнә бит, Андрей Владимирович белән тигез дәрәҗәдә сөйләшә. Ә аның белән «Син!» дип аралашучылар күп түгел. Менә сиңа Чанга! Димәк, барысын да аңлады инде бу. Димәк, үч алачак. Нишләмәк кирәк, үзем гаепле, нәрсә генә булса да, йотасы булыр...»

– Андрей дустым, әнә минем гараждагы берәр машинаны алып тор, – диде Алмаз. – Ә синең чибәркәең әзер булгач, машина йөртүчең аны синең офис янына илтеп куяр, ә минекен, сиңа кирәге калмаса, монда алып кайтыр.

– Ә нәрсә? Яхшы фикер бу, – дип шатланды Андрей. – Рәхмәт, туган!

Аннары Андрейга сыйныфташы да ишетерлек тавыш белән:

– Андрюха! Эш хакына түгел, дуслык хакына! Машина йөртүчеңә тагын бер шанс биреп кара инде. Эштән кума инде, яме? – диде.

Андрей Алмазга сәерсенеп карап куйды:

– Сез танышлармы әллә?

– Бергә укып йөргән идек, – диде Алмаз. – Болай начар егет түгел ул...

– Син әйткәч, ярар, эшләп карасын соң. Тик монысы чын-чынлап соңгы шанс булачак!

Бу сүзләрне Андрей Хәмитнең күзләренә туп-туры карап әйтте.

«Лексус»ны ремонт остаханәсенә алып кереп киттеләр. Алмаз «шук телле» сыйныфташын үз кабинетына әйдәкләде. Хәмит биредә барысы да зәвык белән эшләнгәнен искәрде. Алмаз ым кагып кына аны кәнәфигә утырырга чакырды. Үзе каршыдагы урындыкка утырды.

– Мин сиңа җавап бирергә тиеш, – дип башлады Алмаз сүзен, сыйныфташының күзләренә карап. – Теге вакытта очрашуда бер сүз әйтмәдем. Үзем турында әйткән пычракларыңны кичердем, анысы ярар, ә менә Нәсимә синең сүзләрне ишеткән булса, рәнҗер иде. Әйе, ул кайчандыр санитарка булып эшләде, ә хәзер әйдәп баручы балалар хирургы. Мәктәптә укыганда ук хыялланганча. Очрашуга да, әйтүемчә, командировкада булу сәбәпле килә алмады – бер айдан артык инде, Казакъстан Сәламәтлек саклау министрлыгы үтенече белән шунда эшли. Казакъстандагы коллегаларын катлаулы операцияләр үткәрергә өйрәтә. Мин дә, күрәсең, юкка гына яхшы укымаганмын. Бу миңа университетта төпле белем алырга да ярдәм итте. Һәм мин машина юучы түгел. Дөрес, моның бер начарлыгын да күрмим, кирәк чакта рәхәтләнеп ул эшне дә башкарам. Мин, синең тел белән әйтсәк, кәттә бизнесмен. Ә хәзер уйлап кара, әлбәттә, җавап бирмәсәң дә була, сиңа, мисал өчен, менә дигән конферансье яки ток-шоу алып баручысы булырга нәрсә комачаулады? Мин беләм, син аудиторияне тотып тора беләсең. Кызыл сызыкны узмаганда, шаяра да беләсең. Әле соң түгел бит. Үзеңә ошаган эш белән шөгыльләнүдән дә яхшысы юк. Укырга кирәк икән

– укы. Сиңа бит әле өч дистә дә юк. – Һәм бераз уйлап торганнан соң өстәп куйды. – Уңышлар сиңа, сабакташ!

Сыйныфташы урыныннан торып басты. Бер мизгел уйланып торды да Алмазга кулын сузды.

– Рәхмәт, Алмаз!.. Һәм гафу ит мине. Мәктәптә укыган чаклардан бирле мыскыллауларым өчен гафу ит. Нәсимәгә дә минем гафу үтенүемне әйт. Син хаклы, әле соң түгел!

...Ике ел үтте. Утыз беренче декабрьдә Алмазлар йортына бала-чага җыелды: үзләренең игезәк кызлары, Андрейның кызы, Миләүшәнең малае. Яңа елны, Кыш бабай белән Кар кызын каршыларга әзерләнәләр. Аларның киләсен Миләүшә алдан ук белде. Балалар берсен-берсе узышып ятлаган шигырьләрен кабатлыйлар, түземсезлек белән ишек ягына карап-карап алалар: кайчан килә соң инде Кыш бабай белән Кар кызы?

Һәм менә ишек кыңгыравы шалтырады. Балалар борчак кебек ишек ягына атылдылар. Нәсимә ишекне ачу өчен алар арасыннан көчкә үтте. Бусагада мәһабәт буй-сынлы, матур тун кигән, аркасына зур бизәкле капчык күтәргән Кыш бабай пәйда булды. Ләкин аның белән Кар кызы юк иде. Кыш бабайның бу хәлнең сәбәбен ничек итеп аңлатуы балаларга да, өлкәннәргә дә ошады:

– Оныгым чирләп китте шул әле, шуңа килә алмады. Юк, курыкмагыз. Нык түгел, ләкин бүген ятып торса яхшырак булыр, дидем. Бер утыруда ике эскимо ашарга ярыймыни инде?.. Ничек уйлыйсыз, ярыймы?

– Юу-у-ук! – дип кычкырды өйдәгеләр барысы бергә.

– Менә үзенә дә шулай дип әйтермен, – диде Кыш бабай, мыек астыннан гына елмаеп.

Һәм башланды! Шигырьләр, табышмаклар... Алмазның кызлары шпагат ясарга өйрәнгәнлекләрен күрсәтте, Миләүшәнең улы ел буе бер тапкыр да авырмавы турында сөйләде... Балалар Кыш бабайга бал кебек ябышты, таягын тотып, бияләен киеп карадылар...

– Карале, Алмаз, – диде Миләүшә, егетнең колагына пышылдап. – Бу Кыш бабайның тавышы таныш тоелмыймы сиңа?

Кыш бабай үзе турында сүз барганын аңлады булса кирәк, аларга күз кысып алды. Ә инде китәргә дип, ишегалдына чыккач, сакал-мыеклары белән бергә башлыгын салды. Аларның сыйныфташы – төртмә телле Хәмит иде ул.

– Таныш булыйк, цирк училищесы студенты, булачак клоун. Каникулларда бераз акча эшләп алырга булдым. Гастрольләр белән безнең шәһәргә килсәгез, иң яхшы контрамаркалар сезнеке! – диде Хәмит, елмаеп.

Алмаз аны кочаклап алды.

– Менә бит, тапкансың үзеңне! Без барыбыз да синең өчен шат.

Кыш бабай кыюсыз гына:

– Үткәннәр өчен кичерегез, яшьтиләр! Һәм... рәхмәт сезгә!.. – диде.

Ләбиб
Лерон

КҮҢЕЛЕМӘ ШИГЫРЬ ОЯЛАДЫ...

Сизәсезме, салкыная көннәр...

Сизәсезме, салкыная көннәр –
Кар уйнаклый җирдә, боз ката...
Күксел көннең кырпак иртәләре
Көзнең өянәгеп кузгата.

Сизәсезме, салкыная көннәр –
Җил себерә карны... Җир – шәрә!
Җирнең шәрәлеге – безгә әллә
Бер кисәтү, әллә ишарә.

Сизәсезме, салкыная көннәр –
Мактанырлык түгел хәлебез:
Йөзе качкан сырхау көзгә карап,
Шөбһәләнеп торган мәлебез!

Сизәсезме, салкыная көннәр,
Салкыная бара дөньясы...
Шом тантана иткән шул дөньяда
Зәхмәт үзе бүген туй ясый.

Сизәсезме, дөнья белән бергә
Салкыная бара кешеләр...
Күпме язмыш, ышыкланам, диеп,
Ятим куышларда күшегә.

Сизәсезме, салкыная бара
Илләр белән илләр арасы...
Сөртелмәгән бәллүр көзгеләрдән
Без торабыз гүя карашып.

Ләбиб ЛЕРОН (1961) – *шагыйрь, прозаик, драматург; М.Җәлил исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Сине генә сөям», «Сөяксез тел», «Бәхеткә биш минут кала» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Сизәсезме, салкыная көннәр –
Учак эзли күңел күзләрдән...
Бер уч җылы җитми...
И Ходаем,
Бер җылылык бирче безләргә!

Шигырь оялады күңелемә...

Бер-бер хикмәт килеп чыкмагае –
Шигырь оялады күңелемә.
Бар хисләрем, мөлдерәмә булып,
Түгелергә тора, түгелергә.

Күңелемә шигырь оялады! –
Бер-бер хикмәт килеп чыкмагае.
Шигырь мине Ходай бөртеге дип,
Бөтенләем белән йотмагае!

Килеп чыкмагае бер-бер хикмәт –
Күңелемә шигырь оялады!
Йөрим гүя гомер тавында мин –
Барлап йөрим тормыш кыяларын.

Оялады шигырь күңелемә –
Килеп чыкмагае бер-бер хикмәт.
Бар теләгем чынга ашсын диеп,
Өмет белән бүген гомер итмәк!

Бер-бер хикмәт килеп чыкмагае –
Оялады шигырь күңелемә...
Ышандырып кара мине, әйдә,
Бу хәлнең син алай түгеленә!

Кемнәргәдер җырым дәва булыр,
Кемгәдер ул, бәлки, булыр икмәк...
...Шигырь оялады күңелемә –
Түгелмени бу бер Олы Хикмәт?!

Әннәй

«Әни», диләр, яки «әнкәй», диләр –
Күпләр шулай дәшә үз итеп.
Әни, диеп йөрсәм әнине мин,
Сөйләмәс тә идем сүз итеп.

Бер карасаң, монда искитәрлек
Аерма юк кебек әллә ни:
Мин әбине «әнкәй» диеп үстем,
Әниемә дәштем «әннәй» дип!

«Ән-нә!» диеп телем ачылгандыр...
«Әннәй», бәлки, шуннан киләдер?! –
Моны белсә, әби беләдер дә,
Моны белсә, әни беләдер...

Әни эштә булган... Мин, күрәсең,
Әби белән күбрәк йөргәнмен:
Бәлки, шуңа «әнкәй» дигәнмендер –
Әни кебек кабул күргәнмен?!

Җәйләүләрдә сыер сауды әннәй,
Кибетче дә булды соңыннан...
«Әннәй, прәнник бир әле!» – дип, мине
Үчеклиләр иде сеңелләр.

Әни-әнкәйләргә «инәкәй» дип,
Дәшә күпләр безнең якларда...

И, ояла идем, әниемә
«Әннәй», диеп әйткән чакларда.

Шулай дигәнемне ишетсәләр,
Кызлар көләр төсле иде бик...
Мәктәп бетергәнче, «әннәй», дидем –
Әйтәлмәдем тәки: әни, дип!

Казаннарга киткәч, гел «әни» дип,
Читенсенеп дәштем әнигә.
Шул чакларны искә төшерәм дә...
Кыен булып китә әле дә.

Әни сүзе – изге, кадерле сүз,
Газиз миңа «әннәй» сүзе дә.
Әннәй, дисәм, дөньям балкып китә,
Кояш яна кебек йөземдә!

«Әннә!» диеп, телем ачылгандыр –
«Әннәй», бәлки, шуннан киләдер...
Моны белсә, әби беләдер дә,
Моны белсә, әни беләдер!

Их, сорарга иде үзләреннән
Җайлы вакыт табып берара...
...Әби дә юк бүген, әни дә юк –
Берсе дә юк инде сорарга.

Дисбеләр

Ит алырга кайткан шагыйрь яшьти
Авылына – ике дус белән.
Итен белмим, әмма авылдан ул
Алып килгән иске дисбеләр!

– Моның берсе – Шәкүр каракныкы!
Нинди затлы! Кара син аңа!
Бусы – Закир хәзрәтнеке! – диеп,
Бүләк итте берсен миңа да.

– Шәкүр карак?! Китче! Шыттырмале!
Сөйләмә син юкны, булмасны!
Закир хәзрәт, дисең... Анысы кем?
– Әткәсе ул – Фәтхи Бурнашның!

Яшьтигә мин бик ышанып бетмим:
Шаярта ич, димен, дус минем...
Ә шулай да кулда әйләндерәм
Закир хәзрәт тоткан дисбене...

...Шулчак яшьти кинәт гаип булды.
Ә мин... күзне ачып... уяндым...

– Бу төш кенә булган икән бит! – дип,
Мин, әлбәттә, гаять куандым.

Иң гаҗәбе: кулда дисбе иде.
Каян килгән миңа – белгән юк...
...Бүген иртән яшьти шалтыратты:
Ит алырга кайтып килгән ул.

Соңгы патриот

Кәефсез ул бүген...
Аның тагын –
Йөзе чытык, кашы җимерек...
Дөньясы – бик котсыз...
Гүя бер корт
Йөри аның җанын кимереп.

Үзенә һич урын таба алмый –
Әрле-бирле килә бүлмәдә.
Иртәгә ул, бәлки, борчылмас та...
Алай-болай бүген үлмәсә.

Йодрыкларын йомарлаган әнә –
Ул нишләргә белми... Чарасыз...
Кайчак бүлмәдән үк... Юк!.. Бу илдән...
Килә аның чыгып чабасы.

Йөренә ул шыксыз бүлмә буйлап –
Тибеп китә ауган итеген.
Әрле-бирле килә...
Таптап үтә
Идәндәге кояш китеген!

Тузан баскан тәрәзәгә килеп,
Карап тора чебен эзенә...
Шул арада, кинәт, сугып ала
Ватык көзгедәге йөзенә!

Ничәмә көн менә, ничәмә ай
Тынгы табалмый ул җанына:
Гаҗизләнеп, тыштан нидер эзләп,
Тәрәзәгә килеп сарыла!

Дивардагы иске сәгать кебек,
Вакыт калган гүя туктальп.
Әнисенең фотодагы йөзе
Карап тора аңа укталып.

Бу халәттән ничек котылырга,
Алга таба аңа нишләргә –
Танк кебек сытып, алдау-ялган
Килгән чакта синең өсләргә?

Бушбугазлар буш сүз сөйләгәндә –
Трибунадан торып, мөнбәрдән,
Ничәмә кат кайтып егылды ул
Үткәндәге шанлы көннәргә.

Беркая да китмәс ул бу илдән,
Башка илне аңа тиң күреп.
Яши бирер кендек каны тамган
Туган туфрагында тир түгеп.

...Кыйбла якка карап яткан мәлдә,
Кемдер дөбердәтте ишекне...
...Һәм ул «Бабай! Ач ишекне!» – дигән
Җанга якын тавыш ишетте.

Редакциядән:

Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.

Гөл
Мирһади

ГИТАРА

хикәя

1

Менә шундый минутларда мин Нәфистән чынлап торып көнләшәм. Юк, пединститутның тулай торагында кысан бүлмәгә җыелышып, ачкан авызларын ябарга онытып, Нәфисне тыңлаган икенче курс кызларыннан түгел. Алар күп, сабыйларча беркатлы. Алардан түгел, кулындагы гитарадан көнләшәм. Нәфис аны шундый кадерләп кочаклаган... Назлы бармаклары белән йомшак кына итеп кылларына чиртә. Искедән-иске өстәл янына терәп куелган өр-яңа «полировкалы» тумбочкага менеп кунаклаган да йомшак тавышы белән җырлый да җырлый. Фирзәр Мортазинның бөтен репертуарын җырлап чыкты бугай инде, әле туктарга исәбе юк. Кызлар күзләрен дә алмый. Җыр-моң яраталардыр. Гитара чирткән егетне дә беренче күрүләредер әле. Татарча гармунда гына уйныйлар бит. Үзебезнең җырларның көен гитарада чыгарган кешене мин дә көн дә күрмим, әлбәттә. Тик менә… Икенче курс кызлары арасына утырып, концерт тыңламам бит инде. Әй, әй, тырышалар үзләре, җыр беткәч, чәбәкәйләп-чәбәкәйләп мактарга, «Тагын, тагын!» – дип сорарга керешәләр. Салпы ягына салам кыстыра беләләр бит. Ух! Мактау кемгә килешмәсен, Нәфис тагын җырлый:

Гөлем, гөлем, гөлем, Гөлчәчәгем,
Син – минем киләчәгем...

«Сөрмә күзләреңне мөлдерәтеп карама миңа! Ач булсаң... Сәгатькә карый белсәң... Башыңа тай типмәгән булса, туктар идең инде әллә кайчан... Нәрсә өчен килдең соң монда? Концерт куяргадыр шул...»

Ә минем ашарга пешкән... Авылдан әнкәйләр җибәргән сөт-каймакны мул гына салып, бәрәңге измәсе издем, «подлив» ясадым, чәй ясап бирдем – Нәфис шулай чәй белән юешләп ашарга ярата. Чәйсез тыгылам, ди...

Гөл МИРҺАДИ (Гөлнара ШӘЙМӨХӘММӘТОВА) (1971) – *язучы, журналист; «Алмалы уләннәрем», «Адашкан сер» дигән китаплар авторы. Башкортстанның Балтач районында яши.*

Измә суына... Миңа төбәлеп җырлавың беләнмени, икәү генә булмагач... Аһ! Сул кулының бармакларын күчергәндә, кылларның зыңлавы... Нәкъ хатын-кыз кебек. Уң кулы белән гитараның «ян башыннан» кочаклап тотканда, бармаклары белән бермләп кылларын тарта... Аннары сугып уйный башлый – йомшак итеп, назлап кына суга... Көн-лә-шәм! Тиздән унбер тула, вахтёр ятак ишеген бикләп куя бит инде! Кунакларым һаман утыра. Измә суына... Мин кайныйм... Карашың: «Коткар мине болардан тизрәк!» – дип кычкыра инде, аңлап торам. Кистереп әйтергә артык тәрбияле шул син... Кырт кисеп, тамашачыларыңны озатырга, дисәң, миңа куш.

– Иртәгә математикадан коллоквиум икәнен онытып җибәрдегез, ахры, кызлар. Мазинов чәчегездән сыйпамас, – дип, кызларны күк тарафларыннан җиргә тартып төшерәм. Алар тишеккә качышкан тычкан балаларыдай, тиз генә күз алдыннан юкка чыгалар. Уф!

Нәфис ашыгып, гитарасын тумбочка кырыена терәп куя да – тегесе ачулангандай зыңгылдап ала – мине кочаклап, җылы тыны белән иркәли-иркәли, куеныма чума, үзе: «Үләм, ачыктым», – дип пышылдый. Измә суынып бетте инде...

2

Абзар тулы мал-туарларын көчкә җыеп бетереп килгән, фермадан сыер савып төшкән, иген кырыннан комбайннарын ярдәмче малайларга калдырып, бер-ике сәгатькә генә туйга сугылган бу халык таң калып, синең «Карыш сылуы»ңны тыңлаганда, шул гитарада уйнап-җырлап кына, Нәфис Гөлчәчәкне үзенә караткан дип уйлап утыра инде. Юк шул, гитарасы белән дә, миңа багышлап язган җыры белән дә түгел. Белмисез...

Менә әлегедәй дулкынланудан дымланган, сөрмә тарткандай матур, моң тулы юаш күзләренең бер каравы җитте апагызга. Дөньясын онытты... Үземнең дә исем-акылым китә. Эссе һәм эшле җәйдән арып беткән авыл публикасына «спектакль» уйнап утырабыз. Кешенең бер җиренә кыл да сыймый торган печән һәм урып-җыю чорында. Син таңнан уянып, басуга китәчәксең – эшкә. Без бүгеннән дөнья көтә башлыйбыз... Бөтен нәрсә дә әлегедәй рәхәт, җайлы булыр төсле...

Бу җырны кайчан язган идең соң әле? Бергә яши башлаганчы дуслашып йөргән барлы-юклы бер ай эчендә булган бөтен вакыйганы да яттан беләм кебек... Шул чорда үзең җырлап яздырган кассетаңны бүләк иткән идең – анда бу җыр юк. Беренче тапкыр кайчан җырлаган идең соң бу «Карыш сылуы»н? Икәүдән-икәү генә чактамы? Әллә «тамашачылар» беләнме? Хәтерләмим нигәдер... Тырышып-тырышып та, исемә төшерә алмый интегәм һаман.

Тамашачы тулы залга да ике-өч тапкыр гына уйнап җырладың. Дөресрәге, мин этеп-төртеп, сәхнәгә чыгардым. Кулыңа гитараңны алмас өчен нинди генә сәбәпләр уйлап тапмый идең:

– Мин бит «самоучка» гына. Камчаткада хезмәт иткәндә, эш юктан суккалап утырып кына өйрәнгән идем. Әллә дөрес, әллә юк.

– Кылларын көйли дә белмим бит. Кешегә ялынырга кирәк. Уйнавым да чамалы. Берәр оста күрсә, көләр...

Әнкәйләр туган көнеңә бүләк иткән гитараны мин шулай да кызыл тасма тагып, беренче кабат «үзебезгә башка чыгып» яши башлаган иске өебезнең түр стенасына кадак кагып, элеп куйдым.

– Мә, тот, уйна әле миңа гына?! Җырла әле, – дия идем буранлы кышның озын кичләрендә.

– Арыткан, Гөл...

– Бер генә уйна әле! Үземә генә... Яныма утыр да, – дия идем балалар изрәп йокыга талган сихри төннәрдә. Назлы бармакларыңны сагынып арыган кылларга бер-ике генә кагыласың, чыелдатып, елатып таныш яшьлек көйләренең онытылган аккордларын эзлисең, бер җырны башлап, икенчесен ташлап, берсенең дә азагына барып җитә алмый бераз кыешасың да:

– Булмый, Гөл, интектермә. Онытылган. Бармаклар каткан. Авырталар, – дип, гитараны тагын стенага эләсең. Кыллар, үпкәләгәндәй, төн тынлыгында зыңгылдап куялар...

Җигелеп, тормыш йөген тарттык. Ашыгып. Башта абзар, аннары таштан өй салдык. Булмаган акчаларны тартып-сузып... Бер-бер артлы балалар туа торды. Моңлы күзләреңә карап, кара-каршы утыру түгел, кочаклашып сөешерлек вакыт та, көч-хәл дә калмаган чаклар ешайды. Дөнья басты...

Гитара тавышы табыннарда гына, хуҗа эчеп алгач – бармак буыннары йомшарып, авыртынулар басылып киткәч кенә яңгырар булды. Аракы капкач, нишләптер онытылган җырларның көйләре дә исенә төште, исерек публика дөрес булмаган урыннарын ишетмәде. Мескен гитара бу сирәк кенә назлауга да риза иде: җырлады да җырлады. Нидер югалткан күңел елады да елады...

3

Табыннар алдыннан Нәфиснең гитарасын килеп көйләп китүче егет яшь-яшь көенә кинәт кенә үлеп китте.

Авылдан авылга, өйдән өйгә күченеп йөреп, түрдәге кадагыннан язып, урынын тузанлы шифоньер башында тапкан гитара көннәрдән бер көнне идәнгә төшеп ватылды. Кыллар зыңгылдап өзелде...

Шул минутта, бер кып-кыска мизгелгә генә синең кыенсынган күзләрең минем әрнүле карашым белән очрашты. Тик хисләр кычкырып әйтелмәде. Күзләрдә калды. Беренче сабыеңны кулыңа алгач, миңа тутырып караган бәхетле күзләрдә... Улыңның үле гәүдәсен юл буена кочаклап кайтып, өй ишеген ачканда, миңа төбәлгән кайгылы күзләрдә... Бәләкәй кызыңның бәләкәч кенә йөрәгенә операция кирәклеген әйткәч, мөлдерәп яшь тулган чарасыз күзләрдә... Күтеп, теләп алган тап-таза уларыңны көчле кочагыңа кысканда, шатлык чәчкән нурлы күзләреңдә... Урынсыз үпкәләр, тормыш күрсәткән исәпсез-сансыз михнәтләр, иңнәргә күтәргән авырлыклар өчен гафу үтенгәндәй, миңа текәлгән гаепле дә, сагышлы да, моңлы да күзләрдә... Сөрмә тарткандай матур, оялчан карашлары белән кайчандыр мине әсир иткән соры күзләрдә калды барысы да: мине сагышларымнан аралый алмый әрнүең дә, кычкырып әйтелер, шашып сөелер өчен вакыт җитмәгән мәхәббәтең дә, мең яралы күңелемне аңлый алмый газаплануларың да...

Түгелер бу моң дип өметләнгән идем. Юк, түгелмәде...

Балалар өйрәнсен дигән булып, яңа гитара алып кайттым. Кибеттә бергәләп сайлап алдык. Стенага элеп тоттык. Кагылмадың да. Уйнамадың. Өйрәтмәдең.

4

– Нәфи-ис!
– Әү!
– Плитә эшлиме? Өйдә суык кебек...
– Эшли.
– Утларны сүндердең, ишекне элдеңме?
– Әйе.
– Нәрсәдер онытылды сыман. Сыерны карап кердем. Бүген генә бозауламас. Шулай да төнлә уятырмын, чыгып карап керерсең, ышанып булмый дөнья хәленә.
– Әһе...
– Иртәгәгә аш кайнатып куйдым әле. Иртән болай да эш күп. Бишесе дә мәктәпкә китә, баланы тотып торырга да кеше калмый. Уф, арыганмын, ахры, аякларым үтереп сызлый, ничек куеп ятсам да, җае юк. Ярый бүген помидорларны күчереп өлгердем әле.
– ...
– Йокладыңмы?
– Юк. Уйлап ятам. Утынны юл өзелгәнче барып кисәргә иде. Урманнан чыгарып торырга трактор кирәк. Кемне белешергә?
– Әй, кисәлсәң, әйбәт тә булыр иде. Алдагы кышта коры утын ягар идек.
– ...
– Иртәгә базарга кереп чыгарсың әле. Малайларның ноские бетте. Тавыкларга теге йомырка салдыра торган витамин да кирәк. А-а-аһ. Уф, авыз ачыла, йоклап китәм хәзер...
– Акча бетте бит.
– Минем кошелёкның замоклы кесәсендә кара көнгә дип яшергән ике йөз сумлык бар... Т-с-с! Ләчтит сатып, баланы уяттык бугай инде. Тагын йокы күрсәтми бу миңа!
– Хыр-р-р...
– Нәрсәдер онытылды кебек барыбер... Ипи издем, баланың керләрен элдем... Тагын нәрсә соң? Уф, искә төшми...
– Эт ашаганмы?
– Ю-у-ук. Әллә нинди бик кирәкле нәрсә ул... Мөһим әйбер. Онытылды...
Уянып бетмәгән бәләкәчемнең ачык авызына имчәк каптырам. Бөтен гәүдәм авыраеп, караватка сеңгәннән сеңә бара. Бу йокы хәтле татлы нәрсә юктыр... «Их, барыбер искә төшмәде».

5

Эреп аккан кар суларының татлы исе, сулышларны киңәйтеп иркәләгән, тезелешеп кайткан кыр казларының арык тавышлары башны күккә чөяргә мәҗбүр иткән, яңа эшләп элгән умарталарга сыерчыклар килүен көткән, күздән вакыт җиткерә алмый калган эшләр, кар астыннан чыгып, үткән-сүткән саен күзгә чалынып, җиңнәрне сызгандырган бер вакыт иде. Шул

тынгысыз чакның бер көнендә станокта такта чыгарганда, Нәфис зырылдап әйләнеп торган үткер пычкыга бармакларын өздерде. Сул кулының ике бармагын...

Беренче көн курку белән үтте дә китте.

Икенче көнне шаярырга тырыштык. Дарулар Нәфиснең авыртусызлануларын баса иде әле. Мин кешегә ишеттерми генә: «Үзе исән әле, шөкер, бармак кына...» – дип, туктаусыз кабатлавымны белдем...

Өченче көнне юк бармаклар әрнеп интектерә башлады...

– Нишләдем мин? Унбиш ел станокта эшләп, шушы куллар белән ике өй, ике абзар төзеп чыгып... Их, эш күп иде! Ишегалдын бетерәсе, йортның коймасын тотасы... Бармакларымның самый кирәк чагы иде!!! Нишләдем мин?! – Сөрмә күзләр дымланды. Ирем аркасын миңа таба куеп әйләнеп ятты...

– Көймә әле. Төзәлгәч, барысын да эшләрсең. Булган – булган инде, хәзер көеп, ни үзгәртәсең? – Мин Нәфисне юатырга тырыштым.

– Кадакны да тотып кагып булмас инде…

Бу минем «төзәлгәч»емә җавап иде, ахры...

Эчемнән генә: «Ни хәл итәсең, җайланыр, өйрәнер әле», – дип уйладым. Нишләптер һаман бу хәлне йөрәгемә якын алмаска, «Исән әле, үзе исән», – дип, ераккарак этәрергә тырыштым. Әллә моннан зуррак кайгыларны күп кичергәнгә? Әллә дөньям бик түгәрәкләнеп, бәхетем ташып киткән чакларда язмыштан яшерен генә аяк чалулар, сынаулар көтеп өйрәнгәнгә? Һаман шөкер иттем: «Үзе исән. Кулы бар әле...»

Бер көнне улым сәнгать мәктәбенә барырга җыенды. Ул анда баянда уйнарга өйрәнә. Инде күптән стенадан төшеп, футлярына кереп яткан гитараны да аркасына асты:

– Укытучы абый аккордлар күрсәтәм дип әйтте, – ди.

Шул вакыт башыма китереп суктылармыни: кылларны иркәләгән назлы бармакларын күзләрендәге моңына буйсындыра алган егетнең тумбочка өстенә утырып җырлавыннан башланган, уйнасаң-уйнамасаң да, гитара белән бергәләп үткән гомерем яшен тизлегендә күз алдымнан үтте. Тик... Хәзер... Башка беркайчан да, син бик теләсәң-теләмәсәң дә, мин бик ялынсам-ялынмасам да, син гитарада уйный алмаячаксың! Кылларга басмый гына, көй чыгарып булмый...

«Кайгы түгел бу, көенеч кенә», – дип йөргән фаҗига бөтен тирәнлеге, авырлыгы, быелгы язның шул минутын кайтарып алып булмаслыгы, берни дә үзгәртеп булмаслык көчсезлегем белән йөрәгемне телгәләп үтте.

Син башкача кылларга кагылмаячаксың...

Тартма төбендә еллар буе онытылып яткан кассетаңны тыңлыйм. Бушка ялынасы да, өметләнеп тилмерәсе дә, көтәсе дә юк.

Гитара моңы. Синең йомшак тавышың.

«Гөлем, гөлем, гөлем, Гөлчәчәгем...»

Алинә
Хисамиева

АК КӘГАЗЬДӘН НӘНИ ОЧКЫЧ ЯСЫЙМ...

Йөзгә җиткәндә

Йөзгә җиткәндә дә яшәү ямьле,
Һич кенә дә килми китәсе.
«Тагын бер кыш кышлар идем», – диеп,
Укый әби «Әлхәм» сүрәсен.

Ярдан-ярга айкый хатирәләр,
Истәлекләр аңга сарыла,
Сөюләрен нәкъ кызларча сөйләп,
Кайтып килә япь-яшь чагына.

Исән калган балаларын барлый,
Аннан мәрхүмнәрен сагына.
Бер гасырлык язмыш ялкыннары
Моңсу күзләрендә чагыла.

Оныкларның яндагысын түгел,
Читтәгесен эзли җиһаннан.
Хәвефләнеп куя, «гөж-гөж» килеп,
Машиналар узса урамнан.

Холкы көйсезләнеп, сабыйларча,
Үпкәләгән була, кайчакта.
Шул мизгелдә телдән ычкынганы
Ирешмәсен берүк Аллаһка.

Йөзгә җиткәндә дә яшәү ямьле,
«Авыр» диеп килми әйтәсем.
Мең сабырлык телим әниемә
Тәрбияләр өчен әнкәсен...

Алинә ХИСАМИЕВА (1986) – *шагыйрә, «Көзге яфраклар кочагында», «Күбәләкле җәймә» китапларының авторы. Азнакайда яши.*

Әтиле әтисезләр

Сулышыңны өреп учларыма,
Җылытканың истә әле дә...
Мин әтиле булдым тик бер ара,
Шуңа газиз кыска мәле дә!

Чаналарда тартып йөргән чагың
Төшләремә кереп йөдәтә.
«Тагын бер кат шуыйм әле, димен,
Синең белән рәхәт меңләтә».

Ашыгасың! Ашкынасың һәрчак,
Өйдә башка гаиләң көткәнгә,
Йолкып алыр булып, ул чагыңнан,
Кайтыйк димен, әти, үткәнгә.

Ярар дисең, үзең сәгатеңә,
Минут саен карап аласың,
Син караган саен, өметләргә,
Язмыш сөртә, буйый карасын.

Тар вакытны миннән урлар өчен
Йә кар, йә җил сыза, ыжгырып.
– Өшедеңме, кызым?
– Һич юк! – диям,
Сәгадәтле мәлне, чак сузып.

Үткән берен таныгандай булып,
Сәлам бирәм таныш-белешкә.
Күрми калмасыннар, әтием бар!
Дәү гәүдәле! Чибәр төс-биткә!

Җебеп, бияләйгә ияртелгән
Карны озак кактым төшемдә.
...Әрнүләрем-яңарудан, кинәт,
Яктылыгын җуйды өнем дә.

...Сөю үтә, чорлар алышына,
Дөнья рәхәт! Кеше – гаепсез...
Тын галәмдә җылы табалмыйча,
Әтиләләр үкси әтисез.

Кәгазь очкыч

Үксезлекнең күзләреннән саркып,
Бер хатирәм тама йөрәккә.
...Ак кәгазьдән нәни очкыч ясыйм,
Февраль бәйрәменә бүләккә.

Сыйныф чыр-чу килә. Бәйрәм алды.
Тынлык тапмый үтә дәресләр.
Очкыч канатында – бер газиз сүз
Тере котлау! Җылы хәрефләр!

Бер әйтергә мең тилмергән сүзем
Үзем язам, үзем кабатлыйм!
Шыңшып елар чагын үксез җанның,
Чит күзләрдән генә чак саклыйм.

«Әтиемә» диям, үзем никтер,
Гаеп эзлим язган сүземнән.
– Төзәт әле, «Бабама», дип, кызым,
Сөрт әле, сөрт, яшең күзеңнән.

– Исән ич ул, – димен, – язам әле,
Күрешкәндә бирәм үзенә.
...Күп җыела иде кесәләрдә
Очкыч, көймә... Туган көненә.

...Ул очрады беркөн. Җитәкләгән
Сөйгән ярын, үги улларын.

Букчам кесәсеннән бүләгемне
Калтыранып эзли кулларым.

Җәйге эссе мизгел. Мең кат өшеп,
Сулкылдады бәгырь бик озак.
Кул сузымы ара – газиз кешем,
Бәхет кенә ерак... Бик ерак!

Очкычымны куеп утыргычка
Кулым изим, читтән, әтигә.
Якын килер иде... Үги уллар
Өстериләр аны: «Әни-и-игә!»

Әти китә... Уллар ерагая...
Киң офыкта томан тарала.
Очкыч кына, канатсыз кош кебек
Талпына да... Җиргә кадала.

Кызым

Ап-ак хыял идең, дөньялыкка,
Язлар кызы булып килеп кердең.
Җир йөзендә сине өз(е)леп-өз(е)леп,
Көтүемне минем сиздең! Сиздең!

Иренеңә кунган елмаюың,
Төшләремнән уелып калган төсле.
Син дөньяга килгән көннән башлап,
Галәм чиксез, үзем үтә хисле!

Язлар саен ургып аккан күңел,
Садә тынлык тапкан кебек булды.
Күзләреңдә чиксез диңгез синең,
Дулкыннары аның шаян, нурлы.

Гел сабырсыз, иркә чагың әле,
Балачагың чәчәк аткан вакыт.
Җитәкләгән нәни кулларыңнан,
Җәй җылысы ага ташып-ташып.

Синле дөньям! Кабат сабыйлыкның,
Ләззәт-намын татып гомер кичәм.
Мең ярату төреп гади сүзгә:
– Кызым! Балам! – диеп, сиңа дәшәм!

МИЛЛӘТНЕҢ ӘДӘБИ АВАЗЫ

Минем әдәби язмышымда «Казан утлары» журналы, мөгаен, хәлиткеч роль уйнагандыр... Утыз яшьләремдә, Монголиядә яшәп кайткач, мин шушы журнал редакциясенә эшкә урнаштым. Корректор булып. Әдәби бүлекләрдә эшләрлек югары белемем дә, зур иҗатым да юк иде әле ул чагында. Ә әдәби мохиткә тартылу көчле иде. Ни әйтсәң дә, мин Монголиягә чаклы төрле редакцияләрдә, телевидениедә эшләгән, каләм чарлап караган, режиссёрлык буенча һөнәри белем алган кеше идем. Шуңа күрә ике кечкенә балам булса да, Дәрвишләр бистәсеннән өч транспорт белән йөреп, аена 80-90 сумга «Казан утлары» журналында эшли башладым. Корректор булып биш ел эшләдем. Шушы вакыт эчендә Казан дәүләт университетына читтән торып укырга кердем, беренче күләмле әдәби әсәрләремне яздым, 1983 елның сентябрендә «Болын» повесте «Казан утлары» битләрендә дөнья күрде. Һәм шушы чордан минем иҗади гомерем башланды...

1984 елның көзендә мин «Казан утлары» журналыннан киттем. Үз теләгем белән. Иҗат итү өчен. Архивларда эшләү өчен. Дөнья гизү һәм тормышны өйрәнү өчен... «Казан утлары»нда тагы бераз эшләсәм, әдәби бүлеккә дә күчергән булырлар иде, әмма мин башка юлны сайладым. Үземне картайганчы унынчы каттагы кечкенә бүлмәгә бикләп куя алмадым. Миңа зур дөнья – милләт тормышы кирәк иде… «Казан утлары» унынчы каттагы якты тәрәзәләре һәм хатирәләре белән мине озатып калды, хәер-фатихасын бирде...

Хәзер уйланып утырам – «Казан утлары» минем өчен алыштыргысыз әдәби мәктәп булган икән! Дөрес, университет та күп бирде, тормыштан да иҗатым өчен күп нәрсәләр алдым, әмма җанлы әдәби процессны мин бары тик «Казан утлары»нда гына күрдем... Тере, тарихи шәхесләрне, классик язучыларны да беренче булып биредә күрдем. Аларның әсәрләрен беренчеләрдән булып укыдым, шул дөньяда яшәдем. Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романы чыккан вакыт иде, аның аша тарих төпкелләренә чумдым, теленең байлыгына таң калдым. Әмирхан Еникинең тел белән ни дәрәҗәдә сак эш итүен, җөмләсендә һәр сүзенең үз урынында булуын күрдем, аның әсәрләрендә күңеленең моңын-сагышын тойдым. Әмирхан абыйның бер җөмләсенә, бер сүзенә кагылырга ярамый, бу әсәрнең табигый агышын, көен бозу булыр иде. Ә ничек кенә кагылалар иде әле! Ничек кенә ботарлыйлар иде! Главлит дигән шымчы оешма аның әсәрләрен аерата нык күзәтә, алардан совет властена каршы яшерен кинаялар эзли иде. Һәм табалар иде. Һәм ботарлыйлар иде. Боларга Әмирхан абый ничек түзгәндер...

«Казан утлары»нда төрле авторлар басыла иде. Әйтик, Мөхәммәт Мәһдиевтә сүзләр уйнаклап тора, җөмләләр биеп тора, ә сюжет линиясе юк диярлек. Шуңа карамастан, татар теленең байлыгына сокланып, йотлыгып укыйсың. Ә Атилла Расихта, Мөсәгыйт Хәбибуллинда әллә ни тел байлыгы юк, җөмләләре дә кытыршырак булырга мөмкин, ә укучыны эчтәлек һәм сюжеты белән тотып тора. Корректор буларак, миңа бу зур-зур әсәрләрне берничә тапкыр укырга туры килә иде, шул вакытта ук мин аларның уңай якларын да, җитешмәгән урыннарын да күрә идем. Техник хезмәткәр буларак, әдәби процесска катнашырга ярамаса да, кайбер кимчелекләрен авторларның үзләренә дә әйтә идем. Бер генә язучының да каршы килгәнен хәтерләмим, киресенчә, рәхмәт әйтеп чыгып китәләр иде. Ул чакта авторлар кеше фикеренә хөрмәт белән карыйлар, аны кабул итә беләләр иде шул...

Күңелгә нык уелып калган хәлләр дә булды. Ахрысы, музей архивыннан, Һади

Такташның беренче хатыны Гөлчәһрәгә 1929 елда язган хатларын журналда бастыру өчен китергәннәр иде. Гөлчәһрә Мәскәүдә укып йөри, Такташ – монда, аңа хатыны турында төрле авыр сүзләр килеп ирешә. Бу хатларында Такташ өзгәләнеп, хатынына мөрәҗәгать итә, Казандагы әдәби мохитнең җанын талавын, моңа өстәп, Гөлчәһрә турында кара гайбәтнең куеруын яза. Безнең буын өчен Такташның шәхси тормышы бу дәрәҗәдә билгеле түгел иде, мин бу хатларны тетрәнеп укыдым. Әмма мине тагы да тетрәндергәне – Такташ хатларының аркылыга-буйга сызып, эшкәртелүе иде. Баш редактор Зәки Нури кызыл кара белән, бүлек мөдире Мөдәррис Вәлиев яшел кара белән Такташ хатларын сызгалап, эшкәртеп чыкканнар иде. Моны күреп, мин телсез калдым – ничек инде Такташ хәтле Такташны шулай ботарларга була?! Классик шагыйрьнең язганнарын шулай үзгәртергә, төзәтергә мөмкин?! Була икән шул, Такташ хатлары шулай ботарланган килеш дөнья күрде, бәлки, бу Главлит таләбе булгандыр...

Шушы вакыйга мине Такташ иҗатын ныклап өйрәнә башларга этәрде. Эштән китүемнең дә беренче сәбәбе шул булды. 1984 елның көзендә үк Такташның туган авылы Сыркыдыда булып кайттым. Алты ай буе университет китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә утырып, Һади Такташ белән бәйле бөтен тәнкыйть мәкаләләрен укып, өйрәнеп чыктым. Аларның бер өлеше гарәп хәрефләре белән язылган, бер өлеше латинда иде. Шундагы мәгълүматларга таянып, мин Такташка багышлап, «Атылган йолдыз» дип аталган драма яздым, соңрак ул «Казан утлары» журналында да басылып чыкты. Һади Такташ турында күп кенә фәнни мәкаләләр яздым, 2001 елда «Мишәрнең бөек улы» дип аталган китап бастырып чыгардым. Күрәсез, «Казан утлары» журналында Такташ өчен туган җан әрнүләрем, аның иҗатын һәм тормышын өйрәнүгә этәреп, шушындый нәтиҗәгә китерде...

«Казан утлары»нда эшләгәндә, мин тагы бер тарихи шәхес белән ныклап кызыксына башладым, ул – Михаил Георгиевич Худяков. Аның «Очерки по истории Казанского ханства» дип аталган тыелган китабы күчермәсен Рәдиф Гаташ бер генә төнгә укырга биреп торган иде, ул исә баҗасы Разил Вәлиев аша Ленин исемендәге китапханәдән тапкан. Бу китап миңа бик көчле тәэсир итте, чын татар тарихын беренче тапкыр шунда белдем. Аны укыгач, бик нык дулкынланып, Сөембикә манарасы янына барганым, Казан өчен шәһит киткән әби-бабаларыбызга дога кылганым хәтердә. Ул чакларда «Сөембикә» дип аталган драма да язган идем әле. Михаил Худяковның иҗаты буенча университетта диплом эше яздым, соңыннан бу темага тарих буенча диссертация якладым, аның турында ике китап язып бастырдым. Татар тарихы буенча «Казан утлары»нда салынган орлыклар менә шундый мул уңыш бирде...

Журналда мин ике баш редактор белән эшләдем, беренчесе – Зәки Нури, икенчесе – Ренат Харис. Зәки абый олпат гәүдәле, киң күңелле кеше иде, безгә юкка-барга бәйләнмәде, вакланмады. Улым тугач, бөтен редакция коллективы безгә бәби котларга килгәннәр иде. Зәки абый баланы күрсәтүне сорагач, ыштансыз улымны кулыма күтәреп, кунакларга күрсәткән идем. Зәки абый барыбыздан да нык сөенде, чын егет бит бу, диде. Хәзер ул егеткә дә инде 42 яшь…

Ренат Харис бик фәлсәфи редактор иде, озаклап, иҗат турында сөйләшергә ярата, нәрсә язарга, нәрсә язмаска кирәген дә өйрәтә иде. Алай да, мин Ренат Харис белән аның урынбасары Ринат Мөхәммәдиевка бик рәхмәтле, алар минем югары белем алуыма сәбәпче булдылар. «Болын» әсәре басылып чыккач, язучылар арасында минем үзем белән дә, иҗатым белән дә кызыксынучылар шактый булды. Нурихан Фәттах, Шәриф Хөсәенов мине хәтта өйләренә кунакка чакырып, хөрмәт күрсәттеләр. Нурихан абый редакциягә килгәч, мине аерым бүлмәгә алып кереп, бик җитди сөйләшү башлады. Сүзенең төп темасы – минем университетка укырга керү мәсьәләсе иде. Нурихан абый миңа университетка укырга кермәскә киңәш итте, «Син инде әзер язучы, университет сине бозачак кына, чын халыкчан җырчыларны консерватория тавышсыз калдырган кебек», – диде. Мин уйлана калдым...

Безнең бу сөйләшү Ренат Хариска да билгеле булган, ә ул минем университетка керүем ягында иде. Әле дә хәтерлим, соңгы аргумент буларак, Ренат Харис бүлмә уртасына чыгып басты да биленә таянып: «Университетны тәмамлау сиңа менә шулай бөереңә таянып сөйләшү өчен кирәк булачак!» – диде. Һәм дөрес әйткән бит! Әгәр шул вакытта мин инде болай да яза беләм дип, университетта укымаган булсам, гомер буе бармак белән төртеп күрсәтеп: «Аның югары белеме дә юк бит!» – дип чукырлар иде... Ә университет миңа бөергә таянып сөйләшү хокукын гына бирмәде, ә системага салынган, киң күләмдә, чын мәгънәсендә югары белем бирде. Университеттан соң укуымны дәвам итеп, тарих буенча фәнни диссертация якларга нигез булды. Университет укытучыларым, шулай ук «Казан утлары» журналы авторлары Мөхәммәт Мәһдиев, Хатыйп Миңнегулов, Гомәр Саттаров, Марсель Бакировларга биргән белемнәре өчен мин гомер буе рәхмәтле...

Ә Нурихан абыйның кисәтүенә килгәндә, ул минем иҗатымда табигый сәләт юкка чыгар, университет мине дә стандарт калыпка салыр, дип борчылгандыр. Хәер, «Казан утлары»нда «Болын» әсәрем басылып чыккач, төрле фикерләр булды бит! «Монда сүз стихиясе генә, ул үзе турында әйтәсен әйтеп бетергән инде, башка әсәр яза алмаячак», дип тә гоманладылар. Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Фәрваз Миңнуллин бу әсәргә бик югары бәя бирделәр, Әмирхан абый хәтта «Бу бала үзенең нәрсә язганын аңладымы икән?» дип тә әйткән. 1986 елда басылып чыккан «Болын» китабына Әмирхан Еники кереш сүз дә язды, ә бу ул вакытта бик сирәк күренеш иде. Дөрес, Рафаэль Мостафин «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә минем ул әсәрне каты тәнкыйтьләп, «Болын сөрелергә тиеш!» дип аталган күләмле мәкалә дә бастырды. Әмма ул болынның кеше күңеле тамгасы-символы икәнен күренекле тәнкыйтьче нигәдер сизмәгән булып чыкты...

«Казан утлары» редакциясе коллективы минем күңелемдә бары тик яхшы яктан гына истә калды. Җаваплы сәркатипләр булып, Ләбибә Ихсанова һәм Кояш Тимбикова эшләделәр, алар миңа карата һәрвакыт хәерхаһ булдылар. Әдәби бүлекләрдә нигәдер башка хатын-кызлар юк иде. Хәер, ул чагында хатын-кыз язучылар да аз иде бит. Шигърият бүлегендә – Рәдиф Гаташ, прозада – Марсель Галиев, тәнкыйть бүлегендә – Мансур Вәлиев, хатларда Рәшит Әхмәтҗанов эшләделәр. Алар мине ул вакытта шәхес итеп кабул иткәнме-юкмы – әйтә алмыйм, ә минем өчен алар барысы да зур шәхесләр иде һәм шулай булып кала да... Редакция коллективының үзенә генә хас, үзләре генә аңлый торган сөйләм теле бар иде. Әйтик, Марсель Галиев миңа «Даһи» кушаматы такты, «Шулай дәшкәч, әйләнеп карый бит әле», – дип, үзе гаҗәпләнә иде тагы... Ай саен бер повесть язып килә башлагач, Рәдиф Гаташ, «Аңа җеннәре булыша, ахры», – дигән хәбәр таратты... Бу – үзенә күрә матур итеп төрттерү, бер-береңнән ягымлы көлү иде...

Соңыннан да минем күп кенә әсәрләрем, беренче булып, «Казан утлары» журналында басылып чыкты, төрле сәбәпләр белән басылмый калганнары да булды. Журнал битләрендә, чәчмә әсәрләремнән тыш, күп кенә публицистик язмаларым да урын алды. Мин редакция коллективына бик рәхмәтлемен – әсәрләремне укучыларга җиткергәннәре өчен дә, мең еллык татар әдәбияты традицияләрен дәвам иткәннәре өчен дә, тел сагында торганнары, милләткә тугры хезмәт иткәннәре өчен дә – мин «Казан утлары» журналына рәхмәтләремне әйтәм һәм аңа озын гомер, якты иҗат телим! Милләт яшәгәндә, аның әдәби авазы булган «Казан утлары» журналы да яшәр, иншалла! «Казан утлары» булганда, аның рухи яктысында милләт тә яшәр!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, тарих фәннәре кандидаты.

«МИЧКӘДӘ ДАРЫ БЕТМӘГӘН ӘЛЕ»

Мин «Казан утлары» журналына беренче мәртәбә узган гасырның җитмешенче еллар башында мөрәҗәгать иткән идем. Ул вакытта аспирантурада укымыйча гына сайлаган белгечлегең буенча кандидатлык минимумы имтиханнарын тапшыру мөмкинлеге бар иде. Мин дә әлеге мөмкинлектән файдаланып, диссертация язарга ният иттем. Бу ниятем нигезсез түгел иде, чөнки кесәмдә Мәскәү милли мәктәпләр институты Казан филиалының штаттан тыш фәнни хезмәткәре таныклыгын йөртәм. Үзем эшләгән Бөгелмә районы һәм шәһәре мәктәпләрендә «Әдәби образлар ярдәмендә югары сыйныф укучыларында ихтыяр көче тәрбияләү» темасы буенча анкеталар да уздырдым, шактый материал тупладым. Һәм аларны тәртипкә китереп, мәкалә яздым да, «Казан утлары» журналы редакциясенә юлладым.

Озак көттермичә генә хатлар бүлеге мөдире Вакыйф Нуруллин имзасы белән җавап та алдым. Ул кыска һәм аңлаешлы иде: «Мәкаләгез безнең журнал профиленә туры килми».

Мәкаләне «Совет мәктәбе» журналы кабул итте.

«Алаяк» исемле тәүге хикәям авылыбызның легендар, үземә дә аңа атланып йөрү бәхете татыган, чабышкы ат турында иде. Ул 1978 елда «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыкты. Аны «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Ринат Мөхәммәдиев күреп алган.

– Марат абый, син яшертен генә күптәннән язасың булыр, каләмең шома күренә, – диде бер очрашуда. – Безне дә онытма.

Күп тә үтми, сугышта башын салган әткәем истәлегенә багышланган «Соңгы җыр» дигән озын гына хикәямне журнал укучыларга җиткерде.

Шуннан башланды инде...

Канатланып китеп, күләмлерәк жанрда да үземне сынап карарга булдым.

Аяз Гыйләҗевләрнең Зәйдә яшәгән вакыты. Сугыш чоры авылы кешеләренең тормышын тасвирлаган повестемны аңа җибәрдем.

Атна-ун көн үттеме-юкмы, аннан хат та килеп төште. Анда түбәндәге юллар да бар иде: «...Нәкъ татарча, егерменче еллар татар прозасының эзенә баса-баса, кайнарлыгы тере күңелләрне кузгатырлык реалистик әсәр язгансың. Байтактан мондый төгәл, сыгылмалы тел белән язылган әсәр укыган юк иде... Повестьның исемен «Гөлнәзирә» дип алыштырсаң *(миндә – «Зина» иде)*, мәгънә дә үзгәрә, фикер дә... «Казан утлары» егетләренең колагына: һич кичекмәстән бу әсәрне укучыга җиткерергә кирәк».

Аяз Гыйләҗев «Казан утлары»нда бирелгән «Дөя муены» исемле сатирик повестемны да бик ошаткан иде. «Мәдәни җомга» атналыгында «Бәрәкалла, Әмирхан» дигән күләмле мәкалә дә бастырып чыгарды. Гомумән, ул минем иҗади үсешемдә аерым урын биләп тора. Әдәби алмаш турында чынлап торып кайгыртучы бөек әдип һәм дә эчкерсез дус иде. Урыны оҗмахта булсын.

Селтәнгәч селтәнергә инде, бәлки, романга да теш үтәр? Тик моны уптым-илаһи гына башкарып булмаска охшап тора. Әүвәл иҗатның генераль линиясен тәгаенләү зарурдыр, мөгаен. Уйлана торгач, тарих укытучысы буларак, тарихи жанрга тукталу

максатка ярашлырак булыр, дигән нәтиҗәгә килдем. Шулай итеп, иҗат концепциясе тамырдан үзгәреш кичерде.

Беренче булып, «Тәкъдир» романы туды. Аңа «Тояк эзе», «И, кылган догам минем», «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг», «Ир-Мамай», «Тәхетсез патша», «Олуг Мөхәммәд» романнары ялганды.

«Дөньяга бөек Тукайны тудырган шагыйрь әнкәсе – Бибимәмдүдәнең катлаулы язмышына багышлап, Марат Әмирханов тарафыннан югары кимәлдәге әдәби әсәр языльп, журналыбызда нәшер ителде». Бу юлларның авторы – «Казан утлары» журналының ул вакыттагы баш мөхәррире Илфак Ибраһимов. Мин аңа, бүлек мөдире Камил Кәримовка, баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнановка зур бурычлымын. Алар минем озак еллар буе нахакка кагылып, әдәби мәйданнан читкә тибелеп килгән Милләт анасы – Бибимәмдүдә абыстай турында әсәр язуымны хуплап, күтәреп алдылыр, ярдәм кулларын суздылар. Әлеге башлангыч тора-бара «Тукайның әһле якыннары» дигән цикл булып тәгаенләнде. Дүрт бәянның өчесе «Казан утлары»нда басылды. Абыстайның тууына 155 ел тулу уңаеннан ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров фатихасы һәм ТР Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды булышлыгы белән Мәрҗани мәчетендә Коръән багышлау мәҗлесе үткәрелде; «Бибимәмдүдә абыстай» исемле китабым укучыларга барып иреште.

«Казан утлары» журналы төрле елларда үз укучыларына минем 8 романымны, 10 повестемны, уннан артык хикәя һәм очеркларымны; иҗатым турында әдәбият белгече Хатыйп Миңнегулов, тәнкыйтьче Мансур Вәли-Барҗылы, язучы Рашат Низамиевларның бәяләмә мәкаләләрен тәкъдим итте.

Мин журнал үткәргән «Яңа дәвер кешесе», «Печән базары» бәйгеләрендә катнашып, II, III дәрәҗә дипломнар белән бүләкләндем.

Журналда дөнья күргән әсәрләремнең туксан проценты проза бүлеге мөдире, күпкырлы талант иясе, миңа Язучылар берлегенә керү өчен тәкъдимнамә язган күренекле каләм осталарының берсе, таләпчән, гадел һәм ихтирамлы Камил Кәримовның кулы аша узды, аларның барысын да ул редакцияләде. Озак еллар журналны җитәкләгән бүгенге дәвер классигы Равил Фәйзуллин да иҗатыма һәрвакыт хәерхаһ булды, әсәрләремә юл ачты. Шулай ук мин ачык йөзле, һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торган Рәдиф Гаташ, Тәүфикъ Әйди, Әхәт Гаффар, Флүс Латыйфи, Шамил Маннапов, Наис Гамбәр, Марат Закир, алыштыргысыз тел белгече, мөлаем һәм чибәр Лилия Гатауллина кебек хөрмәтле казанутлыларны күңелем түрендә йөртәм.

Җыеп кына әйткәндә, мине «Казан утлары» язучы итте. Һәм моның белән ихластан горурланам.

Марат ӘМИРХАНОВ

Илшат
Билалов

МӘДИНӘ ТАВЫ

ПОВЕСТЬ *

Авыл урамнары кар астында калган. Бик сирәк өйләрдән генә кеше чыккан эзләр күренгәли. Аяк астында кар шыгырдый. Итекләр урыны-урыны белән тезгә хәтле бата. Арттан ук эзләрне җәяүле буран сылап бара. Хастаханәгә килеп җиткәндә, Гөлшатның аркасы манма су булды. Дамир абый хастаханәнең ишегалдын көрәп ята иде.

– Хәерле иртә, Дамир абый. Хәлләрең ничек? Иртүк эшкә тотынгансың, авыл башыннан ничек болай иртә килеп җитә алдың? Урамда йөреп булмый бит. Мин якын гына торсам да, кар ерып килеп, аркамнан сулар акты,– дип, Гөлшат аяк киеменә ябышкан карны кагарга тотынды.

– Мин, атымны җигеп, чанага утырып килдем. Буран туктарга җыенмый әле, кичкә тагын яварга тиеш, – диде Дамир абый. Кар көрәүдән туктап, хәл алды.

– Тагын яумас, болай да бик күп яуды, җил дә тынган төсле. Әллә сиңа синоптиклар шалтыраттымы?

– Сез тагын көләсез. Кичкә тагын көчле буран була, ышанасың килсә – ышан, ышанасың килмәсә – ышанма, мин үз сүземә хуҗа, юкка әйтеп тормыйм, – дип, үпкәләгәндәй әйтеп куйды Дамир абый.

– Ярар инде, Дамир абый, үпкәләмә, мин шаяртып кына әйттем бит, – дип, Гөлшат хастаханәгә кереп китте.

Хастаханәдә гадәттәгечә тыныч иде. Кичә барысы ундүрт авыру калган. Машинада барганда, хәле начарланган бер ир-атны малае алып килгән. «Аны бүген тикшереп, районга озатсаң, әйбәт булыр иде дә, юллар булмагач калдырырга туры килер», дигән уйлар белән Гөлшат ашыкмыйча гына, авыруларны урап чыкты, кайберләренең дәвалау тарихларына үзгәрешләр кертте. «Бүген кешеләрне чыгарып булмас, бөтенесе күрше авыллардан, өйләренә кайта алмаслар, юллар ябык. Шуңа күрә ятарга да беркем килмәс», дип уйлады Гөлшат. Ашыкмый гына башкарса да, көндезгә ашка кадәр эшләре беткән иде. Урамда һаман җил улый. «Урамда буран, мин өйдә торам, тәрәзә аша тик авыз ерам», – дип куйды Гөлшат, тәрәзә аша

* Журнал варианты.

Ахыры. Башы узган санда

урамга карап. Бу авылга килеп эшли башлавына инде менә сигез айдан артык вакыт узып бара. Килгәненә бер дә үкенми. Ул күргән авырлыклар, төрле-төрле авырулар һөнәрен дөрес сайлавы турындагы фикерен тагын да ныгытты гына.

– Гөлшат Равилевна, әйдәгез берәр чиләк чәй эчеп алыйк, – дип, шаярта-шаярта, бүлмәгә хастаханәнең өлкән шәфкать туташы Фәимә апа керде. Табибка карап, хастаханәдә эшләүчеләрнең күбесе шаяртып сөйләшә башладылар.

– Әйдәгез, эш бетте, чәй эчсәк тә була. Фәимә апа, тәмле балыгыз бармы? Алып керегез әле. Кызларның эшләре бетсә, аларны да чакырыгыз. Бергә-бергә күңеллерәк булыр.

Гөлшат торып, самавыр куеп җибәрде, өстәлгә чынаяклар тезә башлады.

Фәимә апа чыгып, өеннән алып килгән бәлешләр белән бал чыгарып, кызларны чакырып керде. Ләкин озаклап чәй эчеп утырырга туры килмәде. Бүлмәдә телефон шалтырады. Күрше авылда фельдшер булып эшләүче Рамилә шалтырата иде:

– Гөлшат Равилевнаны телефонга чакырыгыз әле, бик кирәк иде.

– Ни булды, Рамилә? Борчуларыңны сөйләп җибәр, Гөлшат Равилевна тыңлый.

– Гөлшат апа, мине бүген бер өйгә чакырдылар, анда бер апаның эче бик нык авырта.

– Авыртса, но-шпа яса.

– Ул авырлы бит, тугызынчы аенда.

– Каян килеп чыккан соң ул?

– Аның әбисе үлде, шуны җирләргә кайткан иде. Иртәгә җидесен уздыргач, Казанга кайтып китәргә тиеш булган. Ләкин менә шундый бәла килеп чыкты.

– Район үзәгенә шалтыратып карадыңмы?

– Шалтыраттым да, ләкин юлларны кар баскан, машиналар чыга алмый, диделәр. Безнең авылга сездән соң да тагын унбиш чакрым бит, нишләргә дә белмим. Әгәр тулгагы башланса, минем бит бер тапкыр да бала таптырганым булмады, булдыра алмам дип куркам.

– Тынычлан, нәрсә булса да уйлап табарбыз, – дип, Гөлшат телефонны куйды.

– Тагын нинди көтелмәгән хәлләр килеп чыкты инде? – дип, борчуга төште Фәимә апа.

– Рамилә шалтыратты, күрше авылга барып кайтырга кирәк, Мансур абый ерак микән?

– Игезәкләр авылынамы? Урамда яңадан буран чыгарга тора, юлларны кар каплаган, күрше авылга түгел, үзебезнең авыл буйлап та машиналар йөри алмый.

– Рәис трактор бирә алмасмы икән?

– Була торган эш түгел, авыл буйлап юл ачар өчен дә көне буе эшләргә кирәк.

– Илдар Азатовичка шалтыратсам, ул ярдәм итә алмасмы икән?

– Ул ни эшли ала? Сиңа бер сәгать эчендә юлны чистарта алмый бит? Бәлки, сез шалтыратсагыз, тулпар атына утырып, очып килер. Әгәр бала

табарга вакыты җитсә, табар. Элек хатын-кызлар үзләре генә тапканнар, табиблар булмаган. Ходай бирсә, табар.

Фәимә апа Гөлшатны шулай тынычландырырга тырышты.

– Ат белән, дисезме? Дамир абый ат җигеп килгән иде. Атка утырып барсам?

– Акылдан яздыңмы әллә? – дип, Фәимә апа Гөлшатка каршы төште.

Ләкин Гөлшат аны тыңларга да теләмәде:

– Дамир абыйга ничек шалтыратырга, кайсыгыз белә?

– Ул әле китмәгәндер, без чәй эчәргә әзерләнгәндә, ишегалдында йөри иде, – диде шәфкать туташы Гөлгенә.

Гөлшат тиз генә киенеп, урамга чыгып китте. Дамир абый эшен бетереп, өйгә кайтырга җыенып йөри иде. Ул табибны күреп:

– Әйдә, кызым, утыр чанага, өеңә кайтарып куям, барыбер сезнең урамнан кайтам, – диде.

– Дамир абый, әйдә күрше авылга барып кайтыйк әле.

– Нәрсә калган анда, кияү сорарга барабызмы әллә?

– Син һаман шаяртасың. Бер хатынга ярдәм кирәк.

– Синең белән башкача сөйләшеп тә булмый. Мондый шайтан котырган көнне акыллы кеше күрше авылга бару түгел, урамга да чыкмый.

– Мин шаяртмыйм, бик кирәк. Анда бер хатынның тулгагы башланган, бала таба. Рамилә үзе генә башкарып чыга алмам дип курка. Миңа барырга кирәк.

– Кызым, кар йомшак, атка икебезне тартып барырга бик авыр булыр, барып җитә алмас дип куркам. Кызганыч, атым тулпар түгел, оча алмый.

– Мин бит җиңел, атка авыр булмас! – дип үтенде Гөлшат.

– Ә мин алты поттан артык.

– Син кирәкмисең, үзем генә барып кайтам. Атыңны йөрткәнем бар, узган атнада үзең өйрәттең бит.

Фәимә апа Гөлшатның уйларын белгәч: «Бу кыз юләрдер», – дип, табиб кушкан даруларны кызыл хач төшерелгән кечкенә чемоданга тутыра башлады. Унбиш минуттан Гөлшат инде әзер иде. Аның үзләрендә ике тапкыр бала таптырганы бар, шуңа күрә ул, күрше авылга барып, бала таптырудан курыкмый иде, башка бәла генә чыкмасын. Гөлшат җыенып чыкканда, Дамир абыйның аты әзер иде.

– Менә шушы толыпка төренеп утыр, атны бик нык куалама, ул үз эшен яхшы белә. Бәхетеңә, җил дә басылган төсле. Хәвеф-хәтәрсез барып кайт.

Фельдшер пункты авылның уртасында урнашкан иде. Бала табасы хатынны монда алып килеп, процедуралар ясый торган бүлмәгә салганнар. Табиб утырып килгән атны чанасы белән күршедәге ишегалдына кертеп бәйләделәр. Берничә кеше ишек төбендә басып тора. Араларыннан: «Аллага шөкер, табиб килде», – дигән сүзләр ишетелде. Гөлшат кергәндә үк, хатынның кычкырган тавышларын ишетте. Эченең ник авыртуы билгеле иде. Табиб өстендәге киемен тиз генә алыштырып, кулларын юа башлады.

Алланың рәхмәте белән, хәвеф-хәтәрсез генә исән-сау кыз бала туды. Ләкин Гөлшат, нишләптер, тынычлана алмады. Нәрсәнедер эшләп бетермәгән төсле тоелды аңа. Ул бала тапкан хатын янына яңадан килде. Нишләп соң аның эче кимемәде, йомшармады? Берничә минуттан Айсылу

яңадан кычкырып җибәрде, яңадан тулгагы башланды. Соңгылык чыгадыр, дип көтеп торганда, тагын бер бала дөньяга аваз салды.

– Игезәкләр... Менә нишләп сезнең авылны «Игезәкләр авылы» дип йөртәләр икән, – дип, соңгылык чыгуыннан тынычланган Гөлшат, перчаткаларын салып, урындыкка барып утырды.

– Аңламадым сезне? – диде янында басып торган Рамилә.

– Сезгә килер алдыннан, Фәимә апа сезнең авылны «Игезәкләр авылы» дип атады, мин бу сүзләргә игътибар бирмәгән идем, хәзер аңладым. Сезнең авылда, чынлап та, игезәкләр күпме?

– Җитәрлек. Һәрбер дүртенче гаиләдә игезәкләр туа, дип әйтәләр. Дөрестерме, юкмы – белмим. Мин үзем бу авыл кызы түгел. Гөлшат апа, килгәнегез өчен бик зур рәхмәт. Бу минем беренче бала таптыруым. Җитмәсә, игезәкләр булып чыкты.

Рамиләнең күзләре шатлыктан ялтырап тора иде.

– Минем дә бу өченче тапкыр гына бала таптыруым: ике малай, ике кыз. Икегә-ике, – дип елмайды Гөлшат.

– Эшегез буенча гомер буе балалар таптыргансыз дип уйларга була, кулыгыз калтырап та карамады, – дип мактады Рамилә.

Кинәт бүлмәгә олы яшьтәге бер апа килеп керде дә:

– Бик зур рәхмәт сиңа, кызым, – дип, Гөлшатның кулын үбәргә тотынды.

– Туктагыз, туктагыз, сез нишлисез? – диде Гөлшат, кулларын артка яшерә-яшерә.

– Мин бу бала тапкан хатын Айсылуның әнисе булам. Без андый-мондый хәл булмасын дип бик курыккан идек. Узган атнада каенанамны җирләдек. Кайгы парлап йөри, диләр бит. Каенанамның яраткан оныгы иде ул, үзе белән алып китмәсә ярый инде дип, бик курыктык.

– Тынычланыгыз, тузга язмаган сүзләр сөйләмәгез. Барысы да яхшы. Кызыгыз исән-сау, өстегезгә халат киеп, янына кереп чыксагыз да була, ләкин озак тормагыз, аңа ял итәргә кирәк. Рамилә, сиңа монда кунарга туры килер инде, Айсылуны балалары белән өйгә чыгарып булмас, игезәкләрне дә караштыргаларсың. Иртәгә нәрсә дә булса уйлап табарбыз, – дип, Гөлшат икенче бүлмәгә өс киемен алыштырырга кереп китте.

Гөлшатның кинәт хәле китеп, аяклары калтырый башлады. Ул урындыкка барып утырды. Күңеле шатланса да, арыганлыгы сизелә иде. Калган хәлен җыеп, ул өс киемен алыштырды. Шулвакыт керергә рөхсәт сорап, ишектә Рамилә күренде:

– Гөлшат апа, Айсылуның әти-әнисе өстәл әзерләгәннәр, бик үтенеп, сезне кунакка чакыралар, бармыйча ярамый. Алар күрше йортта гына яшиләр. Бармасагыз, атыгызны барыбер бирмәячәкләр, ризалашмыйча хәлегез юк, – дип куйды Рамилә, табибның барырга теләмәгәнен күреп.

Гөлшат кышкы мамык курткасын кия-кия:

– Минем башка чарам юк. Алай булгач, кереп, тиз генә чәйләр эчеп чыксаң, начар булмас, аннары кире кайтырга кирәк, – диде.

Тиз генә чәйләп чыгып китеп булмады. Гөлшатны әбинең җидесен уздырырга дип әзерләнгән табын көтеп тора иде. Кайгы белән шатлык кайвакыт бергә йөриләр бит. Гөлшат кайтып киткәнче дип, кабат бала тапкан хатын белән аның игезәкләрен карап чыкты. Айсылу тыныч кына

йоклый иде. Янында ике кечкенә курчак бу дөньяның беренче төнен уздыралар. Кызык: «Әле генә туган балага төш керә микән?» – дип уйлап куйды Гөлшат, игезәкләргә карап. Аннары үз уе үзенә дә көлке булып тоелды. Атка җигелгән чанасына утырып, авылдан чыкканда, сәгать кичке уннар тирәсе иде. Айсылуның туганнары бик кыстаса да, Гөлшат кунарга калмады. «Хастаханәгә авыру кешеләрне алып килсәләр, аларга кем ярдәм итәр? Район үзәгенә, үзегез беләсез, барып җитеп булмый, машиналар да йөри алмый», – дип, ул кайтып китте.

Ат, яхшы ашаткангамы, әллә өйгә таба кайтканны сизгәнгәме, тизрәк чапкан сыман. Урамда җил яңадан котыра башлаган, кар ява иде.

Чанада утырып кайткан Гөлшат йокыга киткәнен сизмичә дә калды. Ул битенә салкын кар бәрелгәннән уянып китте. Үзе карда ята, чанасы капланган, тирә-якта берни дә юк, котыра-котыра буран улый. Чананы әйләндереп куярга аның көче җитмәде. Ерак китте микән, юкмы, аңларлык түгел. Якын-тирәдә агачлар да күренми. Нишләргә? Басып торсаң, катып үләсең. Толыпның җиңнәренә кар кереп тулды. «Дамир абыйның әйткәннәре дөрес булып чыкты, кызганыч, ул ялгышмаган. Кар күмеп катып үлсәң, язга хәтле беркем дә таба алмас. Мин бит әле генә ике яңа тормышка дөньяга килергә ярдәм иттем, язмышым шушы микәнни?» – Гөлшатның башыннан шундый уйлар йөгереп үтте. Юк, паникага бирелергә ярамый. Ниндидер чара күрергә кирәк. Дамир абыйның аты катып үлсә, мине гафу итмәс, аны да ташларга ярамый. Беренчедән, атны чанадан азат итәргә кирәк. Салкын кар кулга ябышып комачауласа да, бармакларын өшетә-өшетә, Гөлшат атны тугарды. Ләкин ат китәргә ашыкмады. Авыл кайсы якта? Кереп качып торырга да ышык урын юк. Гөлшат озак уйлап тормастан, толыпны ат өстенә ябып бәйләп куйды да үзе ат белән толып арасына кереп ятты. Әйдә, Йолдыз, өйгә таба кайт, мин – сине, син мине җылытырсың. Ат, аның сүзләрен аңлагандай, әкрен генә атлап, каядыр китте...

Наилә апа кичке намазын укыгач, Гөлшатның кайтмавына борчыла башлады. Хастаханәгә дә шалтыратып карады, аңа: «Дамир абыйның атында күрше авылга киттеләр», – диделәр. Бу сүзләрдән аз гына тынычлангандай булса да, тынычлыгы озакка бармады. Урамда яңадан буран котыра. Әллә нинди начар уйлар аңа тынгылык бирмәде. «Бу кызның кайда киткәнен Фәимә белергә тиеш», дигән уй белән, телефон номерлары язылган дәфтәрне эзли башлады. Болай да авырта торган аяклары, бурангамы, бүген ныграк сызладылар. Алар аңа тиз-тиз йөрергә ирек бирмәделәр. «Эх, картлык, шатлык түгел. Кичә Гөлшат өйне җыештырып чыккан иде, телефон китабын тагын каядыр тыгып куйган», – дип, өй буйлап йөргән вакытта телефон үзе шалтырады:

– Тыңлыйм, кем бу?

– Гафу ит, Наилә апа, Дамир шалтырата, Гөлшат Равилевна кайтса, безгә хәтле килеп йөрмәсен. Атны үзегезнең ишегалдына гына кертеп, ат өстенә мин биргән толыпны ябып куйсын.

– Тукта әле, Дамир! Нинди ат? Син аның белән түгелмени?

– Юк, ул үзе генә Шамилевкага китте. Бер хатын анда бала табарга җыенган да, ашыга-ашыга шунда китте. Кар күп булгач, атка авыр була дип, мин бармадым, – диде Дамир, гафу үтегәндәй.

– Син, карт баш, буранлы көнне яшь кызны берүзен генә ничек җибәрдең? Әгәр адашып катып үлсә? Атың турында уйлагансың, ә япь-яшь кызның гомере турында уйладыңмы?

Наилә апаның ачуы урамдагы буран төсле дулый башлады.

– Куркытма инде, Наилә апа. Шамилевкада кунарга калгандыр. Мондый буранда акыллы кеше кире кайтмас. Гөлшат киткәндә, буран тынып торган иде бит.

– Ул кызның акылы юк икәнен белмисеңме әллә син?! Авыруларым янына кайтырга тиеш дип кайтып киткәндер әле. Фәимәнең телефон номерын беләсеңме? Кая язганымны таба алмыйм.

– Беләм.

– Алайса шалтырат, Шамилевкага шалтыратып белсен, кайтып киткәнме, юкмы? Күңелем тыныч түгел, начар төшләр дә күрдем.

Наилә апа, кинәт хәлсезләнеп, телефон янындагы урындыкка утырды.

– Борчылма, Наилә апа, хәзер бөтенесен оештырырмын. Гөлшат югалып кала торган кыз түгел.

– Белешкәч, миңа яңадан шалтыратып алырсың, – дип, Наилә апа телефон трубкасын куйды. – Исән-сау кайтса, колагын борам бу кызның. Карт кешене шундый борчуларга салырга ярыймыни?

Күп тә узмады, Дамир кире шалтыратты:

– Наилә апа, сезнең сүзегез дөрес булып чыкты. Безнең акылсыз кызыбыз сәгать унда ук кире кайтып киткән, кунарга калмаган. Сәгать унике тула, тиздән кайтып җитәргә тиеш.

– Тиеш кенә шул. Урамда нинди буран икәнен күрәсеңме? Кешеләр җыеп, каршысына чыгарга кирәк. Андый-мондый адашса, туңып үлә күрмәсен. Кар басып китсә, язга хәтле таба да алмабыз, син шуны аңлыйсыңмы?

– Син бигрәк инде, Наилә апа, куркытма. Кемгә әйтим икән, сәгать төнге унике бит? Авыл кешесе йокларга иртә ята, аннары мондый буранда кемнең чыгасы килер икән? Тагын берәр сәгать көтик, әгәр кайтмаса, кешеләрне җыярбыз.

– Ярар, көтик. Син ярдәмгә кемне чакырырга була икәнлеген уйла. Минем ише картлар кар ерып йөри алмыйлар, монда яшьләр кирәк.

– Ярар, уйлармын, – дип, Дамир трубканы куйды.

Бер сәгать көтеп утырырга Наилә апаның сабырлыгы җитмәде: «Агроном Хәйдәргә шалтыратырга кирәк, ул хәзер председатель урынына калган кеше, оештырса, халыкны ул гына оештыра ала. Тизрәк шалтыратырга кирәк». Эзли торгач, Наилә апа телефон китабын тапты. Хәйдәрнең номерын җыйды. Хәйдәр башта озак кына телефонын алмады, аннары, йокы аралаш уянып җитә алмыйча, аңламыйча торды. Аңлап җиткәч:

– Наилә апа, борчылма, хәзер үзем бөтенесен оештырам, әгәр кайтып керсә, хәбәр итәрсең, – диде.

Авыл, төн уртасы булуга карамастан, уяна башлады. Идарә янында төнге бердә утызлап ир-ат җыелган иде. Кемгәдер Хәйдәр, кемгәдер Дамир, Гөлшат Равилевнаның югалуы турында хәбәрне җиткергән иде. Алты кеше чаңгы күтәреп килгән. Хәйдәр, кешеләр белән киңәшләшкәннән соң, буранга карамастан, Шамилевкага таба табиб кызны эзләргә чыктылар...

Күпме вакыт узгандыр, эзләүчеләр агачлык янына кадәр килеп җиттеләр,

ләкин беркемне дә тапмадылар. Эзләүчеләрнең берсе кар астында яткан бер агачка ялгыш абынып егылды. Игътибар белән карагач, ул әйләнеп капланган чананың тәртәсе булып чыкты. Эзләүчеләр чана янына җыелды. Аларның күбесе, арып тунса да, өйләренә кире кайту турында сүз дә кузгатырга уйламый иде. Посадка ышыгында буран аз гына сабыррак кебек иде. Бөтенесе дә Дамир абыйның чанасын таныдылар: «Ат өйгә таба кайтырга тиеш, ләкин каршыга очрамады. Тагын кайдан эзләргә? Ат өйгә кайтыр, ә Гөлшат кайда? Чананы әйләндерделәр, ләкин астында беркем дә табылмады, чана астына булса да кереп ятмаган, ичмасам».

– Бүгенгә эзләүне туктатырга кирәк, таралышыйк, барыбер караңгыда, буран котырганда таба алмыйбыз. Иртәгә, кояш чыккач, тагын эзләргә чыгарбыз, – дип, Хәйдәр кешеләрне җыеп, кире авылга кайтырга җыенды.

– Таптым, таптым, – дип кычкыра-кычкыра, Дамир абыйның күршесе Мулланур, нишләргә белмичә аптырап торган ирләр янына чабып килде.

– Кайда, кемне таптың?

– Тегендә, салам эскертләре янында Дамир абыйның аты басып тора, – диде Мулланур.

– Гөлшат юкмы?

– Аны күрмәдем.

– Күрсәт, атны кайда күрдең, бәлки, Гөлшат шул тирәдәдер? Бәлки, салам арасына кереп качкандыр? – дип, Хәйдәр Мулланур күрсәткән якка таба ашыкты.

Дамир абыйның аты салам эскерте янында бураннан качып басып тора иде.

– Гөлшат каядыр якын-тирәдә булырга тиеш, эскертләрдән эзләгез, – дип, Хәйдәр эскертләрне капшап чыкты.

Ләкин Гөлшат беркайда да юк иде. Эзләүчеләр эскерт янына җыелдылар. Аларны күреп, ат та яннарына якынрак килде. Ат өстенә ябылган толып нишләптер кабарып тора иде, аның итәге астыннан киез итекләр башы күренеп тора. Толып итәген күтәреп карагач, Хәйдәр тирән йокыга киткән Гөлшатны күрде. Менә кая кереп качкан безнең Гөлшатыбыз? Шәһәр кызы булса да, югалып калмаган. Хәйдәр, Мулланурны чакырып:

– Мулланур, бөтен кешене җыеп, авылга таба кайтыгыз, миннән башка егерме җиде кеше булырга тиеш, берәрсе ялгыш буранда адашып калмасын, аңладыңмы? Мин атны авылга таба алып кайта торам.

– Нишләп, башка эзләмибезмени? – дип кычкырып сорады Мулланур.

– Кычкырма, ат өстендә Гөлшат апаң йоклый. Бөтенегез җыелгач, бергәләшеп кайтырсыз. Барысы егерме җиде кеше булырга тиеш, мин кайта торам, аңладыңмы? – дип кабатлап әйтте Хәйдәр Мулланурга.

Эзләргә чыккан ирләр Хәйдәрне авыл башында куып җиттеләр. Ирләр аруга, туңуга карамастан, Мулланур өстеннән шаяртып, көлешә-көлешә кайталар иде.

– Гөлшат Равилевнаны хастаханәгә илтик, бәлки, аңа ярдәм кирәктер? – дигән нәтиҗәгә килделәр алар. Шуңа күрә Хәйдәр авыл уртасына таба юл тотты.

Наилә апа, буранга карамастан, өйдә утыра алмады, мунчаны томалап, акрын гына идарәгә таба китте. Юлда аның каршысына Мулланур очрады.

Ул булган хәлләрнең барысын да сөйләп бирде, Хәйдәр абыйсының табибны хастаханәгә илтергә китүе турында да әйтте. Наилә апа да ашыга-ашыга хастаханәгә китте. Гөлшатның исән-сау икәнен күргәч кенә тынычланды. Алар Фәимә апа белән чәй эчеп утыралар иде. Гөлшатның җилкәсендә җылы мамык шәл. Бите һәм куллары кып-кызыл. Наилә апаны күргәч, урыныннан торды да, гафу үтенгәндәй:

– Наилә апа, уз әйдә, безнең белән чәй эчеп ал. Сиңа да йокларга бирмәдем. Менә төн уртасы булуга карамастан, Фәимә апа да килеп җиткән. Минем аркада бүген бөтен авыл йокламый, ахрысы.

– Утыр, утыр. Чәеңне эч. Ярар, кызым, без йоклыйсын йоклаган, исән-сау икәнеңне күргәч, тынычландым инде. Син, кычыткан чыпчыгы, шуны гына әйт миңа: нигә төнгә каршы, буран дулаган вакытта чыгып киттең, шул Шамилевка авылында кунсаң, ни булыр иде?

– Ярар, Наилә апа, безнең кар кызыбыздан сорау алма инде. Әйдә, киемнәреңне сал, утыр, сызлаган аякларың белән кар ерып килгәнсең, ял итеп ал. Ә бу акылсыз кызны, үзең әйтмешли, кычыткан чыпчыгын, ачуландың ни, ачуланмадың ни, барыбер файда юк. Юкка нервыларыбызны гына какшатабыз. Гөлшат, син безгә шуны сөйлә: бала ничек, исән-саумы?

Баш шәфкать туташы, Наилә апаны утыртып, чәйләр ясады.

– Барысы да яхшы узды, бернинди дә көтелмәгән хәлләр булмады, – дип җавап бирде Гөлшат, җилкәсеннән шуып төшкән мамык шәлен төзәтеп.

– Ничек инде берни дә булмады? Игезәк бала таптыргансың бит, бу – үзенә бер шатлыклы хәбәр.

– Ә сез каян беләсез, Рамилә шалтыраттымы әллә? – диде Гөлшат, аптыраган күзләрен ялтыратып.

– Юк, сине эзләгәндә, үзем шалтыраттым. Рамилә мактанды инде. Наилә апа, тагын чәй ясыйммы? – дип, Фәимә апа урындыктан торды.

– Юк, Фәимә, рәхмәт, кайтырга кирәк. Буран да тынган төсле. Чәйләрегез бик тәмле булды. Аякларым да әз генә ял итеп алды. Кайтыйм. Иртәнге намазга да вакыт җитеп килә, – дип, тынычланып, Наилә апа кайтырга кузгалды.

– Син, ял ит, – дип, Фәимә апа өстәлне җыештырды да бүлмәдән чыгып китте. Гөлшат үзе генә калды.

Наилә апа ашыкмыйча гына коридорга чыгып, пәлтәсен урындыкка куйды, җилкәсенә төшкән мамык шәлен башына урады.

Караңгы коридорда бик таныш тавыш яңгырады:

– Синме соң бу, Наилә? Исәнме!

Наилә әлеге тавыштан катып калгандай булды:

– Закир, синме бу? Әллә саташам инде?

– Юк, саташмыйсың. Бу, чынлап та мин, Закир.

– Син монда каян килеп чыктың?

– Менә туган авылыма кунакка кайткан идем, монда кунакханәгә урнаштым. Авылда якын туганнарым калмады бит, – дип елмайды Закир.

– Ник безгә кермәдең? Бер кешегә генә урын тапкан булыр идем. Бәлки, син үзең генә түгелдер, хатының, балаларың кайда?

– Мин үзем генә.

– Ярар, җитәр, мин бит унсигез яшьлек кыз түгел, дөресен сөйләсәң дә була, өйгә кайтырга кирәк.

– Тукта, ашыкма. Без күрешмәгәнгә кырык елга якын бит.

– Утыз сигез ел да алты ай, – дип төзәтте Наилә апа, Закирның йөзенә туры карап.

– Алайса, мин сине кунакка чакырам. Әйдә, минем бүлмәмә керик. Коридорда басып тору яхшы түгел, авыруларны уятырбыз, палатада мин берүзем генә, – дип, Наилә апаның сүзләрен ишетмәгәндәй, ул үзе яткан палатага күрсәтте.

Наилә апа теләмичә генә, бүлмәгә керде.

– Синең белән болай очрашырбыз дип уйламаган идем, – дип, Наилә апа, чатанлый-чатанлый, урындыкка барып утырды. – Бер дә кирәкмәгәнгә тез башлары сызлый башлады, кар ерып килү файдага китмәде.

– Син һаман шул элеккеге кечкенә Наилә икәнсең, – дип, Закир да караватына барып утырды.

– Шулайдыр инде, салпы якка салам кыстырып ятма. Йә, сөйлә, кайларда йөрдең, ничек яшәдең? Кырык ел узгач, туган якларга нинди җилләр ташлады? Гаиләң кайда? Өйләндең дип ишеткән идем. Балаларың зурлардыр инде?

– Боларны сөйләп бетерергә төн дә җитмәс.

– Мин беркая да ашыкмыйм, сөйлисең килмәсә, сөйләмә, кайтып китәм.

– Үзең ничек яшисең?

– Аллага шөкер, бер кызым бар, монда табиб булып эшли, аякларым сызламаса, калганына зарланып булмый. Мин авылыбыздан китмәдем. Син армиягә киттең дә югалдың. Әниеңне җирләргә дә кайтмадың.

– Ярама тоз сипмә инде, Наилә. Хәзер дә ярсып тора. Кабере кайда икәнен дә белмим. Мин бит Владивостокта хезмәт иттем. Анда хатлар да айлар буе килә, кайтып килү турында сүз дә юк. Беренче ел хезмәт итүче матросны кем җибәрсен?

– Хезмәтең беткәч, ник авылга кайтмадың?

– Башта җибәрмәделәр, тагын бер елга мәҗбүри калдырдылар. Аннары кайтуның мәгънәсе дә калмады, авылдашларым алдында да оят иде.

Наилә апа, «Ничек инде мәгънәсе юк, ә мин, Мәдинә тавында бер-беребезгә биргән вәгъдәләребез, син алар турында ничек оныта алдың?» дип, бик тә әйтергә теләгән иде, ләкин эчендә кинәт яңарган яшьлек хисләрен басып:

– Бер хат та язмадың, – дип кенә әйтә алды.

– Башта Советлар иле буйлап акча эшләп йөрдем, аннары техникумда укыдым, Әлмәткә нефтьче булып кайттым, – дип сөйләвен дәвам итте Закир абый, Наилә апаның соңгы сүзләрен ишетмәгәндәй. – Читтән торып укып, институт тәмамладым, өйләндем, ике малай туды. Шулай сизелмичә гомер узып та китте. Менә хәзер бөтен эшләремне улларыма тапшырдым да эшсез калдым. Буш вакытым күп. Картаймыш көнемдә туган авылыма кайтасым килде.

– Җан тартмаса да, кан тарта, – дип, Наилә апа авыр сулап куйды.

– Шулай, ахрысы. Монда кайткач, йөрәк кысып алды, улым районга илтмәкче иде дә, мин бирегә килдем. Үлсәм монда үләрмен, дигән идем дә,

тик Гөлшат Равилевна үләргә бирмәде. Ник соң мин һаман үзем турында гына сөйлим. Син дә үзең турында сөйлә әле.

– Әгәр минем ничек яшәгәнемне күрәсең килсә, миңа кунакка кил, чәйләр эчәрбез, шунда барысын да сөйләрмен. Сине моннан кайчан чыгаралар?

– Гөлшат Равилевна ул турыда бер сүз дә әйтмәде. Син үзең сора, кызым, диден бит. Яхшырак һәм тизрәк дәваласын.

– Ярар алайса, мин кайтыйм, очрашырбыз әле. Монда ничектер күңелсез. Сау бул. Тизрәк терел, – дип, Наилә апа, торып, ишеккә таба китте.

– Сау бул. Алла боерса, тагын очрашырбыз әле, – дип, Закир абый озата чыкты.

...Наилә апа янына иртән иртүк торып, мич янында мәш килде: тәмле сумсалар, бәлешләр пешерде, иң соңыннан мичкә ипи салды. Тиздән өйгә яңа пешкән икмәк исе таралды. Гөлшат, тәмле исләргә исереп, тиз генә юынды да өстәл янына килеп утырды, ләкин әле генә пешкән ризыкларның берсе дә өстәлгә чыкмады. Гөлшат:

– Бүген нинди бәйрәм, туган көнең түгелдер бит? – дип кызыксынса да, аңларлык җавап ала алмады. Тәмле исләрдән тәмам исермәс өчен ул, бизәнеп тә тормыйча, тизрәк киенеп, өйдән чыгып китте.

Көн гадәттәгечә узды, бернинди дә көтелмәгән вакыйгалар булмады. Каты авырулар булмагач, Гөлшат көндәгедән иртәрәк тә кайтты. Өйдә өстәл әзерләнгән иде.

– Бүген нинди бәйрәм соң, Наилә апа? Иртәдән бирле мәш киләсең. Бүген сиңа кунаклар килә, ахрысы?

– Яшьлегем искә төште, бәлки, кем булса да килеп чыгар? – дип, серле генә елмайды Наилә апа. Гөлшат, кунакларга комачаулыйсы килмичә:

– Минем Гөлҗамал апаның хәлен белеп киләсем бар, – дип, яңадан киенеп, өйдән чыгып китәргә җыенды.

– Гөлшат, Закир абыеңны бүген чыгарырга тиеш идең, аның белән андый-мондый хәл булмагандыр бит? – дип, кинәт сорап куйды Наилә апа.

– Аны иртә белән үк малае алырга килгән иде, – дип, уйламыйча җавап бирде Гөлшат.

– Ничек, иртүк? Син бит гадәттә уникеләр тирәсендә чыгара идең.

– Миңа кәгазьләр кирәк түгел, үземне яхшы хис итәм, тарих китабым болай да тулы дип, Закир абый иртүк китеп барды, – диде Гөлшат өйдән чыкканда.

Гөлшат кайтып кергәндә, өстәл җыелган иде.

– Кунакларың киттеләр дәмени, Наилә апа, бигрәк аз утырганнар?

– Картлар озак утырмыйлар, кулларыңны ю да, ашарга утыр, авыл буйлап кар ерып йөреп ачыккансыңдыр.

– Урамда шундый күңелле, яз килә, табигать уяна, түбәләрдән тып-тып тамчылар тама, сыерчыклар да килгән, шундый рәхәт.

Кинәт Гөлшат, бәлешнең башланмаганлыгын күреп, шунда ук иртүк әзерләнеп көтеп тә килми калган кунакның кем икәнен аңлап алды:

– Закир абый килмәдемени? – дип, үзе дә сизмәстән сорап куйды Гөлшат.

– Килмәде, яңадан китеп барды.

– Син аны яшьтән үк яраттыңмы?

– Кем белгән инде аны яшь чакта. Без бергә үстек, күршеләр идек.

Сугышта әтиебез һәлак булгач, безнең өйдә ирләр калмады, без, өч кыз бала, ятим калдык. Әниебез иртәдән кичкә хәтле фермада, колхозда эшләде. Иң олысы булгач, бөтен өй эше миндә иде: утын алып кайту да, су ташу да. Закир һәрвакыт миңа ярдәм итә иде. Урманга утынга да бергә йөрдек. Ул мине «уфалла арбасы»на утыртып бара иде, аннары, утынны төягәч, бергәләп, арбаны тартып кайта идек. Яшь чаклар авыр булса да, күңелле иде. Җәй көннәрендә бергә урамга чыга идек. Бервакыт хәтта Мәдинә тавында кунып калдык. Шулай утынга дип баргач, кинәт каяндыр болыт чыгып, көчле яңгыр яварга тотынды. Безнең бер серле урыныбыз бар иде, шунда качып тордык. Яңгыр туктагач чыксак, теге елгабыз, күтәрелеп, котырынып ага. Елганы кичеп чыга алмыйча, Мәдинә тавында кунарга мәҗбүр булдык. Төне буе учак ягып чыктык. Ярый әле әнкәй өйдә булмады, районга киткән иде. Сеңелкәшләр минем өйдә төн кунмаганны әнигә сатмадылар. Шул вакытта «Үлгәнче бергә булырбыз», дип вәгъдәләшкән идек. Закир армиягә китәргә тиеш иде. Мин аны көтәрмен дип тә вәгъдә бирдем. Ә ул армиядән авылга әйләнеп кайтмады, Советлар Союзы буйлап йөргән...

Наилә апа тынып калды.

– Мәдинә тавында яшьләр вәгъдәләшсәләр, гомер буе бергә булалар, дигән идең бит.

– Ул бит, кызым, халык уйлап чыгарган бер матур әкият кенә. Тормыш үзенчә бара. Менә бүген дә, хастаханәдән чыккач күрешербез, дип сөйләшкән идек тә, насыйп булмады, тагын китеп барган.

– Син аны һаман яратасыңмы? – дип, Гөлшат Наилә апасының каршысына ук килеп утырды.

– Әй, кызым, безнең яшьтә нинди ярату булсын? Ничә еллардан соң очрашкач, яшьлек искә төшеп китте. Тагын бер тапкыр күрешеп, сөйләшеп утырасы килгән иде, ләкин барып чыкмады. Нишлисең инде. Әйдәле, бергәләп, тагын бер чынаяк чәй эчеп алыйк.

Гөлшат, сүзне башкага борып, аның күңелен күтәрергә тырышты. Закир абый турында башка сораулар бирмәде.

...Фәимә апа иртән гадәттәгечә эшкә барырга чыкты. Урамда кар күп булса да, яз исе сизелә. Төнлә салкын булганга, күрәсең, юлдагы сулар боз белән капланган. «Яз килә. Авыручылар тагын күбәячәк», – дип уйланып барганда, аның алдына күрше урамда яшәүче Рәмзия ханым килеп чыкты.

– Исәнме, Фәимә. Гафу ит инде, сине урам уртасында туктаткан өчен. Миңа киңәш кирәк иде. Нишләптер эчем авырткалый. Нинди дә булса дару тәкъдим итмәссең микән? Бүген дә төнлә борчып алды.

– Син октябрь аенда районга барып тикшеренгән идең бит?

– Мин ятып тормадым, йөреп кенә УЗИ ясаттым, ашказанын тикшерттем, бернәрсә дә тапмадылар. Кендек турысында кечкенә генә бүсер бар, диләр, бәлки, шул борчый торгандыр?

– Син Гөлшат янына кереп кара, бәлки, ул дөрес киңәш бирер.

– Ул яшь бит әле, укып кына бетергән. Нәрсә белсен ул?

– Алай димә, Гөлшат Равилевна яшь булса да, белеме бар. Мин төрле табибларны күп күрдем. Бу кыз яхшы табиб булачак: белеме дә бар, тырышлыгы да җитәрлек, бик кешелекле дә. Килеп күренеп кит, синнән беркем дә акча сорамый, бәлки, берәр нәрсә тәкъдим итәр.

– Алайса, кайчанрак килим икән?

– Үзеңә кара. Иртән эш күп була, сәгать унберләр тирәсендә килсәң, яхшы булыр. Гөлшат Равилевна да шул вакытка бушый.

– Ярар алайса, – дип, Рәмзия акрын гына өенә кайтып китте.

Фәимә хастаханәгә таба атлады. Хастаханәдә аны көндәлек эшләр, иртән килгән яңа авырулар көтә иде. Иртәнге обход белән вакыт бик тиз уза. Ләкин иртән очраган Рәмзия өлкән шәфкать туташының башыннан чыкмады. Ул эштән бушый төшкәч, табиб янына керде:

– Гөлшат Равилевна, бер хатынны карап ала алмассың микән? Ярты ел буе эче белән нужара, районга да барып кайтты, ләкин берни дә тапмадылар.

– Мин табар дип уйлысызмы? Миндә бернинди дә аппаратура юк бит. Без монда патша заманындагы табиблар төсле эшлибез.

– Ярар инде, бәяңне күтәрмә. Син яшь күзләрең белән кара. Бәлки, Казанга җибәрербез? Кайсы табибка күренергә кирәклеген әйтерсең. Алар бик яхшы кешеләр. Син игътибарлырак кара инде.

– Килгән булса, чакыр.

Фәимә апа чыгып, Рәмзияне алып керде. Кечкенә генә буйлы матур ханымның өстендәге киеме ничектер берәр үлчәмгә зуррак төсле күренде Гөлшатка. Кайчандыр калын булган чәчләре тыйнак кына артка җыеп куелган. Табиб:

– Апа, ниләр борчый, нәрсә китерде безгә? – диде.

– Болай нык авырткан җирем дә юк төсле, ләкин нишләптер хәлем юк, вакыты-вакыты белән эчем борчып ала. Районга да барып, тикшерелеп карадым: УЗИда да карадылар, куркыныч берни дә тапмадылар.

– Монда узыгыз, чишенегез, хәзер без эзләп карарбыз.

Бу апаны күргәч, Гөлшатның башында ниндидер шик туды. Ныклап карый, тикшерә торгач, шиге үсә генә барды. Гөлшатның күз алдына әнисе килеп басты. Ул да бит шулай зарлана башлаган иде, аны да шундый авырту борчыды. Гөлшат куркудан калтырап куйды. Бөтен көчен җыеп, үзен кулга алырга тырышты, аның йөзе агарып китте, кул бармаклары калтырый башлады. Бәхетенә, Рәмзия боларны күрмәде. Тикшерүне бетергәч, Гөлшат тирән итеп сулап куйды һәм, киенегез дип, өстәл артына барып утырды. Ул Рәмзиянең элек узган тикшеренү нәтиҗәләре белән танышты. Ләкин аларда бернинди дә куркыныч нәрсәләр юк иде. Гөлшат Рәмзия алып килгән язмаларны кире үзенә бирде.

– Минем уемча, сезгә кайбер тикшерүләрне яңадан узарга туры килер.

– Кирәк булса, узарбыз. Сез миңа нинди тикшерүләр узарга кирәклеген язып бирегез, мин районга барып, тикшеренеп кайтырмын. Күбесен уздым бит, тагын ниндиләре калган?

Гөлшат берничә минутка югалып калды. Читтән генә күзәтеп торган Фәимә апа, табибның сүзсез калуын күреп:

– Рәмзия, син бар, кайта тор. Мин сиңа юлламаларны кайтканда кертеп чыгармын, бәлки, кайбер тикшерүләрне Казанда узарга туры килер. Шуңа күрә башта районга шалтыратып, рөхсәт алырга кирәк, аңладыңмы?

– Рәхмәт, Гөлшат Равилевна, болай куркыныч чир юктыр бит? – дип, шикләнеп сорады Рәмзия.

– Тикшерүләр уздырмыйча, мин төгәл әйтә алмыйм. Мин Илдар

Азатовичка хәзер үк шалтыратам, аның рөхсәтеннән башка мин сезне Казанга җибәрә алмыйм, – дип, Фәимә апаның сүзен җөпләп куйды Гөлшат.

– Ярар алайса, мин кайтам, Фәимә апа, кичтән сине көтәм, – дип, Рәмзия чыгып китте.

Гөлшат урындыкка барып утырды:

– Рәхмәт, Фәимә апа.

– Тагын нәрсә булды инде, нишләп агарып каттың, кулларың да калтырый башлады? Син бит беренче көн генә эшләмисең? Тикшеренергә кая җибәрәбез?

– Рәмзия апада шеш.

– Кай җирендә?

– Минем уемча, ашказанында.

– Юк, Гөлшат Равилевна, сез ялгышасыз. Ике ай элек ашказанын районда каратып кайтты гына әле ул. Анда бернинди дә зыянлы әйбер тапмадылар, – Фәимә апа тынычлана төште.

– Ялгышсам, мин бик шат булыр идем. Ләкин, минем уйлавымча, бу апаны Казанга, онкологиягә җибәрергә кирәк.

– Ничек җибәрәбез? Аны бит безнең район хирурглары карады. Син, Гөлшат Равилевна, тагын уйлап кара әле, бәлки, ялгышасыңдыр. Әйдә, төшке аш вакыты җитте, бәлки чәйләр эчкәч, башка уйлар килер.

Чәйне эчеп бетерергә бирмәделәр, Рәмзиянең ире Таһир килеп керде:

– Гөлшат Равилевна, минем Рәмзиядә нәрсә? Ул мине Казанга җибәрәләр, диде. Илдар Азатовичтан ниндидер рөхсәт кирәк дип ишеткән. Мин аны яхшы беләм. Кирәк булса, Илдар Азатовичка үзем кереп сорыйм.

– Таһир абый, монда узыгыз. Бик вакытлы кердегез. Сезнең белән сөйләшәсе сүз бар иде, – дип, Гөлшат торып, үзе утырган урындыкны тәкъдим итте.

– Юк, рәхмәт, мин утырып торырга өйрәнмәгән, сез миңа нинди тикшерүләр кирәклеген әйтегез. Миңа Рәмзиянең сәламәтлеге бик кадерле.

– Сезгә, Казанга онкологиягә барып, тикшеренеп кайтырга кирәк. Минем уйлавымча, сезнең хатыныгызның ашказанында шеш бар.

Бу сүзләрдән соң, зур, көчле гәүдәле илле алты яшьтәге ир-ат кинәт кечерәеп, хәлсезләнеп, тәкъдим иткән урындыкка барып утырды.

– Юк, сез ялгышасыз, аны бит тикшерделәр, ашказанын да карадылар, бәлки, сез яшьлегегез белән генә ялгышасыздыр? – дип, Таһир зур куллары белән битен каплады, агарып килгән чәчләрен сыйпап куйды һәм Гөлшатка текәлеп карады.

– Мин кабатлап әйтәм, сезгә, Казанга барып, яңадан тикшеренеп кайтырга кирәк. Ким дигәндә, ашказанын яңадан тикшертергә һәм УЗИ белән бавырын, бөерен, гомумән, эчке әгъзаларын каратырга кирәк. Онкологиядә тикшеренсәгез, тагы да яхшы булыр иде. Озакка сузарга тырышмагыз. Казанда аппаратура да яхшырак. Минем бик ялгышасым килә, әгәр мин ялгыш диагноз куйган булсам, бик шат булыр идем, – дип, Гөлшат, өстәл артына утырып, юллама язды һәм Таһирга кәгазьне сузды.

Фәимә апа Таһирга торырга ярдәм итте:

– Син бит ир-ат, җебеп төшмә. Мондый кыяфәтеңне Рәмзия күрсә, барысын аңлап алачак.

– Рәхмәт, Фәимә. Сау булыгыз, Гөлшат Равилевна. Мин алайса киттем, – дип, Таһир бүлмәдән чыгып китте.

– Гөлшат Равилевна, сез бигрәк туры һәм каты әйттегез, алай иртә әйтергә кирәк түгел иде. Үзем әкрен генә әйткән булыр идем, – дип, Фәимә апа Таһир артыннан чыкты.

...Тормыш туктап тормый. Көн артыннан көн уза, атна артыннан атна, Гөлшатның тормышында гына үзгәрешләр күренми. Бүген дә иртән ул, гадәттәгечә, хастаханәдә ятучыларны карап чыкты һәм авырулар тарихын язарга утырды. Тагын бер ай узып бара. Тормыш акрын гына үз тәртибе белән дәвам итә. Гөлшатны уйларыннан бүлеп, кинәт телефон шалтырады:

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна тыңлый.

Телефонда баш табиб тавышы ишетелде:

– Исәнмесез, Илдар Азатович.

– Сез нишләп партизанить итеп ятасыз? Үзегезне бик акыллы дип саныйсызмы әллә? Нишләп сез кешеләрне безнең рөхсәттән башка Казанга җибәрәсез. Алар, акча түләп, Казанда тикшерүләр узып йөриләр, районда узар урынга. Аларның болай да акчалары юк. Сез нәрсә, белмисезме әллә, медицина ярдәме безнең илдә бушлай күрсәтелгәнне?

– Мин беркемне дә Казанга җибәргәнем юк. Бөтен кешеләрне районга җибәрергә тырышам, – дип акланырга тырышты Гөлшат.

– Син минем башымны әйләндермә. Сибгатуллиннарны син җибәрдең бит. Ярар, районга килгәч, сөйләшербез әле, – дип, баш табиб трубкасын куйды.

Эш көне бетеп килгәндә, кабул итү бүлмәсе ишек төбенә, сызгыртып, машина килеп туктады. Хастаханәгә бер ханым белән машина йөртүче керделәр. Ханым кабул итү бүлмәсендә утырып калды, ә Мансур хастаханәгә кереп югалды.

– Гөлшат Равилевна, без кире кайтып җиттек, – диде Мансур керә керешкә.

– Нәсимәне салдылармы? – Әйберләрен урнаштырудан туктамыйча сорады Гөлшат.

– Юк, без кире кайтык.

– Ничек инде кире? Аңа бит операция ясарга кирәк. Кинәт, туктап, табиб урындыкка утырды. Нәсимәне кем карады? Хирурглар, гинеколог карадылармы?

– Карадылар, карадылар. Безнең Гөлшат Равилевнаның бармаклары УЗИ аппаратын алыштыра, дип көлешә-көлешә карадылар.

Табибларның, җыелып, аннан ничек көлүләрен күз алдына китерепме, Гөлшатның битләре кызарып чыкты. Ләкин ул, тиз генә тынычланып, үзен кулга алырга тырышты.

– Гөлшат Равилевна, Нәсимәгә, ничек, өенә кайтырга ярыймы соң? – диде Мансур, Гөлшатның югалып калуын күреп.

– Ә ул үзе кайда?

– Кабул итү бүлмәсендә калды.

– Әз генә көтеп торсын, мин хәзер килермен.

Гөлшат уйга калды: «Әгәр районга шалтыратса да, бер кайтарып җибәргәч, Нәсимәне кире хастаханәгә алмаячаклар. Нишләргә? Ник соң мин шуның кадәр борчылам? Миннән өлкәнрәк, остарак табиблар карасыннар

дип, районга җибәрдем, йөкне үземнең өстән төшердем. Нишләптер күңел тыныч түгел. Тагын бер тапкыр карыйм да кайтарып җибәрәм».

«Фәимә апа эштән иртә китми» дигән уйлар белән Гөлшат өлкән шәфкать туташы бүлмәсе янына килде:

– Фәимә апа, бер хатынны бергәләшеп карыйк әле.

– Нәрсә, профессор Гөлшат Равилевна тагын диагноз куя алмыймы әллә?

– Көлмә. Мин бер хатынны районга җибәргән идем. Минем уемча аның «трубная беременность» булырга мөмкин, ләкин аны районда салмаганнар, бернәрсә юк дип, кире кайтарып җибәргәннәр.

– Ә үзең ничек уйлыйсың?

– Менә тагын бер тапкыр бергәләп карыйк әле, аннары уйларбыз.

Фәимә Нәсимәне чакыртып кертте.

– Нәсимә, сезне хәзер нәрсә борчый?

– Болай берни дә юк төсле, ләкин машинада озак баргангамы, эчнең аскы өлеше авыртып тора, зур йомыш белән тышка чыгасы килгән төсле, ләкин бернәрсә дә чыкмый, – диде Нәсимә, оялып кына.

Фәимә апа Нәсимәгә хатын-кызларны карый торган креслога менеп ятарга ярдәм итте. Карап бетерде, перчаткада кан...

– Кунакларың килгән, ахрысы, Нәсимә, – дип, Фәимә апа, раковина янына килеп, кулын юды.

– Аллага шөкер, бераз соңарып калганнар иде, быел бала табу планга кермәгән иде әле, – дип, Нәсимә шаяртырга тырышты.

Гөлшатның кинәт дүртенче курста акушерлыктан биргән имтихан исенә килеп төште. Аның билетында нәкъ менә шушындый мәсьәлә иде, ул аны дөрес чишә алмады, шуна күрә дүртле алды. Ә дөрес җавабы – «прервавшаяся трубная беременность» иде, эчтә кан ага. Гөлшат уйланып торган арада Нәсимә креслодан төшеп киенә башлады һәм көтмәгәндә, идәнгә егылды. Фәимә апа, моны күреп, тиз генә аңа кушеткага ятарга ярдәм итте дә, «нишлибез» дигәндәй, сораулы күзләре белән табибка карады.

– Фәимә апа, кан тамырына система куярга кирәк. Мин каталка алып киләм, – дип, Гөлшат, ашыгып, бүлмәдән чыгып китте.

Ул коридорда Мансурны очратты:

– Тиз генә шәфкать туташын чакыр әле, – дип, бүлмәгә каталка тәгәрәтеп керде.

Фәимә апа озак кына система куеп маташты, ләкин куя алмады, кан тамырлары каядыр качкан иде:

– Кан басымы бик түбән, ахрысы, кулларында веналары батып кергән, таба алмыйм.

– Ярар, Фәимә апа, каталкага күтәреп салыйк та безнең операцияләр бүлмәсенә алып керик.

– Тагын ни эшләмәкче буласың?

– Үзем дә белмим әле. Бу хатынны ничек тә булса үлем тырнагыннан йолып калырга кирәк.

Бүлмәгә Мансур белән шәфкать туташы Асия килеп керделәр.

– Әйдәгез, күтәреп салырга ярдәм итегез! – Фәимә апа Нәсимәнең башы очына килеп басты. Ханымны тиз генә күтәреп, каталкага салдылар һәм операцияләр бүлмәсенә алып кереп киттеләр.

– Фәимә апа, Илдар Азатовичка шалтырат, барысын да аңлатып бир, без Нәсимәне әзерли торабыз, аны үзәк хастаханәгә алып барып җиткерә алмыйбыз, тизрәк үзләре килеп җитсеннәр, анестезиолог белән бергә. Мин система куя торам, – дип, Гөлшат ашыгып чыгып китте.

Операцияләр бүлмәсендәге Асия:

– Гөлшат Равилевна, мин веналарны таба алмадым, бәлки, венесекция ясарсыз?

– Хәзер карарбыз. Асия, инструментларны әзерли тор. Тиз генә кан басымын үлчә.

Гөлшат Нәсимә янына килде, ул көчкә күзләрен ачты:

– Башым әйләнә, бөтенләй хәлем юк, мин исән калырмынмы? Коткарыгыз мине, Гөлшат Равилевна.

– Борчылма, хәзер система куябыз, хәлең әйбәтләнер, – дип, Гөлшат Нәсимәнең кулларын карады. Кулындагы кан тамырлары батып кергән, аларга энә белән керүгә бер дә өмет юк иде.

– Гөлшат Равилевна, кан басымы сиксән, түбән, – дип, Асия Гөлшатны кисәтеп куйды.

– Миңа катетер белән шприц бир, муенында кан тамыры яхшы, монда куеп карыйбыз, – дип, Гөлшат кулына спиртлы мамык алды да Нәсимәнең муенында кан тамыры турысын сөртә башлады.

Фәимә апа килеп керде:

– Йә, ни эшлибез, Илдар Азатович бер сәгать эчендә килеп житәргә тырышырбыз, – диде.

– Безнең бер сәгать вакыт юк. Тиз генә нәрсә булса да эшләмәсәк, без аны югалтачакбыз. Фәимә апа мин венага катетер куйдым. Операцияне үзебез башлыйбыз, башка чара юк, Нәсимәнең эчендә кан ага, тиз арада туктатмасак... Үзең беләсең.

– Син нәрсә, акылдан яздыңмы әллә, эчне яру җиңел эш түгел, аннары кем наркоз бирер?

– Безнең калипсол белән промедол бар, шуның белән башлыйбыз, Илдар Азатовичлар килеп җиткәч, калганын эшләрләр. Безнең стерильный инструментлар бар бит. Фәимә апа, бар инде әзерлән, вакытыбыз юк.

– Нәрсә эшләгәнеңне үзең беләсеңдер. Мин хәзер әзер булам.

– Асия, аз гына кан ал, миңа кан группасы белән резусын тикшерергә кирәк, – дип, Гөлшат муендагы кан тамырына куйган системаны тизләтә төште.

Инде ун минуттан Гөлшат стерильле халат, перчаткалардан операцияләр өстәле янында басып тора иде. Куркудан бөтен дөньясы калтырый, ләкин ул аны сиздермәскә тырыша:

– Аллага тапшырып башладык.

Гөлшат кендектән түбәнрәк эчне ярды. Нәсимәнең эче тулы кан. Салфеткалар белән канны җыеп алмакчы булды, ләкин кан кимемәде.

– Кан басымы бик түбән, – дип кисәтте Асия.

Канаган урын һаман табылмады. Эчәкләрне бер кырыйга этеп торып, Гөлшат аналыкны тапты, уң якта кечкенә генә кан тамырыннан сиптереп кан ага иде. Шул кан тамырын кыскыч ярдәмендә эләктереп, җеп белән

бәйләгәч, кан агудан туктады. Хәзер ашыкмыйча гына эчәкләр арасыннан канны җыеп алырга да була. Нишләптер эчтәге канны җыеп, кире кан тамырына салырга Гөлшатның башы җитмәде. Андый уй таздагы канга баткан салфеткаларга карагач кына килде.

– Гөлшат апа, кан басымы күтәрелми, – дип, Асия тынлыкны бозды.

– Мезатон, адреналин яса, полиглюкинны тизләт.

– Болай да инде тиз тама, кан тамырына ике литрдан артык су салдым бит инде, даруларны да ясадым.

– Кискән эчнең ярасы да каный башлады тагын, – дип өстәп куйды Фәимә апа.

Гөлшат кинәт туктап калды. «Әгәр бу ханым үлсә, мине беркем дә яклап чыкмас, мин бит хирург түгел, операцияне ник башладым?» дигән уйлар аңа тынгылык бирмәде. «Юк, туктарга ярамый, йөрәк эшли бит әле. Нәрсәдер эшләргә кирәк».

– Асия, тиз генә каталка алып кер, – дип, Гөлшат халаты белән перчаткаларын салды һәм, сул кулына жгут урап, Асия керткән каталкага менеп ятты:

– Минем шундый ук группа, резус. Минем канны ал.

Илдар Азатович белән хирург операцияләр бүлмәсенә кергәндә, Гөлшат каталкада ята иде. Аның канын Нәсимәгә тамыза башлаганнар иде. Илдар Азатович бер күрүдә барысын да аңлады, Нәсимә янына килеп басты:

– Кан басымы күпме?

– Җитмешкә якын.

– Наркозга нәрсәләр ясадыгыз?

– Биш кубик калипсол белән ике кубик морфий, – диде Асия.

Хирург тиз генә операция өстәле янына килеп басты.

– Хәзер мин дә ярдәм итәрмен.

Гөлшат торып басмакчы булды.

– Син эшлисен эшләгәнсең инде, артыгы белән, калганын без Фәимә апа белән эшләп бетерербез. Прокурорга нәрсә әйтәчәгең турында уйла, бар, – дип, Илдар Азатович коры гына әйтеп куйды.

Гөлшат акрын гына, операцияләр бүлмәсеннән чыгып, үз бүлмәсендәге диванга кереп утырды. Аның аз гына башы әйләнә һәм куллары калтырый иде. Ул бернәрсә турында да уйларга теләмәде. Үз-үзенә: «Нәрсә булса, шул булыр. Нәсимә генә исән калса ярар иде. Куып чыгарсалар, кире Казанга кайтып китәрмен», – дип кенә куйды.

Ярты сәгатьләп вакыт узгач, операцияне бетереп, бүлмәгә хирург керде:

– Синең турында күп нәрсәләр ишетергә туры килсә дә, мондый ук кыюсыңдыр дип уйламаган идем.

– Акылсыз кыю, Илдар Азатович мине хәзер куып чыгарыр инде. Нәсимәнең хәле ничек? Нәрсә эшләдегез? – дип сикереп торды Гөлшат.

– Син барысын да эшләгәнсең бит инде. Миңа корсакны тегәсе генә калган иде. Син ничек курыкмыйча операция ясарга булдың? – дип сорады, шаккатып, өлкән яшьтәге хирург.

– Нәсимә үләр дип курыктым, кан басымы төшеп киткәч, башкача бернәрсә дә эшләп булмавын аңладым. Мин бишенче-алтынчы курсларда укыганда, хирург булырга хыялланып, төнге дежурстволарга йөргән идем,

операцияләргә ярдәм итәргә дә еш кына алалар иде, бәлки, шуңа күрә башлаганмындыр.

– Син, Нәсимәнең тормышын коткарып, безнең дәрәҗәне дә саклап калдың. Без бит аны хирургиягә салмыйча, кайтарып җибәргәнбез. Нәсимәне без бүген алып китә алмыйбыз, ул монда кунар инде. Сиңа да аның янында кунарга кирәк булыр, бик арысаң да, түзәргә туры килер.

Илдар Азатович китеп барганда:

– Син, шайтан кыз, башка кешене ярма. Бу турыда бик каты сөйләшәсе бар, прокурор безне аңламас, икебезнең дә башыбыз очып төшәчәк.

Нәсимә бер сәгатьтән соң уянып, аңына килде. Фәимә апа аның яныннан китмәде. Гөлшат төн буена берничә тапкыр кереп чыкты, ләкин бернинди дә куркынычлы үзгәрешләр юк иде. Иртән иртүк, ашыгыч ярдәм машинасы килеп, Нәсимәне район үзәк хастаханәсенә алып китте. Көн бик тыныч узды, яңа килүче авырулар булмады. Алай да иртән бер биш яшьлек кыз баланы алып килгәннәр иде. Бу баланы, әллә уйнап, әллә усаллык белән, үгез сөзеп еккан. Әнисе районга алып барырга теләмәде, Гөлшат та карап, куркыныч бернәрсә дә тапмады. Эче аз гына авыртып тора, үгез сөзгән җире кара янып чыккан иде. Районга барырга теләмәгәч, баланы әнисе белән аерым бер палатага урнаштырдылар. Палаталар барыбер буш, аз гына булса да, план үтәлер. Илдар Азатович болай да атна саен җыелышта: «Планны үтәмисең», – дип, кисәтү ясый. Бүлмәсендә узган көнгә нәтиҗә ясап утырганда, ишектә Фәимә апа күренде:

– Гөлшат Равилевна, бүгенгә җитәр инде, «колхоз эше бетмәс», сезгә кайтсагыз да була торгандыр. Наилә апа да: «Минем кызым ник кайтмый», – дип борчылып шалтыратты, – диде.

– Мин, чынлап та, Наилә апа турында онытканмын, кайткач, тагын гафу үтенергә туры килер. Фәимә апа, үзегез ник кайтмыйсыз?

– Мин хәзер кызларга даруларны калдырам да кайтам.

– «Патша сарае» хуҗабикәсе рөхсәт иткәч, мин дә алайса хәзер кайтам, күзләр дә йомыла башлады, кайтканда, йоклап китмәсәм ярый инде.

– Шаяртырга хәлең булгач, кайтып җитәрсең, – дип, Фәимә апа бүлмәдән чыгып китте.

Гөлшат өстәленә карап алды, барысы да тәртиптә: «Бүгенгә эшләр бетте шикелле, кайтсаң да була». Гөлшатның күзләре авырулар тарихларына төште, иң өстә иртән кергән кызның тарихы ята иде. «Шул кыз янына кереп чыгам да кайтам»,– дип уйлап, табиб бүлмәдән чыгып китте. Коридорда утырган Тәнзилә белән бераз сүз алышканнан соң, палатага керде. Кечкенә бала берүзе йоклап ята иде, янында әнисе юк. Гөлшат, уятырга теләмичә, әкрен генә кыз янына килде, кулыннан йөрәк тибешен санады, бала ыңгырашып алды. Йөрәге бик еш тибә иде, йөз утыз – йөз кырык тирәсендә. Гөлшат, кызны уятырга тырышып, исемен әйтте, ләкин ул уянмады, кулыннан җиңелчә генә чеметеп тә карады. Бала көчкә күзләрен ачты, ләкин аның күз карашы нindидер томанлы иде. Гөлшат тиз генә юрганны күтәрде, бала, эче белән суламыйча, күкрәге белән еш-еш сулый иде. Табиб тиз генә палатадан чыгып, Фәимә апа янына керде:

– Фәимә апа, Мансур кайда?

– Әле монда гына йөри иде, ул нигә кирәк булды сиңа, сине кайтарып куйсынмы әллә?

– Юк, иртән кергән кечкенә кызны тизрәк районга алып барырга кирәк, селезёнкасы шартлаган, ахрысы, эче миңа бер дә ошамый, йөрәк тибеше дә бик еш, – дип, кире коридорга чыкты.

Тәнзилә табибның чабып йөргөен күреп, борчыла башлаган иде:

– Ни булды, Гөлшат Равилевна?

– Тәнзилә, безнең нәзек кан тамырына куя торган катетер бармы?

– Бар иде каядыр.

– Тиз генә кечкенә кызга куярга кирәк һәм система аркылы полиглюкинны тоташтыр, ә мин аның әнисен эзлим.

– Әнисе, бала йоклаганда, өйгә кайтып килим дип киткән иде, ул бит күп балалы хатын. Калган балаларны ашатасым бар, дип...

– Ярар, аңладым, син бар, мин әйткәнне тиз генә эшлә, мин районга, Илдар Азатовичка шалтыратам, операциягә әзерләнә торсыннар. Бу балага да операцияне монда гына ясасак, безне аңламаслар, – дип, Гөлшат үз бүлмәсенә кереп китте.

Илдар Азатович трубканы озак кына алмый торды. Гөлшат эченнән аны ачуланып та алды. Бераздан таныш тавыш ишетелде:

– Илдар Азатович тыңлый.

– Бу әле тагын мин, Гөлшат.

– Тагын ни булды, тынгысыз табибым?

– Шаяртып торырга вакыт юк. Илдар Азатович, операция бүлмәсен әзерли торыгыз, мин хәзер бер авыру баланы алып киләм, аңа тизрәк операция ясарга кирәк.

– Тагын ни булды инде, ник үзең ясамыйсың? Син бит безнең бөтен һөнәргә оста.

– Илдар Азатович, шаяртырга вакыт юк, чөнки авыруым биш яшьлек бала, аны иртән үгез сөзгән булган, хәзер хәле бик начар, талагы шартласа мин аны кисеп ала алмам дип куркам, – диде Гөлшат, эшнең бик куркыныч икәнлеген аңлатып.

– Иртән сөзгәч, ник соң син хәзер генә шалтыратасың, ник иртә белән алып килмәдең.

– Иртән аның хәле яхшы иде, әнисе дә районга барырга теләмәде, мин дә бик кыстамадым. Баланың йөрәк тибеше йөз иллегә якын, эче белән дә суламый.

– Аңладым, тизрәк алып килегез, алып килеп җитә алсагыз.

Ишек төбендә торган Фәимә апа:

– Син, шайтан кыз, баланы тагын үзең ярмакчы буласыңмы?

– Юк, Фәимә апа, районга алып барабыз. Тәнзилә система куйган булса, баланы тизрәк машинага чыгарып салыгыз, мин районга аны үзем озатам. Монда минем гаеп, иртүк теге кичәге хатын белән озатасы калган.

– Ярар, ни булса, шул булыр. Мансур ишек төбендә көтеп тора, баланы тиз генә чыгарып салырбыз. Син төнлә дә йокламадың, бәлки, Тәнзилә генә илтеп кайтыр.

– Юк инде, үзем илтәм.

– Ләкин бер тоткарлык бар.

– Тагын нинди тоткарлык?

– Әнисе өенә кайтып киткән бит, хастаханәдән ерак яшиләр, бәлки, башта аның артыннан барып килергәдер?

– Юк, Фәимә апа, аның артыннан йөрергә вакыт юк, баланы алып барып җиткерә алырбызмы, юкмы? Әнисе килеп чыкса, район үзәгенә үз җае белән барсын.

– Алайса барыгыз тизрәк, – диде Фәимә апа баланың хәле начар икәнлеген аңлап, эченнән белгән догаларын укый-укый.

Гөлшат даруларны җыеп чыкканчы, баланы машинага чыгарып салганнар иде инде. Фәимә апа Мансурга барысын да аңлаткан, шуңа күрә ул бер сүз дәшмичә, машинаны куа бирде. Районга ярты сәгатьтән артыграк барылгандыр. Машина бик кызу барса да, Мансур бик сикертмәле урыннарны акрын узарга тырышты. Район хастаханәсендә аларны көтәләр иде. Баланы тиз генә операцияләр бүлмәсенә алып кереп киттеләр. Гөлшат та хирургка ярдәм итәргә дип, кулларын юды. Баланың эче тулы кан иде, Гөлшатның уйлары дөрес булып чыкты. Операция сәгать ярым дәвам итте. Наркозны Илдар Азатович үзе бирде. Ләкин операция беткәндә дә, баланың кискән җирләреннән һаман кан туктамады.

– Кан салмасак, баланы коткарып булмый, – диде Илдар Азатович.

– Кан юк шул, булган канны иртән сездән алып килгән хатынга салдык, – дип җавап бирде операция ясаучы хирург.

– Минем шул ук группа һәм резус фактор, минем канны алыгыз, – диде Гөлшат.

– Син кичә кан бирдең бит инде, синнән ярамый. Әнисе дә юк, ичмасам, – дип сыкранып куйды Илдар Азатович.

– Мин хатын-кыз бит, без кан югалтуга түзем. Балага бик күп кирәк тә түгел? Аннары баланы коткара алмасак, мин гомерем буе үземне гаепле санаячакмын.

– Ярар, әйдә, син минем чәчләремне агартып бетерәсең, ахрысы, төрмәгә утыртсалар, миңа борылып та карамассың әле.

– Илдар Азатович, ник алай дисез? Төрмәгә утыртырлык без нәрсә эшләдек? – Гөлшат аңламыйча, баш табибка карады.

– Әле эшли генә башлаган бер табибым кичә сертификатсыз операция ясады, бүген ата-анасы рөхсәтеннән башка баланы операциягә алып кереп киттек, хәзер мине бер көн эчендә бер кешедән икенче тапкыр кан алырга мәҗбүр итә. Ә болар барысы да закон буенча дөрес түгел, әгәр баланы югалтсак, прокурорга ничек аңлатып бирербез?

– Шулай булгач, без бу баланы коткарырга тиеш, аны коткарыр өчен мин кан бирергә тиеш, – диде Гөлшат үзенең тәкъдимен яклар өчен.

– Тиеш, тиеш. Без күп нәрсә тиеш, законны да, министрлыктан килгән кагыйдәләрне дә без үтәргә тиеш. Прокурорга бергә барырбыз, бар, күрше бүлмәгә чыгып ят, ике йөз грамм җитәр дип уйлыйм.

Гөлшат перчаткаларын салып, күрше бүлмәгә чыкты. Кан алганда Гөлшатның башы әйләнеп, ул аңын югалтты. Нашатырь исеннән айныгач, эченнән генә: «Мондагы кызлар, бу табиб каннан курка икән, дип көләрләр инде», дип уйлады. Ләкин беркем дә бер сүз дәшмәде. Илдар Азатович кына кереп, хәлен белеп чыкты. Гөлшат баланың хәле белән кызыксынды:

– Кан агуы туктады, ләкин хәле бик авыр, – диде баш табиб.

Гөлшатны хастаханәдә кундырмакчылар иде, ләкин ул: «Кунмыйм, кайтам», – дигәч, Илдар Азатович үз машинасын биреп, аны авылга кайтарып куйдылар.

...Май бәйрәмнәренә «патша сарае»нда дүрт авыру гына калды. «Һәрберебезгә берәр кеше дә тими», – дип көлештеләр шәфкать туташлары. Гөлшат та хастаханәгә бер-ике сәгатькә генә килеп йөрде. Наилә апа, аяклары сызлавына карамастан, бакчага чыгып эшләде. Гөлшат буш вакытларында чыгып, аңа ярдәм иткәли иде. Ләкин шәһәрдә үскән, җир эшен белмәгән кыздан нинди ярдәм?! Урамда исерткеч шомырт чәчәге исләре таралган. Уянып килгән табигать үзенең ямь-яшел яшь яфраклары, кошлар сайравы белән күңелне тибрәтә һәм бакчага чакырып тора иде. Бакча эшләренең очы-кырые күренми.

Бүген дә, иртүк торып, алар бакчага чыктылар. Гөлшат спорт киеменнән яшь укучы баланы хәтерләтә иде.

– Кара инде үзеңә, гәүдәң дә матур, акылың да бар, шунда, ичмасам, ел буена берәр егетнең башын да әйләндерә алмадың, әз-мәз булса да, безгә ярдәме тияр иде, – дип куйгалады Наилә апа бөтенләй хәле беткән вакытларда. – Элекке чакларым булса, уйлап та тормас идем. Егетләр трактор белән бакчаны сукалап та бирерләр иде. Тик менә бәрәңгесен ничек утыртырга?

– Наилә апа, нигә сиңа шуның хәтле бәрәңге? Аны бит әле утыйсы, өясе, кортын җыясы бар. Безнең икебезгә ел буена өч-дүрт капчык бәрәңге җитә. Рафаэль абыйдан сорасам, бер-ике капчык кына китереп тә бирерләр иде. Бәлки, нужарып торасы да юктыр? Шул җиләк бакчасын гына эшкәртик тә, җитәр.

– Ничек инде ул бәрәңге утыртмау? Кап-кара җир калдырыйм, диме? Аны чүп үләне басып алачак. Мин бакчамда кычыткан белән алабута үстереп ятыйммы? Күршеләрдән оят. Юк инде, кызым, аягым, кулым йөргәндә, үзем эшлим әле, – дип, Наилә апа Гөлшатның тәкъдименә коры итеп җавап бирде. Аның усал карашыннан Гөлшат үзе дә җир тишегенә кереп югалырдай булды.

– Мин булдыра алмагач, Наилә апа, әйдә сине кияүгә бирик, – дип әйтеп куйды Гөлшат, сүзне икенчегә борырга теләгәндәй.

– Синнән тагын нинди тузга язмаган сүз ишетермен икән? Син нәрсә әйткәнеңне аңлыйсыңмы? – дип, Наилә апа үпкәләп, кич буе Гөлшат белән сөйләшмәде. Гөлшат берничә тапкыр гафу үтенсә дә, файдасы булмады.

Икенче көнне 9 Май иде. Эшкә барасы булмагач, Гөлшат, иртүк торып, чәйләр эчкәч, бакчага эшләргә чыкты. Шулвакыт капка төбенә машина килеп туктады:

– Керергә рөхсәтме? – дип, ишектән Закир абый керде. Гөлшатның көрәк күтәреп йөргәнен күргәч: – Алла ярдәм бирсен. Әллә инде безнең гүзәл кызыбыз, бердәнбер табибыбыз җир каезлыймы? – диде.

– Ярар инде, Закир абый, көлмәгез. Безнең якларга нинди җилләр ташлады?

– Сезне сагынып килдем. Ләкин син сорауга җавап бирмәдең. Керергә рөхсәт итәсезме?

– Кердегез бит инде.

– Мин берүзем генә түгел.

– Кем белән тагын?

– Улларым белән.

Закир абый артыннан матур костюмнардан, берсеннән-берсе чибәр, таза гәүдәле ике егет керде.

– Әйдәгез, ишек төбендә тормагыз, өйгә керегез, – дип, Гөлшат, өстенә кигән иске халатыннан уңайсызланып, өйгә кереп китте. Кергәндә: – Наилә апа, кунаклар килде, каршы ал, – дип кычкырды.

– Бөтен кеше бакчада эшләгән вакытта нинди кунаклар тагын? – Наилә апа чатанлый-чатанлый әкрен генә чыгып җиткәнче, ир-атлар өйгә үк керделәр. Закир абыйның кулында төрле төстәге чәчәкләр иде. Закирны күргәч, Наилә апа аптыравыннан сүзсез калды һәм урындыкка барып утырды.

Алар берничә минут сүзсез генә бер-берсенә карашып тордылар. Матур күлмәген кияргә өлгергән Гөлшат бу тынычлыкны бозып:

– Нишләп ишек төбендә катып калдыгыз, түргә узыгыз, – диде.

Закир абый, кинәт уянып киткәндәй, чәчәкләр белән Наилә апа янына килеп басты да бер тезенә тезләнде:

– Наилә, улларым алдында синең кулыңны сорарга килдем. Миңа карата әз генә мәхәббәтең сакланган булса, чык миңа кияүгә. Гомеребез күпме калгандыр, актык елларыбызны булса да, бергә уздырыйк.

Шулчак Гөлшат чыркылдап көлеп җибәрде һәм үзе дә оялып, бүлмәгә кереп китте. Закир абый белән егетләр бернәрсә аңламыйча аның артыннан карап калдылар. Наилә апа тагын ныграк аптыраштa калды, ул нәрсә әйтергә белмәде. Көлүеннән тыелып, Гөлшат кире әйләнеп чыкты:

– Сез шулай көне буе ишек төбендә торачаксызмы? Әйдәгез, түргә узыгыз. Наилә апа, юкка гына, иртүк торып, кыстыбыйлар пешермәгәнсең икән. Мин өстәл әзерлим, ә син кыстыбыйларны майлап бетер, – дип, ул Закир абыйдан чәчәкләрне алып, вазага утыртты.

Наилә апа акрын гына аңына килде. Ул соңгы минутларда булган хәлне һаман аңлап бетерә алмый иде әле. Барысы да өстәл тирәли утырышып беткәч, Наилә апа кыстыбыйларын чыгарды, Гөлшат тиз генә чәйләр ясады.

– Закир, син миңа өйләнергә дип килдеңме? – дип сорап куйды шул вакыт Наилә апа, башындагы уйларын тәртипкә салырга тырышып.

– Әйе, Наилә. Минә ике улым да риза. Таныш булыгыз, олысы – Әнвәр, кечесе – Камил, – дип, Закир абый уллары белән таныштырды.

– Закир, кеше көлдереп йөрмә. Мин, аксак үрдәк, сиңа нигә кирәк? Күпме гомер калгандыр, кеше көлдермик.

– Нишләп алай дисең? Мин бит сиңа Мәдинә тавында, соңгы көннәребезгә кадәр бергә булырбыз, дип ант иттем. Күпме гомеребез калса калгандыр – бер елмы, унмы – бергә булыйк.

– Наилә апа, әтиебез сүзенә без дә кушылабыз, чык безнең әтиебезгә кияүгә, безгә – әни, балаларыбызга әби булырсың. Курыкма, без сине эшләтмәбез, әтиебезгә иптәш бул, – дип, Закир абыйның уллары да әтиләре сүзенә кушылдылар.

Наилә апа бер Закирга, бер Гөлшатка карады:

– Сез мине ашыктырмагыз, миңа уйларга кирәк. Аннары минем әле бәрәңгем дә утыртылмаган.

– Наилә апа, син монда уйлый тор, ә без бакчага чыгып, бәрәңге утыртып алабыз. Кыстыбыйларың шундый тәмле булды, бик зур рәхмәт, мин хәзер машинадан эш киемнәрен алып керәм, – дип, Әнвәр өйдән чыгып китте.

– Әйдәгез, егетләргә бәрәңге утыртырга булышыйк, алар казырлар, без бәрәңге салып барырбыз, – дип, Гөлшат та аларга иярде.

– Әйе шул. Син Камилгә ярдәм ит, мин Әнвәр белән утыртырмын, – дип, Закир абый, чиләген күтәреп, бәрәңге бакчасына китте.

Сәгать икеләргә эш беткән иде инде. Егетләр бакчаны тырмалаган арада, Гөлшат белән Закир абый яшелчә бакчасына чыктылар:

– Ай, улларыгыз эшкә булган, мин бәрәңге салып кына барсам да арыдым, – дип, Гөлшат бакчада торган эскәмиягә барып утырды.

– Булганнар, булганнар, үземә охшаганнар, Аллага шөкер, – дип горурланып куйды Закир абый. – Зурысын өйләндердем, кечесе генә калды. Анысына да синең төсле бер акыллы кыз тапсам, тынычланыр идем.

– Нишләп, аның кызы юкмыни? – дип сорап куйды Гөлшат, кызарып.

– Ул эшкә генә уңган, кызлар дисәң, коела да төшә, абыйсына бер дә охшамаган. Берсе тәмам башын әйләндергәнче, абыйсы кызлар яныннан кайтып кермәде. Киленем болай яхшы кешегә охшаган. Миңа гел «әти» дип кенә тора, йомшак сүзен бер дә жәлләми. Безгә картларга тагын ни кирәк?

Бакчага Наилә апа чыкты:

– Сез бөтен эшне бетергәнсез дә инде.

– Син тизрәк ризалашсын дип тырышалар алар, – дип шаяртты Гөлшат.

– Бар, телеңә салынма, мунчага кереп, юынып чык. Кайнар су бар анда, өстеңне дә алыштыр, егетләр янында матур күлмәкләр кияргә кирәк, бу сәләмә ыштаннарыңны алыштыр, хәзер ашарга утырабыз, минем бөтенесе әзер, Закир абыең белән сөйләшәсем бар, – дип, Наилә апа коры гына Гөлшатка карап куйды.

– Аңладым, аңладым, – дип, Гөлшат өйгә кереп китте.

– Йә, нәрсә уйладың, Наилә, син ризамы? – дип яңадан сорап куйды Закир абый.

– Ә без кайда яшәрбез?

– Кыш көне миндә, аннары, теләсәң, җәйгә монда кайтырбыз. Ризалаш, Наилә, ант итеп әйтәм, үкенмәссең.

– Ә хатыныңның туганнары нәрсә диярләр?

– Минем хатыным үлгәнгә быел ун ел булды. Аның туганнары юк, ул ятим иде.

– Әйдә инде алайса, бергәләшеп яшәп карыйк, әгәр ошамаса, минем кайтыр урыным бар.

Закир абый шатлыгыннан Наиләне кочаклап, битеннән үбеп алды.

– Син нәрсә инде, балалар күрсә, оят бит. Әнә егетләр тырмалап та бетергәннәр. Әнвәр, Камил, әйдәгез, кулларыгызны юыгыз да ашарга керегез. Мунчада су җылы булырга тиеш, кичә яккан идек, – дип, Наилә апа өйгә кереп китте. Өйгә тәмле өчпочмак исе таралган иде.

– Наилә апа, сез кай арада бөтенесен әзерләп өлгердегез? – дип, Камил өстәл янына барып утырды, аның артыннан әтисе белән Әнвәр дә керде.

– Һай, уңган да икән минем хатыным, шул арада аш та, өчпочмаклар да пешереп куйган. Аргансыңдыр, кил әле, яныма утыр, яшьләр йөгерсеннәр, – дип, Закир абый буш урындыкны үзе янына куйды да Наилә апаны утыртмакчы булды.

– Син монда бигрәк тиз хуҗа булып киттең әле, Закир әфәнде. Нинди хатын булыйм, ди, мин сиңа, никах укытмаган, паспортта штамп куелмаган, фамилиям, Аллага шөкер, үземнеке, – дип, Наилә апа Гөлшат янына утырды. – Бар, кызым, ашларны чыгар, аякларым тагын сызлый башлады, йөрергә бер дә ирек бирмиләр, яңгыр явар, ахрысы.

Гөлшат ирләргә тиз генә аш бүлеп чыгарды. Өстәл уртасында зур табакта өчпочмаклар авыз суын китереп торалар. Ашаганда, беркем бер сүз дәшмәде.

– Наилә апа, ризыкларың бигрәк тәмле булган, ирләр телләрен йоттылар, ахрысы, – диде Гөлшат, тынычлыкны бозып һәм чәй әзерләргә тотынды.

– Бәлки, кемгәдер аш өстәргә кирәктер? – дип сорады Наилә апа.

– Гөлшат, миңа тагын бер чүмеч аш чыгар әле. Үзем туйдым, күзем туймады. Мондый тәмле ашларны күптән ашаган юк иде, – дип, Закир абый тәлинкәсен Гөлшатка сузды.

– Әйдәгез, чәйләр эчкәч, Мәдинә тавына менеп төшәбез. Көн шундый матур, бер дә өйдә утырасы килми, аннан соң бит авыл тәртипләрен бозарга ярамый, – дип тәкъдим итте Гөлшат.

– Наилә, нинди тәртип турында сөйли ул? – Закир абый да кызыксынып куйды.

– Яңа гаиләләр корылганда, авыл кешеләре Мәдинә тавына менеп, теләкләр телиләр, – диде Гөлшат, Наилә ападан алданрак җавап бирергә теләп.

– Ну кызый, телең бүген бигрәк ачылып китте. Атна буе олы кеше өстеннән шаяртып йөрисең.

– Ул нинди Мәдинә тавы тагын? Безгә әтиебез аның турында бер дә сөйләгәне булмады, – дип, егетләр дә кызыксындылар.

– Мәдинә тавы – ул бик тарихи җир. Чынлап та, нишләп менеп төшмәскә? Машинабыз бар. Без тагын яшьлегебезгә кайтырбыз, улларым да табигатьнең иң гүзәл урынын күреп китәрләр, – дип ризалашты Закир абый.

– Минем ризалашмыйча хәлем юк, – диде Наилә апа, Гөлшат белән ирләргә карап.

Ничек кенә тиз җыенырга тырышсалар да, берәр сәгать чамасы вакыт узгандыр. Алар авылдан чыгып киткәндә, урман борыныннан кап-кара болыт күренде, ләкин аңа игътибар итүче булмады. Әнвәр машинаны яр буена ук китереп туктатты. Мәдинә тавы аларны кошлар сайравы белән каршы алды. Табигатьнең әле яңа уянып килгән мәле. Яңа гына төртеп чыккан яшел яфраклар, шомырт чәчәкләре исе, күңелдә мәхәббәт очкыннары кабызып, зур ялкынлы ярату учагы яндырып җибәрерлек сихри көчкә ия. Әнвәр белән Камил яр кырыена килеп бастылар. Алар алдында, уч төбендәге кебек, авыл һәм кырлар җәелеп ята. Авыл халкының күбесе тырыша-тырыша бакчаларында эшли. Күпчелек бакчалардан төтен күтәрелә, былтырдан калган кипкән яфракларны, үләннәрне яндыралар

булса кирәк. Авылның бер кырые яшелләнеп килгән урманга барып тоташа. Тагын даерактарак кырда трактор җир сөрә. Зәңгәр күктә бик биектә тилгән очып йөри. Егетләр берничә минут әлеге искиткеч күренештән күзләрен алмыйча, сокланып карап тордылар.

– Әти, ник син безне монда элегрәк алып килмәдең? Бирегә рәссамнарны чакырырга кирәк, монда искиткеч табигать. Бу күренешләрне бөтен кеше күрергә тиеш, – диде Камил, матурлыкка хозурланып.

– Мин монда менгән саен табигатькә сокланып туя алмыйм. Күпме килсәм, күрсәм дә, һаман киләсе килә, бу урын үзенә тартып тора. Яшьләр монда никахлашкан көннәрендә, бер-берсенә вәгъдәләр бирергә дип киләләр, – дип, сүзгә кушылды Наилә апа.

– Пластик шешәләрең кайда? Мин чишмәгә барып, тәмле су алып киләм. Егетләр монда хәтле килеп тә, чишмә суын авыз итеп карамасалар, үкенерләр, без дә гөнаһлы булырбыз, – дип, Гөлшат Наилә апасы янына килде.

– Әйдә, мин дә синең белән чишмәгә төшәм, – дип, Камил машинадан пластик шешәләр алып, Гөлшат артыннан атлады.

Закир абый җыелма урындык чыгарып куйды:

– Наилә, әйдә утыр, җир әле салкын.

Ярты сәгатьләр чамасы вакыт узгандыр, Гөлшат белән Камил тулы шешәләр күтәреп, әйләнеп тә килделәр.

– Наилә апа, мондагы чишмә суын, чынлап та, эчеп туеп булмый икән, – диде Камил.

– Йә әле, улым, миңа да салып бир, – дип, Закир абый да эчәргә чишмә суы сорап алды һәм сусавын баса алмагандай, бер-бер атлы өч чокыр су эчте. – Яңадан яшьлегемә кайткандай булдым, – дип өстәде ул, иркен сулап. – Хәтерлисеңме, Наилә, яшь чакларыбызны, без монда бергәләшеп күпме йөрдек? Наилә, безнең каядыр бер оябыз да бар иде, анда яңгырдан качып торгалый идек.

– Нинди оя ул, Наилә апа? Миңа аның турында бер дә сөйләгәнең булмады. Әйдәгез, бергәләшеп барып карыйк әле, ерак булмаса?

– Син юлын хәтерлисеңме, Наилә?

– Каядыр шушы сукмак белән барырга кирәк бугай, – диде Наилә апа, бергә үсеп утырган куш каенга күрсәтеп.

– Наилә апа, әйдә барыйк инде, – дип үтенде Гөлшат, кызыксынуы артканнан-арта барып.

– Мин үзем алдан барам, ул тау тишеген мин тапкан идем бит, – дип, Закир абый Наилә апа күрсәткән якка таба китте. Аның артыннан Камил белән Гөлшат, тагын да арттарак Наилә апа белән, җыелма урындык күтәргән Әнвәр атладылар.

Алар элек йөргән сукмакның эзе дә калмаган. Закир абый, як-ягына каранып, үзе генә белгән ниндидер тамгаларга карап барды. Вакыт-вакыт туктап та калгалады. Алар яшь чактагы агачлар, куаклар зур булып үскәннәр. Күрәсең, ул тау тишеге турында башка беркем дә белми торгандыр. Шактый гына баргач, алар бер тауга барып терәлделәр.

– Мин дөрес алып бармадым, ахрысы, адаштым бугай? – дип, Закир абый арттан килгән Гөлшатка борылды.

– Дөрес, дөрес барасың, – дип, артларыннан чатанлый-чатанлый Наилә апа куып тотты.

– Мин кая барырга да белмим, Наилә, монда барысы да бик нык үзгәргән, теге тау тишеге, бәлки, ишелеп җимерелгәндер?

– Ишелмәгән, әнә теге куаклар артында булырга тиеш. Камил, барып кара әле, – дип, Наилә апа тау кырыенда үскән чикләвек куакларына күрсәтте.

Камил куаклар артына кереп китте. Аның: «Монда! Монда! Килегез, чынлап та, монда зур куыш бар», – дигән тавышы ишетелде.

Башта Гөлшат белән Әнвәр куаклар артына кереп югалдылар, аннары Закир абый Наилә апага узарга ярдәм итте. Куыш артык зур түгел иде, ләкин биш кеше иркенләп сыйды. Тыгыз чикләвек куаклары арасыннан сызык кына булып кояш нурлары сузылган. Түгәрәк шар формасындагы тау куышында һава салкынчарак иде. Әнвәр шырпы кабызды. Эчтәрәк черек агач башлары ята, алар янында күптән яндырылган учак эзе дә бар.

– Егетләр, артыгыздан барып, мин аяксыз калдым. Бер ярты сәгать ял итмичә, адым да атлый алмыйм, – дип, Наилә апа Әнвәр күтәреп килгән җыелма урындыкка утырды.

– Наилә апа, син миңа бер убырлы карчык турында сөйләгән идең, бәлки ул монда яшәгәндер? – дип, Гөлшат тау куышын карый-карый, серле генә сорап куйды.

– Белмим, белмим, убырлы карчык монда яшәгәндерме, юкмы, Закир абыең белән безгә дә бер тапкыр монда кунарга туры килде, – диде Наилә апа.

– Кызык, безгә дә сөйләгез әле. Нинди убырлы карчык, нинди вакыйгалар турында әйтәсез сез? – дип, Әнвәр әтисенә карады.

Кинәт тагын да караңгыланды һәм коеп яңгыр ява башлады.

– Әнвәр, син бар тиз генә машинаны чокыр аша чыгарып куй. Юл юешләнсә, чыга алмыйбыз. Син, Камил, тиз генә корырак чыбыклар җыеп алып кер, учак ягып җибәрергә кирәк, туңдыра башлады, яңгыр беткәнче әз генә җылынып алырбыз, – дип, Закир абый тиз генә улларына боерыклар бирде.

Егетләр чыгып китүгә, яңгыр тагын да көчлерәк ява башлады. Бераздан бер кочак кипкән ботак, чыбыклар җыеп, Камил кире керде. Учак ягып җибәрделәр. Тау йорты яктырып китте һәм төтен исе белән тулды. Ләкин төтен каядыр тарала барды. Алар барысы да учак янына җыелышты. Наилә апа да якынрак килеп утырды, аның аягы тагын да ныграк сызлый башлады. Ул берничә мәртәбә кулы белән тез башын угалап та алды.

– Бик нык сызлыймы, Наилә апа? – дип, борчылып сорады Гөлшат.

– Син барысын да күрәсең, нишләптер җибәрми шул, – дип зарланып куйды Наилә апа.

– Машинада дарулар бар иде, бар әле, улым, алып кил, – дип, Закир абый Камилне машинага җибәрде. Бераз вакыт узгач, дарулар, пакет белән ризыклар һәм иске бишмәтләр күтәреп, егетләр куышка әйләнеп килделәр.

– Без монда, озакка бикләнеп калдык, ахрысы, – диде Әнвәр, күтәреп килгән әйберләрен учак янына куеп.

– Нишләп? – дип сорады Гөлшат.

– Чокырда гөрләп ташу ага, чыгарлык түгел, – дип җавап бирде Камил.

– Закир абый белән Наилә апа серле генә бер-берсенә карап куйдылар. – Бәлки, телефоннан шалтыратып, кемнән дә булса ярдәм сорарбыз?

– Монда телефоннар, нишләптер, эшләми, аннары авылдашларым алдында ничектер оят, – дип уңайсызланды Наилә апа.

– Ташу озакка бармас, әйдәгез, бераз көтеп торыйк, монда да начар түгел. Җәеп утырырга – бишмәтләр, ашарга – өчпочмаклар, җылынырга учак бар. Безгә кая ашыгырга? Өстебездән яңгыр яумый. Утырышыгыз, – дип, Закир абый бөтенесен тынычландырырга тырышты.

– Беләсезме, мин нишләп кире авылыма кайтырга булдым? – дип, сүзгә кысылып, Закир абый сөйли башлады. Барысы да сораулы күзләре белән аңа текәлделәр. – Ничектер минем кулыма армия фотоальбомым килеп керде. Аны өйләнгәннән бирле кулыма алганым юк иде. Шуны ачып, карап утыра башладым. Фоторәсемнәр арасыннан бер иске конверт килеп чыкты. Беләсеңме аның эчендә нәрсә бар иде? – дип, Закир абый Наилә апага карады һәм күкрәк кесәсеннән чигелгән иске генә бер кечкенә кульяулык тартып чыгарды да: – Хәтерлисеңме? – дип, шул чигелгән кульяулыкны аңа сузды.

– Бу бит – мин сиңа дип чиккән кульяулык. Мин аны сиңа армиягә озатканда бүләк иткән идем. Ул һаман да исән икән.

Бик кадерле әйберне тоткандай, Наилә апа үзе чиккән кульяулыкны алды һәм итәгенә җәеп салды да кулы белән сыпырып куйды.

– Шуны күрдем дә яшьлегемә кайткан кебек булдым, авылымны бик сагынганлыгымны аңладым. Шушы Мәдинә тауларында уздырган яшьлегем күз алдымнан һич китмәде. Кыш булуга карамастан, юлга чыктым. Ә калганын сез инде беләсез.

Барысы да тынып калдылар, бары чытыр-чытыр янган учак һәм урамда яуган яңгыр тавышы гына ишетелеп тора иде. Бу минутта кем нәрсә турында уйлагандыр?

Яңгыр туктаганда, таң беленә башлаган иде. Мәдинә тавында, берсеннән-берсе уздырып, кошлар сайрый, яңа көн уянып килә. Гөрләп аккан чишмәнең суы ничек тиз күтәрелсә, шулай ук тиз урынына кайтты. Хәзер инде өйгә кайтырга бернинди киртә дә юк иде. Мәдинә тавында таң каршылауларына берсе дә үкенмичә, алар Наилә апа йортына кайттылар. Гөлшат тиз генә җыенып, «патша сарае»на китте, Закир абый белән Наилә апа авыл зиратына барырга җыенып калдылар.

...Эшләрен тәмамлап, хастаханәдән чыгып барганда, Гөлшатның каршысына машина килеп туктады:

– Гөлшат Равилевна, сәлам. Утыр әйдә, алып кайтам, көн буе чабып йөреп арыгансыңдыр?

– Исәнме, Рафаэль абый. Рәхмәт. Хәлләр ничек? Әйдә сөйләп җибәр. Нинди йомыш белән йөрисең? Син бер дә юкка гына килмисең бит, – дип, Гөлшат машинага утырды. Шунда гына аякларының, чынлап та, арыганлыгын аңлады.

– Нигә алай дисең? Мин болай да керә алам. Тик бүген, дөрес әйттең, йомыш белән килдем. Рәмзия белән Таһирны хәтерлисеңме?

– Сибгатуллиннарнымы?

– Әйе.

– Мин Рәмзия апаны Казанга тикшеренергә җибәргән идем, башка килеп күренмәделәр, мин алар турында онытып та җибәргәнмен. Рәмзия апаның хәле ничек соң? Мин ялгышканмынмы?

– Ялгышкансың шул. Шеш ашказанында түгел, астарак, хатын-кыз эчке органнарында булып чыккан. Иртәгә онкодиспансердан чыгаралар, операция да булган, химия дә ясаганнар. Хәле бик авыр. Кыскасы шул. Иртәгә каршы алырга барырга кирәк. Син бара алмассың микән?

– Ничәдә китәбез?

– Иртәгә җиделәр тирәсендә кереп алырмын. Менә өеңә килеп тә җиттек.

– Өйгә кайтарып куйган өчен рәхмәт. Бүген нишләптер арылды. Иртәгәгә кадәр, сау булыгыз, – дип, Гөлшат ишегалдына кереп югалды. Рафаэль абзый берничә минут машинасында утырып торды да ашыкмыйча гына кузгалып китте.

Казанның онкология үзәгенә Гөлшат белән Рафаэль абзый төш алдыннан килеп җиттеләр. Хастаханә янындагы мәйдан машина белән тулган. Вакытлыча гына туктап торырга да урын юк. Рафаэль абзый алга таба да узып карады, анда да туктарлык урын табылмады. Әйтерсең, ярты Казан монда җыелган.

– Кара инде моны? Казанда сәламәт кеше калмаган, ахрысы? Машина куярга да урын юк, – дип зарланып алды Рафаэль абзый.

– Монда бөтен республикадан киләләр. Шуңа күрә кеше бик күп. Бөтенесе ышанып, өметләнеп, ярдәм эзләп килә, ләкин ярдәм...

Гөлшат авыр сулап куйды. Әле күптән түгел генә ул үзе дә монда әнисен алып килеп, ярдәм эзләп йөргән иде. Әле кайчан гына «Ышаныч бар, операция ясарга кирәк» дигәнне ишеткәч, әнисе белән бик шатланганнар иде. Ышанып, операциягә керделәр. Гөлшат, дәресләрен калдырып, коридорда хирургларны көтеп торды. Ләкин хирург: «Бернәрсә дә эшли алмадык», – дигәч, аяклары хәлсезләнде. Ул өенә ничек кайтып җиткәнен дә хәтерләмәде. Төне буе елап чыкты. Бу вакытта әле ул әнисен югалтканын аңламый иде. Булган барлык авыр мизгелләр Гөлшатның күз алдыннан узды. Аны, уйларыннан бүлеп, якында узып баручы поезд тавышы ишетелде, аннары Рафаэль абзыйның телефоны шалтырады. Таһир шалтырата иде:

– Без хәзер чыгабыз, сез еракмы? Гөлшат Равилевна килдеме?

– Без хастаханә каршысында торабыз. Гөлшат Равилевна да янымда.

– Син кабул итү бүлмәсе янына килеп туктый алмассың микән?

– Проблема юк, хәзер кереп карыйбыз, борчылма, Рәмзияне алып чыга тор. Гөлшат Равилевна, монда кабул итү бүлмәсе кайда?

– Шлагбаум каршысында урнашкан төп ишектән сулгарак.

Рафаэль абзый машинасын шлагбаум янына килеп туктатты. Машинадан чыгып, ишек саклаучы янына барып сөйләшеп килде. Шлагбаум күтәрелде. Алар машина белән кабул итү бүлмәсе ишеге янына ук килеп туктадылар. Берничә минуттан ишектә Таһир белән Рәмзия күренде. Ләкин Рәмзия таный торган түгел иде: бик нык ябыккан, күзләре батып кергән, өстенә кигән күлмәге асылынып тора. Урам һавасыннан булса кирәк, Рәмзия башы әйләнүдән егыла башлады. Таһир аны кулларына күтәреп алды. Рәмзия хәле юклыктанмы, яраткан кешесенең кочагына эләккәч, куллары белән

Таһирның муеныннан кысып кочаклады, башын күкрәгенә куйды. Рафаэль абзый, тиз генә чыгып, машинасының алгы ишеген ачты.

– Рафаэль, син каршы килмәсәң, без арттагы утыргычка утырыр идек. Иремнең кочагына эләккәч, шундый рәхәт булып китте, үземне күптән болай хис иткәнем юк иде. Алга Гөлшат Равилевна утырсын, аны да борчыгансыз, – дип, Рәмзия көчкә башын күтәрде.

– Юк, мин монда Казанга үз эшләрем белән килгән идем, Рафаэль абый белән уйламаганда очраштык, ул мине дә утыртып кайтырга ризалашты,– дип ялганлый-ялганлый, Гөлшат арткы ишекне ачып, Рәмзиягә утырырга ярдәм итте.

– Хәтерлисеңме, Таһир? Егерме дүрт ел элек син мине шулай ЗАГСтан күтәреп чыккан идең. Бүген кочаклаган төсле, мин сине кочаклаган идем. Ул көнне мин иң бәхетле кеше идем, бүген Мендельсон вальсы гына яңгырамый. Рафаэль, егерме дүрт ел элек тә рульдә син идең түгелме? Машинаң гына шестерка иде, бүген менә джипка утырып кайтабыз. Шулай бит, Таһирым? – дип шаяртырга теләде Рәмзия.

Рафаэль абзый күңеле тулудан күз яшен тыя алмыйча:

– Мин эчәргә су алып киләм, – дип китеп барды.

– Әйе, Рәмзиякәй, яңа тормыш башлап җибәрәбез. Тиздән көмеш туебызны да уздырырбыз, – диде Таһир, күз яшьләрен йота-йота.

Берничә минуттан, ике кулына ике пластик шешә күтәреп, Рафаэль абзый килеп тә җитте. Машина кузгалып, Казанны чыгып киткәнче, беркем дә сүз башларга кыймады. Рәмзия йокыга киткән төсле иде. Һәркем үз уена баткан.

Казанны чыккач, Рәмзия кинәт:

– Гөлшат Равилевна, бик нык сызлый, түзәр хәлем калмады, берәр уколыңны яса инде, кайтып җитәрлек булсын, – диде.

Рафаэль абзый машинасын туктатты. Гөлшат сумкасыннан кирәкле даруны чыгарды.

– Рафаэль, сиңа бер үтенечем бар, безнең туйдагы төсле, әйдә әле җырлап кайтыйк. Синең җырлавың тәнгә сихәт бирә, булдыра алсам, бергәләп җырларбыз.

Берара Рәмзия дә, Рафаэль абзыйга кушылып, җырларга тырышып карады, ләкин аның хәле тиз бетте, юл буе бертуктаусыз, күз яшьләрен йота-йота, Рафаэль абзый үзе генә җырлап кайтты. Аның җырлары күңелнең иң тирән төпләренә җитеп яңгырадылар.

Авылга килеп җитәрәк Рәмзия:

– Рафаэль, бик арымасаң, минем тагын бер үтенечем бар. Әйдә Мәдинә тавына да менеп төшик.

– Юлда арыгансыңдыр, икенче көнне менәрбез. Авыртуыңа түзә алмыйча, яңадан иреңеңне тешли башлагансың. Башка көнне менеп төшәрбез, – дип, Таһир каршы килмәкче иде дә, Рәмзия:

– Ярар инде, Таһирым, арысаң да каршы килмә. Башка чак әллә була, әллә юк. Көне дә матур. Каршы килмә инде, Рафаэль каршы түгел бит. Ә авырту мәсьәләсен без хәзер Гөлшат Равилевна белән хәл итәбез. Аның сумкасында тагын берәр ампула бардыр әле. Фәимә саран түгел, ул бер ампула белән генә чыгарып җибәрмәгәндер, – дип үтенеп диярлек сорады.

Рафаэль куерып килгән күз яшьләрен басар өчен «Мәдинә җыры»н җырлап җибәрде һәм машинасын Мәдинә тавына таба борды.

Әкрен генә кич тә якынлашты. Кояш баеп килә иде. Машина туктагач, ирләр машинадан төштеләр. Гөлшат арткы утыргычка күчеп утырды.

– Рафаэль, җырларың, түземлегең өчен бик зур рәхмәт сиңа, – диде Таһир. Аның күзләре кып-кызыл иде. Ул яшьләрен күрсәтмәс өчен зур йодрыгы белән яшереп кенә, күзләрен сөрткәләп алды. Куллары сизелер-сизелмәс кенә калтырыйлар иде.

– Дускай, үзеңә Алла ярдәм бирсен, әле авыр көннәрең алда, – диде Рафаэль һәм Таһирны тынычландырырга теләп, аркасыннан ирләрчә кочаклады, аннан Таһирны Мәдинә тавы чишмәсенә алып килде.

– Битеңне юып ал, безнең Мәдинәнең суы бик шифалы, үзең беләсең, бераз хәл дә кереп китәр.

Таһир чишмә суында битен, муеннарын юды. Үзен кулга алырга тырышып, берничә тапкыр тирән итеп сулыш алды. Рәмзиянең:

– Егетләр, сез кайда? Безне ташлап киттегез, – дигән тавышы ишетелде. Алар да Гөлшат белән култыклашып, чишмә янына килделәр. – Таһир, мине хастаханәгә илткәнче, монда гына шалаш ясап кундырган булсаң, үзем дә терелгән булыр идем. Һавалары нинди бит. Сулап туеп бетергесез. Егетләр, тыңлагыз әле, ишетәсезме сандугачлар ничек сайрый, искиткеч бит. Җәннәт менә шундый булырга тиеш, минем уемча.

Кинәт Рәмзия аяк киемнәрен салмыйча гына суга кереп китте. Битләрен, кулларын юды.

– Син кая кердең, су салкын бит, суык тидерерсең? Гөлшат Равилевна, әйтегезче бу хатынга, бәлки, сезне тыңлар? – дип, Таһир хатынын судан чыгармакчы булды.

– Эх, Таһирым, аякларның, эчләрнең януларын белсәң? Балык булып чумар идем бу салкын суларга. Бу чишмәнең суларын эчсәм, эчемнең янулары басылыр төсле, – дип, Рәмзия, каядыр чишмә төбенә карап, башын да күтәрми җавап бирде.

Рәмзия шарлавыктан агып төшкән салкын суны, учына җыеп, эчендә янган утны сүндерергә теләгәндәй, берничә тапкыр йотлыга-йотлыга эчте. Гөлшат чишмә янында асылынып торган тустаганны тәкъдим итсә дә, ул башын гына селкеде.

– Балачактагы кебек, учтан тәмлерәк, менә үзең эчеп кара. Син бу чишмә турында каян беләсең? – дип сорады Рәмзия, Гөлшатка борылып.

– Мине монда беренче мәртәбә Наилә апа алып килгән иде. Аннары тагын берничә тапкыр килергә туры килде.

– Гөлшат, яшь булсаң да, үз эшеңнең остасы икәнсең. Син миңа дөресен генә әйт әле, ялганламыйча, миңа тагын күпме калды? – диде Рәмзия, кинәт борылып, Гөлшатның күзләренә карап.

Гөлшат Рәмзиянең күз карашыннанмы, әллә көтмәгәндә яңгыраган сораудaнмы калтыранып куйды.

– Мин Аллаһы Тәгалә түгел, әйтә алмыйм. Ләкин сез мине аңларга тырышыгыз. Сезгә операция ясадылар, химиотерапия уздырдылар, барысы да яхшы, уңышлы булыр, һәм сез тагын яшәрсез әле.

Гөлшат югалып калды, ул Рәмзиянең битендә кинәт үлем билгеләрен

тоемлады. Нәкъ шундый билгеләрне ул беренче тапкыр әнисендә күрде, ләкин ул вакытта бернәрсә дә аңламаган иде.

– Ничә, ничә?.. Син дә әйтмисең... Әйдә, шешәңә су тутырып ал да егетләр янына барыйк. Алар безнең өчен борчылып торалардыр, Рафаэльнең дә көнен алдык, – дип, әкрен генә машинага таба атлады. Тирә-юньдә үзәк өздереп, сандугачлар сайрый, ләкин аларның тавышы нишләптер бер дә күңелне күтәрми иде.

– Әйдәгез, өйгә кайтыйк, балалар борчылып көтәләрдер, Рафаэльне дә тоткарладык, – дип, Таһир хатынына утырырга ярдәм итте.

– Әйдәгез, хастаханәгә кайтабыз, Рәмзия апа, уколлар ясарбыз, берничә көн ятып, хәл җыярсың, – дип тәкъдим итте Гөлшат.

– Юк, минем беркая да барасым килми. Өйгә кайтабыз, балаларым янына, – дип, кырт кисте Рәмзия.

Өйләре янына килеп туктагач, Рәмзия:

– Гөлшат Равилевна, киткәнче машинада гына тагын бер уколыңны ясап ал инде. Мин өйгә үзем керергә тиеш. Балаларны куркытасым килми. Аннары тагын бер үтенечем бар, Гөлшат Равилевна, теге сулы пластик шешәңне миңа калдыра алмассың микән? Ә сиңа, Рафаэль, ярдәмең, җырларың өчен бик зур рәхмәт. Хәл җыя алсам, Алла боерса, бер айдан көмеш туебызда синең белән тагын бер җырлашып утырырбыз әле. Бәлки, Мәдинә тавына да менәргә насыйп булыр. Гөлшат Равилевна, әле үлмисең, ышаныч бар, диде. Шулай бит, Гөлшат Равилевна?

Рәмзия үз сүзләренә таяныч эзләп, Гөлшатка текәлеп карады. Гөлшат, аның күзләренә карый алмыйча, Фәимә апа биргән дарулар сумкасын актара башлады һәм:

– Рәмзия, әйдә укол ясыйм, ә сез, егетләр, төшеп торыгыз, – диде.

– Ярар, – дип, Рафаэль белән Таһир машинадан төштеләр.

Гөлшат арткы утыргычка күчеп утырды. Күп тә үтмәде Рәмзия, акрын гына машинадан төшеп, өенә кереп китте. Сумкалар күтәреп, Таһир да аның артыннан китте. Гөлшат, Таһирны куып җитеп, чишмә суы тутырылган пластик шешәне аның сумкасына салды, борылып китмәкче иде. Таһир аның кулыннан тотып:

– Рәмзия тагын күпме яши алыр икән? – дип, Таһир Гөлшатның күзләренә карады.

– Минем әнием бер айдан ким яшәде, – дип җавап бирде Гөлшат күзләрен алмыйча, һәм кире машинага таба китте.

...Эшкә килгәч үк, Гөлшатка Илдар Азатович шалтыратты:

– Иртәнге эшләрегез беткәч, сәгать икеләргә минем яныма килегез, сөйләшәсе сүзләр бар.

Баш табиб чакыргач, бармыйча булмый. Мансур Гөлшатны әйткән сәгатькә илтеп куйды.

– Гөлшат Равилевна, сез Илдар Азатовичта озак буласызмы?

– Белмим бит, ярты сәгатьтән артык булмамын дип уйлыйм, – диде Гөлшат.

– Алайса мин монда гына көтәм, Фәимә апа кушкан даруларны ала торам, – дип, Мансур машинасын бикләп, хастаханәгә кереп китте.

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна, узыгыз. Илдар Азатович сезне көтә,

– дип, салкынча гына каршы алды яңа сәркатип кыз. Гөлнара, күрәсең, теләгенә ирешкән.

– Белмисеңме, нигә шулай кинәт чакыртты икән? Бик орышыр микән? – дип сорады Гөлшат.

– Гөлшат Равилевна, Илдар Азатович үзе әйтер, – дип, кыз Гөлшатны баш табибка кертеп җибәрде.

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна, узыгыз, утырыгыз, – дип, Илдар Азатович күтәрелеп карамыйча гына, Гөлшатны каршысындагы урындыкка утыртты. – Кичә Сәламәтлек саклау министрлыгында җыелыш булды.

– Әллә министр, безнең «патша сарае»н искә алып, ремонтка акча бирдеме? – дип, Гөлшат, баш табибның сүзен бүлеп сикереп үк торды.

– Мин, сезнең урында булсам, шаяртмас идем. Беренчедән, баш табибның сүзен бүлдерү яхшы түгел, – дип, Илдар Азатович тавышын күтәреп, Гөлшатны кисәтеп куйды һәм торып, арлы-бирле йөри башлады.

– Гафу итегез, башка алай эшләмәм.

Гөлшат гафу үтенде, баш табибның тынычсызлануын күреп, урынына утырды.

– Озын сүзнең кыскасы шул, сезнең «патша сарае»н ябалар, – дип, кыска гына әйтеп куйды Илдар Азатович һәм урынына барып утырды. Ул көне буе ничегрәк әйтергә икән, дип уйлап йөргән иде, ләкин уңышлы сүз таба алмады.

– Ремонтка ябалармы? – дип сорады Гөлшат.

– Юк, бөтенләй. Бер журналист безнең Каратау турында газетада язып чыккан. Шунда безнең «патша сарае» хакында да әйтелгән. Имеш, бик тарихи бина икән. Шуңа күрә, авыруларны чыгарып, анда тарихи эзләнүләр башларга җыеналар. Безнең министрга шул җитә калган, финанслар җитмәгәнгә күрә, оптимизация дип, безнең участок хастаханәсен ябарга карар чыгарганнар.

– Кайчан? – дип сорады Гөлшат, уйларын көчкә бер тәртипкә җыеп.

– Әгәр теге журналист, Илһам Дәүләтшин бугай, язып чыкмаса, акрын гына эшләп ятасы идек, главадан ремонтка ничек тә акча сорап алган булыр идем.

– Бәлки, главага керсәң, ул хастаханәне калдырыр, бәлки, безне япмаслар? – дип, Гөлшат суда батканда, саламга ябышкан кырмыскадай, баш табибка карады.

– Кызганыч, бу мәсьәлә хәл ителгән инде, глава газетадагы язманы күргәч шатланды гына. Әгәр «патша сарае»н тарихи урын дип расласалар, безнең якларга туристлар килә башлар. Ә бу яңа инвестицияләр, бизнес дигән сүз. Район мондый борылыш белән бу яктан отачак кына.

– Бер эшмәкәр кыш көне инвестицияләр белән безнең авылга килгән иде инде, – диде Гөлшат һәм аның куз алдына Гамир Альбертович килеп басты. Ул кинәт калтыранып куйды. Яраткан авылын, аның табигатен чын күңелдән кызганды.

– Гөлшат Равилевна, сез ни өчен үзегез турында сорамыйсыз? – дип сорады аптырап Илдар Азатович.

– Миңа барыбер.

– Ничек инде барыбер, мин сезне Казанга ординатурага җибәрмәкче

булам. Үзегез сайлагыз: кем буласыгыз килә. Укый башлаганчы, сезгә тулай торакта бер бүлмә табарбыз. Ике ел эчендә, бәлки, главадан бер бүлмәле фатир сорап алып булмасмы? Сез миңа бик ошадыгыз. Кызганыч, сезнең кебек яшь белгечләр бик сирәк очрый. Әле сезнең бер айдан артык ялыгыз да бар.

Илдар Азатович, каршысында утырган яшь табибның күңелен күтәреп, кызыксындырырга тырышты. Аның бу кызны районнан бер дә җибәрәсе килми иде. Тиз генә кияүгә биреп, районда калдырсаң, бик яхшы булыр иде дә, ләкин кеше сүзенә караганда, бу чибәр кыз бер дә егетләр белән йөрми. Хәйдәр белән берничә тапкыр күргәләсәләр дә, ул да бу кызның йөрәген яндырып җибәрә алмаган, ахрысы.

– Безне кайчан ябалар? – дип сорады Гөлшат, күзен дә күтәрмичә.

– Шушы җәйге айларда ябарбыз инде. Минем тәкъдимнәргә сез ничек карыйсыз? – диде кызыксынып баш табиб.

– Гафу итегез, тәкъдимнәрегез өчен рәхмәт, мин уйлап карармын. Миңа китәргә ярыймы? – диде Гөлшат, салкын гына Илдар Азатовичка карап.

– Бер килгән-килгән, ялга китәргә гариза язып, сәркатиптә калдырыгыз. Сау булыгыз, – дип, Илдар Азатович сүзен бетерде.

– Сау булыгыз, – дип, Гөлшат бүлмәдән чыгып китте.

Мансур Гөлшатны машинасында көтеп утыра иде. Кыз кәефсез генә чыгып утырды.

– Тагын ни өчен чакырганнар? Орыштылармы, мактадылармы? – дип, Мансур Гөлшатны сөйләштермәкче иде, ләкин җавап ишетелмәгәч, тынып калды. Ниндидер бик начар хәл булуын аңлап, ул башка бер сүз дә дәшмәде.

Алар «патша сарае»на кайтып җиткәндә, сәгать дүртенче киткән иде. Машина туктаганны ишетеп, Фәимә апа каршыларына чыкты. Гөлшатның кәефе юклыгын күреп:

– Ни булды, Илдар Азатовичтан нык эләктеме әллә? Йөзең агарып каткан. Тукта, әйдә минем бүлмәгә керәбез, чәй эчкәндә барысын да сөйләрсең, – дип, Фәимә апа Гөлшатны үз бүлмәсенә алып кереп китте. – Йә, әйдә, утыр, сөйлә ни булды, – дип, бүлмәнең ишеген дә катырак итеп япты да чәй әзерли башлады.

– Фәимә апа, безне ябалар.

– Ремонткамы?

– Юк, бөтенләй ябалар, ә безнең хастаханә урынында тарихи музей ачарга телиләр, – дип, Гөлшат елый ук башлады.

Фәимә апа кулындагы чынаягын төшереп җибәрде, стенада эленеп торган Ефим Михайловичның рамкадагы фотосы идәнгә килеп төшеп, пыяласы ярылды.

– Безнең белән нәрсә була?

Фәимә апа аптырап, урындыкка барып утырды.

– Сезне район үзәк хастаханәсенә күчерәләр, мине Казанга ординатурага укырга җибәрәләр, ике елга, – дип дәвам итте Гөлшат, елый-елый.

– Тукта, елама, – диде Фәимә апа, үзен кулга алып. Идәндә яткан фотоны өстәлгә куйды. – Мин иртәгә үк Казанга үзем барам, министр янына керәм.

– Сине анда бик көтеп торалар, ди.

– Мин бит министр белән бер группада укыдым, ул мине хәтерләргә

тиеш. Беренче курсларда артымнан да озаткалап йөргәне булды. Яшь чаклардагы мәхәббәтен онытмагандыр, бәлки? – дип, Фәимә апа өенә кайтырга җыена башлады.

Гөлшат күз яшьләрен сөртә-сөртә, бераз тынычланган сыман үз бүлмәсенә чыгып китте.

...Бүген иртәдән бирле нишләптер эш бармады. Фәимә апаны Мансур иртүк район үзәгенә автобуска илтеп кайтты. «Патша сарае»н ябалар дигән хәбәр авыл буйлап бик тиз таралган, эшкә килгәннән бирле Гөлшатка кемнәр генә шалтыратып белешмәде. Гөлшат хәтта телефонны алмый башлады. Хастаханәдә эшләүчеләрнең куллары эшкә бармады, барысы да бергә җыелдылар. Һәркем түземсезлек белән Фәимә апаның шалтыратуын көтә иде. Хәтта Дамир абый да килгән. Ул болай да чиста ишегалдын кат-кат себергән булды. Аларның исәпләүләре буенча Фәимә апа сәгать икеләрдән соң шалтыратырга тиеш. Барысы да аңа ышаналар, Фәимә апа булдыра алмаган эш юк, министр аның танышы да булгач, эшләр уңай якка хәл ителергә тиеш. «Патша сарае»нда урнашкан хастаханә эшләргә тиеш. Берсенең дә күңелләре тыныч түгел иде – Фәимә апа хәл итә алмаса, алар белән нәрсә булыр? Сәгать ике тулгач, Гөлшат та бүлмәсенә кереп, телефонга карап утыра башлады. Көн уртасына кадәр бертуктаусыз шалтыратулардан шартларга җиткән телефон тып-тын калды. Кинәт телефон шалтырады, Гөлшат әлеге тавышны түземсезлек белән көтсә дә, куркудан калтыранып куйды, берничә мизгел трубканы алмыйча торды.

– Тыңлыйм, – диде ул.

– Исәнмесез, сезне Казаннан Эчке эшләр министрлыгыннан борчыйлар. Сез Сөнгатуллина Фәимә Вахитовнаны беләсезме?

Гөлшат бу сүзләрне ишеткәч, бөтенләй югалып калды:

– Алло, сез мине яхшы ишетәсезме? – дип сорады дежурный.

– Әйе, әйе, яхшы ишетәбез, Фәимә апаны да яхшы беләбез. Аның белән нәрсә булды?

– Бүген ул утырган автобус Казанга җитәрәк һәлакәткә очрап, Фәимә ханым, кызганыч, вафат булган.

– Нәрсә, нәрсә? – дип, Гөлшат кычкырып җибәрде.

– Сөнгатуллина Фәимә Вахитовна авариядә һәлак булды, аның мәетен иртәгә Республика судмедэкспертизадан алып китә аласыз, – дигән коры гына тавыш яңгырады. – Сез үзегез кем буласыз? Кемгә хәбәр җиткерелгәнне миңа язып куярга кирәк.

– Мин – Гөлшат Равилевна, Фәимә апа эшләгән хастаханәнең табибы булам, – диде Гөлшат, ишеткән сүзләренә ышанасы килмичә.

– Миңа сезнең фамилиягез кирәк, туганнарына хәбәр итәрсез дип уйлыйм, – диде яңадан телефон трубкасында таныш булмаган тавыш.

Гөлшат фамилиясен әйтеп, трубканы куйды. Аның уйлары бөтенләй буталып беттеләр. Ул нәрсә эшләргә белмичә, аптырап, озак кына телефонга карап утырды. Шулчак бүлмәгә телефон шалтыраганын ишеткән кызлар килеп керде.

– Гөлшат Равилевна, йә ничек, Фәимә апа шалтыраттымы? Булдырып чыга алмаган, ахрысы? – дип борчылып сорадылар кызлар, Гөлшатның агарынган йөзен күреп.

– Кызлар, Фәимә апабыз авариягә очрап һәлак булган, – диде Гөлшат үз сүзләренә үзе ышанмыйча.

Кызлар бернәрсә дә аңламыйча, бүлмәгә кереп тулдылар.

– Фәимә апабыз авариягә очрап һәлак булган, – дип, яңадан кабатлады Гөлшат. – Иртәгә гәүдәсен моргтан барып алырга кирәк, диделәр.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Кызларның әлеге хәбәргә ышанасылары килмәде. Беренче булып Гөлшат, аңына килде, Илдар Азатовичка шалтыратып, хәбәрне җиткерде, Казаннан мәетен алып кайтырга машина сорады.

– Кызлар, бик зур үтенеч, бу хәбәрне авыл буйлап таратмагыз, зинһар өчен. Тәнзилә, Мансурны чакыр, ул ишегалдында булырга тиеш. Фәимә апаның гаиләсенә барып әйтергә кирәк.

Кызлар бер-берсен тыңламыйча:

– Мин бармыйм, мин бармыйм, – диештеләр.

Гөлшат, халатын салып, урамга чыкты. Мансур калтыраган куллары белән машинасы янында тәмәке тартып тора иде. Күзләре мөлдерәп яшь белән тулган:

– Гөлшат Равилевна, дөресме?

– Әйе, әйдә, өйләренә барып, гаиләсенә хәбәр итәргә кирәк, – дип, Гөлшат машинага кереп утырды.

– Мин өйләренә кермим, үзегез генә керегез, – диде Мансур, Фәимә апаларның капкасы янына килеп туктагач.

Фәимә апаның кечкенә кызы ишегалдында нидер эшләп йөри иде. Гөлшатны күргәч:

– Гөлшат апа, әни кайтмады әле, ул Казанга киткән иде, миңа яңа кесә телефоны алып кайтырга сүз бирде, – диде.

– Исәнме, Миләүшә, әтиең өйдәме? – диде Гөлшат, күз яшьләрен яшерә-яшерә.

– Әти өйдә, әнием кайтуына ашарга әзерли иде, – дип, Миләүшә шикләнеп, Гөлшатка карады. Бала күңеле нәрсәдер сизде. Күп тапкырлар күргән бу апа бүген ниндидер икенче иде, нәрсәдер әйтеп бетерми төсле тоелды аңа.

Гөлшат өйгә кереп китте. Рөстәм, чынлап та, ашарга әзерләп йөри иде.

– Исәнмесез, Рөстәм абый.

– О-о-о, безгә кунакка данлыклы Гөлшат Равилевна үзе килде. Фәимә кайтып җитмәде шул әле, – дип, күтәренке кәеф белән каршы алды Гөлшатны Рөстәм.

– Рөстәм абый, кил әле, яныма утыр, – дип, Гөлшат урындыкка күрсәтте.

– Хәзер, кулларымны гына сөртәм дә... Фәимә булмаганда, син миңа нәрсәдер әйтмәкче буласың, ахрысы, – дип килеп утырды.

– Рөстәм абый, бүген Казанга баручы автобус, авариягә очрап, Фәимә апа һәлак булган, – диде Гөлшат, бөтен кыюлыгын җыеп.

– Аңламадым.

– Фәимә апа һәлак булган. Иртәгә Фәимә апаның гәүдәсен моргтан барып алырга кирәк, Илдар Азатович белән сөйләштек. Ул машина бирергә тиеш, – диде Гөлшат.

– Нинди гәүдә, син нәрсә сөйлисең? – дип, Рөстәм һаман бернәрсә дә аңламыйча торды.

– Рөстәм абый, ярты сәгать элек Казаннан милициядән шалтыраттылар, Фәимә апа, авариягә очрап, һәлак булган. Иртәгә Фәимә апаны моргтан барып алырга кирәк, Илдар Азатович машина бирә, – диде Гөлшат, кабатлап һәм торып, ашыкмыйча ишеккә таба китте. Ишек төбендә, Гөлшат апасы артыннан кереп, олылар нәрсә турында сөйләшкәнен барысын да ишеткән Миләүшә басып тора иде. Гөлшат кызны кочаклап алып, маңгаеннан үпте дә өйдән чыгып китте. Машинага чыгып утыргач, ул бөтенләй хәле беткәнен аңлады:

– Мансур, мине кайтарып куй, зинһар өчен. Аннары кызлардан кемне дә булса монда ярдәмгә алып килерсең, яме.

– Ярар, Гөлшат Равилевна, – дип, Мансур машинасын кабызды.

Гөлшат буш өйгә кайтып керде. Кайгыны уртаклашырга да беркем юк. Ул өс киемнәрен салып, диванга барып утырды, нәрсә эшләргә дә белмичә, бер ноктага текәлеп, озак кына утырып торды, хәтта ут та кабызмады. Караңгыланып килгән бүлмәдә кинәт телефон шалтырады:

– Исәнме, кызым! Хәлләрең ничек?

Телефон трубкасында Наилә апа тавышы иде.

– Наилә апа, Фәимә апа авариягә очрап үлгән, – дип, көчкә әйтеп, Гөлшат үкси-үкси елап җибәрде. Ул башка бер сүз дә әйтә алмады. Гөлшат төне буе мендәрен кочаклап, әнисен күмгәндәге төсле елап чыкты.

Фәимә апаны озатырга бөтен авыл гына түгел, ярты район халкы килде. Барысының да йөзләрендә кайгы иде. Аны Ефим Михайлович янына җирләделәр.

...Иртән торулары хәзер авыр. «Тор, самавыр кайнады, эшкә барасың бар», – дип әйтүче дә юк, өйдә яңа гына әзерләнгән тәмле ризык исләре дә чыкмый. Бүген Гөлшат торалмыйча озак ятты. Ул үзенең тагын япа-ялгыз икәнлеген сизде. Наилә апа, Фәимә апаның кырыгы узгач, яңа гаиләсе янына Әлмәт якларына китте. Эшкә дә барасы килми. «Патша сарае»ның нур биреп торучы хуҗабикәсе юклыкка да менә инде кырык беренче көн. Гөлшат, бер ел эшләп, үзен «патша сарае»ның хуҗасы итеп сизә башлаган иде. Ләкин аның хуҗабикәсе, нур сибеп торучы гөле, Фәимә апа булган икән. Кырык көн узса да, өлкән шәфкать туташы бүлмәсенә кереп, тәртип салырга беркемнең дә кулы күтәрелмәде. Бергә эшләп йөргән кызларның да күзләре боек иде. Кызык, Фәимә апа үлгәннән бирле Гөлшатның бер тапкыр да эштә утырып чәй эчкәне булмады. «Әйдә, кызлар, колхоз эше бетмәс, чәй эчеп алыйк әле», дигән сүзләр «патша сарае»нда инде башка яңгырамас. Тиздән «патша сарае»нда урнашкан хастаханә дә юкка чыгачак. Бәлки, үз тормышын бу эшеннән, бу бинадан башка күз алдына китерә алмаган Фәимә апа шуңа да китеп баргандыр...

Гөлшат үзен көчләп торгызды, тиз генә урыннарын җыеп, самавырын куйды. Үзен тәртипкә кертеп, юынып чыкканда, самавыр гөрләп кайнап утыра иде. Фәимә апаның кичә узган кырыгыннан калган бәлешләр белән чәй эчеп, Гөлшат ашыкмыйча гына эшкә китте. Көн кояшлы булуга карамастан, иртәнгечә, салкынчарак. Каршыга очраган кешеләр юл буе исәнләшеп барсалар да, ул беркемне дә күрмәде. «Патша сарае»нда

авырулар аз. Матур җәй көннәрендә авыл кешеләре барысы да эштә, бик каты авыручылар гына хастаханәгә кереп ятарга мәҗбүр. Хастаханәдә шәфкать туташы Тәнзилә үзе генә иде. Гөлшат тиз генә авыруларны карап чыкты да Тәнзиләгә күрсәтмәләр бирде, көндәлек язмаларына төрле үзгәртүләр кертте. Кабул итү бүлмәсеннән әйләнеп килде, анда беркем дә юк иде. Аннан соң Тәнзиләдән ачкыч алып, теләмичә генә өлкән шәфкать туташы бүлмәсенә керде. Кичә Рөстәм, Фәимә апаның әйберләрен җыеп, әзерләп куюын сораган иде. «Кичкә таба, бәлки, кереп тә алырмын», – дип ышандырды.

Бүлмәдә тыныч, бөтен нәрсә тәртиптә, тик өстәл өстендәге әйберләрне аз гына тузан каплаган. Гөлшат кеше әйберләренә кагылырга курыккан сыман өстәл янында торган урындыкка барып утырды. Күңеленең һаман ышанасы килмәде, бу әйберләрнең хуҗасы үзе ишекне ачып керер сыман тоелды аңа. Ләкин бүлмә хуҗасы инде юк, тик стенага эленгән фоторәсемнән ак чәчле Ефим Михайлович кына карап тора. Гөлшат ашыкмыйча гына Фәимә апаның әйберләрен кәгазь тартмаларга тутырды. Соңыннан стенадагы фоторәсемне һәм Фәимә апаның фотосын кулына алып, яңадан урындыкка барып утырды. Кинәт кемдер ишеккә шакыды һәм «керегез» дигәнне дә көтмичә, бүлмәгә керде. Гөлшатның каршысына башка киемнәр кигән Фәимә апа кереп басты. Гөлшат үз күзләренә ышанмыйча, күзләрен бер ачты, бер йомды. «Уйларымнан саташам, ахрысы инде», – дип уйлап куйды.

– Исәнмесез, өлкән шәфкать туташы сез буласызмы? Мин сезнең хастаханәгездә беркемне дә очрата алмадым, кая китеп беткәннәрдер? – дигән таныш түгел тавыш яңгырады.

– Гафу итегез, – дип, урлауда тотылкан кеше кебек Гөлшат урыныннан сикереп торды. – Мин мондагы табиб, хәзер Фәимә апаны чакырам, түргә узыгыз, утырыгыз, – диде. Нәрсә әйткәнен соңыннан гына аңлап һәм үзен кулга алырга тырышып: – Сез кем буласыз? – дип сорап куйды.

– Мин – Светлана Александровна, сезгә Санкт-Петербургтан бер йомыш белән килгән идем.

Кинәт бу апаның күзләре Гөлшатның кулындагы фоторәсемгә төште, һәм бу юлы ул, күзләрен йомып, аркасы белән стенага сөялде. Гөлшат моны күреп, аңа утырырга урындык тәкъдим итте.

– Гафу итегез. Мин бернәрсә дә аңламадым. Сез кем? – дип, яңадан сорады Гөлшат.

– Мин – Светлана Александровна. Бу фотода кем төшерелгән?

– Ефим Михайлович. Гафу итегез. Сез кем?

Алдында кем утырганын аңламыйча, Гөлшат фотоны әлеге ханымга сузды. Ул һаман бернәрсә дә аңламады. Аның каршысында Фәимә апа утыра иде: йөзе, чәче. Өстенә кигән киеме генә башка.

– Сез кем?

Ханым озак кына фоторәсемгә карап утырды.

– Бу – минем әтием, ә икенче фотода кем? Миңа бик ошаса да, бу мин түгел, – дип, ул Гөлшатка карады. Бу ханымны кайда күреп сөйләшергә була?

– Фоторәсемдәге хатын Фәимә апа, кызганыч, сез аның белән очраша алмыйсыз.

– Нишләп?

– Кичә кырыгын уздырдык. Авариягә очрап, вафат булды.

Көне буе үзен тыеп йөргәнгәме, Гөлшатның күңеле тулып, тагын күз яшьләре ага башлады.

– Ярагызны яңадан кузгаткан өчен гафу итегез, ул сезнең кемегез иде?

– Укытучым, апам, якын дустым, өлкән шәфкать туташым. Без бергә бер ел эшләдек. Мин монда бер ел элек эшкә килдем, ул миңа бөтен белгән осталыгын тапшырырга тырышты.

– Сез, Гөлшат Равилевна, ялгышмасам?

– Дөрес. Сез кем? Кайдан килдегез?

– Минем сезгә бер үтенечем бар. Әгәр вакытыгыз булса, минем белән зиратка барып, әтиемнең каберен карап кайта алмабыз микән? – диде ханым, Гөлшатның соравын ишетмәгәндәй.

– Гафу итегез, Светлана Александровна. Мин сезнең кем икәнлегегезне аңлап бетермәдем. Кемнең каберенә барып кайтасыгыз килә? – дип, Гөлшат, бердән, бик таныш, икенчедән, бөтенләй дә таныш булмаган бу кеше алдында үзенең бик уңайсыз хәлдә калганын сизә башлады.

– Мин сезгә Санкт-Петербургтан килдем, менә бу фоторәсемдә, уйлавымча, минем әтием Ефим Михайлович төшерелгән. Ул сезнең авылыгызда җирләнгән дип ишеттем. Шуның каберен күрергә дип, сезнең авылыгызга килгән идем. Кайгыгызны уртаклашам. Мин Фәимә апагыз турында ишеткән идем, ләкин аның үлеме хакында белмәдем. Әгәр инде вакытыгыз булса, кайдалыгын белсәгез, миңа әтиемнең каберен күрсәтә алмассыз микән? Үзем генә таба алмам дип куркам.

– Мин каршы түгел, вакытым да бар, – дип, Гөлшат, уңайсызланып, Фәимә апага бик охшаган ханымга тагын бер кат текәлеп карады.

– Алайса, мин сезне урамда көтәм, мин машина белән килдем, – дип, Светлана Александровна фоторәсемнәрне өстәлгә куйды. – Гафу итегез, сездә әтинең башка фоторәсемнәре юктыр? Бу рәсемне сорарга уңайсызланам, – дип, сораулы күзләре белән Гөлшатка карап торды да, җавап ишетмәгәч, бүлмәдән чыгып китте.

Ишек артында ниндидер тавыш ишетелде. Гөлшат тиз генә тартмаларга тутырылган әйберләр арасыннан Ефим Михайловичның элек Фәимә апа өстәлендә торган фоторәсемен табып алды. Халатын салып, өстәлгә куйды һәм фоторәсемне алып, бүлмәдән чыгып китте.

Коридор идәнендә Тәнзилә дүрт аякланган хәлдә аңына килә алмыйча утыра иде.

– Ишекне үзең бикләрсең, мин чакырулар буенча киттем, ачкыч өстәлдә калды, – дип, Тәнзиләгә бөтенләй игътибар итмичә, Гөлшат хастаханәдән чыгып китте. Тәнзилә, күзләрен зур ачып, идәндә сүзсез генә утырып калды.

Урамда Гөлшатны эшләп торган кызыл «Жигули» көтеп тора иде.

– Кая, ничек барабыз?

– Шушы урам буйлап туп-туры, – Гөлшат ханымга яңадан игътибар белән карады. Алдында Фәимә апа утыра иде, шундый ук кызу, җитез.

– Нәрсә, бик охшаганмы? Җавап бирмәсәгез дә була, үзем күрдем. Мине сезгә классташыгыз Илһам җибәрде. Башта киләсем дә килмәгән иде. Мин әтиемне бөтенләй белмим дип әйтсәм дә була. Мин Казанга лекцияләр

укырга килгән идем. Берничә буш көнем бар. Вакыт булгач, монда килергә уйладым. Әнием үләр алдыннан мине чакырып, гаиләбезнең тарихын, әтием турында сөйләде. Сезгә кызык та түгелдер?

– Юк, юк, зинһар өчен, сөйләгез, миңа бик кызык. Теге зәңгәр йортны узгач, сулга борылыгыз, – дип, юлны күрсәтеп, Гөлшат игътибар белән тыңларга әзерләнде.

– Ефим Михайлович Ленинградта медицина институтын тәмамлап, хирург булып эшли башлый, әни белән танышалар, ләкин әтине Ерак Көнчыгышка хезмәт итәргә җибәрәләр, аннан соң кырыгынчы елны Белоруссиягә күчерәләр. Алар әни белән хатлар язышалар, очрашкалыйлар, арада мәхәббәт туа. Шул мәхәббәтнең җимеше булып, мин туганмын. Әти белән әни никахлашып өлгермиләр, сугыш башлана. Әти Белоруссиядә кала, әни эвакуациягә Казанга килә. Әтидән хәбәрләр булмагач, әни икенче кешегә кияүгә чыга. Шуңа күрә минем исемем Светлана Александровна. Сугыштан соң әти, Мәскәүгә кайтып, профессор Юдин кул астында эшли башлый, 1948 елны Юдин төрмәгә ябылгач, әти озакламый Мәскәүдән китеп бара, күрәсең, монда килеп урнаша. Без яңадан Ленинградка кайтып төпләнгәч, ул минем әниемне эзләп таба. Әни минем фоторәсемне җибәреп, гафу үтенгән, ләкин гаиләне таркатмас өчен килмәскә кушкан, минем тагын ике энем бар. Ул вакытта миңа инде егерме бер яшь тулган була. Мин ул фоторәсемдә ак борчаклы күлмәк киеп төшкән идем.

– Мин ул фоторәсемне күрдем. Без килеп тә җиттек, – дип, Гөлшат зират капкасына күрсәтте.

Алар машинадан чыгып, зиратка кереп киттеләр.

...Өлкән шәфкать туташы бүлмәсеннән күптән түгел генә җирләгән Фәимә апа чыкканын күргәч, Тәнзилә кулындагы шприцларны төшереп җибәрде дә аяклары калтыраудан идәнгә чүгәләп утырды һәм Гөлшатны күргәч кенә, аңына килгәндәй булды. Тиз генә идәндә чәчелгән шприцларны җыеп, телефонга ташланды. Телефон трубкасын күтәрүгә уйга калды: «Кемгә шалтыратырга? Гөлшат Равилевна чыгып кына китте, Илдар Азатовичка шалтыратсаң, бу кыз акылдан язган диячәк. Кемгә? Кемгә? Фәимә апа кайткан бит теге дөньядан, күрәсең, монда эше бетмәгән. Шулай булгач, Фәимә апаның иренә шалтыратырга кирәк».

Тәнзилә тиз генә номерны җыйды:

– Рөстәм абый, исәнмесез. Сез мине, акылдан язган бу кыз, димәгез, сезнең кайгыдан көлә дип тә уйламагыз. Мин кемгә шалтыратырга да белмим.

– Тәнзилә, синме бу?

– Әйе.

– Әйдә, әйт сүзеңне, сузма, эшем күп.

– Рөстәм абый, син мине ачуланмыйсыңмы?

– Җитәр инде, әйт сүзеңне. Әйтмәсәң, трубканы куям.

– Юк, юк, куйма. Рөстәм абый, биш-ун минут элек кенә, Фәимә апа эшкә килеп, Гөлшат апаны алып чыгып китте.

– Син нәрсә, акылыңны җуйдыңмы әллә? Тузга язмаган сүз сөйлисең.

– Рөстәм абый, мин үзем дә аңлыйм, сүзем җүләрнекенә охшаган. Ләкин алар аллы-артлы Фәимә апа бүлмәсеннән чыгып киттеләр.

– Нәрсә сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы син, юкмы? Кичә генә кырыгында утырдың бит.

– Гафу ит инде, Рөстәм абый, мин үзем дә аңлыйм, ләкин бит үз күзем белән күрдем, тик күлмәге генә башка иде, – дип, ник шалтыратканына үкенеп, үксеп елый башлады.

– Нинди күлмәк, Тәнзилә, тынычлан, үзең уйлап кара, теге дөньядан кайтмыйлар?

Ләкин телефонда елаган тавыш кына ишетелде һәм элемтә өзелде.

Рөстәм, бернәрсә дә аңламыйча, телефон янында торган урындыкка барып утырды. Акылы белән бу хәлнең булуы мөмкин түгел икәнлеген ул яхшы аңласа да: «Бәлки, Фәимәнең җаны «патша сарае»на кайткандыр?» – дип уйлап куйды. Ләкин Тәнзилә: «Фәимә Гөлшат белән чыгып киттеләр», – диде, ахрысы.

Кинәт телефон кабат шалтырады. Рөстәм уянып киткәндәй, сискәнеп куйды, трубканы алды:

– Рөстәм, сәлам! Бу – Илдус.

– Сәлам, таныдым, Илдус.

– Син мине җүләргә санама, эчүемне ташлаганга да бер атна.

– Аракым юк, сорама, эчәргә акча да бирмим, – дип, кырт кисте Рөстәм.

– Юк, миңа аракы да, акча да кирәкми. Мин теге, синең Фәимәңне күрдем.

– Кайда? Төшеңдәме?

– Юк инде, төштә түгел. Урам буйлап бара идем, күрәм таныш булмаган кызыл машина бара, кем икән дип карасам, рульдә Фәимәң утыра. Мин башта күземә күренәме әллә дип уйлаган идем, алар янымнан тизлекне әкренләтеп узып киттеләр. Безнең урамда юллар яхшыдан түгел, үзең беләсең.

– Кем алар?

– Кем булсын инде, Гөлшат Равилевна белән синең Фәимәң.

– Кая киттеләр?

– Кая булсын инде, шунда.

– Кая шунда?

– Шунда инде, кырык көн элек кая илттек, зиратка.

Рөстәм телефон төймәсенә басты. «Авылдашларым акылдан яза башлаганнар бугай, бәлки, җеннәр котыра торганнардыр. Фәимә электән дә бик кызык кеше иде, үлгәч тә, кире кайтып йөрмәс бит инде. Рөстәм, тукта, син дә Тәнзилә белән Илдус сыман юләр сатып утырма. Илдус, Гөлшат Равилевна белән зират янында күрдем, диде бит. Барып кайтыйм, үз күзем белән күрермен.

Кешеләр еллар буе бер-берсен күрмичә ничек яши торганнардыр? Бу узган кырык көне дә бик озак тоелды. Рөстәм аңы белән Фәимәнең инде башка кайтмаячагын аңласа да, күңеле һаман нидер көтә иде: кич җиткәч, эштән кайтып керер дә тиз генә ашарга әзерләр сыман. Иртән уянгач та, ул озак кына өйдәге тавышларны тыңлап ята, ләкин табак-савыт шалтыраганы да, «Ашарга торыгыз!» дигән сүзләр дә ишетелми. Ял көннәрендә өйдә яңа пешкән тәмле камыр ризыгы исләре дә таралмый. Кичләрен йокларга яткач, Рөстәм Фәимәнең мендәрен кочаклый. Мендәрдә яраткан Фәимәсенең

күңелгә бик якын һәм таныш исе. Бәлки, чынлап та, кайткандыр, бәлки, кырык көн элек башка кешене җирләгәнбездер, шундый хәлләр дә булгалый бит бу тормышта. Юлдагы фаҗигадән соң, Казаннан өйгә алып кайткач, моргта рәткә китерергә бик тырышсалар да, Фәимәнең йөзе танырлык түгел иде бит.

Зиратка якыная барган саен Рөстәмнең башында, хатыны бәлки, исәндер, башка кешене җирләмәдек микән, дигән уй ныгый барды. Гөлшат Равилевна чит кешеләр белән зиратка барып йөрмәс бит, аның анда беркеме дә юк. Тиз барудан тыны кысылган Рөстәм зиратка керде һәм туп-туры хатыны каберенә таба китте. Ерактан Гөлшат Равилевнаны күреп: «Фәимә!» – дип, кычкырырга тырышты. Ләкин авызы кипкәнгә, пышылдау гына ишетелде. Кинәт Рөстәмнең хәле китте, аяклары атламас булды. Ул юл буенда үскән каенга терәлеп, яшел яфраклар арасыннан Гөлшат Равилевна янында басып торган хатынны яхшырак күрергә тырышты. Өстендә башка кием булса да, Гөлшат янында Фәимә басып тора иде. Ул актык көчен җыеп, калган араны узды.

– Фәимә, җаным, синме бу? – дигән сүзләр белән хатыннар янына килеп басты. Икесе дә тавышка таба борылдылар. Берсе – Гөлшат, икенчесе Фәимәгә бик ошаган ханым, ләкин аның хатыны түгел иде.

– Рөстәм абый, сез кайдан килеп чыктыгыз? Нәрсә булды? – диде Гөлшат аптырап, кинәт каршысында пәйда булган агарынган ирне күргәч.

Рөстәм бер Гөлшатка, бер Фәимәгә охшаган хатынга карады.

– Таныш булыгыз, бу – Светлана Александровна, Ефим Михайловичның кызы, безгә әтисенең каберен күрергә кайткан, – дип, Гөлшат бер-берсенә карап торучы кешеләрне таныштырырга тырышты.

– Исәнмесез, – дип, Рөстәм, картларча, кулын сузды. Гөлшат күз алдында картаеп киткән Рөстәм абыйсын күреп, аны чын күңеленнән кызганып куйды.

– Исәнмесез, – дип, кулын биреп исәнләште Светлана Александровна.

– Светлана Александровна безгә Санкт-Петербургтан килгән. Без, минә аның белән, Ефим Михайлович һәм Фәимә апа янына килгән идек, – диде Гөлшат, тынлыкны бозып, ни әйтергә дә белмичә.

Зиратта тыныч, агачлар шаулавы һәм сандугачлар сайравы ишетелә. Ефим Михайловичның кабере чиста. Кабер өстендә матур чәчәкләр үсеп утыра.

– Рәхмәт сезгә, сезнең хатыныгызга, минем әтиемнең каберен шулай кадерләп карап торганга. Миңа Гөлшат Равилевна барысын да сөйләде, – диде Светлана Александровна, артында басып торган кешеләргә борылмыйча гына.

– Фәимәгә рәхмәт, ул Ефим Михайловичны үз әтисе кебек яратты. Исән чагында Ефим Михайлович безгә бик ярдәм итте. Туебызда да Фәимәнең әтисе урынында утырды.

Рөстәм, үзен кулга алып, Светлана Александровнага түгел, ә Фәимә каберенә карап торды.

Алар өчәүләп, әкрен генә чыгу ягына киттеләр.

– Әйдәгез безгә, чәйләр эчеп, ял итеп алырсыз. Бездә берничә фотоальбом бар. Анда Ефим Михайловичның фотолары күп, – дип тәкъдим итте Рөстәм,

– Гөлшат Равилевна да каршы килмәс дип уйлыйм, көндезге аш вакыты җиткән, әйдәгез, кыстатмагыз.

Светлана Александровнаны үзләренә алып кайтуының нәтиҗәсен, Рөстәм, өйгә кереп, Миләш, кунакларны каршы ал, дип, кызын чакыргач кына аңлады.

Каршыга чыккан Миләүшә, Светлана Александровнаны күргәч, телсез калды, кулындагы яраткан «Ак чәчәкләр» китабын идәнгә төшереп җибәрде һәм бер мизгелгә катып калды. Әтисенең «Кызым, самавырны куеп җибәр» дигән сүзләрен ишеткәч, ул уянып киткәндәй булды һәм кереп баручы Гөлшатны бәреп ега язып, өйдән чыгып йөгерде.

– Миләүшәгә ни булды, Рөстәм абый? – дип пышылдады Гөлшат.

– Кунаклар, әйдәгез, түргә узыгыз. Гөлшат, миңа башта өйгә кереп, Миләүшәне әзерләргә кирәк иде. Әнисенә бик охшаган кешене күрү кызыма авыр булгандыр, мин урамга чыгып, тиз генә аны эзләп керим, син монда хуҗабикә булып тор инде, син кайда нәрсә ятканын беләсең, чәйләр әзерлә, мин хәзер керәм, – дип, урамга чыгып китте.

Фәимә апа исән чагында Гөлшат бу йортта еш була иде. Шуңа күрә кайда нәрсә ятканын, чыннан да, яхшы белә. Ул тиз генә самавыр куеп, өстәл әзерли башлады. Светлана Александровна түргә узды. Матур, чиста якты бүлмәләр, һәр бүлмә ишеге өстендә шамаил эленеп тора. Бу өйдә Фәимә яшәгән, аның игезәге булмаса да, йөзе белән аңа бик охшаган кеше. Язмышның борылышлары нинди? Бу авылга әтисенең эшләгән урынын, каберен күрергә дип килгән иде, нинди кешеләр белән күрешергә, танышырга туры килде. Һәрбер өйнең үз исе, үз яме була. Светлана Александровна бу йортта беренче тапкыр гына булса да, үзен бик иркен хис итте. Бөтен нәрсә чит булса да, аның өчен бар да таныш, якын булып тоелды. Чигелгән мендәрләр, тәрәзә төбендәге тамчы гөлләр күңелгә җылылык бирә иде.

Бүлмәгә Рөстәм керде, аның артында качып кына, унике-ундүрт яшьлек кыз басып тора:

– Миләүшә, таныш бул, бу – Светлана Александровна, безнең бабаебызның кызы. Сез, Светлана Александровна, аптырамагыз, без Ефим Михайловичны бабай дип йөртергә өйрәнгән инде.

– Йә, Миләш, кил әле яныма, – дип, Светлана Александровна кызның кулыннан тотты, кочаклап алды.

Миләүшә, башта куркып кына, чит хатын янына килеп, кулын бирде, аннары кинәт, каршысында әнисен күргәндәй булып, күңеле йомшарып китте, күз яшьләре мөлдерәп тулды, ул ачылган кочакка кереп чумды. Светлана Александровна кызны күргәч, үзенчә яратып, әнисен югалту кайгысын уртаклашмакчы булган иде дә, Миләүшәне кочаклагач, аның күңеле тетрәнеп куйды, тәненә рәхәт җылылык таралды. Светлана Александровнаның үз балалары юк. Институтта укыганда, дуслашып йөргән егете булса да, кияүгә чыгарга иртә дип уйлаган иде. Укып бетергәч, аларны язмыш илнең төрле якларына ташлады. Башта хатлар языштылар, кинәт хатлар да тукталды, ул егетнең өйләнгәнлеге ишетелде. Ялгызлыкны башта эш алыштырды, аннары аспирантурага кереп, кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклады, профессор булды. Әнисе авырып киткәч, бөтен

көчен әнисен карауга багышлады. Берничә елдан әнисе дә үлгәч, үзенең бу тормышта ялгыз икәнлеген аңлады. Юк, ул бөтенләй үк ялгыз түгел түгелен, аның бертуган энесе, сеңлесе, аларның гаиләләре, балалары бар. Ул ял көннәрен, бәйрәмнәрне алар белән бергә уздыра. Ләкин өенә кайтса, андагы тынычлык ялгызлыкны исенә төшерә. Санкт-Петербургта ике бүлмәле зур фатиры бар. Аны үзенчә матурлап, чисталыкта, тәртиптә тота. Менә бу Рөстәм белән Фәимә яшәгән йортка килгәч, ул өйнең чын ямен күрде. Монда байлык күзгә ташланып тормый, чиккән гади тәрәзә пәрдәләре, мендәрләр, тәрәз төбендәге тамчылы гөл чәчәкләре – болар барысы да бу өйдә чын бәхетле гаилә, мәхәббәт яшәгәнлеген күрсәтәләр иде. Бу кызның аны шулай кочаклап алуы бөтенләй күңелен өзгәләп атты, гомере буе үзен кулда тотарга өйрәнгән хатын бу мизгелдә югалып калды, күзләре мөлдерәмә тулды, ул, ни эшләргә белмичә, кызны куенынна җибәрергә теләмәде. Рөстәм белән Гөлшат та нәрсә эшләргә белмичә баскан урыннарында катып калдылар. Бу кискенлекне тудырган Миләүшә мәсьәләне, әнисе кебек зурларча чиште:

– Светлана апа, ерак юлдан килеп, арыгансыздыр. Мин хәзер самавыр куям, чәйләр эчеп алыйк, – диде.

Чәйләр эчкәч, Миләүшә фотоальбомнар чыгарды. Алар озаклап фотолар карап утырдылар. Светлана Александровна үзе өчен әтисен яңадан ачты. Рөстәм Ефим Михайлович турында бик күп нәрсәләр сөйләде. Бераздан Гөлшат сиздермичә генә чыгып китте. Аны, чынлап та, карап чыгасы авыру әби-бабайлары, авылдашлары көтеп тора иде.

Светлана Александровна стенада эленеп торган сәгатькә күзен төшереп алды, сәгать дүрт тулып, бишенче киткән иде. Рөстәм белән Миләүшә аны үзләрендә кунып китәргә күпме генә кыстасалар да, ул риза булмады. Үзенең Санкт-Петербургтагы адресын язып калдырды һәм рәхмәтләр әйтеп, юлга кузгалды. Йорт хуҗалары аны озатырга чыктылар. Светлана Александровна Рөстәм белән ирләрчә кул бирешеп саубуллашты, Миләүшәне кочаклап, күкрәгенә кысты да машинага кереп утырды. Машина кузгалып киткәч, Миләүшә әтисенә:

– Ә безнең әниебез барыбер матуррак та, яхшырак та иде, шулай бит, әти? – диде.

Рөстәм нәрсә әйтергә дә белмичә, кызын кочаклап алды һәм алар ашыкмыйча гына өйгә кереп киттеләр.

Светлана Александровнаның күзләре юлда булса, күңеле белән ул тау итәгендә урнашкан авылда, аның гади кешеләре янында иде. Әтисен эзләп килеп, ул үзенең «игезәге»нең гаиләсе белән танышты, бик гаҗәеп хәлләр ишетте. Аңа охшаган хатын, аның яшьтәше, гаиләсе өчен укуын ташлап, гомере буе авылда яшәгән, тормышын кешеләр сәламәтлеген кайгыртуга багышлаган. Кечкенә Миләш, аның кочаклап алуы... Светлананың әтисе кырык елга якын монда эшләгән. Язмыш Светлана урынына аңа охшаган Фәимәне биргән. Әтисенең фоторәсемнәрендә ул бәхетле кеше йөзен күрде. Ул әти дә, бабай да булган. Кабере дә матур урында, күпме еллар узса да, кешеләр хөрмәт белән искә алалар. Светлана Александровна, син фәннәр докторы, ә сине искә алырлар микән? Кайчан да булса тагын бу авылга, бу

кешеләр янына әйләнеп кайтыр микән ул? Тормыш юлларының кая алып барганын кем белә?

Светлана Александровнаның авылга килүе – Фәимә апаның теге дөньядан кайтуы турында Каратау халкы тагын бик күп еллар сөйләячәк әле.

...Гөлшат, гадәттәгечә, иртән иртүк уянды. Бүгенге көннән «патша сарае» эшләми, ә ул ялда. Хастаханәне яптылар, Анжела Идрисовна әйтмешли, «бесперспективно». Каратау һәм якында урнашкан авыл кешеләре район үзәк хастаханәсенә барырга мәҗбүр. Ә Гөлшатның бүген беркая да барасы юк. Илдар Азатович аңа район үзәк хастаханәсендә эш тәкъдим итте. Башка барыр урыны булмаса да, Гөлшат ризалык бирмәде: анда эшләргә барса, үзен нишләптер Фәимә апа белән бер дә белмәгән Ефим Михайловичның рухына хыянәт иткән төсле булып тоелды аңа.

Татарстанда эш бетмәс. Ләкин Гөлшат мондагы табигатькә, кешеләргә, «патша сарае»на гашыйк булып өлгергән иде. Әгәр аңа бер ел элек бу хәлләр турында сөйләгән булсалар, ул ышанмас, бәлки, көләр генә иде. Ә бүген бер дә көләсе килми. Яше егерме алтыда, эшсез, гаиләсе, хәтта очрашып йөргән егете дә юк, япа-ялгыз. Ярар, Гөлшат, тормыш дәвам итә, алда әле тагын бер ай ялың бар, дигән уйлар белән ул тәрәзәне ачып җибәрде һәм чәй эчәргә утырды. Тәрәзә аша саф һавага уралган кояш нурлары өйгә тулды. Мондый матур көндә өйдә утырырга ярамый, утырасы да килми иде. «Нигә әле бүген Мәдинә тавына бармаска? Тагын бер кат искиткеч табигатенә хозурланып кайтмаска, тешне сындырырлык салкын чишмә суын эчмәскә, бәлки йөрәк янулары басылыр иде».

Гөлшат Наилә апасы белән йөргән аланга бер сәгать эчендә диярлек килеп җитте. Бу тауга аны нәрсәдер чакырган төсле, анда нәрсәсендер югалткан төсле тоелды аңа. Юлда авылдашларын очраткалады, барысы да, зурлап, «Гөлшат Равилевна» дип эндәштеләр. Аланда ямь-яшел үлән түшәлгән, тирә-юньдә сандугачлар сайравы үзәкне өзә. Гөлшат бала чагына кайткандай булды, рәхәтләнеп яшел келәмдә аунады. Яткан килеш кенә үлән арасында өлгереп килгән каен җиләген авыз итте. Элек Казанда яшәгәндә, табигатьнең мондый матур чагын ул бер дә күрми иде. Бер ел дигәндә, Гөлшат бөтенләй башка кешегә әйләнде, табигатьнең, кешеләрнең чын матурлыгын күрә башлады. Мәдинә тавы аның тормышына да үтеп керде, аның күңелендә дә эз калдырды. Шулвакыт таныш тавышлар ишетелде. Аланда Хәйдәр белән Земфира күренделәр. Алар кулга-кул тотынышып көлешә-көлешә киләләр иде. Хәйдәр матур тавышы белән бөтен урманны яңгыратып:

Земфирәкәй, сылу аппагым
Җырларымны сиңа сакладым, –

дип җырлап җибәрде.

– Ярар инде, Хәйдәр абый, кеше ишетер.

– Ишетсең, мин кешедән яшеренеп күп яшәдем, эштән башка бернәрсә дә күрмәдем.

Хәйдәрнең күзләре мәхәббәттән, шатлыктан яна иде. Гөлшат качып ятуның мәгънәсезлек икәнлеген аңлап, аларның каршыларына чыкты.

– Исәнмесез, Хәйдәр абый, Земфира. Сезнең шундый бәхетле булуыгызны күрүгә мин бик шат.

– Гөлшат Равилевна, безнең бәхетебездә сезнең дә катнашыгыз бик зур. Сез бит миңа чиремнән котылу өчен Мәдинә тавының һавасын суларга, суын эчәргә язып бирдегез, табигатьнең, кешеләрнең матурлыгын тоярга өйрәттегез, – дип, Хәйдәр Земфирага карап куйды.

– Гөлшат Равилевна, сезне үзебезнең туебызга чакырабыз. Әле чакыру кәгазен китереп бирербез.

Хәйдәрнең куенына сыенган Земфира бер Гөлшатка, бер Хәйдәргә карап алды. Авылда берара Хәйдәр Гөлшат Равилевнага күз атып йөри икән дигән сүзләр чыккан иде, бәлки, сүз генә булмагандыр?

– Әгәр Хәйдәр туеңда җырласа, килермен, аның тавышыннан туеп булмый, – диде Гөлшат.

– Без, Алла боерса, Земфира белән икәүләшеп җырларбыз, сезнең Земфираның тавышын ишеткәнегез юк әле.

– Ярар инде, Хәйдәр абый, мине оялтмагыз. Гөлшат апа, чынлап та, туебызга килерсезме? «Патша сарае»н ябалар дип сөйлиләр, сез китәсез икән дип ишеттек?

– Белмим, тормыш кая ташлар? «Патша сарае»н, чынлап, бүгенге көннән яптылар шул. Ә туегызга мин барыбер киләм, кайда булсам да.

«Патша сарае» турында сүз чыккач, Гөлшатның кәефе төшеп китте.

– Әйдәгез, авылга алып кайтабыз, – дип, Хәйдәр үзләре белән кайтырга тәкъдим итте.

– Юк, сез барыгыз, мин әле кайтмыйм. Монда килгәч, Мәдинә тавы чишмәсенең суын эчми кайтырга ярамас, – дип, Гөлшат кәефсезләнүен сиздерергә теләмичә, урман эченә кереп китте. «Патша сарае»ның ябылуы, киләчәгенең билгесез булуы аны бик борчый иде. Чишмә янына килеп җиткәч, Гөлшат берничә тапкыр битен салкын су белән юып алды, учлап чишмә суы эчте. Аккан чишмә буйлап урман эченә кереп китте. Чишмә юлы аны тау башындагы яр кырыена алып килде. Ярдан авыл күренеше ачылды, авыл уртасында – «патша сарае». Авыл – авыл төсле инде, искитәрлек бернәрсәсе дә юк. Үзенең «патша сарае» белән шушы авыл Гөлшатның күңеленә кереп урнашты.

Кинәт Гөлшатның артында, чишмә ягыннан таныш тавыш ишетелде:

– Синең Мәдинә тавының убырлы карчыгына әйләнәсең киләме әллә? – Бу Наилә апаның тавышы иде.

– Наилә апа, син каян килеп чыктың? – Гөлшат аптырап китте.

– Кил инде, әбиеңне кочаклап ал, сагындым үзеңне. – Наилә апа чатанлый-чатанлый аның каршысына килеп басты.

– Чынлап, Наилә апа, сез каян килеп чыктыгыз, мине ничек эзләп таптыгыз? Закир абый кайда? – диде Гөлшат, кочаклашкан килеш.

– Авылда Хәйдәрне очраттык, ул сине монда диде, синең артыңнан килдек. Закир абыең чишмә суы эчеп калды. Чишмә суы белән самавыр куймакчы. Кунакларны тәмле чәй белән сыйлыйсы килде. Ярар, син бик күп сораулар бирә башладың. Әйдә, яр кырыена басып, авылыма бер карап алыйм әле, – дип, Наилә апа Гөлшатны яңадан яр кырыена алып килде.

Алар берничә минут тыныч кына авылга таба карап тордылар. Юлда

Закир абый белән кече улы Камил күренде. Гөлшат Камилгә күз төшереп алды, ул кара чалбар, ак күлмәктән, муенына кара галстук таккан иде.

– Исәнмесез, Закир абый, исәнме, Камил, – дип, Гөлшат аларның каршыларына чыкты.

– Исәнме, Гөлшат, кызым, – дип, Закир абый олыларча Гөлшатны кочаклап алды.

– Исәнме, Гөлшат, – дип, Камил, күзләрен күтәрмичә генә, Гөлшат белән исәнләште.

– Закир, болай булса, синең улың белән ботка пешереп булмый, – дип, Наилә апа Камилгә карады.

Камил уянып киткәндәй сузып-сузып кына:

– Гөлшат, мин сезне беренче күрүдә үк яраттым, чыгыгыз миңа кияүгә! – диде.

– Мин бернәрсә дә аңламыйм. – Гөлшат аптырап, бер Камилгә, бер Наилә апага, бер Закир абыйга карады.

– Гөлшат, нәрсә аңламыйсың инде, без сине кияүгә чыгарга сорарга кайттык, – дип, Закир абый югалып калган улы урынына сүз башлады. – Ул сине бер күрүдә үк яраткан. Син, Мәдинә тавының кызы, улымның күңелен сихерләп алгансың. Аның синнән башка бер кыз турында да уйлыйсы килми. Улым тәртипле, акыллы, чибәр, дип тә әйтергә була, тик менә кызлар белән сөйләшә белми.

– Кызны әти-әнисе янына килеп сорыйлар түгелме соң? – дип, шаяртырга тырышты Гөлшат.

– Без әтиеңнән сорадык инде, ул риза, әбиең урынына мин дә ярап торырмын, син бит үзең: «Син минем әбиемә охшаган», – дисең.

Урман эченнән чыгып, бер ир-ат боларга каршы килә башлады. Гөлшат күзләренә ышанмыйча торды – аның каршысына әтисе килә иде. Бер ел буе күрмәгән әтисе беренче карашка бераз картайган кебек тоелса да, шул ук элеккеге бик яраткан әтисе иде. Араларында күпме аңлашылмаучанлыклар булса да, Гөлшат бөтен дөньясын онытып, әтисен барып кочаклады. Икесенең дә күзләрендә яшь тәгәреп чыкты.

– Әтием, нишлибез? – диде Гөлшат, әтисен кочаклаган килеш.

– Үзеңә кара, кызым, син хәзер зур инде, мин каршы түгел, алар яхшы кешеләргә охшаган, – диде әтисе, һаман кызыннан күзен ала алмыйча, кулыннан тотып. Ул Гөлшатны кулыннан тоткан килеш, Камил янына алып килде, икесенең дә кулларын бер-берсенә тоташтырды: – Хәерле сәгатьтә, бәхетле булыгыз, балалар – диде.

– Әгәр Мәдинә тавында кунасыгыз килмәсә, әйдәгез, тизрәк кайтыйк, көньяктан кара болыт күренде, – дип, Наилә апа, әллә шаяртып, әллә чынлап, күккә күрсәтте.

Алар көлешә-көлешә машинага таба киттеләр. Кулга-кул тотынышкан яшьләр әкрен генә арттан атлады, аларны күктәге кара болыт куркытмый иде.

«Аһ, туган каумем газиз!» әдәби конкурсы

Халисә
Рәйхан

ПРАСКОВЬЯ

хикәя

– Фатыйма әби, хәлең ничек? Чәй эчәсең килмиме?

Карчык йокы аралаш ишетелгән бу сүзләрдән тынычланып китте... Авызы кибеп уяна соңгы вакытта, еш кына хәле бетә, башы авырта, шуңа күрә йортта артык йөрергә тырышмый, йомышын йомышлап килә дә тиз генә урынына ава.

Күршесе Мәликә кергән икән. Ул шундый инде, көн дә бер хәлен белеп чыга. Чәйгә дип, тәмле ризыкларын да калдырмый. Рәхмәт төшсен инде...

Тәһарәт алып, намаз укыйсы вакыт иде дә бит... Аллаһы Тәгалә гафу итсен, никтер бүген хәле җитмәс кебек...

Шулай да караватына торып утырды әле әби.

– Рәхмәт инде, Мәликә. Әниең төсле игелекле булдың миңа, – дип елап җибәрде карчык. – Өйдә берәрсе бармы? Капканы кем ачты сиңа?

– Нишләп өйдә кеше булмасын инде, кызың сине ташлап, беркая да чыкмый. Үзе җитмештән өстә булса да, барысына да өлгерә, әле менә малларын көтүгә куды да сөтен җылытырга куйды, сепаратын җыя... Мин синең янга кереп утырып торыйм, дидем.

Ул да булмады, кече яктан Нәфисәнең тавышы ишетелде: «Мин хәзер, хәзер, әни!»

Озакламый бүлмәгә ап-ак йөзле, чәчләре агара башлаган, зәңгәр күзле олы яшьтәге мөлаем хатын килеп керде. Бер аякка аксаклый үзе.

– Әни, Мәликә, әйдәгез, чәй әзер.

Әбине ике яктан җитәкләп, өстәл янына утырттылар, иңбашына шәл салдылар. Алдына сөтле чәй, Мәликә керткән коймакны куйдылар.

Тәмләп, чәй эчкәч, күрше хатыны әбине тагын сөйләндерә башлады. Олы кеше белән артык сүз куертып булмый, авыл яңалыклары беткәч, Мәликә, нидер исенә төшкәндәй, капыл сорап куйды:

– Фатыйма әби, синең чын исемең Прасковья диләр, ачуланма инде соравыма, син әллә урысмы ул? Әниләр сөйләшкәндә ишетеп калган идем балачакта. Юк, начар итеп түгел, сине гел мактап торалар иде бит...

Әби елмаеп куйды...

– Аның сере юк, минем урыс кызы Прасковья икәнемне барысы да белә иде... Һәрхәлдә, ирем, балаларым белә иде...

Нәфисә Мәликәгә: «Ник сорыйсың инде», – дигәндәй карап куйды. Шулай да аларның әңгәмәсенә комачауламады, аш бүлмәсенә кереп, табак-савыт юа башлады. Үзе әнисенең һәр сүзен йотлыгып тыңлады...

Тормыш йомгагын сүтү бәйләм йомгагын сүтү генә түгел. Әби, уйларының очына чыга алмагандай, өстәл җәймәсенең чәчәген тырнагандай итте, аннары карашы белән бер ноктага кадалып, уйга батты...

Сугыш алдыннан Себер авылларының берсендә яшәгән кызны әнисе Мәскәүдәге туганнарына бала карарга җибәрергә булды. Гаиләгә артык кашык кирәкми иде, Прасковьяның әтисе Захарны агач басып үтергәч, әнисе дүрт бала белән тол калды. Кыздан кече туганнары – барысы да малайлар.

Мәскәүнең үзәгендә диярлек яшәгән Дмитрий Михайлович сәүдәдә эшләүче номенклатур хезмәткәр булып чыкты. Чынлап та, ашау-эчү, кием турында кайгыртасы булмады. Яхшы кеше иде хуҗа, бик гаилә җанлы иде, барысын да өйгә ташыды, хатынын да яхшы киендерде, Прасковьяга да өлеш чыгарды. Дүрт яшьлек баланы карау кыен булмады. Зур фатирда качышлы уйнарга да урын күп, урамда да бик күңелле иде...

Кечкенә Саша белән дәррәү килеп уйнаганда, ялгыш килеп бәрелде ул бу кара күзле, кара чәчле, төз гәүдәле чибәр егеткә.

– Карабрак уйнагыз, – диде егет, рус сүзләрен бик үк дөрес әйтмичә.

– Үзегез карап йөрегез! – дип, кырт кисеп җаваплады аңа кыз.

Миша белән шулай танышып киттеләр. Соңыннан Мишаның Мәҗит исемле татар егете булуын белде Прасковья.

Мәҗит Мәскәүгә метрополитен төзергә килгән икән, үзе генә түгел, әллә ничә егет. Эшләре авыр, шулай да ошый, ахры, аларга башкала.

Миша белән танышлыгын йорт хуҗасыннан яшереп йөрде Прасковья. Ә авырга узгач, өйдә бик каты тавыш чыкты. Баладан котылырга булдылар, кызны үгетләп, ни генә сөйләмәделәр.

Нәкъ шундый көннәрнең берсендә Бөек Ватан сугышы башланды. Мишаны шунда ук фронтка алдылар, ул кызның кесәсенә әниләренең адресын язып салырга гына өлгерде.

Мәскәүдә ул җәй тәмуг төсле булды.

Немецлар менә-менә шәһәргә керә икән дип, паника таратучылар да күп иде. Бомбага тотылудан куркып, барысы да метрога төште. Шунда ашады, шунда яшәде. Дмитрий Михайлович, бронь алып, хатыны, балалары белән ничек тә бу мәхшәрдән котылырга тели иде. Иң яхшы киемнәрен, алтыннарын чемоданга тутырып, августның бер көнендә алар да метрога төште. Һәм шул ук көнне Прасковьяның кызы туды. Мәрхәмәтле бер акушерка очрап, ул ярдәм итте. Ә кыз Мәҗиткә охшаган иде.

Җир астында тормыш дәвам итте. Дөрес, иң яхшы урыннарны монда балалы хатыннарга, ятып торучыларга бирделәр. Калганнарга урын юл өстендәрәк эләкте. Яшь хатын көндез, шәһәрне бомбага тоту сирәгрәк чакта, хуҗаларына барып килеп тукланды, тик аларның да кәефе юк иде, ничек тә Мәскәүдән ераккарак чыгып китү юлын карады алар, эвакуация көтте.

Башта азык-төлекне карточка белән бирәләр иде, ә октябрь башында

кибетләрне баса башладылар, кем нәрсә тели, шуны кереп алды. Урамда теләсә ни сөйләп йөрүчеләр күбәйде.

15 октябрьдә Дмитрий Михайлович Прасковьяга төенчеген әзерләргә кушты. «Менә әйттем бит, бала кирәк идеме сиңа?» – дип төрттереп алды хуҗабикә шунда. «Рөхсәт бар, иртәгә юлга чыгабыз. Безнең машинада әйбер күп була, беркая чыкма, әләгергә тырыш», – дип, кат-кат искәртте хуҗа да.

16 октябрьдә, шофёр чемоданнарны төягәннән соң, хуҗа хатыны, баласы белән уңайлап урнашкач, машинага Прасковьяны да көч-хәл белән сыйдырдылар. Дмитрий Михайлович «ничек тә Рязань шоссесына чыгарга кирәк», – дип, шофёрына тукый-тукый барды, машина артыннан чапкан халыкны таптап-ерып диярлек, алга ыргылды. Ул да булмады, бер төркем халык килеп ябышып, ике чемоданны алып ыргытты, берәү күпмедер вакыт машина артына тотынып барды. Дмитрий Михайлович, яхшы күн перчаткалары белән ул адәмнең кулларын төеп, чак төшереп калдырды...

«Сволочь, безнен акчалар белән качасызмы?» – дип елаган тавышлар ишетелде. Хатыннар кулларына ни эләксә, шуны машинага ыргыттылар.

Прасковья, баласын сакларга тырышып, башын иеп утырды, халыкка карамаска тырышты. Мәскәүне чыккач, шофёр, запас бензинын карап салыйм дисә, аны тартып алып калганнар булып чыкты. Машина таланган, ватык килеш юлда туталып калды. Дмитрий Михайлович яхшы чемоданын алды да, хатынына төенчекләрен биреп, танышларын эзләп йөгерде.

«Син нишләп торасың монда, бар, үз җаеңны кара», – диде Вера Васильевна Прасковьяга һәм бер кулына улын җитәкләп, икенчесенә әйберләрен тотып, ире артыннан атлады.

Нишләргә белми торган яшь ана, имчәк баласын күтәреп, юл буйлап атлап китте. Бераздан юл читенә хәл алырга туктады, төенчегеннән ипи, су алып, тамак ялгады. Баласын имезде. Кечкенә Настясы түземле булып чыкты, еламады, анасын аңлаган кебек йокларга тырышты.

Урман юлы буйлап бара торгач, Прасковья өч-дүрт чакрымдагы авылны шәйләп алды. Кич җитә. Кереп кунарга кирәк булыр...

Авыл дигәне бер егерме-утыз йорттан торгандыр. Кич җиткәнгәме, урамда кеше-кара күренми. Якындагы бер өйдә бала елаган тавыш ишетеп, Прасковья шул өйнең ишеген какты. Караңгыда хатын-кыз тавышы ишетелде. Ике сүз белән аңлашкач, хуҗабикә чыра яндырып, тышка чыкты. Кул баласы тоткан яшь хатынны күргәч, нишлисең инде дигәндәй, өенә чакырды. Өй дигәненең идәне җир. Караңгы. Берни күренми. Чыра яктысында хатынның мич башында йоклаган ике баласы күренде, зурысына алты яшь чамасы булыр. Кечесе нәкъ Прасковьяның сабые сыман, өч айлык булыр, такта сәкедә елап ята. Сөтем бетте, ашаган юк дип, хатын кунакның төенчегенә ишарәләде. Прасковья тиз генә төенчегеннән шикәр, ипи, консерва чыгарып куйды. Шулчак төн көнгә әйләндемени! Караңгыда да хуҗабикәнең йөзе яктырып киткәндәй тоелды. Ул, туйганчы ашап, баласына да ипидән әлбә ясап каптырды... Озак кына сөйләшеп утыргач, хуҗабикә мич артыннан урын күрсәтте. «Шунда ятарсың идәнгә, мин салам түшәрмен», – диде.

Караңгыда мыркылдаган тавыш ишетеп, яшь хатын куркып калды. «Борчылма, дуңгыз ул, өйдә ята, ашарына юк, чыгып китсә, таба алмам

дип керттем, хәзер тотып суячаклар, – диде хуҗабикә. – Менә күрше Коля бабай, тагын берәрсен тапсаң, суеп бирербез дигән иде».

Прасковья курка-курка мич артына кереп ятты. Идәннең суыклыгы ул кадәр сизелми, салам өстенә иске кием дә ташлаганнар, ахры. Мич җылысы да бетмәгән, төн чыгарлык булыр әле. Ә иртәгә... Анда инде Мишаның туган якларына да юллану җае табылыр... Татлы уйларга бирелеп, баласына күкрәген биреп, күзен йомарга гына әзерләнгән иде, йорт хуҗасы Маруся үзенең нәниен китереп тоттырды: «Минекен дә куш инде теге күкрәгеңә,– диде ул, – ач бит».

Караңгыда ят бала да үзенә кирәген тиз табып алды, өзелеп-өзелеп имә башлады. Күпме ятканнардыр, барысы да тынычланып, йокыга киткәнен сизми дә калган Прасковья. Уянып китсә, уң ягында кемнеңдер аның күкрәген ялавын сизде. Капшап караса, кулында бер генә бала. Икенчесе? Йа Хода, нindидер юеш кисәк кенә! Дуңгыз ашаган бит! Акырып, йөрәге кадауга чыдый алмый сикереп торды да хуҗабикә ягына омтылды хатын. Маруся да сикереп торып, чыра яндырды. Аһ, Прасковьяның баласы бөтенләй юк иде инде, төргән искесе генә калган. Таң яктысында Прасковья чәчләрен йолкып елады... Хәзер инде аның башында бер генә уй: иренең туган якларына кайту кирәкме аңа? Бомба астында шартлап үлүе хәерлерәк булмасмы? Шулчак аның иңбашына ипләп кенә Маруся килеп кагылды. «Мә, баламны сиңа бирәм. Минем улым да, кызым да бар, ә син ничек яшәрсең? – диде хатын, Прасковьяга карап. – Минем иргә «похоронка» килде, ятим балаларны ничек карармын?.. Алар ачтан үлмәсә инде... Сакла... Сиңа бирәм». Маруся баланы калдырып, шул арада юк булды...

Туып барган көн яктысында сабыйның йөзен ачып карады яшь хатын. Аһ, нинди матур! Чәчләре – сап-сары, йөзе ап-ак. Тыныч кына йоклый. Төне буе имеп, хәзер рәхәтлек кичерә шул...

Прасковья кинәт кенә урыныннан торып, олы юлга таба китте... Күлмәк кесәсеннән адресын алып кабатлады. Ни булса, шул булыр. Алга, тик алга! Мәҗите кайтыр, алар бәхетле булыр... Барысы да яхшы булыр...

...Әбинең сөйләгәнен тыңлап утырган Мәликә утырган урыныннан сикереп торды: «Ничек, ә Нәфисә? Нәфисә сезнең....» Аннары кыенсынып, әбинең эченә керердәй булып, яңадан тыңларга утырды.

Нәфисә тыныч кына табак-савыт юуын дәвам итте, ашлы суга яңакларыннан эре-эре күз яшьләре тамганын да сизмәде...

Ире язып калдырган Яңавыл станциясенә ничек килеп төшкәнен үзе генә белә Прасковья. Ничәмә поездның товар вагоннарында селкенеп, күп кешеләрнең миһербанлыгы, ярдәме белән килеп җитте ул Уралга.

Биредә тыныч. Әйтерсең, сугыш юк. Шау-шу юк. Мәскәүдәге тарткалаштан соң, сине беркем дә килеп этмәвенә, төртмәвенә хәтта аптырарлык. Прасковья тимер юлда эшләүче апалар янына килде. Араларында аксак ир-ат та күренә, бригадирлары, ахры.

– Здрасьте, – дип дәште ул эшчеләргә, – вы не подскажете, как мне добраться вот до этой деревни?

Хатыннарның берсе йөгереп килеп, балага бакты. Рус кешесе икән.

– А что ты нашла в этой деревне? Поди, сама русская? В такую даль собралась, да еще с маленьким ребёнком, – дип тә өстәде.

Калган хатын-кызлар үз телендә нидер сөйләде, берсе су бирде, икенчесе ипиен бүлеп тоттырды.

Хатыннарның эше беткәнне көтеп торган Прасковьяны Мария базар мәйданына алып китте. Шунда сарык йоны саткан берәү белән сөйләшеп (ул Мәҗитнең авылдашы икән): «Ул сине авылга үзе белән ияртеп алып кайтыр», – диде.

Наҗия (Надя дип дәште аңа Мария), балалы хатынны күргәч, башын чайкап куйды:

– Ой,ой, ой. 12 чакрым җәяүләп үтә алырсың микән бала белән, – дип хәсрәтләнде. Вата-җимерә русча сөйләшкән Наҗиянең әллә ни кәефе юк иде. Көзге сарык йоны да бик үтмәгән, ахры, ярый әле, бер хатын килеп чыгып, киелгән булса да, ару гына күренгән бушлатка алыштырды йонын. «Булды, әйдә, атладык», – диде йон сатучы Прасковьяга.

Бераз баргач, нидер исенә төшкәндәй, кинәт туктап калды. «Тукта, кемгә барасың анда? Безнең авылда мөселман кешеләре генә яши бит», – диде ул Прасковьяга. Ә инде яшь хатынның кемгә баруын белгәч, Мәҗитнең хатыны икәнен дә аңлагач, бөтенләй егылып китә язды.

– Не ходи туда, тебя в этот дом не пустят. Иди, иди обратно, – дип куа ук башлады.

Прасковья елап җибәрде. Баласына күрсәтте. Наҗия бераз уйланып торды да: «Ярар, күз күрер алайса. Тик син шуны белмисең, Мәҗитнең атасы муллалар нәселеннән, дини кеше, ул сине йортка якын да җибәрмәячәк», – диде.

Юньләп берни аңламаган Прасковья Наҗия артыннан баруын гына белде. Бер урында утырып, су эчтеләр, ипи ашадылар. Баланы имезеп, аны Наҗиянең йонга алыштырып алган бушлатына төреп, хатыннар юлын дәвам итте. Көзге суык җелеккә үтә. Баланы юлдашы күтәрешмәсә, әллә кайчан егылып үләр иде Прасковья.

– Ә-ә-ә-нә Мәҗитләрнең йорты, – дип күрсәтте Наҗия. – Тик әлегә ашыкма, әйдә бүгенгә безгә. Мин башта үзем кереп сөйләшермен, син соңыннан, иртәгә керерсең каенатаңнарга...

Юлда мәрхәмәтле кешеләр очрый бит шулай. Наҗиянең чакырылмаган кунак алып кайтуына бик ризалыгы булмагандыр да, шулай да каенанасы, самоварын яңартып, бәрәңгесен алларына куйды, үзе, өстәл янына утырмыйча, белгән догаларын укына-укына, чыбылдык арасыннан гына урыс хатынын күзәтте.

Ире фронтка киткәч, Наҗия каенанасы белән яшәп калды. Зур улларына уникe яшь инде, кул арасына керә, кәҗә белән сарыкка җитәрлек чыбык ташый, ач утырмыйлар. Югыйсә күршедә бөтенләй авыр хәлдәге кешеләр бар. Әнә, Мәхмүт сугышка киткәч, Гайшәсе биш бала белән калды, сыерлары казага тарып үлде. Сөт түгел, катык күрсәләр дә, зур шатлык аларга.

Төнне ничек чыкканын үзе генә белде Прасковья. Ярый әле, кызчыгы тыныч. Үзенең Настясын искә төшереп елап ала да ят баланы күкрәгенә кыса. Ни гаебе бар сабыйның? Тик менә Мәҗитенә ни дияр?

Сугышка киткәндә, Мәҗит туачак баласына исем дә әйтеп калдырды: «Кыз булса, синеңчә Настя булса, минемчә, Нәфисә. Белсәң иде татарча

ничек матур яңгырый: Нә-фи-сә! Изящная! – дип аңлатырга тырышты ул кәләшенә.– Әниләргә язармын, ул-бу булса, шунда очрашырбыз, хуш, бәгърем!» Шушы булды соңгы сүзләре.

...Прасковьяның иртән торуына Нажия өйдә юк иде. Күп тә үтмәде, ашыгып кайтып керде:

«Әйдә, җыен, ни булса да булыр, аңлаттым мин аларга барысын да», – диде ул, ашыктырып. Нажия Прасковьяга барысын да сөйләп тормады. Мәҗитнең әти-әнисе яңалыкны ишетеп, нәүмиз калды. «Безгә Мәҗит ул турыда язмады, йөргән кызым бар, дип кенә хәбәр иткән иде, без аны марҗа дип уйламадык. Хур-рисвай итте инде бөтен авылга, болай булгач. Нишләрбез икән?» – дип елады Кафия апа.

– Шыңшыма, – диде аңа йорт хуҗасы Миңнеяр. – Син ана кеше, син гаепле барысына да. Аңлатырга иде улыңа кем белән танышырга, кемгә өйләнергә икәнен. Имеш, Мәскәү күрсен, кеше булсын! Мин сине, чүпрәк башны, тыңлап ризалык бирдем аның башкалага китүенә!

Бу гаилә элек-электән диндар булып, балаларына да совет белеменә өстәп, дин сабакларын да өйрәтергә тырышты. Догалар ятлап, яшерен үткәрелгән Коръән ашларында Коръән аятьләре тыңлап үсте балалары. Миңнеяр аганы халык яшертен генә мулла дип йөртте, җеназага да, исем кушканда да чакырды. Дин ничек кенә тыелса да, халык үзенекен итте. Ә инде сугыш башлангач, тыюларга бик игътибар итүче дә булмады.

Миңнеяр Сәгыйтовның усал, гадел икәнен бөтен авылдашлары белә иде. Ул әйткән икән – закон. Менә шундый гаиләгә керергә җыена иде Прасковья.

«Төенчегеңне миңа бир, балаңны юньлерәк искегә төр, – дип, Нажия марҗа хатынны килен булып төшәргә әзерләде. – Чәчеңне күрсәтмә, яулыгыңны салма, каенатаң алдында бик күренеп йөрмә», – дип тә өстәде. Прасковья бу сүзләрдән бөтенләй калтырап төште. Капка төбенә килеп җитүгә, килен буласы кеше пөхтә сакаллы ир белән яулыгын алга төшереп бәйләгән хатынны күрде. Өсләрендәге җылы киемнәре әләм-сәләмгә охшамаган, хәлле икәннәре күренеп тора.

– Кабул итеп алыгыз, киленегез шушы була, – диде аларга карап Нажия, һәм Прасковьяны артыннан төртә-төртә, бәләкәй капкага таба этәрде.

– Здравствуйте, – дип, тавышы чыгар-чыкмас дәште яшь хатын.

– И Аллакаем, күрәселәребез бар икән. Марҗа! Сап-сары чәчле марҗа!

Хуҗабикә шулай сөйләнде. Хуҗа кулындагы камчысын биетеп торды. Ул аны ни өчен тоткандыр, Прасковья моны күреп чигенеп үк куйды.

– Кайтсын гына әле сугыштан, күрсәтермен мин аңа Мәскәү марҗаларын! – дип, билгесез якка карап сукранды Миңнеяр.

– Ярар, атасы, өйгә керсен әле, күрше-күлән алдында сөйләшмик, – диде Кафия.

Берни аңламаса да, каенанасының йомшак дәшкәненнән җаны эреп китте киленнең. Ул Нажия артыннан ялт итеп, өйгә узды.

– Әнә, мич артында сәке, шунда ятар, – дип ишарәләде карт, хатынына гына мөрәҗәгать итеп.

Карчык үзенчә сөйләп, Нажия урысча аңлатырга тырышып, сәкегә барып җиттеләр. Баланың биләвен чиштеләр.

– Кем, кызмы, улмы? – диде Кафия, тизрәк нарасыйны күрәсе килеп.

– Дочь! – диде Прасковья. Үзе эчтән генә калтырап китте. Дөресен Мишасына әйтер, әлегә ничек тә үткәреп җибәрергә иде бу танышу гыйлләләрен.

Ул да булмады, каенанасы баланы кулына алды, йөзен ачып карады. «Һай, бер дә безгә охшамаган, суеп каплаган әнисе бит бу», – диде.

Карт, сер бирмичә, читтән генә балага күз салды: «Нигә, минем әниләр ягында барысы да сары чәчле, зәңгәр күзле мишәрләр», – дигән булды.

Беренче танышу киче шулай тәмамланды...

Иртәгәсен бөтен авыл мулла йортына Мәҗитнең Мәскәү марҗасы кайтканын белә иде инде...

Ул да булмады, бригадир килеп җитте. Тупас тавышлы, атка атланып йөрүче Сәкинә озак сөйләшеп тормады. «Нечего тут отдыхать, бездә өч айлык бала белән түгел, ике атнадан соң да эшкә чыгучылар күп, быстро на ферму, завтра же!» – дип акырынып-бакырынып чыгып китте.

Мәскәү марҗасын авыл хатыннары тормышка бик тиз өйрәтте... Прасковья да яшьлеге белән бирешмәде. Себердә яшәгәндә алган чыныгуы белән бөтен эшне дә белеп башкарды. Баласын да карады, өйдә дә тик тормады. Аның бөтен теләге Мишасын көтеп алу иде. Ул кайтса, барысы да үзгәрер төсле иде...

Татарча сөйләшергә өйрәнүе генә кыен булды. Мичкә утынга дип чыкса, пүләнәләр белән сөйләшеп йөри башлады. «Минем балам туачак, хатынымны кабул итегез инде» дип язган хаты Прасковья кайтып, ике ай үткәч кенә килеп иреште.

1942 елга да чыктылар. Авылга похоронкалар ешайды... Мәҗитнең әти-әнисе дә гел догада булып, улларын көтте.

Кичләрнең берендә каенатасы Прасковьяга эндәште: «Син хәзер татарча ару сөйләшәсең, инде догалар өйрән. Без исән чакта сине мөселман итеп күрәсебез килә», – диде. Анысына да ризалашты Прасковья. Бөтен күрше-күләнне таң калдырып, кечкенә булса да догалар укырга өйрәнеп алды.

Тормыш шулай дәвам итте. 1944 елның сентябрендә көтүче Заһитың улы йөгереп керде. «Миңнеяр абый, Кафия апа, Фатыйма җиңги (Прасковьяга шундый исем кушкан иде хуҗа), сөенче, сөенче, соң нишләп берни бирмисез миңа, сөенче дим бит сезгә!» – дип, тупсага егылды.

Карт белән карчык бөгелеп төште, Фатыйма тиз генә үзен кулга алып: «А что такое сөенче?» – дияргә генә өлгерде.

– Мәҗит абый кайтты, Мәҗит абый, – дип, оран салды малай тагын. Кафия малайга йомырка сонды. Үзе иңбашына шәлен дә салып тормыйча, авыл капкасына таба йөгерде.

Прасковья тиз генә чәчен яулыгы астына матурлап кертте, күлмәген рәтләп куйды да Нәфисәсен җитәклəп, каенанасы артыннан атлады. Каенатасы гына өйдә сабыр гына утырып калды...

Юк, бу Прасковья белгән Миша түгел иде... Какча гәүдәле, аксаклап, әкрен генә атлап килүче җитди йөзле яшь ирне күреп, кәләше бермәлгә югалып калгандай булды... Әнисен кочагыннан җибәрмәгән Мәҗиткә карап, бераз тын да алмый торды. Аннары бөтен көче белән иренең күкрәгенә капланып елый башлады. «Миша, Миша, миленький,» – дип русчага күчкәнен сизми дә калды. «Нинди Миша сиңа, Мәҗит ул, – диде анасы улының беләгенә ябышып. – Балам, менә синең кызың Нәфисәң дә монда...»

Өч яшьлек бала чит кеше күтәреп алудан куркып елый башлады, анасына, дәү әнисенә елышты...

– Әтиең бу, әти дип әйт, – диде Фатыйма, теле шактый матур ачылган баласын әтисенә таба этеп... Прасковьяның татарча сөйләшүен ишеткән Мәҗитнең йөзе яктырып китте, ул хатынын тагын да ныграк кысып кочаклады.

– Әти, әти кая соң? – дип шомланып сорап куйды яшь ир.

– Ул өйдә, сине көтә,– дип елмайды Прасковья. Аннары тагы русчага күчте. – А ты знаешь, меня здесь по другому нарекли, я сейчас Фатима...»

Мәҗит рәхәтләнеп көлде: «Фатыйма тек Фатыйма, күрдеңме, нинди яхшы кешеләр минем әти белән әни», – дип елмайды...

Фронтовик кайту белән мунча яктылар. Кечкенә Нәфисә дә әтисенең биштәреннән чыккан шикәрне әләктергәч ачылып китте, тәтелдәп, сүзе бетмәде. Барысының да йөзеннән шатлык китмәде. Өч тапкыр яраланган Мәҗитнең аягы авыртса да, башка яралары йөрәген телсә дә, моңа әллә ни игътибар итүче булмады. Иң мөһиме, ул исән, ул иң якыннары арасында...

Мунча кызу гына иде. Утынны жәлләмәделәр, көне шундый иде.

Иренең тәнендәге һәр ярасы күңелен сызлатты Фатыйманың... Каһәр суккан сугыш әнә нинди әзмәвер егетне бөгеп салган... «Паша, Пашенькам минем», – дип кочакларга азапланган Мәҗитнең йөзенә сыкрану чыкты. Күрәсең, бөтен сөякләре, сеңерләре авырта, сулкылдый иде...

Ирен тәрбияләп, кадерләп, аяк бармакларына кадәр җентекләп юындырды Прасковья. Моны күреп, күңеле әйтеп бетергесез ләззәт тулы ирнең күзләре яшьләнде...

«Паша, мин сиңа дөресен әйтергә тиеш, мин бик зәгыйфь кеше хәзер... Ир кеше булып чутлансам да, иркәк була алмам инде...»

Фатыйма башта югалып калды. Мәҗиткә серен ничек ачарга белми торганда, күр, ул әнә нәрсә сөйли? «Ярый әле кызыбыз бар, миңа докторлар инде балаң булмас, дип кайтардылар...»

Прасковья иренең кап-кара чәчләрен сыйпап, иркәләде, юатты.

– Син минем белән шушы килеш тә торырга ризамы? – дип сорады Мәҗит.

Фатыйма сүзсез генә аны иреннәреннән үпте...

Икенче көнне Миңнеяр ага яшьләргә никах укыды.

Сугыш тәмамланганчы, бригадир булып йөрде Мәҗит. Яраларын тикшерергә туктаусыз военкоматка чакырып тордылар, кем белә, ныклап төзәлеп киткәндер дә сугыштан качып ятадыр... Кайчак мәсхәрәләнгән кебек кайтып керә иде фронтовик ул комиссияләрдән...

Ярый әле, аягы төзәлеп, аксаклыгы ул кадәр сизелми башлады...

Менә, ниһаять, Җиңү килде. Һай, ул көннәр...

...Фатыйма әби үзен тыңлап утырган күршесенә карап: «Киноларда күрәсез бит инде, беләсез, ул көнне кем онытсын», – дип куйды.

Мәликә өендә эшләре барлыгын искә төшерде, Фатыйма әби ятып тору ягын карады: «Ярар, балалар, калганын соңыннан сөйләрмен, хәлем бетеп китте әле...»

Мәликә икенче көнне иртән тагын керде. Чынаякка чәй агызганда: «Фатыйма әби, сугыштан соң ничек яшәдегез соң?» – дип сорап куйды.

«Башкалар ничек яшәсә, шулай яшәдек. Ил күргәнне без дә күрдек. Халык бик әйбәт иде. Ярдәмчел, миһербанлы булды авылдашларым», – диде карчык бер сүз белән.

Чынлап та, авылда Фатыйманы тиз яратып өлгерделәр. Ирен хөрмәтләп, сүз тидермәгәнгәме, олыны – олы, кечене кече итә белгәнгәме, Прасковья үзенә карата берсеннән дә караңгы йөз күрмәде. Шунысы да бик мөһим булгандыр: инде каенатасы белән каенанасы олыгаеп килгәндә, Миңнеяр ага мәҗлесләрдә Фатыймага Коръән ашы бүлеп торуны йөкләтте. «Мөселман булып киткән башка дин кешесе кулыннан аш алып ашау үтә саваплы, туганнар», – дип тә җибәрә иде бабай, килене белән горурланып. Кафия әби Фатыйманы намазга өйрәтте.

Менә шулай итеп, үз исемен дә онытып, Себер кызы татар гаиләсе гадәтләренә күнде.

Дөрес, Красноярск ягындагы туганнарын эзләп табып, алар белән хат язышып торды ул. Ә энесе Сергей вафат булганнан соң, барып та кайтты.

Пөхтә итеп киенгән, мөселманча яулык-шәлен ябынган Прасковьяны шаккатып каршы алдылар ерак Себер авылында. Кызганыч, ул барганчы энесен күмеп өлгергәннәр. Туганнары кара кайгыда, барысы да кара киемдә... Фотосын бер почмакка элеп, анда аракылы стакан, ипи куйганнар. Апалары кайткач, табын кордылар. Өстәл тулы ризык, ит иде. Ерак юлдан булса да, Прасковья чәй генә сорап алды.

Бисмилла әйтеп, ипи капкач, барысы да тын калды...

Энесе рухына догалар багышлап, хәер өләште Прасковья.

Авылда иң хөрмәтле кешеләрнең берсенә әйләнде Фатыйма. Каенатасы белән каенанасы үлгәч, Мәҗит белән аны бер Коръән ашыннан да калдырмадылар, барган җирләрендә өрмәгән җиргә утыртмадылар.

Нәфисәләре шәһәргә китеп, һөнәр алды, тормышын корды. Ике кызлы булды. Мәҗит оныклары дип, җан атты, Нәфисәсенә шатланып туя алмады.

Тик кызганыч, сугыш яралары үзенекен итте. Йорт хуҗасы озак кына авырып, вафат булды. Соңгы минутына кадәр Нәфисәсе яныннан китмәде. Иреннән уңмады ул, балаларын аякка бастыргач, авылга олыгаеп барган әти-әниләре янына кайтты.

Фатыйма карчык кызына серен әтисе үлгәч кенә сөйләде... Нәфисә моны тәкъдире итеп кабул итте. Үзен карап үстергән, бөтен назын-сөюен бүләк иткән әти белән әнисе тик берәү иде аның...

Бу кичне Фатыйма апа Нәфисәне түшәге янына чакырып алды да кулларын тотып утырды. «Сиңа көн дә рәхмәт укыйм. Минем гаебем бардыр синең алда. Әтиеңә дөресен әйтмәдем. Бәхиллегеңне сорыйм», – диде.

Нәфисә, күз яшьләренә бирелеп, әнисен кочаклады, аның чал чәчләреннән сыйпады.

«Әни, ничек, ни хәл яшәдең син бу сереңбелән? Йөрәккәең ничек түзде барысына да... Бәхилмен, рәхмәт сиңа, мең рәхмәт», – дип, әнисенең кытыршы кулларын үпте...

...Бу көнне Фатыйма әби иртәнге чәйгә тормады. Тышта 2013 елның ямьле җәе иде... Тәрәзә каршындагы агачта чут-чут килеп кошлар сайрады, көтү куганнан соң кычкырып исәнләшеп кереп килгән күрше Мәликәнең тавышы ишетелде: «Фатыйма әбекәй, тагын нинди серләрең бар, бүген дә сөйләшик әле...»

Тик әби боларның берсен дә ишетмәде, елмайган килеш ул мәңгелеккә йокыга талган иде...

Кави Нәҗми

Утызынчы еллар – «Социализм өчен бөек көрәш дәвам иткән» чор. 1933-1934 елларда журналны Кави Нәҗми җитәкли.



1937 ел журнал өчен дә авыр чор була… Редакторлар бик еш алышынып тора, ул вакытта тәрҗемә әсәрләр күп басыла. Гомәр Бәшировның «Сиваш» повесте шушы елларда дөнья күргән.

Гомәр Бәширов

Гази Кашшаф

Газиз Иделле

Бөек Ватан сугышы елларында «Совет әдәбияты» журналы чыгудан туктамый. Бу вакытта журналны Гази Кашшаф, Газиз Иделле, Т. Имаметдинов җитәкли.

Гадел Кутуй, Мирхәйдәр Фәйзи, Кави Нәҗми. 1925 ел. Фото М.Фәйзинең тууына 130 ел тулу уңаеннан бирелә.

Бу көннәрдә үзенең 80 яшен билгеләп үтүче язучы Рауль Мир-Хәйдәров. 2012 ел.

2009 елда шагыйрь һәм тәрҗемәче Рөстәм Кутуйга (бу айда аңа 80 яшь тулган булыр иде) Державин исемендәге премияне тапшыру.

Ләбиб Лерон (уңда) Башкортстанның халык шагыйре Марат Кәримов белән. 2010 ел.

Сәхифәне **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

БӘХЕТНЕ ЭЗЛӘП ТАБАЛАР...

Рифат Җамал – шагыйрьнең әдәби тәхәллүсе. Арча вилаятенең бер чигендә урнашкан Мирҗәм авылында, элек колхозчылар дип йөртелгән гаиләдә туып-үсеп, олы тормыш мәктәбен узган, профессор, фән докторы Рифат Җамалетдин улы Корбанов булыр ул. Үзе белән очрашканчы, аның мәкаль-әйтемнәребезгә, хикмәтле дә, гыйбрәтле дә канатлы сүзләребезгә, якын гына түгел, нәкъ шул рухи мирасыбызны хәтерләтеп торган шигъри тәлгәшләре белән көндәлек матбугат аша таныш булсам да, «Күңел сүрәләре» (1996) исемле беренче җыентыгы мине «әйләнеп» узганмы, ничектер акыл шәрифләремдә төпләнеп калмаган. Аның каравы Мәскәүдә «Заман» нәшриятында чыккан «Янсын йөрәк дөрләп», күкрәгенә сугып «Мин – адәм баласы» (2016) дип оран салган, рухына, иҗади юнәлешенә турырак килгән «Өн» (2019) мәҗмугалары язу өстәлемнең түрендә.

Дөресен әйтим, соңгы елларда тормыш барышын, җәмгыять үсешен, рухи дөнья, кичереш тирәнлекләрен иңләү мөмкинлекләре биниһая булган поэма жанрына «каныгуым» шаукымындадыр инде, Р.Җамал иҗатыннан әүвәл җәелеп сөйләп бирерлек әһәмиятле вакыйгалы, олы язмышлы каһарманлы лиро-эпик әсәрләр эзләп «юлга чыксам» да, мөстәкыйль фикерле, тирән хисле, җанга талгын рәхәтлек биреп, чакма ташыннан чичәнлек утын дөрләткән бер-ике-өч-дүрт юллыклары әсир иткәч, аларны нинди максат белән укыганымны да «онытып» җибәргәнмен. Язма шигърриятебезнең юл башыннан дәвамчыларына хәер-фатиха биреп торган Кол Галинең атаклы «Кыйссаи-Йосыф» дастаны да буш урында, тиктомалдан туа алмаган, аның телдән-телгә, буыннан-буынга тапшырыла килгән халык иҗаты энҗеләренә, дөнья, бигрәк тә Көнчыгыш поэзиясе казанышларына таянып күтәрелгән булуы фәндә исбатланган хакыйкать.

Шигърият дигән тылсымлы могҗиза каләм тибрәтүчедән акыл-хис эшчәнлегенә таянып, төрле әзерлектәге укучыны җәлеп итәрлек, сискәндерерлек нәтиҗә ясый белүне таләп итә. «Шигырь – хикмәт, иҗат – сер», дигән күзәтү сөземтәсе буларак туган гыйбарә нәкъ шул хакта. Р.Җамал «шагыйрь һәм шигырь» турында күп яза, аның чыганагы, вазифасы хакында уйланудан тукталмый.

Кемдер шаярта шигырьдә,
Таланты зур, күрәсең.
Миннән булмый. Алар бары –
Күңелнең бер сүрәсе.

Проза, драма, бигрәк тә сәхнәгә менгән әсәрләрнең берничә авторы була алса да, бәгырьдән өзелеп төшкән җан авазы – шигырь бары тик шәхси генә була, чөнки, Р.Җамал язганча, «Шигырьдә алдап булмый шул / Эчендәге-тышында, / Курыксаң әйтер сүзеңнән, / Эчеңнән тик пышылда».

Р.Җамалның кыска күләмле, «үтә күренмәле, ачык чырайлы» парчалары күңелне эретеп, җанга талгын рәхәтлек биреп, зиһенне уятып, гадәти тормыш-яшәешебез турында болай да язып була икән, күбесендә олы әсәргә җитәрлек эчтәлек ята дип, кат-кат укып, хәтта беришесен кабатлап та йөрдем. Чынлыкта, «Кулымда – каләм. / Күңелдә – галәм», «Курыкмыйм бәхетсезлектән, / Куркам бары белгесезлектән», «Елап туып та, / Җырлап китсәң иде», «Акыл – туфрак, белем – ашлама» кебек тирән мәгънәви эчтәлекле, «Гомер буе бәйсез булдым, әйттем уйлаганымны», шикелле «тәкәббер» юлларга тап булып, үзе белән күрешеп-танышканчы, мин ни өчендер аны

озын бәдәнле, кәрзингә туп ташлаучы баскетболист кебегрәк күз алдыма китергән идем дә, ул уртача буйлы, киң җилкәле, гәүдәсеннән, беләкләреннән көч-дәрт бөркелеп торган, парчалары төсле «көләч йөзле», уен-көлкегә, тапкыр сүзгә маһир ир-егет булып чыкты. Шунда шигърият даһилары Пушкин белән Тукай күз алдына килеп бастылар. Аларга җыйнак, килешле буй-сыннары җиргә аяк терәп басып, мәңгелек белән «сөйләшүләренә», рухи дөнья киңлекләренә, кичереш тирәнлекләренә үтеп керүләренә хилафлык итмәгән. Күрәсең, сүз сәнгате җим-илһамны һавадан түгел, ә җир-анабыздан ала торгандыр! Хәтеремне ничек кенә «җилләндереп» карасам да, татар шагыйрьләре мохитендә көрәшчеләргә, спорт буенча чемпионнарга, йөзүчеләргә тап булсам да, «колга буйлысын» исемә төшерә, таба алмадым.

Р.Җамалның шигырьләре, ихласи күңел күчтәнәчләре, бер яктан, тормыш сөземтәсе булулары, икенчедән, кафия, вәзеннәренең, эчке аһәңнәренең төгәллекләре белән, укучыны битараф калдыра алмаслар, дип уйлыйм.

Ашлык кибәксез булмый дигәндәй, Р.Җамал иҗатында, аеруча юллыкларында «сөткә киткән» яисә мәгънәләре ачылып җитмәгән юллар да күңелне «тырнап» үттеләр:

Укытучы,
У-у, тукучы!

Яки

Утыртсаң – бакча була,
Урламасаң – акча була!

Капканы шыр каерып ачып кергән «Кышларны яз көтеп уздырам», бигрәк тә «Адәмдә – бет, Галәмдә – кеше» кебек «тәэсирләнүләре» аның мөмкинлекләреннән түбәнрәк торалар. Әлегә укучыга ирештерелгән иң тулы җыентыгын «Мин – адәм баласы» дип атаган шагыйрь, аны «беткә батыргач», аңа галәмдә Кеше хокуклары бирә аламы?.. Аннан килеп, Адәм белән Кеше берүк затлар яисә синонимнар түгелме? Бәлки, автор укучыны сискәндереп, уятып алу өчен мондый гайре табигый юллар да кирәк, дип уйлый торгандыр? Белмим тагын. Мондый «тәҗрибәләр», әлбәттә, аның «кое казый инә белән», «ташка да кадак кага торган» лирик героеның «йөзенә» кызыллык китермиләр. Чөнки ул – җир кешесе.

Р.Җамал күптәннән билгеле, әдәбиятта яктыртылган мәүзугъларга яңача төсмер биреп, көтелмәгән үзенчәлекләре белән ача да куя.

Дошманың сукканга
Син һәрвакыт әзер.
Дустың чиертсә дә,
Буладыр бик авыр.

Ошбу дүртьюллыктагы халәтне кем генә кичермәгән дә, кайсыбыз гына дошманына каршы тора алып та, дусларының хыянәтен авыр кабул итмәгән! Яисә менә адәм гомеренең мәңгелек белән чагыштырганда, бер мизгел генә булуын, әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән «тынлык» белән бәйләп, күңелгә сеңдереп, искә-ятькә төшергән юллары:

Кеше тынлыктан килә дә,
Тынлыкка китеп бара.
Күкрәп кал, кеше гомере
Тынлыктагы бер ара.

Галәм киңлекләрен хыялында иңләүдә «Мәңге утта» янган, Вакыт – Чиксезлек белән көрәшүнең мәгънәсезлеген аңлаган философ-шагыйрь, үзен азга булса да тынычландырып, юатып куйган нәтиҗәгә килә, ягъни каршылыкта тәңгәллек, эчке гармония эзли.

Олыгайгач бу дөньяда
Сабырлык кирәк.

Табигате, халәте рухиясе белән лирик шагыйрь, эчке кичерешләргә, интим

мөнәсәбәтләргә өстенлек биргәндәй тоелса да, үз халкының баласы буларак, ул сәяси, иҗтимагый мәсьәләләрне дә чит-ят күрми. Дөньяда барган, ил язмышындагы хәл-әхвәлләргә үз карашын, шулай әйтергә яраса, шәхси бәясен белдермичә калмый. Аерым алганда, шагыйрьнең милләтара мәсьәләләргә мөнәсәбәтен гамәлгә ашырганда, үзара аңлашу, гаделлек хөкем сөрер иде кебек. Чөнки:

Башка милләтләрне хурлап,
Милләт булмый зуррак,

– ди ул, өздереп.

Гасырлар дәвамында хәл ителмичә, безнең чорда аеруча куертылган низагның «чишелеше» ике юлга сыйган да куйган. Чыбыркы шартлаткандагы яисә яшен ялтырап алгандагы шикелле генә.

Халкы, аның теле иң авыр сынаулар кичергән көннәрдә шагыйрь мәрткә китеп, дәрвишләр сыман аякларын бөкләп, оеп утыра алмый. Милләт язмышын үз шәхси хәсрәте дип кабул иткән иҗатчы бүгенге борчуларны тарих «тәрәзәсенә» куеп бәяли. Галимнәр том-том фәнни-гыйльми хезмәтләр, монографияләр багышлаган фикер-фаразларны берничә юлга «сыйдыра».

Берсе – болгар, берсе – кыпчак.
Берсе – Алтын Урдадан.
Әллә инде татар дигән
Милләт һич тә булмаган.

Җитмәсә әле татарны «берсе – мишәр, берсе – типтәр, кайсылары керәшеннәргә бүлгәлиләр». Ошбу фикер гасырлар дәвамында татар «җәйләвендә» гомер сөргән башкорт кабиләсе дә «ата-анасын талап», олы милләт булмакчы, дип тә тулыландыруга «өстери».

«Әй, татарым, син кайда соң?» дип, ул телгә алган мишәрең әйтмешли, безгә «берцәк» бердәмлек, бер йодрыкка төйнәлеп бетү җитмәүгә зарланып, югалып калгандай була да, «аңына килеп», хыялына ирек куеп, «мөстәкыйльлек алган» татарның үткәнен һәм киләчәген болайрак күзаллый:

«Чыңгызхан» да «Тимерхан»дыр,
«Хан»ныкыдыр хәмере.
Мөстәкыйльлек алса татар
Булыр аның әмире.

Әмирләрнең кулы каты,
Каты булыр әмере:
«Миңа каршы килгәннәрнең
Булмас хәтта кабере».

Бу кыю, кырыс юлларны, иншалла, бирсен Ходай дип хуплап, ахыр чиктә, адәм баласының, бу очракта татар милләте вәкиленең, хыялларына «канат куярга» булса да, хаккы бардыр дип тә өстисе килә. Р.Җамалның әлеге фаразында якташы да, кумиры да Тукай иҗатында яңгыраган аһәңнәргә якынлыкны сиземләве кыен түгел. Бөек шагыйребез мирасы Р.Җамал өчен фикри таяныч ноктасы һәм шигъри осталыкка өйрәнү мәктәбе, образын кайта-кайта уйлану, соклану чыганагы. Нәкъ шул ноктада Р.Җамалның полемист холкы, укучыны «котырта», бәхәскә тартып керү сәләте ачыла да куя. Ул «башын җуләргә» салып, гади генә күренгән сөален калкытып куя.

Тукай
Тукай булыр идеме икән,
Әгәр булса бай?

Гади уйлану төсендәрәк әйтелсә дә, бу юллар белән һич кенә дә килешәсе килми. Беренчедән, Тукай тәкъдирен үзе сайлап алмаган, язмыш җилләре аны шул хәлгә куйган. Икенчедән, хәзер кем бар җаваплылыкны алып өздереп әйтә ала: әгәренки, Болгар кунакханәсенең бер караваṭ, өстәл белән берничә урындык кына сыярлык бүлмәсендә гонорар тиеннәрен санап утыру урынына гаилә корырлык йорты булып, янында, Рифат кордашның Даниясе шикелле, «Йөрәгемнең парәсе – Син, / Күземнең карасы – Син! / Син – минем бәллүр бәхет, / Син – минем алтын тәхет» дип зурларлык (бәлки, ул алай ук «төчеләнмәс тә» иде) Зәйтүнәсе – җанкисәге янында рухландырып

торса, үзе исән чакта ук, дөнья киңлекләренә чыгар, тагын да тәэсирлерәк әсәрләрен иҗат итәр иде. Байлыкка килгәндә, Дәрдемәндкә алтын базлары гаҗәеп тирән, моңсу, халкыбыз тормышын, рухи дөньясын иңләгән шигырьләрен иҗат итүгә комачауламаганнар дип беләм. Рус шигъриятенең титаны Пушкин, Пётр патшаның яраткан гарәбенең оныгы, кадер-хөрмәттә яшәп, байлыкта йөзсә дә, халкының холкын, рухи дөньясын, гафу итегез, «хәерче» М.Кольцовтан тирәнрәк чагылдырган.

Фикри җегәре, образлар системасы, жанрлык хасиятләре, кичерешнең эзлекле үсеше яссылыгыннан килеп бәяләгәндә, Р.Җамал иҗатының төп өлешен, мәхәббәт, сөю-сәгадәт мәүзугъларында «куенына сыйдырган», лиризм, психологизм, сагыш белән өретелгән күңел лирикасы алып тора. Аның рухи дөньясын, омтылыш-ниятләрен аңлауда «Ярат» шигыре «манифесты» сыманрак кабул ителә.

Шагыйрь үгет-нәсихәт, киңәш биреп кенә калмый, үз шәхесен тирәнрәк ачуга омтылып, укучысы белән ачыктан-ачык диалог «алып бара». С.Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән гыйбарәсен юллама итеп алып, «Мин үзем белән сөйләшәм әле» шигырендә өлкән каләмдәше белән «астыртын төртмәле» бәхәскә керә. 10-9 иҗекле силлабик системабызда язылган, дүрт куплетлы шигыренең һәр яңа юлын «Үзем белән сөйләшәмен әле» җөмләсе белән башлап, «шыпырт кына, тып-тын килешеп», «талгын җылы җил»не күңел тибрәлешләре уртасына алып кереп, әүвәл үзенең холкы «карлы-бозлы» булса да, вакыт, ара, бигрәк тә ялгызлык, сагыш, өмет, ахыр дуслык кебек «хисси-тойгылы» төшенчәләр даирәсендә күңеленең йомшаруын, игелеклерәк була баруын сизә.

Үзем белән сөйләшәмен әле
Шатлыгымда, кыен чагымда...
Бергә күтәрәбез бу тормышның
Карасын да һәм дә агын да.

Адәм баласының барлыгын биләп алган, беребезне дә әйләнеп узмый торган мәхәббәт турында ул алдарак атап узган «Ярат» шигырендә «Үземнең тик бер гозер – Яратмый узма, гомер!» дип, ошбу мәүзугъның иҗат кредосы буларак калкытып куйган иде. Ошбу интим хисләрне сурәтләүдә Р.Җамал белән 70-80 нче еллар шигырьләре белән «яшь» Р.Гаташ кына ярыша ала торгандыр. Әлеге тойгының кавышу-аерылышу, аңлашу-рәнҗешү, тугрылык-хыянәт кебек кайсы чагылышына мисал ихтыяҗы туса да, «мәңге гашыйк» Р.Җамалның мәхәббәт сагасын[1] табарсың. Менә яшьләрнең тәүге очрашуын күргәзмәле сурәтләгән дүртьюллык.

Беренче үбешү,
Ояла-ояла...
Беренче мәхәббәт –
Пыяла – уала.

«Кемдер пышылдый...» шигырендә хисен һаман да «йөгәнли» алмаган зат үзен аклау юлын сайлый.

Сөям әле. Сөюләрем
Яшем белән килешми.
Сөям дә, сөеләм әле –
Мин яшьләрдән киммени?!

«Йөрим әле юләр булып» дип, үзен «чеметеп», кешеләрдән оялган була да «Кирәкми акыллары» дигән кискен карарга килә. «Яшь гашыйк» белән «карт юләр» узган сөенечле дә, көенечле дә «мәхәббәт юлы» «Бар да үтә...», «Кемдер сөйли, кемдер хурлый», «Арабызда юкса...», «Өнемдә дә син» кебек сөю-сөелү сагасын тәшкил иткән шигырьләренең үзәгендә.

«Сагынуларымны белде...» шигыренең үзәгендә гашыйкның хисләрен бүлешмәгән,

[1] Сага – Скандинавия, Ирландия халыклары фольклорында киң таралган, нигездә мәхәббәткә багышланган шигъри риваять

кабул итмәгән өчен «рәнҗү» ятса, «Учаклар сүнә таңда...», «Синең белән бергә чакта...», «Гомер ике килми, диләр» парчаларында үзен аңлау ләззәтен татыган шәхес мәхәббәт бишегендә «тибрәнә».

Төн йокыларын качырган – сагыш, бәхетсез мәхәббәт, ялгызлык моңы шигырьдән-шигырьгә күчеп, яңа нюанслар алып үстерелә.

Әле ярый яратмадың,
Газапларга салдың да...
Кулга каләм алдым да
Синә әйтәсе сүзләрем
Ак кәгазьгә төшердем.

Лирик затның күңеленнән ташып чыккан ихлас хисләр, тәүбә, истигъфар иң түң йөрәкләрдә дә җавап тойгылары уятмый калмаслар, дип фаразлыйм. Хисси сюжетлы «Йөрәк җилкенә» газәлендә яз исе өн белән төшне бутаган гашыйкның йөрәген иләсләндерә, чөнки табигатьнең бу фасылында киек казлар, торналар туган якларына кайталар, сөйгәнен көтүченең күңеле шул манзараны күзаллап, наз белән тула («Тулы наз«). Шулай бер мизгел саташып ятканнан соң гына, ул уянып китеп, аңына килә.

Чү! Уян әле –
Агачлар сары
Казлар да кайтмый,
Китәләр бары.

Хыялый дөньядан «кайткан» шәхеснең канәгатьсезлек хисен җылы, ягымлы дулкын алыштыра.

Аңладым – килә
Күңелем яры!

«Уйлар, уйлар...», «Хыялларың вак булсалар», «Ярага дәва булырмы?», «Ничә гасыр бара бәхәс», «Соңлама», «Син, кызый, уйнама» кебек шигырьләрендә һәм җырларында югарыда искә алып үтелгән әсәрләрендә. Р.Җамал иҗатының төп үзенчәлеге: капма-каршы мәгънәле күренеш-төшенчәләрне янәшә кую, ягъни антитеза ысулы ятканы күренә һәм аның парадоксларга өстенлек бирүе (чын шигърият, минем уемча, шуннан башка була алмый) иҗатының буеннан-буена сузыла. Менә шуларның иң еш кулланылганнары: өн-төш, йоклау-уяну, ярату-яратмау, кап-кара кайгы-ап-ак бәхет, дошманнар ярсыта-якыннар елата, өстәлә кабер-өзелә бәгырь, вакыт-мизгел бәхет-сагыш...

Мәхәббәт нинди генә бөек көчкә ия булмасын, ул дөнья, яшәеш мәшәкатьләреннән качып, тимер коймалар артына яшеренеп «чәчәк ата» алмый дигән фикерне уздыра шагыйрь «Каен һәм Имән» исемле аллегорик тезмәсендә. Мин бу газәлне хәзерге шигъриятебезнең кешеләр фаҗигасен табигать күренешләренә бәйләп сурәтләгән сугышның асылын фаш иткән иң уңышлы тәҗрибәләренең берсе дип саныйм. Бер-берсенә сыенып үскән сылу Каен белән «баһадир» Имән арасындагы «җылы» мөнәсәбәт кыз белән егетнең рухи якынлыгына, мәхәббәтләренә ишарә сыман кабул ителә.

Мәгълүм булганча, Көнчыгыш шигъриятендә Таһир-Зөһрә, Мәҗнүн-Ләйлә, Ширин-Фәрһадларның (Көнбатышның Отеллолары соңрак пәйда булалар) Җир шарына сыймастай ялкынлы мәхәббәтләре фаҗига белән тәмамлана. Бәхетле сөю-сәгадәт нурында, гадәттә, ике кеше генә «коена», ә трагик мәхәббәт бөтен мәдәни дөньяны сискәндерә. «Каен һәм Имән» шигыренең каһарманы, сөйгәне белән саубуллашып та өлгерә алмыйча, сугышка алына һәм вафат була. Шул ук елны Имәнне яшен суга. Табигать белән кеше язмышы арасындагы параллелизм композицион үзәкнең иң тәэсирле алымы буларак үстерелә. Һәр елны кар сулары агып, язлар килгәч, йөрәге өзгәләнүенә түзә алмыйча, кыз аланга килә.

Сөялә ялгыз Каенга,
Каен аның сердәше...

Әллә каен суы тама,
Әллә инде күз яше.
«Каен белән Имән»

Р.Җамал иҗатында табигать күренешләрен турыдан-туры кеше хисләренә, шигъри аһәңгә бәйләп сурәтләнгән шигырьләре күп түгел. Мәгәр табигать фасылларын үзәккә алган парчаларында аның күзәтү һәм чагыштыру, көйләп-сөйләп бирү осталыгы күренә. Менә шундый дүртъюллыгы.

Көзге шигырь – сары яфрак:
Тын гына, талгын гына...
Язгы шигырь – умырзая! –
Бозларны ватып чыга.

Рифат Җамалның мәхәббәт, һәркемнең аңа гына хас шәхси кичерешләрен сурәтләүгә багышланган шигырьләренә игътибарны юнәлтү һич кенә дә иҗатчыны тематик тарлыкта гаепләүгә алып килмәскә тиеш. Кыска күләмле, хисси фабулалы шигырьләрендә ул яшәешнең төрле, күпъяклы, чагылыш-күренешләрен үзәккә ала.

Каләм иясе, бигрәк тә «шагыйрь гомере буена үзен яза», дигән гыйбарә бар. Хәятебез тоташ шатлыктан, сөенечле хәлләрдән генә тормый шул.

Батырмакчы булдылар,
Батмадым.
....
Мин көчле, мин үлмәм
Барыбер җиңелмәм.

Мондый әрнүле юлларның тиктомалдан тумаганын тирәнрәк күзаллау ихтыяҗы аның тормыш юлы белән танышу теләген тудыруы – табигый. Юл уңаенда гына әйтелгән түбәндәге икеюллыгы аның, төрле «баскычлардан» торган биографиясенә «ачкыч» эзләүгә этәрде. «Сагышларны сорап алмыйлар», дигән беренче мисрагны кул чабып хупларга да өлгермисең, «Бәхетне дә эзләп тапмыйлар», дигән икенче юлы аптыраошта калдыра. Кафия, вәзен тәңгәллеге яисә укучысын «котырту» (аның ул гадәте барын күреп үттек) өчен китерелгән дип кабул итеп, үз тормыш юлын күз алдына китерсә генә дә, бу гыйбарәне бусагадан кире кагар иде кебек.

Һәр елганың чишмә башы булган шикелле, һәммәбезнең беренче сулыш алган, туып үскән төбәге бар. Р.Җамалның туган авылына багышланган гаҗәеп ягымлы, күңелләрне эретердәй, «Мирҗәмем – җир яме» исемле, күңелгә ятышлы мәрсиме бар. «Авылымның тузанына чаклы якын миңа элек-электән... / И Мирҗәмем – минем җир яме!» дип соклануын, ихласи мөнәсәбәтен шигъри юлларга чыгара. Кулы һәр эшкә килгән, көч-дәрте ташып торган, җор телле, аралашучан егет әти-әнисе янында каласы да бит, юк шул, «бәхет» дигән йолдыз аны үзе артыннан «ияртеп» китә. Сәбәбе дә табыла. Туган авылында башлангыч мәктәп кенә булу нәтиҗәсендә урта белемне Балтачта ала һәм күңел сиземләве, җан тартуы белән дип уйлыйм, югары уку йортын тәмамлап, ветеринария буенча белгечлек ала. Армия мөддәтен үтәгәннән соң укыта, әүвәл фәннәр кандидаты, алга таба үз белгечлеге буенча доктор, профессор дәрәҗәләрен яулый. Р.Җамалның «бәхет белән булышуы» шуның белән тәмамланган дип уйласагыз, бик нык хаталанасыз. С.Хәкимнең яраткан гыйбарәсе белән әйткәндә, «сез аны просто» белмисез! Хәйләкәр фортуна, неон утларын җемелдәтеп, аңа елмаеп тора төсле. Фән юлыннан уңышлы атлап баруына карамастан, мәктәптә укыганда ук башлаган мавыгуын дәвам итеп, шигырь язудан да туктамый, 1996 елда беренче мәҗмугасы басылып чыгып, уңай бәя алуы аның административ баскычларны космик тизлектә үтүен хуплап, фатиха биреп тора сыман. 1998 елда Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә, шул ук санәдә «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы дәрәҗәгә лаек була һәм профессор Рифат Корбанов Ветеринария академиясенең ректоры итеп сайлана. Бер елдан соң терлекләрне дәвалауның яңа ысулын тәкъдим иткән өчен аңа Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе бирелә.

Милли җанлы институт хуҗасы кайбер фәннәрне, беришे уку-укыту әсбапларын татарча язуны, укытуны, үзе үрнәк күрсәтеп, башкалардан да таләп итә. Бу яңалыклар күпләргә ошамый. Көнчеләрнең кытыклары килеп, кылган игелекләре өчен «рәхмәт»е дә озак көттерми. Аны милләтчелектә, татар галимнәрен үстерү белән артык мавыгып китүдә, үзенә төрле матди ташламалар ясауда гаепләгән хатлар төрле инстанцияләрдә пәйда була. Тырнак астыннан кер эзләп, чебеннән фил ясаган, еш кына фамилиясен куярга «оныткан» язмалар хуплана. Рифат каләмдәшнең андый шикаятьләрне тикшереп, «ачыклык» кертергә килгән «кәмиссияләр» тудырган йокысыз төннәрен күз алдына китерә алам. Без аның белән төрле елларда бер үк сират күперен кичкәнбез икән. Бу илдә иҗтимагый тормыш шуңа җайланган: яла якканнарны тикшерү, эзләү, аларга җәза бирүгә караганда, «гаепсездән гаепле»дән котылу җиңелрәк булып чыга. Тәлинкә тота белмәгән яисә теләмәгән, җитмәсә, буйсынмас холыклы профессор Рифат Корбановны ректорлыктан азат итәләр. Бу чорда аның кичергәннәре, язмыш сынаулары йомшак холыклы кешеләрне кабергә җыеп куйса, Р.Җамал кебек үз көчләренә ышанганнарны чыныктыра. Нахак гаепләүләр, һәртөрле тикшерүләр үз-үзенә, хакыйкатенә ышанган Рифат Җамалетдин улында көрәшчене уяталар. Ул көнләштерерлек үҗәтлек белән хокук кануннарын, юриспруденция фәне нигезләрен өйрәнә. «Корбанов эше» Россия югары мәхкәмәсенә хәтле барып җитә. Ул үзенә ягылган гаепләүләрне кире кагып, аның җитәкчелегендә академиянең алгарыш кичерүен исбатлап, җиңүче булып чыга. Аңа хәтта ректорлык вазифаларына кире кайтуны да тәкъдим итәләр. Ул аннан баш тартып, югары уку йорты белән арасын өзмәсә дә, башы-аягы белән шигърияткә кереп чума, «каләм белән галәм»не иңләп, «ай нурында» җанын тынычландыра. Бу хакта ул ярым шаярып, чынлыкта, үз башыннан узганнарны күздә тотып, болай дип яза.

Зурладылар – күп яздылар
Яхшысын да, яманын да.
Хурладылар – күп яздылар
Дөресен дә, ялганын да.

Ничек кенә сәер тоелмасын: тормыш сынаулары, лаексыз рәнҗетүләр аның шигъриятенә яңа юнәлеш – мотивлар алып киләләр. Шуларның берсе – җаны белән аңы арасындагы эчке тәңгәллекне, гармонияне сиземләү булса, икенчесе – галимлек, фәнни эзләнүләр белән шигъри фикерләү, аң белән хисси дөнья арасындагы якынлыкны, үзара керешүне яңа югарылыкта аңлау. Шул олы төшенчәләр тыштан гади һәм гадәти күренгән аз сүзле, тирән фикерле дүртьюллыкларда ачылалар да куялар.

Күрелгәнчә, ни-нәрсә турында язса да, гражданлык лирикасы да, сөю-сәгадәт, интим хисләрне сурәтләгән шигырьләре дә «мин» исеменнән бара, ягъни автор тормышның бар күренешләренә үз бәясен бирә, дөнья сурәте аның шәхси кабул итүендә күз алдына бастырыла. Аз сүзлелек акыл катламыннан килсә, «мин«ендә холык-фигылен чагылдырган зирәклеге алга чыга. Тормыш барышында нәрсәнедер югалтуда да (мәсәлән, ректорлык мөнбәрен) ул уңай, позитив якны күрә.

Һаман да алга барам...
Кемнәрдер төшеп кала –
Җиңеләя арбам.

Аның иҗатына хас полемик ялкын, бәхәсләшү рухы сүрелми, ә яңа фәлсәфи-этик юнәлеш ала.

Бу чорда кичергәннәре «Безнең киләчәкләр – куе томан», «Ярага дәва булырмы?», «Уйлану«. «Дусларның яңалары» кебек шигырьләрендә мәгълүм эз калдырып, йөрәгеннән чыккан ярсуын «Бездә үлгәннәрне үлеп яраталар», дигән берьюллыгында чагылдырса да, ул төшенкелеккә бирелеп, үпкәсен, үзен яратмаганнарга рәнҗүен шигырь юлларына кертүне түбәнчелек саный. Шул ук вакытта ул яшәү, кешелегеңне саклап калу өчен көрәшнең кыйммәтен дә ачык күзаллый.

Бу дөньяда юктыр бушлай берни –
Тик бәһасе генә төрлерәк.
...
Тып-тын китә даһи... Ә кайчакта
Дөнья яңгырата «буш куык».

Сүз остасының иҗади үсеше тормыш тәҗрибәсенә, хис-кичереш үсешен эчке дисциплинасына буйсындыра белүенә дә бәйле икәнлеге ачык төсмерләнә. «Буш куыклар» Р.Җамалның сурәтле фикерләвендә шигърият дип аталган тылсымның тышында «калдырылалар».

Күргәнебезчә, катлаулы, олы тормыш мәктәбе узган, белемле, күп яктан әзерлекле Р.Җамал күзәтүчән, һәр детальгә игътибарлы булса да, күргән-белгәнне чәчми-түкми, реалистик төгәллек белән кәгазьгә төшерүче дә, тормышны бизәп сурәтләүче дә түгел. Илебез, бигрәк тә Татарстаныбыз яшәешендә дә барысы да ал-гөл, тормыш ямьле, дөнья түгәрәк дип күпертеп сурәтләүче романтик дип тә булмый аны. Тормышны нәкъ булганча кәгазьгә төшерүче натурализмны да шигъриятенә кертмәскә тырыша.

Һәр язучы рухына, иҗади юнәлешенә, өслүбенә якын кумирларын сайлый яисә аны «табып» алалар. «Ак каеннар, акбүз атлар» исемле «Өн» җыентыгына язган керешендә Р.Зәйдулла болай ди: «Дүртъюллык робагыйлар Шәрыктан килгән мирасыбызның бер өлешен тәшкил итә. Дәрдемәнднең халык күңеленә кереп калган кыска шигырьләре дә хәтергә килә. Узган гасырның 70 нче елларында Равил Фәйзуллин да татар укучысын «нюанслар иле«нә сәяхәткә чакырды». Р.Җамал С.Хәким, Ф.Яруллин, М.Әгъләм, үзе белән иңгә-иң терәп иҗат иткән М.Мирза, Р.Мөхәммәтшиннардан «якты нур» алса да, аңа Р. Фәйзуллинның очкынлы да, ялкынлы да тыгыз эчтәлекле кыска шигырьләре аеруча якын һәм таяныч ноктасы. Өлкән каләмдәше иҗатыннан алган «Сагынырсың дип уйласаң да, ялыныр дип уйлама» кебек юлларын мөстәкыйль шигыренә нигез-өлге итеп ала. «Равил Фәйзуллинга ияреп», дип аңлатма бирүне дә оят яисә хурлыкка санамый.

Р.Җамал каләмдәшләрен, тәнкыйтьчеләрне игътибарсызлыкта яисә иҗади казанышларын күрмәмешкә салынуда гаепли алмый. Аның кыска күләмле, югары зәвыклы, яшәешебезнең төрле якларын, кыйбла-кыйтгаларын үзәккә алган шигърияте Г.Бәйрәмова, Х.Ибраһим, Р.Низами, Р.Зәйдулла, З.Мансуров кебек таләпчән, югары дәрәҗәле шагыйрьләр, КФУ профессоры, язучы Ф.Галимуллиннарның күңелендә илһам нуры кабызып, җыентыкларына юллама язуга, иҗатына бәя бирүгә кулларына «Каурый каләм» тоттыра. Беришесен ректорлыгы (дөнья хәлен белеп булмый) үзенә тарткандыр дияр идең, мәкаләләрнең барысы да диярлек аны инде югары дәрәҗәдән «коткаргач» язылганнар. Димәк, хикмәт бары тик шигъриятенең сыйфатында гына. Әйтик, Р.Зәйдулла мәкаләсен «Шигырь кешедә өмет уятырга тиеш», дип башлап җибәрсә, З.Мансуров мәкаләсен Р.Җамал «галимлектә дә, шагыйрьлектә дә яңадан-яңа казанышларга ирешсен», кебек теләк белән тәмамлый. Ф.Галимуллин «Шагыйрь җаны» мәкаләсендә «Р.Җамал шигырьләре йөрәктән сыгылып чыккан хисләр ташкынын хәтерләтә», дип өсти.

Хакыйкый, агымдагы сүз сәнгатебезнең «кыскалыкта – осталык» таләбен үтәү юлында, меңьеллык поэзиябезнең тотрыклы ачышларына таянып, үз өслүбен, үз юлын тапкан «Рифат Җамал» тәхәллүсле шагыйре бар дигән идек. Ул бай һәм тыгыз эчтәлекле бер-ике-өч-дүрт юллыкларында афористик фикерләүнең чикләнмәгән мөмкинлекләрен ачып, хисси сюжетлы әсәрләрендә кеше кичерешләренең тирән серләренә үтеп кереп, үзен тел тылсымын тоемлап иҗат итүче хәрәкәттәге лирик-моңсу җанлы шәхес итеп танытты. Аңа илһам нуры халкыбызның олы рухыннан, самимилек туган җиреннән килә, дип уйлыйм.

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,
филология фәннәре докторы

«ЧҮП БАЗАРЫ»НДА ЯҢГЫРАГАН ШАГЫЙРЬ ТАВЫШЫНДА НИНДИ АҺӘҢНӘР ИШЕТЕЛӘ?..

Флёра Гыйззәтуллинаның «Казан утлары» журналының быелгы сентябрь санында басылган «Коллык зинданы» поэмасы игътибарны җәлеп итте. Моңа кадәр аның иҗатын аерып өйрәнгәнем юк иде, шулай да моннан күпмедер еллар элек шагыйрәнең җыр лирикасына кагылышлы туган фикерләрем хәтергә килде. Җырчы Габделфәт Сафин репертуарында Флёра Гыйззәтуллина сүзләренә иҗат ителгән «Кайтам илкәемә» дигән җыр бар. Анда ул язмыш җилләре белән иксез-чиксез илебезнең төрле почмакларына сибелгән татарларның хис-кичерешләрен тасвирлап бирә. Текст структурасында «сибелгән татар» белән Идел елгасы аша гәүдәләнгән туган җир образлары мөһим урын били. Автор чит җирләрдә каңгырап йөрергә мәҗбүр булган татар кешесенең кичерешләрен – туган илен сагынуын, туган җиренә кайту шатлыгын һәм шул ук вакытта шомлануын да психологик яктан ышандырырлык итеп җиткерергә омтыла. «Кайтам илкәемә» шигыренең героена туган җире – Идел аны акчарлаклары белән каршы алыр кебек тоела. Төп фикер җырның кушымтасында әйтелә – автор туган илгә кайтырга кирәк дигән идеяне җиткерә. Бу җыр озак вакытлар туган җирләреннән аерылып торганнан соң, янә әйләнеп кайтырга карар кылган меңнәрчә татар кешесенең хисләрен белдерә. Бу Ф.Табеевның юмарт кулыннан комсомол юлламалары алып, СССРдагы гигант төзелешләргә җибәрелгән яшьләргә язылган язмышларның соңгы аккордлары.

Ф.Гыйззәтуллинаның берничә җыры минем яраткан композиторым Луиза Батыр-Болгари белән берлектә иҗат ителгән. Алар арасында Г.Тукайның туган ягына шигъри дан җырлаган җырлар аерым урынны били. «Син, изге Кырлаем» җырында шагыйрә татар шагыйренең берничә буын өчен илһам чыганагы, даһига баш ию урыны булып әверелгән туган ягын сакральләштерә («халыкның сафлыгы үзәге»; «Иң мөкатдәс шигъри хиснең, Кырлай, / тамырлары синдә»). Җыр Г.Тукайның туган ягын барып күрергә өнди, анда кылынган сәфәр шагыйрь күңелендә хаҗ белән ассоциацияләшә. Халык шагыйренең образы туган ягының табигате белән тыгыз бәйләнгән, шагыйрь өчен ул илһам чыганагы булган. Тукайның бишеге Кушлавыч авылына багышланган «Кушлавыч каеннары» җыры да күңелгә үтеп керде. Ф.Гыйззәтуллина анда шагыйрьнең халык язмышы белән үрелгән ятим язмышы турында уйлана. Образлар системасында фольклордан алынган чуклы каен, кушкаен образлары мөһим роль уйный. Җыр халык язмышында үзгәрешләр көтү, авырлыклар һәм кайгы-сагышлардан арынуга өмет белән сугарылган. Җыр авторы игътибарны Г.Тукайның гади кешеләрнең күңел түрендәге бөтен өмет-ышанычларын әйтеп бирә алган халыкчан шигъриятенә җәлеп иттерә.

Гөлзадә Сафиуллина репертуарыннан «Арча гимны» – иң яраткан җырларымның берсе. Шушы җырлар аша күз алдына олы тормыш тәҗрибәсе туплаган шагыйрь образы килеп баса. Туган ягыннан читтә яшәргә мәҗбүр булуы аны туган җиренең гүзәллеген тоемларга өйрәтә. Ф.Гыйззәтуллина шигырьләрендә фольклорның шигъри ачышлары белән табигый рәвештә үрелеп киткән татар әдәбиятының иң күркәм традицияләре тере килеш саклана. Шигъри юллар афоризмнарга хас булганча, мәгънә тыгызлыгы һәм кыскалыгы белән сокландыра, укучыны уйланырга этәрә. Ф.Гыйззәтуллина тудырган образлар, ул образларга салынган фикерләр тәсбих төймәләре кебек бер-бер артлы тезелеп, күңелдә кайтаваз булып яңгырый.

Аның тормышка аек, ачык карашы сокландыра, бу бигрәк тә аның «Чынлык» шигырендәге «чынлык» – «чиксезлек» оппозициясендә аерымачык чагылыш таба. Ф.Гыйззәтуллина шигъриятенә тарихилык хас: «Җир буйлата ничә тарих гиздем / Ил тарихын сөйләр өчен мин». Бу сыйфат «Күзәтәбез тарих мизгелләрен», «Милләт юлыннан

барам», «Биш гасыр яткан явызлык»[1] һ.б. шигырьләренә дә хас. Нинди генә чор – үткән заман турында язса да, бүгенге заманны язса да, теләсә кайсы шагыйрьгә кирәк булган тарихи хис Ф.Гыйззәтуллина лирикасында бик табигый яши; шигырьдә тарихилык булсын өчен аңа теге яки бу фактларга махсус мөрәҗәгать итәргә кирәкми, ә нибары балачагындагы табигать күренешләрен искә төшерү, ак каенга, елга ярларына кагучы дулкынга, туган якларына оя корырга ашыгучы кыр казларына бер күз төшерү дә җитә. Шагыйрьнең уй-фикерләре туган ягындагы вакыйгаларны табигый рәвештә бер җепкә тезә, ул вакыйгаларның үткәндә яки бүгенге көннәрдә булуы әллә ни әһәмиятле роль уйнамый.

Ф.Гыйззәтуллина лирикасына хас булган тарих хисе аның заманны үтә дә нечкә тоюыннан аерылгысыз. Ул бүгенге көндә яши, бүгенге көн турында кайгырта, шуның өчен дә аның үткәннәргә мөрәҗәгать итүе ныклы терәк, нигез эзләү булып аңлашыла.

Шагыйрә һәрвакытта да үзенең замандашларына карата таләпчән. Шигырьләренең берсендә Ф.Гыйззәтуллина аларның рухи офыкларын билгеләп, болай дип белдерә: «Илгә тиңдәш биеклектән килү / Тиештер бит инде бездән дә» («Тарих юнәлеше»)[2].

Аның илһам чыганагы – тормыш үзе, ә аның үлчәме – «сугыш чоры балалары» буыныннан булган шагыйрьнең үз язмышы («Сатин чуклар»[3]). Ф.Гыйззәтуллинаның тирә-юньгә мөнәсәбәтенең драматик ягы аның лирикасының музыкальлегендә, аһәңнәрендә, рухи борылышларында чагыла. Аның күңелендә ятимлек ачысы, тулы бер илнең төзәлмәс ялалары әрни. Ф.Гыйззәтуллина сугышта катнашмаса да, тирән яралар алган буынның җанындагы, язмышындагы фаҗигалелекне күрсәтә алган («Себер юлы – сөрген юлы», «Дүрт кыз», «Тормыш кораблары»).

Ф.Гыйззәтуллинаның шигърияте – туган җиргә мәңгелек табыну ул:

Ихтимал, без җирдән китәр идек, / Җир кадерен белми яшәсәк!.. / «Туган җир!» – дип без өзелгән саен, / Җиргә башын ия гөлчәчәк. («Ил өчен»)

Шагыйрә тормышны мәңгелек яну белән чагыштыра, аның ялкыны һәр кешенең күңелендә була торган уттан тора: *«ярый әле җир йөзендә... гомерләр бар утка капларга».*

Ф.Гыйззәтуллинаның шигырьләре купшылыктан азат, ул иҗатының буеннан-буена үзенең тормыш позициясенә тугрылык саклый:

Бераүләр мактаудан илерә-илерә, / Орденга, медальгә үрелә. / Миңа да бу дөнья бик матур күренә, – / Юлыксам бер шигъри бөрегә...

«Җидегән яшем җиз кыңгырау кага» шигырендә Ф.Гыйззәтуллина, узган гомеренә бәя биреп, үзенең иҗаттагы омтылышларының мәгънәсен болай дип билгели:

Ә мин төпкә, тирәнгәрәк очам, / Милләтемнең йөрәгенә таба... / «Хисләреңә ал, – дип, – шуннан тәхет!» – / Җидегән яшем җиз кыңгырау кага.

Тукай традицияләренә тугры калып, Ф.Гыйззәтуллина гомерен милләт язмышыннан аерып карамый: *«Минем вөҗдан – милләт вөҗданы ул!»* («Хаклык»). Мөстәкыйльлек идеяләре белән канатланып, ул үзенең халкын азат һәм бәйсез итеп күрү турында хыяллана («Татарга мин чордан хөрлек сорыйм»). Татар халкының язмышы турында уйланганда, шагыйрә аны романтик идеаллаштыру юлына басмый, аның шигыре арзанлы мелодраматик ноталардан азат, карашы ачык, бәһасе төгәл: «аптыраулы, таркау милләт» («Гасырлардан иңгән сагыш»).

Ф.Гыйззәтуллина шигырьләре татар халкы мәдәниятенең иҗади офыкларын яшендәй телеп үтә, алар безнең һәркайсыбызга аерым-аерым эндәшә:

Чын дуслык йөзеннән/Мин сезгә маяклар кабыздым. / Мин сезне яраттым... / ...Ышанам: хәлемне / Хәзер дә аңларсыз – / Ярата белсәгез, әгәр, Сез! («Яшенгә әйтмәгез авыр сүз»).

Ф.Гыйззәтуллина талантының үзәге, аның иҗади булмышының асылы һәм формасы булып халыкчанлык тора. Аны укыганда, без хәзерге заман кешесенең тавышын ишетәбез. Аның фәлсәфи шигырьләре, шулай ук аларны шартлы рәвештә тарихи-фәлсәфи дип тә атап була, табигый һәм сыгылмалы килеп чыга, аларда авторның

[1] Гыйззәтуллина Ф. Күз нурларым: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 43-44 б.
[2] Гыйззәтуллина Ф. Сер ачкычым сердәштә: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 5 б.
[3] Гыйззәтуллина Ф. Яшеннәрнең күз яше: поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 6-8 б.

хис-кичерешләренең, фикерләренең һәр борылышы җиңел укыла, аны аңлау өчен махсус фәлсәфи һәм сәяси сүзлекләр белән коралланырга кирәк түгел. Көчәнмичә генә, Ф.Гыйззәтуллина үзенең шигъри сүзендә Г.Тукайның лирик эчкерсезлеген һәм Дәрдемәнднең югары медитатив корылышын берләштерә алган; ул үзенең шигырендә М.Җәлилнең милли-патриотик мотивларын һәм Һ.Такташ васыять итеп калдырган ораторларча публицистик аһәңнәрне эчке бер казанышы итеп эреткән. Шагыйрә үзенең бу җиргә килү максатын туган халкы алдындагы гражданлык бурычларын үтәүдә күрә: *«Гомерләр җитәрме... Туләргә телсезлек бурычын»* («Гомерләр җитәрме?!»)[4]

Татар язучыларының күптән инде укучыларын гражданлык позицияләре ачык белдерелгән иҗат җимешләре белән сөендергәннәре юк иде. Татар дөньясының мәдәни киңлеге, кызганычка каршы, бүген, Бразилия сериалларына охшатып, арзанлы мелодраматик тарихлар белән күбек очырта, сафсата һәм икейөзлелектән тончыга, ә инде нindидер масштаблы тарихи темаларга алыну омтылышлары «сары тарихлар»ны алып кагу, бөекләрнең язмышларыннан «эчке киемнәрен», «шкафларыннан сөякләрен» эзләүгә кайтып кала. Сирәк булса да, татар дөньясын селкетеп алырдай, чын татар әдәбиятының исәнлеге турында искә төшерердәй әсәрләр барлыкка килеп тора.

Ф.Гыйззәтуллинаның «Коллык зинданы» поэмасы – вакыт һәм үзебез турында уйлану ул. Татар дөньясын тутык кебек эчтән ашый торган коллык психологиясенең сәбәпләре турында уйланырга чакырган поэма иҗат итүе өчен шагыйрәгә баш иеп, рәхмәт әйтәм. Шагыйрь безне вакыт һәм үзебез турында, халкыбызның үткәне һәм киләчәге турында җитди сөйләшүгә чакыра.

«Коллык зинданы» биш өлештән тора. Поэманың исеме Платон шәрехләвендәге Сократның фәлсәфи постулатын искә төшерә. Билгеле булганча, әлеге постулат тән рәхәте турында уйлаганчы, җан турында күбрәк кайгыртырга чакыра. Тән – җанның зинданы ул. Кеше – тәненең колы. Россия – халыклар төрмәсе... Журналның эчтәлегендә 5 өлештән торган поэманың исемен укуга, башымнан шундый ассоциацияләр узды.

«Минем янәшәмнән атлый Тукай» дип аталган өлеш кереш ролен уйный. Татар әдәбиятының күпгасырлар дәвамында формалашкан традициясе кысаларында Ф.Гыйззәтуллина укучыларын үзенең шигъри кредосы белән таныштыра. Мондый әдәби традиция Кол Галиләрнең шигъри чишмәсеннән үк башлангыч ала. Ф.Гыйззәтуллина өчен Габдулла Тукай гражданлык позициясе, милләтпәрвәрлек һәм шигъри талант үлчәме булып тора. Шагыйрә дәвердән зарланмый. Ул укучысын хәзерге заман шигъриятен, татарларның рухи тормышын бәяләр өчен, үзебезне шомартубизәүләрдән башка гына күрер өчен Тукай көзгесенә карарга чакыра.

Беренче юлларыннан ук шагыйрә череп барган цивилизация, кешелек дөньясын «кыргый көтү»гә әйләндергән заман образы белән укучысының һушын ала. Хәзерге заман кешелек дөньясын сурәтләгән юллар үзенең образлылыгы һәм тыгызлыгы белән җәлеп итә: *«сукыр күзле, сынык кабыргалы... – / Кайда ышык күрсә – шунда туктап, / Тугарыла чегән таборлары».* Дөньяның киңлеге, иркенлеге турында сөйли-сөйли, тар дөньяда яшәүче адәм баласының конформизмга һәвәс рухы шундый. Шагыйрьлек миссиясе турында уйланып, Ф.Гыйззәтуллина үзе яшәгән заманга гына түгел, үзенә дә хөкем чыгара: «Хак алдында кан косудан куркып, / Мин дә авызымны ачмадым».

Шагыйрь һәм шигърият темасын дәвам иттереп, поэма авторы иҗат итү өчен илһам чыганагы, ватанпәрвәрлек проблемалары турында уйлана. Ф.Гыйззәтуллина үзенең татар шигъриятенә керткән өлешен барлап чыга һәм аның карашы үзенең «Арча гимны» шигырендә туктала. Бу шигырендә автор Казан артының мәдәни пространствосын киңәйтеп, Тукайның даһилыгы һәм М.Мәһдиевнең таланты буш урында гына барлыкка килмәгән, бу җир татар халкының Курсави, Мәрҗани кебек бөек уллары вакытыннан ук ватанпәрвәрлек идеаллары белән дан тота дип раслаган

[4] Гыйззәтуллина Ф. Башкаемда дөнья исәпләре: шигырьләр, поэмалар, балладалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 7 б.

иде. Аларның реформаторлык эшчәнлеге алып баручылар дигән даннары бөтен дөньяга таралган. Бохарада үлем җәзасына хөкем ителгән Курсави ниятләреннән ваз кичми: татар мөселман дөньясына реформалар кертүен дәвам иттерә. Мәрҗанинең бөеклегенә совет цензурасы да куләгә төшерә алмый. Кормаш-Җәлил яшерен төркеменең батырлыгы турында бөтен дөнья сөйли.

Шул рәвешле, Ф.Гыйззәтуллина Казан ханлыгының батырлар үткән юлының бүгенге көндә сукмакка гына әйләнеп калуына әрнүен белдерә, кайчандыр үз дәүләтчелеге булган татарларның яшәү рәвешен без күтәрә алырлык дәрәҗәдә түгел дип борчыла.

Татарларның коллык психологиясенең масштаблары турында фикер йөртеп, Ф.Гыйззәтуллина колониаль травма кысаларын җимерергә, һәркемнең йөрәгенә үтеп керергә, шуның аша алга бару юлына басарга кирәк, ди. Поэмада Аккош күле образы хәзерге заман шагыйрьләренең иҗаты белән ассоциацияләр тудырып, тулы канлы шигъри символ дәрәҗәсенә кадәр үстерелә. Ул шагыйрьләр туган җиребезнең гүзәллегенә дан җырласа да, үзләренең җырлары белән дәүләтчелеген югалткан татарларның күңел яраларын дәвалый алмый. Бу бүлектә «эт – кол» антитезасы аның структурасын кора, ә инде җиңүче белән җиңелүчеләр каршылыгы ахырзаман билгеләренә ия.

Поэманың «Тарих аһы» дип исемләнгән өченче бүлегендә Ф.Гыйззәтуллина тарихи хәтер җуелу мәсьәләсен күтәрә. Хәтер җуелу – шулай ук, татар мохитендә коллык психологиясенең тамыр җәюенең нәтиҗәсе. Шагыйрә татар мохитендәге шигъри фикернең, иҗади чишмәнең саегуын билгели. Әлеге фаҗигале процессның тамырлары, Ф.Гыйззәтуллина фикеренчә, татар дөньясын тотып торган рухи баганаларның какшавына барып тоташа: Г.Тукайның даһилыгына соклану һәм аның алдында баш июнең ихласлыгы бетә, Бөек Ватан сугышы каһарманнары турындагы хәтер онытыла бара.

Ф.Гыйззәтуллина табигатьнең тереклек энергиясен адәм баласының җимергеч көченә каршы куя. Шагыйрә табигатьнең көн саен бер канун белән яшәвен тыгыз фәлсәфи образ аша тасвирлап бирә: кешелек явызлык һәм рухсызлык баткаклыгына бата барганда, табигать көн саен кояш чыгу белән яктылыкның караңгылыкны җиңүен күрсәтә. Корбанга киткән аккош каны – Шигърият, Ф.Гыйззәтуллина фикеренчә, татар халкының ярасын төзәтер көчкә ия түгел, ул, киресенчә, торган саен зураеп, хәтерсезлек чоңгылына әверелү куркынычы белән яный.

Дүртенче бүлектә шагыйрә татарларны күрәкараганнары, дөреслекнең күзенә карарга теләмичә, буш иллюзияләр белән үзләрен юатып яшәгәннәре өчен гаепли: олы бер халыктан ил буйлап җил куып йөртә торган дүңгәләккә әйләнү ихтималлыгын кисәтә.

Поэманың бишенче бүлегендә Ф.Гыйззәтуллина чаң кага. Аны татар әдәбиятының киләчәге, шигъри эстафетаны кемнәр кабул итеп алуы, Шигъри Җиһанның кемнәр кулына калуы борчый. Шагыйрь буларак, ул хәзерге заман мәдәниятенең саегуын күреп, өметсезлеккә бирелә, рухи төшенкелек кичерә. Аның өчен татар шигъриятенең символик гәүдәләнеше, татар шагыйрьләрен үзенә тартып торган үзәк – Аккош күле. Менә шушы шигъриятнең гүзәллеген мирас итеп калдырыр, Ил өчен җаваплылык алып калыр буынның булмавы турындагы уйдан да аның күңеле әрни.

Минемчә, «Коллык зинданы» поэмасы безнең заманның йөзен билгели торган әсәрләрнең берсе булып танылачак. Ф.Гыйззәтуллинаның шигъри җыентыкларына тупланган («Чишмә юлы» (1974), «Сәлам хаты» (1981), «Акчарлагым – асыл кошым», (1983), «Утлы минутлар» (1986), «Сер ачкычым сердәштә» (1990), «Яшеннәрнең күз яше» (1995), «Йөрәгемдә шаулый карурман» (2001), «Күз нурларым» (2002), «Башкаемда дөнья исәпләре» (2007), «Яну дәверләрендә» (2013)) чиста, саф шигъри чишмәсенә һәркем кагылсын иде. Аның иҗат дөньясының карурманында йөргәндә, үзегез өчен бик күп ачышлар ясарсыз һәм аның ялкынлы йөрәгенең кайнарлыгын тоярсыз!

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,
әдәбият белгече

ӨЗЕЛГӘН КЫЛЛАР МОҢЫ

Гөл Мирһади – бүгенге көндә үзен Башкортстанның татар әдәби барышында оста прозаик итеп таныткан язучыларның берсе. Тумышы белән каһарман шәхес Батыршаны биргән Балтач районыннан. Гөлнара Зиннәтнур кызы Шәймөхәммәтова (Гөл Мирһади) Түбән Карыш авылында 1971 елның 23 апрелендә дөньяга килгән. Башкорт дәүләт педагогия институтын тәмамлап, мәктәптә башлангыч сыйныфлар укытучысы, районда мәдәният бүлеге җитәкчесе, балалар йортында патронат тәрбиячесе, газетада хәбәрче булып эшли. Хәзер дә мәдәният, журналистика өлкәсендә бердәй хезмәт итүче Гөл Мирһади дүрт балага гомер бүләк итеп, язмыш кыерсыткан тагын тугыз баланы үз канаты астына алып, гаилә мәшәкатьләре белән генә түгел, иҗат итеп тә яши.

Гөл Мирһади – балалар һәм өлкәннәр өчен шигырь китаплары, сатира-юмор һәм проза әсәрләре авторы[1], Башкортстан Республикасының мәгариф отличнигы, Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Аның каләменең сәнгати көче гадәти булып тоелган тормыш күренешләрен киеренке ноктага җиткерә белүдә, кеше күңелен актарып салырлык кичерешләр дулкынын, күңелнең җиде кылына салынган моң палитрасын тудыра алудадыр. Яшәеш кануннарына, тормыш асылына, язмышка, тирә-яктагыларга үпкә, рәнҗеш, нәфрәт, шуның нәтиҗәсе буларак курку, чарасызлык кебек кичерешләр өермәсе вакыты-вакыты белән рәхмәтле булу, бәхеткә тиенгән мизгелләрнең рәхәтен тою хисләре белән алышына. Шуңа да язучының повесть-хикәяләрендәге геройлар язмышы төрледән-төрле, хыялда тергезелгән тормышның чынбарлыкта күтелмәгәнчә оешуы, яшәеш кануннарының һәрвакытта да бертөрле булмавы конфликтның асылын тәшкил итә. Гөл Мирһади геройлары тормыш кыенлыкларын, язмыш мәрхәмәтсезлеген, гадәттә, ялгыз үтәләр. Күпчелек геройлар тормышны катлаулы-газаплы ситуацияләр җыелмасы буларак кабул итеп, дөньяны яхшы якка үзгәртү, башкаларга да файда китерерлек итеп оештыру теләге белән яна.

Бу уңайдан «Лаеклы ял» хикәясенә тукталу урынлы булыр. Үзәк дәваханәдә баш бухгалтер булып эшләгән, хезмәтен җиренә җиткереп башкарган Мөнирә Бариевнаны, дәрәҗәле кешенең хатынына эш урыны кирәккәнгә, пенсия яшенә җитү белән эшеннән азат итәләр. Әмма ул югалып, төшенкелеккә бирелеп кала торганнардан түгел. Кечкенә бакчасында хәләл көче белән яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәкләр үстерә башлый, аларны сатуга чыгара. Көннәрен сериаллар карап үткәргән, чир-сырхауларын барлап, мәгънәсез әңгәмәләр корган ахирәтләреннән аермалы буларак, ул үзе өчен дә, башкалар өчен файдалы эшкә алына. Көнне-төнне ял белми эшләгән Мөнирә Бариевна өчен лаеклы ял үзе өчен яши башлау, тормышның матурлыгын тою чоры дигән якты ышаныч барлыкка килә. Геройның характер ныклыгы, үҗәтлеге аны ялгызлыктан, тормышның мәгънәсезлегеннән коткара.

«Ике әби» хикәясен автор үзенчәлекле сюжет сызыгына кора: сөйләүче герой бер-бер артлы ике өйгә, бер-берсеннән холык һәм фигыльләре белән шактый аерылып торган авылдашлары Вәкыйфә һәм Рабига әби рухына хәер салырга бара. Контрастлык йорт-кура тирәсеннән башлап, кешеләрнең үз-үзләрен тотышларында, аралашу-сөйләшүләрендә дә ачык чагыла. Эш белән абзар арасында көнен үткәргән, уңган, булдыклы, әмма үз көенә генә яшәгән, балаларына кычкырып, бер сүз дә дәшмәгән,

[1] Мирһади Г. Алмалы үләннәрем. Шигырьләр, җырлар. – Уфа: Китап, 2006. – 112 б.; Мирһади Г. Адашкан сер. Повестьлар. – Уфа: Китап, 2014. – 208 б.; Мирһади Г. Уйларым-сөйләннәрем. – Казан: Ак бүре, 2018.- 191 б.; Мирһади Г. Өйрән хуҗа булырга! Балалар өчен шигырьләр. – Уфа: Китап, 2019. – 80 б.

аларны тәрбияләүгә вакыт булмаган Вәкыйфә әбинең өендә түбәтәйсез авыл мулласы, өстәлгә тәртипсез сибелгән хәерләр, кызларының мәет өстендә кычкырып елаулары, белер-белмәс рәвештә кәфенлек тегү... Вәкыйфә әбинең соңгы айлары да шактый аянычлы итеп телгә алына: чирле әниләреннән туеп, улы Сәлим белән килене аны мал аранына ябып тоталар.

Чама белән сабыр, кирәк чакта усал да була белгән Рабига әби өендә бөтенләй башка күренеш: хушлашырга килгән һәр кеше олы кайгыда, бертуктамый дога укыйлар, мәрхүмәне яхшы яктан гына искә алган сүзләр ишетелә, бар җирдә тәртип, пөхтәлек.

Менә шулай, язучы мәрхүмнәрне өйләрендә «кич кундыру»ны тормышчан детальләрдә ача, мөселманча җеназаның үтәлү-үтәлмәвен ачык күрсәтеп, әсәрнең укучыга тәэсир итү көчен бермә-бер арттыра. Әсәрдә тормыш мәгънәсе, яшәү һәм үлем хакындагы фәлсәфи уйланулар бергә үрелеп бирелә.

Үлем вакыйгасына бәйле фәлсәфә аның белән генә төгәлләнми әле. Тормышның дәвам итүен күрсәтеп, язучы әбиләрнең елы җитүгә ике гаиләдә дә ике киленнең бала табу вакыйгасын телгә ала. Кызлардан соң көттереп туган малайларга йөкләнгән нәсел дәвам итү бурычы уйлану-борчылу чигенә җиткерелә. (Вәкыйфә әбинең улы Сәлим, мәсәлән, улы туу шатлыгыннан эчеп, машинасы белән юл читенә төшә). Ничек кенә булмасын, киләчәк буыннар алдындагы җаваплылык кимеми, картлык көнендә үзләрен карарга тиешле балалар туу кебек кабул ителә.

«Кәгазь кисәге» хикәясендә кеше язмышын үзгәртергә дучар булган медицина белешмәсе тирәсенә тупланган вакыйга очраклык ноктасыннан чыгып аңлатыла. Биш ел буена ана булу теләге белән янып яшәгән утыз биш яшьлек Зилиянең, сөяркәсен ничек тә үзенә «бәйләргә» белмәгән Гөлсинәнең тормышларын әлеге кәгазь кисәге хәл итәчәк. Карынында сабый яралганлыгын тойган, шатлыклы хисләренә дәлилләү эзләп, табибларга мөрәҗәгать иткән Зилияне яман шеш диагнозы, үзенең беркайчан да бала күтәрә алмаячагын бик яхшы белгән Гөлсинәне дүрт айлык авыры бар дигән хәбәр көтә. Очраклы рәвештә белешмәнең алышыну вакыйгасы, уч төбе кадәр генә кәгазь кисәгенең табигать кануннарын юкка чыгарга сәләтле булуын, корбаннар таләп итүен искәртә кебек. Гомер буе бала дип тилмергән Вәгыйзь дә, бала турында хыялланган Зилия дә язмыш шаяруын авыр кабул итәләр. Газап эчендә яшәгән яшь хатын баласын да, аналыгын да югалта, алданганын аңлаган шактый өлкән яшьтәге ирнең йөрәге тота. Әкияттәге «үләргә киткән түтәй баеп кайтты» дигәндәй, ничек тә үткәндәге «пычрак» тормышыннан котылырга, шәһәрдә бай һәм җиңел тормыш корырлык кеше эләктерергә хыялланган Гөлсинә генә үз максатына ирешә бугай: башта Вәгыйзьнең ярты байлыгын, ул үлгәннән соң бар мөлкәтен үзенә күчерә. Тик бу байлык аның чын диагнозы фонында чираттагы бер алдану кебек кабул ителә. Бу әле бары тик укучыга гына билгеле сер булып кала.

Фәлсәфи яңгырашы буенча охшаш «Ялгышу» хикәясе дә төрле катгый кануннар, чикләүләр эчендә тәрбияләнеп үскән Рәзифәнең яшьлек хатасы өчен җавап тотуы кебек тәкъдим ителә. Тәртипле, тыйнак кызның авырга узу тарихы кешелеклелек, гуманлылык кысаларыннан чыгып, сюрреалистик төс ала (Риянның этисе булуын кыз соңыннан гына белә). Геройлар тарафыннан кылынган ялгышларның төрлелеге яссылыгында, Рәзифәнең акылга килеп, калдырган баласын еллар үткәч эзләп чыгуы – ялгызлыктан, «хиссез курчак» булудан котылу өчен генә башкарылган адым дип түгел, ә күңелендә үкенү дулкынының күтәрелүе буларак кабул ителә. Кызы тәрбияләнгән гаиләнең кәккүк ананы кабул итәргә әзер булуы укучыга сюжетны уйлап бетерергә мөмкинлек бирә.

«Гитара» хикәясендә, алдагылардан аермалы буларак, романтик сурәт тудырыла. Төп сюжет тулай торак бүлмәсендә Нәфис исемле кунак егетенең гитарада уйнап җырлавын, студент кызларның җыр-моңга хозурланып утыруларын бәян итүдән башлана. Гөлчәчәкнең Нәфисне «ачкан авызларын ябарга онытып» тыңлаган кызлардан түгел, ә гитарадан көнләшүе хикәядәге психологик конфликтка нигез

сала. Тора-бара гитара көндәштән гаилә ядкаренә, яшьлек истәлегенә әверелә. Ир, ялындырып кына булса да, ара-тирә гитара кылларын чирткәли.

Әмма көннәрдән бер көнне гитараның идәнгә төшеп ватылуы, кылларның зыңлап өзелүе алдагы тормышның инде элеккечә булмавы турында кисәтә. Балалар өйрәнсен дип алынган яңа гитарага да кагылучы булмый... Җигелеп, дөнья йөген тарткан, йорт-кура җитештергән, бер-бер артлы балалар үстереп яткан гаилә тормышы тоныклана, үз көен югалта бара.

Нәфиснең станокта такта чыгарганда, сул кулының ике бармагын кистерүе – бихисап кайгы-шатлыкларны кичергән гаилә өчен тагын бер сынау. Әлеге вакыйга ир өчен хуҗалык эшләрендә уңайсызлыклар тудырса («Кадакны ды тотып кагып булмас инде...»), хатын өчен исә фаҗигагә әверелә. Романтик герой күңелендә барган каршылыкның (гитара-көндәш, гитара-сердәш) көтелмәгән ноктада чишелүе аны чынбарлыкка алып кайта.

Сабыр һәм зирәк хатын Гөлчәчәкнең «Кылларга басмый гына көй чыгарып булмый...» дигән сүзләре ир-хатын мөнәсәбәтләренең асылын да, гаилә җылысын саклаучы эчке бер гармониянең югалуын да ачып сала кебек. Җыр-моң белән башланган матур һәм җиңел тормыш турындагы уйның хыялда гына калуы романтик геройның күңелендә барган каршылыклы фикерләр тарткалашын, күңел көйсезлеген, рухи фаҗигасен тагын да көчәйтә.

Күп очракта беренче заттан барган хикәяләү хатынның йөгерек уйларын, күңелендәге кичерешләрне теркәү рәвешендәге психологик алымга корылган. Гитара чиртеп утырган мизгелне сагыну геройның яшьлеген, егетнең кызга карата булган җылы хисләрен, иркәләү-назларын сагыну, шул җылы мөнәсәбәтләрне саклый алмаган өчен үпкә белдерүе кебек аңлашыла башлый.

Гомумән, алда сөйләнгәнчә, җәмгыятьтәге тотнаксызлык, тәртипсезлек, азгынлыкны фаш итү белән бергә ихласлык, тыйнаклык, олы хисләр барлыгын исбат итәргә алынган әлеге әсәрләр кешелек дөньясының төрле һәм каршылыклы булуын ассызыклый, аны үзенчәлекле характерлар аша ача. Әлеге сыйфат-билгеләре повестьларда тагын да калкурак чагылыш таба.

Язучы каләменең осталыгын ачып салган «Төш» повесте «Казан утлары» журналы (2015, №1) укучыларына таныш. Әсәрдәге вакыйгалар тезмәсе каймалы композициягә корылып, чынбарлык-хыял-чынбарлык тезмәсендә бирелгән. Сәгать бер белән ике арасында күрше ирләрнең төшке ашка кайтып китүләрен күзәтеп, тәрәзәдән тәрәзәгә йөргән Сөмбелнең кичерешләрен үз эченә алган чынбарлык сурәте әрнү һәм чарасызлык хисе белән сугарылган. Тавышсыз-тынсыз гына телевизор карап утырган ике улы да, корсагында сигез ай элек яралган сабые да ялгызлыкта бәргәләнгән хатынны өзгәләнүләрдән арындыра алмый. Камил исеме белән телгә алынган ирнең кая югалуы гына әлегә сер булып кала, укучы күңелендә бер-бер артлы сорау туа: житеш тормышын тагын да ныгытам дип, берәр җирдә акча хәстәрләп йөриме? Бәла-казага юлыкканмы? Әллә хыянәт юлына басып, башка хатын-кыз белән чуаламы?

Әсәрнең дәвамы булган хыял өлеше вакыйгаларны сигез бүлектә тәкъдим итә. Беренче бүлек Сөмбел белән Камилнең бәхетле тормышыннан бирелгән күренешләрне тасвирлый, хуҗалык мәшәкатьләре хакында сөйли. Бәбигә чирләгән хатын операция өстәленә ята, өченче балаларын, кызлары Дамираны таба. Хатынның гомерен куркыныч астына куйган өчен үзен гаепләгән, аның сәламәтлеге өчен борчылган ирнең үз-үзен битәрләве әсәрне хисси яссылыкка алып чыга.

Икенче кисәктә районның салым инспекциясен җитәкләгән Камилнең эчкечелеккә сабышуы, әлеге сазлыкка батуның сәбәпләре күпкә тирәндә булуы ачыклана. Намусы һәм чынбарлык арасындагы тарткалашта герой бары тик хәмер белән генә күңеленә тынычлык таба, вакытлыча гына булса да онытылып тора.

Өченче бүлектә Камилнең шәһәрдә дәваланып кайтуы, дүртенчесендә тыныч кына тормыш көтеп яткан җирдән эштән китәргә гариза язуы хәбәр ителә.

Бишенче кисәк күңеленә тынычлык таба алмаган геройның гаиләсен алып, шәһәргә күченеп китәргә карар кылуын тасвирлый.

Алдагы өч бүлек гаиләнең шәһәрдәге тормышын сурәтли. Шәһәр читеннән алган йортның астагы катында Камил балта-агач эшләре белән шөгыльләнә. Танышлык аша балалар бакчасына мөдир булып урнашкан Сөмбел, булдыклылыгын эшкә җигеп, төрлечә акча эшләү, баю юлларын эзли. Балаларны бакчага урнаштырган өчен башка мөдирләр кебек ата-аналардан акча сорамый, Камил ясаган җиһазларны гына саттырып алдыра. Һәр як өчен отышлы булган алыш-биреш Сөмбелнең абруена һич тә тап төшерми.

Шәһәрдә дә үзенә урын таба алмаган, үзе теләгәнчә яшәргә теләгән ирнең кире авылга кайтып китү теләге көчле холыклы Сөмбелне дә җиңә, ул ире белән китәргә риза була («Юк! Кыенсынмыйм да, үпкәләмим дә, рәнҗемим дә! Корган дөньям да җәл түгел! Авылга икән, авылга! Артыңнан барам! Ышансам да, ышанмасам да... Син булган урынга, ул җирнең чите дисәләр дә, очып кына барып җитәргә дә ризамын...»).

Повесть укучыны чынбарлыкка алып кайту белән тәмамлана, уй-хыялларыннан арынган хатын иренең өстәлдәге рәсеме алдында күңелен бушата. Әсәр башланганда, Камилнең кайда икәнлеге укучыда сорау уятса, хәзер инде Сөмбел ачыклык кертә. Аның мөрәҗәгатендә чынбарлыкта гомерен элмәккә алыштырган, фани дөньяны ташлап киткән иренә рәнҗү сүзләре яңгырый...

Шунысы үзенчәлекле, Сөмбел хыялында тергезелгән тормыш идеаль булудан шактый ерак, ул чынбарлык кебек үк катлаулы, каршылыклы. Үзе уйлап тапкан тормышын ул да, күпләр хыялланганча, зиннәтле сарайларда үткән ваемсыз көннәрдән, сый-нигъмәткә, дан-шөһрәткә тулган, чәчәкләргә күмелгән рәхәт мизгелләрдән күз алдына китерә алыр иде. Төш вакытын уздырып җибәрү өчен уйлап табылган хыяллану көндәлек уен рәвешен ала башлый, анда кешенең үз-үзе белән көрәше өстенлек итә, яшәү кануннарының катлаулыгы, кеше характерының ныклыгы, намуслы тормыш кору хакыйкате гомумиләштерелә. Хыялларны чынга ашыру өчен Сөмбелнең үҗәтлеге, булдыклылыгы, Камилнең уңганлыгы гына җитми, кешенең үз-үзеннән канәгатьсезлеге, үз асылын эзләргә омтылуы идиллик сурәтне җимерергә сәләтле булып чыга.

Сөмбелнең аквариум алып кайту вакыйгасы әсәрдәге фәлсәфәне калкыта төшә. Алтын койрыклы балыкта Камил үзенә җандаш күрә. Рухи хөрлеккә омтылган геройның хыяллары тормыш чынбарлыгында чәлпәрәмә килә («Син ничектер, ә мин бу тормышка үзем теләп ризалаштым бит. Котылыр юлны да үзем табарга кирәк...»). Геройның күңелендәге тынгысыз минутларда матди байлык туплауны заман чире итеп кабул итү, рухият өчен күбрәк борчылуы саташулы-төшле халәттә башкарыла. Үз-үзе белән көрәштә корбан булуны сайлаган Камилнең гаиләдә дә рухи тынычлыкка ирешә алмавы кызгану хисләре тудыра.

Кеше гомере, тормыш мәгънәсе турында уйлануларга этәрүче «Имәннәр көче» повесте герое Биктимер туган туфракта үскән имәннәр ныклыгын үзендә гомумиләштергән герой буларак гәүдәләндерелә. Яман шеш белән көрәшүче геройның тормышка булган мәхәббәте, ихтыяр көче яшәеш фәлсәфәсе дәрәҗәсенә күтәрелеп, әсәрнең мәгънә чикләрен шактый киңәйтә. Язмыш аңа күңеле кушканча яшәргә мөмкинлек биргән. Әсәрдә табигатьтән, туган җиреннән яшәргә көч алган аксакалның оныкларын кешеләр арасында кеше булып яшәргә өйрәтеп өлгерер өчен имәннәр янына алып кайтуы буыннар арасындагы бәйләнешнең никадәр мөһим булуын раслый.

«Адашкан сер»дәге Лида-Фәгыйль-Сәҗидә өчпочмагының бәхетле чишелеше, «Чүплек илендә» повестенда юл һәлакәте нәтиҗәсендә хәтерен җуеп, шәһәр читендәге чүплеккә килеп эләккән Фәридә язмышы, «Килмешәк»тә кемне дә үз кубызында биетергә сәләтле Фәзилә образы шулай ук укучыларны битараф калдыра торган түгел.

Г.Мирһади үзенең каләмен сатира-юмор өлкәсендә дә уңышлы сынап карады.

Язучының җиңелчә юмор белән язылган «Ике яшәр Газнәви» хикәясен генә алыйк. Кайчандыр гөрләп торган, бүген бөлгенлеккә төшкән «Үрнәк» колхозының данлыклы председателе Газнәви Габдулыч үлгән дигән хәбәр белән башланып китә ул. Үрмәле авылында мәчет салып ятучы дүрт ир, бар эшләрен ташлап, мәрхүм белән хушлашырга барырга җыеналар. Үлем хәбәре алар ярдәмендә авыл буйлап тиз тарала. Төштән башлап, кичкә кадәр Үрмәле авылыннан Инешкә төркем-төркем халык юллана. Ни гаҗәп, сау-сәламәт, яшьләрне көнләштереп яшәп яткан Газнәви Габдулыч һәркемне ачык йөз белән каршылый. Абдуллинның үлмәгәненә ни шатланырга, ни кайгырырга белмәгән халык авылда яңа хәбәр тарата: без үлсәк тә, ул калыр әле! Ике яшәр әле ул Газнәви! Татар авылының көчле традицияләре фонында туган мәгънәви каршылык көлкеле эффект тудырып кына калмый, тасма телләрне, гайбәтчеләрне, аларның ямьсез гамәлләрен дә фаш итә.

Язучының тәүге романы – «Куян кучтәнәче» әсәрендә үзгәртеп кору чорыннан алып, бүгенгәчә Тургай авылы проблемалары һәм анда яшәгән, аның язмышы белән бәйле кешеләрнең кичерешләре, мөнәсәбәтләре тасвирлана. Бер чиктән икенче чиккә бәргәләнгән җәмгыятьтә изге эшләрнең, дөреслекнең, намус төшенчәсенең кыйммәте югалып, эчкечелек, эшсезлек, хәтта оятсызлык арткан чор бу. Үз әти-әнисе тәрбиясеннән мәхрүм Илгизәр белән Линарның, бер-берсен яраткан Эдик белән Илүзәнең тормышта үз урынын эзләүләре, гасырлар, системалар алышынганда барлыкка килгән байлар һәм «яшәргә тырышучыларның» уй-фикер, эш-гамәлләре, адымнарының сәбәпләре ачылыш таба әсәрдә. Карт коммунистлар Вилдан һәм Фәтхи, заманага яраклаша алган Дамир һәм Филария, эшсөяр авыл гаиләләренең язмышлары да төп геройларныкы белән үрелеп бара.

Гөл Мирһади прозасы турында сөйләгәндә, геройлар арасында күпчелеге хатын-кызлар булуын әйтергә кирәк. Гомумән, эшлекле, ихтыярлы, ирекле хатын-кыз образларын заманча шартларда сурәтләү авторның әдәбиятка алып килгән яңалыгы буларак карала ала. Ирләреннән алда тормыш-көнкүреш ваклыкларын хәл итәргә алынган әлеге героинялар дәртле, сөю-сөешүдә талымсыз, хата-ялгышулар аша үз асылларына кайталар, нәсел дәвам итү инстинкты, итәк тутырып балалар үстерү теләге көчле.

Көчле һәм гайрәтле булып кыланган ир-атлар хатын-кыздан, гаиләсеннән башка тулы канлы тормыш белән яши алмый. Хатын-кызның нечкә күңелен аңларга тырышкан, хыял һәм чынбарлык арасында бәргәләнгән көчле затлар үзләре дә рухи газапларга дучар булалар. Рухи чыныгу кичергән геройлар көчле характерлар буларак ачылалар. Шашкын хис-тойгы агымы әсәрләрнең фәлсәфи-психологик йөкләнешен тәэмин итсә, натуралистик элементлар, ситуацияләрне бәяләүдәге рациональлек тормышны гротеск формасында сурәтләүгә дә алып чыга. Язучының кайбер әсәрләрендә оригиналь сюжетлар эзләве укучыны шаккатырырга, аның иң нечкә кылларына тияргә тиешле вакыйгалар тезмәсенә китерә (үлем, җенси азгынлык, һ.б.). Сюжетның тыгызлыгын тәэмин итә алмаган кайбер хикәяләрдә идея бераз томанланып, тоныкланып калу да күзәтелә. Телнең сәнгатьчә нечкәлеген тоеп, отышлы куллана белү язучыга традицион алымнарны яңа табышлар белән үреп бирергә мөмкинлек тудыра.

Гомумән, Гөл Мирһади геройларының бай кичерешләр палитрасын биреп, кешенең асылын, булмышын ачарга тырыша. Чынбарлык һәм хыял арасындагы аерма, җәмгыятьтәге гаделсезлек, җан тынгысызлыгы кеше күңеленең иң нечкә кылларын өзә. Өзелгән кыллар моңында нәфрәт тә, ачыну да, рәнҗү дә, сагыш та, үкенү дә яңгыраш ала.

Альбина ХӘЛИУЛЛИНА,
филология фәннәре кандидаты

Алтай халкының мәшһүр шагыйре Борис Укачин (1936 – 2003) Таулы Алтай автономияле өлкәсенең (хәзерге Таулы Алтай Республикасы) Онгудай районындагы Каярлык авылында дөньяга килә. Өлкә башкаласындагы милли мәктәпне тәмамлагач, ул армия сафларына алына. Аннары Мәскәүдәге М.Горький исемендәге Әдәбият институтына укырга керә. Соңрак «Алтайдын чолманы» исемле өлкә газетасында, радиокомитетта, РСФСР Язучылар берлегенең Таулы Алтай бүлегендә эшли.

Борис
Укачин

АЛТАЙ ИЛЕМ! МИН БИТ СИНЕҢ УЛЫҢ!

Кеше булу

Человек начинается с горя...
Ольга Берггольц

Бу сүзләргә җавап эзли-эзли,
Буталып та бетте башларым...
Тик үземә кайгы төшкәч кенә,
Кешеләрне аңлый башладым.

Бәхетленең уе синдә түгел,
Ул яши күк башка, чит илдә.
Коткарам дип сине, кулын сузмас,
Торган чакта упкын читендә.

Сагышлыны мәңге аңламас ул,
Сагышларга үзе чуммаса.
Ярлы сүзе аңа ишетелмәс,
Янчыгында алтын чыңласа.

Язмыш сине утка салган чакта,
Көтмә аннан һич тә мәрхәмәт.
Сине аңлап, яшен түгәр бары
Мең кайгылар кичкән мәхәббәт.

Бу дөньяда яши-яши әле
Күп нәрсәдән гыйбрәт аласы...
Кайгы кичеп, михнәт чигеп кенә
КЕШЕ була адәм баласы.

Алтаем

Алтай илем! Мин бит синең улың!
Син җырымда – күңел түремдә!
Күктә йөзгән ак болытлар миңа
Ак бәрәннәр булып күренә.

Карыйм сиңа сөеп, гаҗәпләнеп,
Җәйрәп ята басу-кырларың,
Тау-кыялар гүя Алтаемның
Акыл җыйган маңгай сырлары.

Мәгърур таулар тора йокымсырап,
Тик Өч Сөмер* сакта калачак...
Челеменнән ургый зәңгәр томан,
Димәк, төнлә яңгыр явачак.

Алтай илем, әкияти җирем,
Күпме серләр сыйган җаныңа!
Шул серләрне ачар өчен бүген
Агылалар Хатын ярына.

Алтай илем! Мин бит синең улың!
Башка җирләр миңа ят сыман.
Һич көнләшмим: Хатын белән Аргыт**
Мине узып ерак аксыннар!

Ялгыз йөрим. Керәм урманнарга.
Шигырь укыйм. Җилләр исәләр.
Аяк очларымда җырлар көйли
Бер исемсез челтер чишмәләр.

Минем язмыш мәңге синең белән,
Син – Кояшым минем, син – Аем!
Синең кебек була алсам иде,
Күккә ашкан мәгърур Алтаем!

Мин гаделлек эзлим

Ау этедәй эзли-эзли барам,
Калышмыйча заман артыннан...
Кыядагы язуларны укып,
Җәяү барам, төшеп атымнан.

Гүзәл затлар мине кызыктырмый,
Башларында уй-гамь булмаса.
Көлә алмый күзләр, әгәр җаның
Ялгызлыктан сыкрап еласа.

Хәйлә-мәкер миннән читтә йөри,
Ул сыйфат хас бары төлкегә.
Төлке белән бергә юлга чыгып,
Ничә тапкыр калдым көлкегә...

Аманнар бар илдә, яманнар бар, –
Кешеләрне шулай аерам,
Ак-карадан тора минем дөньям,
Шатлыклардан тора, кайгыдан.

Таулар кичәм. Җаным күшеккәндә
Җылы табам учак янында.
Тау халкының бөтен зирәклеге
Күчә кебек шулчак җаныма.

Бер бушбугаз һаман нотык сөйли,
Хәтерләтеп җилләр искәнне...
Сизми бит ул үткен теле белән
Үз муенын үзе кискәнне.

Бер карасаң, ул баһадир кебек, –
Яманлыгын аның сизмисең,
Яман исе үзәгендә кала
Тышкы ягы кипкән тиреснең.

Яшәмәдем вакыт узсынга дип,
Күрдем шатлык, күрдем нужасын...
Мин Гаделлек эзлим. Эзли шулай
Ау этләре үзенең хуҗасын.

Эзләп барам таудан тауга менеп,
Алга дәшә һаман хыялым.
Эт булырга риза, таба алсам
Мин «Гаделлек» дигән кыяны.

---

* Өч Сөмер – Алтайдагы өч өркәчле мәһабәт тау.

** Хатын белән Аргыт – Алтайдагы ургыл сулы тау елгалары.

Шагыйрь, галим-тюрколог, фольклорчы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Бронтой Бедюров хәзерге Алтай Республикасының Онгудай авылында 1947 елда дөньяга килгән. Өлкәнең милли мәктәбендә урта белем алгач, ул укуын башта Таулы Алтай педагогика институтында, аннары Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институтында дәвам итә, СССР Фәннәр академиясенең Шәркыять институтында аспирантура тәмамлый. Укуын тәмамлап, туган ягына кайткач, бераз вакыт өлкә газетасында эшләп ала, Таулы Алтай радиокомитеты һәм Язучылар берлеге җитәкчесе була. 1990 елларда Бронтой Бедюров республика парламентында хезмәт итә, аннары матбугат һәм мәгълүмат комитеты башлыгы итеп билгеләнә. Ул Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре (1994), Алтай Республикасының Халык язучысы. Алтай Республикасының Г.И.Чорос-Гуркин исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Таулы Алтай шәһәрендә яши.

Бронтой
Бедюров

МИН БУ ҖИРНЕҢ ҺӘР ТӨСЕНӘ ГАШЫЙК...

Тулган ай әкияте

Ястык итеп язымны,
Ятам мин күккә карап.
Җылы сүзләр табалмыйм...
Җил, сагышымны тарат.

Серле, сихерле сүзләр
Йөри колак янымда.
Тотам дип кулым суздым –
Очты-китте тагын да.

Баш очымда, биектә
Илемнең тау-ташлары.
Күзләремнең төбендә
Илемнең аккошлары.

Күзем ачам,
Күзем йомам...
Тыңлыйм күкнең тавышын,
Кошлар оча,
Кошлар кайта.
Барысы – илем кошы!

Ап-ак көмеш канатлар
Җилгә тиеп сызгыра.
Телләремә алтайча
Иң кадерле сүз куна.

Яшел ястык язымны
Онытып кошлар санадым.
Кошлар булып кайтучы
Сүзләремне таныдым.

Җанымдагы сагышлар
Яшькә кушылып актылар.
Чит телләрдә адаштым...
Кошлар килеп таптылар.

Туган якта

Сукырларның ике күзе булам,
Өметсезгә бирәм ышаныч,
Телсезләрнең туган теле булам,
Ятимнәрне кочам. Мин – шагыйрь.

Диңгезләрнең төшәм төпләренә,
Күтәреләм кыя-тауларга,
Үлемсезлек серен эзлим җирдә,
Чыкмыйм таңнан киек ауларга.

Бар нәрсәгә көчем җитәр кебек,
Мин көрәшче, кермәм читлеккә!
Тик син генә мине кире какма,
Туган ягым, мине чит итмә.

Мин бу җирнең һәр төсенә гашыйк, –
Карасына гашыйк, агына.
Бар өметем, ышанычым минем
Бары синдә, туган ягымда.

Сәмәркандта

Биби-ханым атлы гүзәл мәчет....
Күз алдымнан китми ул һаман.
Ничә гасыр узып, чорлар тузып,
Гүзәллеген вакыт юмаган.

Сөйгәненә олы бүләк итеп
Салган аны гашыйк Тамерлан,
Мәхәббәткә асыл ядкарь итеп,
Һәйкәл итеп безгә калдырган.

Афәт чәчкән үзе тирә-юньгә –
Туздырылган илләр, калалар...
Ил яулаган кансыз яугирләрдән
Риваятьләр генә калганнар.

Утка салган күпме халыкларны,
Кая барса, шунда җимергән...
Янгын чыккан куздан... Еллар узган,
Нәрсә калган Аксак Тимердән?!

Мәчет калган. Ул бүген дә исән!
Ил түрендә балкый берүзе...
Алты гасыр саклый гүзәллеген, –
Төсе уңмый, һаман фирүзә.

Зур дәүләтләр берчак җимерелә,
Мәңге яши бары бер дәүләт.
Ул дәүләтнең аты – Биби-ханым,
Ул дәүләтнең аты – Мәхәббәт.

Алтайчадан **Разил ВӘЛИЕВ** *тәрҗемәләре*

Кулер Тепуков (Тепуков Кулер Эзендик улы) – алтай язучысы, шагыйрь. 1952 елда Алтай Республикасының Онгудай районы Сальяр авылында туа. Мәскәүдә Әдәбият институтын тәмамлый. «Солоны» (Салават күпере) исемле балалар журналының баш мөхәррире булып эшли. Алтай Республикасының Г.И.Чорос-Гуркин исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Таулы Алтай шәһәрендә яши.

Кулер
Тепуков

ТАУЛАР ЙОКЛЫЙ КҮПТӘН, ТӨШ КҮРЕП...

Җибәрелмәгән хат

Исәнмесез!
Мин – Тепуков Кулер. Минем хакта
Белмисездер хәтта ишетеп.
Гәзитләргә мактап язмадылар
Чабаннарга мине иш итеп.

Мин шигырьләр язам. Ихлас әгәр,
Басылуым әле беренче.
Борчылмагыз, бар да белә – мин
Шагыйрьләр күк түгел эчкече!

Шулай да мин бүген тост күтәрәм,
Авыз итеп ачы хәмердән,
Беркайчан да бүгенге кич безнең
Җуелмасын өчен хәтердән!

Тост күтәрәм иркенлеге өчен,
Биеклеге өчен тауларның!
Чабаннармы? Мин җырымда зурлыйм
Хезмәтләрен бүген аларның.

Бар да үтә –
Онытылырбыз без дә.
Утырганда табын янында,
Атамаслар безнең исемнәрне,
Мактап тостлар әйткән чагында.

Хәлләрегез ничек, әй, чабаннар?
Эшләрегез әйбәт барамы?
Март аенда туган бәрәннәр кук,
Шигырьләр дә сорый карауны!

Ничек анда, бәрәнләгән чакта
Куйларыгыз, этәч кычкырып
Уяттымы?
Мин дә шигырьләрне
Төн йокламый язам... Кичкырын.

Ак кәгазьгә кучә куңелемне
Борчып йөргән бөтен уйларым.
Мин дә чабан, сезнең кебек чабам!
Шигырьләрем – минем куйларым!..

* * *

Елдан-ел илдә танылa
Барса да туган ягым,
Белмиләр әле халыкта
Күп салаларын аның.

Очратырга булса да еш
Кичүләрендә аның
Бер тапкыр да кеше аяк
Басмаган сукмакларын,

Төрле бәла-казаларга
Юлыкса әгәр юлың,

Курыкмыйча атла, монда
Сузарлар ярдәм кулын.

Табарсың мәхәббәтеңне –
Очрамый калмас монда
Бердәнбер ярың булыр кыз
Олы тормыш юлыңда.

Һәм шуны бел: туган якта
Минем дә синең өчен
Тугры дустың һәм сөйгәнең
Булырга җитәр көчем!

* * *

Таулар йоклый күптән, төш күреп.
Ай яктысы уйный диварда.
Сәгать кенә бары йокламый,
Йокы килми никтер миңа да.

Сәгать саный вакыт исәбен,
Йөрәк типкән кебек күкрәктә.

Ватылырга мөмкин сәгать тә,
Тукталырга мөмкин йөрәк тә!

Тик туктамый вакыт беркайчан,
Уйламый да хәтта туктарга.
Тормый вакыт карап сәгатькә,
Вакыты юк аның йокларга.

Алтайчадан **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре*

САХА КАРДӘШЛӘРЕБЕЗНЕҢ ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ

Советлар Союзының барлык республикаларында да әдәби журналлар узган гасырның 20 нче елларында чыга башлый. Киләсе елның маенда безнең «Казан утлары» журналының беренче саны басылып чыкканга 100 ел тула. Быелның октябрендә исә Якутия (Саха) Республикасында чыгучы «Чолбон» журналы үзенең 95 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. «Чолбон» сүзенең мәгънәсен аңлагансыздыр – бу төрки сүзне без «чулпан» дибез. Таң йолдызыбыз.

Язучылар берлегендә эшләгәндә, миңа элекке СССРның барлык тарафларына (БДБ илләре) таралып яшәгән һәм Төркиядә гомер итүче төрки туганнарыбыз белән күп очрашырга, аралашырга насыйп булды. Үзебезнең Казанда да кардәш язучыларыбызны җыеп, берничә фестиваль, семинарлар үткәрдек. Аеруча истә калганы һәм нәтиҗәлесе – 2015 елда үткәрелгән Халыкара төрки яшь язучылар семинары. Анда төрек, кырым татары, азәрбайҗан, казакъ, балкар, кумык, тыва, башкорт, якут яшьләре үзара аралашып дуслаштылар. Шул очрашулар кардәш язучыларыбызның киләчәк тормышы, эшчәнлеге өчен бер трамплин, этәргеч булып калды һәм берлекләрдә җитәкчеләр алмашынгач, бигрәк тә эш башына ул чактагы яшьләр килгәч, яңа бер эчтәлек белән дәвам итә. Татарстан белән Якутия Язучылар берлекләре арасындагы хезмәттәшлек аеруча нәтиҗәле бара, дияр идем. Якутиядә һәр ике ел саен үткәрелә торган «Зур кар бәйрәме» дип исемләнгән Халыкара поэзия фестивалендә татар шагыйрьләре дә катнаша башлады. Рөстәм Галиуллин, Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Ркаил Зәйдулла, Газинур Моратлардан соң, быелгы фестивальгә катнашырга Рүзәл Мөхәммәтшин белән миңа да бәхет елмайды. Электән танышып, аралашып калган күп дусларны очраттык.

«Сүз башым бит шүрәле!» дигәндәй, «Зур кар бәйрәме»ндә катнашу тәэсиреннән чанам шуып, темадан читкә салулап алып кереп китте бугай. Менә шул шигырь бәйрәмен эзлекле рәвештә алып баручы якут туганнарның «Чолбон» журналы чыга башлауга октябрь аенда 95 ел булган. Якут телендә беренче әдәби журнал ВКП(б)ның Якутия бюросы махсус карары белән, 1926 елның октябрендә ЯАССР Мәгариф һәм сәламәтлек саклау халык комиссариаты белән «Саха омук» мәдәни-агарту җәмгыяте органы буларак чыга башлый. Аның беренче редакторы якут әдәбиятының нигез ташларын салучыларның берсе А.И.Софронов була. Журнал чыгаручылар арасында шулай ук язучылар В.Н.Леонтьев, А.Ф.Бояров, А.А.Иванов-Кюндя да була. ВКП(б) Үзәк Комитеты 1928 елның 9 августында кабул иткән «Якутия партия оешмасы турында» карары нигезендә «Чолбон» журналының редакция составы тулысынча репрессияләнә. А.И.Софронов сөргенгә җибәрелә. Ләкин журнал чыгудан туктамый, ул чактагы Якутия язучылар оешмасы җитәкчесе П.А.Ойунский бу эшне үз кулына ала. Югарыда әйтелгән карар шактый озак вакытлар әле әдәби журнал өстендә кара шәүлә булып эленеп тора. Журналның исемен дә алыштырып карыйлар. 1930-1938

елларда ул «Кыһыл ыллык» («Кызыл сукмак») исеме белән, 1938-1940 елларда «Матур әдәбият» дигән исемдә альманах буларак чыгарыла.

1939 елда Якутия Язучылар берлеге оеша. Шуннан соң 1940 елда калын журнал берлекнең органы буларак, «Хотугу сулус» дигән исем белән дөнья күрә башлый, 1943 елда альманах рәвешендә чыгарыла. Бер үк вакытта ул «Полярная звезда» дигән исем белән урыс телендә дә басыла. 1999 елда басмага яңадан беренче исеме кайтарыла. 95 ел эчендә «Чолбон»да бик күп әдәби әсәрләр, публицистик чыгышлар, очерклар һәм мәкаләләр, тәнкыйди һәм әдәби-гыйльми тикшеренүләр, тарихи материаллар, язучыларның әдәби портретлары, төрле халыкларның әдәбияты дөнья күрә. «Әдәбиятлар дуслыгы – халыклар дуслыгы» дигән рубриканың әһәмияте аеруча зур. Әлеге сәхифәне Семён Данилов Якутиянең Язучылар берлеген җитәкләгәндә башлап җибәргән, аның рухи кыйммәтләр алышу тәҗрибәсендәге роле бәһаләп бетергесез.

Әдәбиятка яңа талантлар килә, «Чолбон»да яңа исемнәр барлыкка килә. Журнал редакциясе түгәрәк өстәл тирәсендә әдәбият турында фикер алышулар оештыра, шигырьләр, хикәяләр, очерклар бәйгеләре үткәрә. Укучылары белән очрашуларга чыга. 2018-2019 елларда берничә тапкыр «Чолбон» журналының швед өстәле» дигән ярминкә-акция оештырган. 2015 елдан алып, олысларның һәм шәһәрләрнең әдәби берләшмәләре әгъзаларының әсәрләрен түләүле нигездә «Сэмсэ» дигән кушымтада бастырып бара.

Бүген «Чолбон»ның баш редакторы булып Гаврил Андросов эшли. Якут телендә аның исеме Хабырыыс Ондороос дип яңгырый. Хабырыыс – 2015 елда Татарстан Язучылар берлеге оештырган Халыкара төрки яшь язучылар семинарында катнашкан ике яшь якут язучысының берсе. Ул чагында ул Якутия (Саха) Республикасының Яшьләр эшләре һәм гаилә сәясәте министрлыгында эшли иде. Хабырыыс шулай ук Якутия Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары булып тора. 2018 елдан – Россия Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе. Безнең семинарга килгән егетләрнең икенчесе – Рөстәм Каженкин. Рөстәм дә, Хабырыыс та 1985 елда туган егетләр. Икесе дә 2007 елда М.К.Аммосов исемендәге Якут дәүләт университетын тәмамлаганнар. Рөстәм – Якутия Язучылар берлегенең яшь язучылар советы җитәкчесе. Университеттан соң укытучылык һөнәрен сайлаган. Бүгенге көндә Якутск шәһәрендәге «Айыы кыһата» («Иҗат остаханәсе») милли гимназиясендә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли.

Якутиядә Язучылар союзлары икәү. Аның берсе Якутия (Саха) Язучылар союзы дип йөртелә. Идарә рәисе булып, 2003 елдан бирле Наталья Харлампиева тора. Икенче оешма – Саха (Якутия) Язучылар союзы, җитәкчесе – Иван Мигалкин. Иван Васильевич белән еш кына Мәскәүдә Язучылар берлекләренең халыкара оешмасы (МСПС) җыелышларында очраша идек. Ул заманында Мәскәүдә, безнең Разил Вәлиевләр белән бергә М.Горький исемендәге Әдәбият институтында укыган. И.Мигалкин 2017 елда минем 60 яшьлек юбилеемда катнашып, институттан соң 40 ел үткәч, Казанда үзенең сабакташы Разил Вәлиев белән очрашуын сәхнәдән тәэсирләнеп сөйләгән иде. Мин Иван Мигалкинның балалар өчен шигырьләрен татарчага тәрҗемә иттем, ул Казанда аерым китап булып басылып чыкты.

Бу язманы 95 ел буе Якутия (Саха) язучыларының әсәрләрен бастырып дөньяга танытучы журналлары «Чолбон»ның олуг юбилее уңаеннан, якут дусларыбызны тагын бер кат искә төшереп, аларны шушы бәйрәмнәре белән котлап язарга ниятләгән идек. Кунак ашы – кара каршы, диләр бит. Киләсе елның апрелендә, Тукай туган көннәрдә үз журналыбызның юбилей тантаналарында якут дусларыбызны да бәйрәм табыныбыз түрендә күрербез дип өметләнәбез.

Рафис КОРБАН

Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 130 ел

МИЛЛИ МУЗЫКАЛЬ ДРАМАНЫҢ АТАСЫ



Фото millattashlar.ru сайтыннан алынды.

Быел ноябрь аенда татар әдәбияты классигы, драматург, шагыйрь Мирхәйдәр Фәйзинең (1891-1958) тууына 130 ел тулды. Без аны иң әүвәл татар халкының музыкаль драма жанрына нигез салучыларның берсе буларак беләбез. Җырлы-моңлы татар халкының күңеленә нәкъ менә шушы жанр таләп ителүен беренчеләрдән булып ул аңлап ала.

Шул уңайдан Татарстан радиосы эфирында аның иҗатына һәм язмыш юлына багышланган тапшырулар яңгырады. Әлбәттә инде, әдипкә кагылышлы фонд язмалары хәрәкәткә китерелде.

Хәзерге вакытта радио архивында Мирхәйдәр Фәйзи исеменә бәйле берничә дистә язма саклана. Алар, беренчедән, төрле театр коллективлары тарафыннан сәхнәләштерелгән драма әсәрләре. Мәсәлән, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 1979 елда куелган «Ак калфак», 1982 елда сәхнәгә чыккан «Асылъяр» спектакльләренең радиовариантлары әле дә тыңлаучыларыбыз тарафыннан көтеп алына. Әлеге спектакльләрдә катнашкан күренекле артистларыбызның байтагы инде бакыйлыкта. Бу язмаларны тыңлаганда, аларның уйнау осталыкларына сокланып кына калмыйча, якты рухларын да дога белән искә алабыз.

«Галиябану»ның 1950 еллардагы куелышы язмасын исә бүгенге көндә үтә кадерләп сакланырга тиешле мирас, милли хәзинәбез дип бәяләргә мөмкиндер. Бу спектакль магнитофон тасмасына 1960 елга язып алынган булган. Шулай ук архивыбызда шушы әсәрнең радио өчен махсус язылган өзекләре дә бар. Аларда легендар актёрлар Барый Шәрапов, Вера Минкина, Хәлил Әбҗәлилов, Мәрьям Сульва, Асия Хәйруллина катнаша.

Мәгълүм булганча, Мирхәйдәр Фәйзи үзенең музыкаль драмаларындагы җыр текстларын үзе иҗат иткән. «Хәмдия», «Ак калфак», «Галиябану», «Рәйхан», «Асылъяр» кебек татар халык җырлары нәкъ менә аның әсәрләре аша халык күңеленә мәңге онытылмаслык булып үтеп кергән. Мирхәйдәр Фәйзи шигырьләренә композиторларыбыз да мөрәҗәгать иткән. Җәүдәт Фәйзи иҗат иткән «Егет, кил», «Чишмә янында», Сара Садыйкова көйгә салган «Сөмбел» җырлары шулай ук тыңлаучыларыбыз тарафыннан сорап алына. Алар Илһам Шакиров, Мәръям Рахманкулова, Сөләйман Йосыпов, Зөләйха Хисмәтуллина, Мөнирә Булатова язмаларында саклана.

Ә хәзер, әйдәгез, QR- код аша сайтыбызга кереп, Мирхәйдәр Фәйзинең мәңгелек әсәрләренең берсе «Галиябану» музыкаль драмасыннан бер өзек тыңлыйк. Анда Барый Шәрапов һәм Вера Минкина катнаша.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.

КҮҢЕЛДӘН ҖУЕЛМАС МОҢ ИЯСЕ

Ноябрь аенда татар халкы читләтеп уза алмый торган, читләтеп узарга ярамый торган тагын бер зур вакыйга бар – җырчы, композитор, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты Мәрьям Рахманкулованың (1901-1990) тууына 120 ел тулды.

Ул халкыбыз тарихына хатын-кызлар арасыннан беренче булып сәхнәгә күтәрелергә җөрьәт иткән җырчыларның, шулай ук татар опера сәнгатенә нигез салучыларның берсе буларак кереп калды. Аның башкаруында классик әсәрләр, татар халык җырлары замандашлары һәм үз артыннан килгән яшь башкаручылар өчен үзе бер вокал мәктәбе булды. Татар халкының ничәмә-ничә буыны Мәрьям Рахманкулова җырлары белән рухланып, тәрбияләнеп үсте.

Кабатланмас һәм затлы тавышлы җырчы үз вакытында Татарстан радиосы белән дә актив хезмәттәшлек иткән. Безнең фондта сакланган язмаларны хронологик тәртиптә тыңлап барып кына да, республикабызда опера сәнгатенең, татар эстрадасының үсешен күз алдына китереп булыр иде.

Җырчының юбилее уңаеннан оештырылган радиоконцертларда ул башкарган «Яшьләр вальсы» (Әгъзам Фәттах көе, Әхмәт Ерикәй сүзләре), «Безгә кунакка килегез!» (Мәрьям Рахманкулова көе, Мирхәйдәр Фәйзи сүзләре), «Сөмбел» (Сара Садыйкова көе, Мирхәйдәр Фәйзи сүзләре), «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» (Җәүдәт Фәйзи көе, Сибгат Хәким сүзләре), «Табын җыры» (Рөстәм Яхин көе, Кави Нәҗми сүзләре) кебек дистәләгән язмалары яңгырады. Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил либреттосына язган «Алтынчәч» операсыннан Тугзак ана арияләре эфирга бирелде. Безнең белән элемтәгә кергән тыңлаучыларыбыз фикеренчә, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры һәм Казан дәүләт консерваториясенең берләштерелгән симфоник оркестрына кушылып башкарылган «Кечкенә Идел» (Заһид Хәбибуллин көе, Шәйхи Маннур сүзләре) һәм «Җырла, тургай!» (Заһид Хәбибуллин көе, Гамир Насрый сүзләре) җырлары әле бүген дә татар башкару сәнгатенең югары үрнәге булып кала.

Журнал укучылар игътибарына Татарстан радиосы эфирында Мәрьям Рахманкулованың юбилее уңаеннан яңгыраган концертларның берсен тәкъдим итәргә булдык. Халкыбызга киләчәктә дә шушындый җырчылар насыйп булса иде, дип тыңлыйк.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.

Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

ТАТАРНЫҢ ФӘН ЙОЛДЫЗЛАРЫ

Журналыбыз исемнәре гыйлем тарихына язылган мәшһүр татар фикер ияләре, аларның аерым бер хезмәтләре турында да, бүген Татарстаннан читтә яшәп, казанышлары белән дөнья фәнендә исем-ат казанган күренекле татар галимнәре хакында да сөйләп килә. Үз вакытында Камил Вәлиев, Тамурбәк Дәүләтшин, Роальд Сәгъдиев, Надир Дәүләт, Рәшит Сүнәев һ.б. шәхесләрне татар дөньясына танытуда басмабызның өлеше зур булды. Шушы традицияне дәвам итеп, Фән һәм технологияләр елында халкыбызның горурлыгы булган галимнәр белән таныштыруны дәвам итәбез.

Татар галиме – мәртәбәле бүләк иясе

13 октябрьдә Мәскәүдә Россиянең иң зур халыкара фәнни бүләге – «Глобаль энергия» («Global Energy International») премиясен тапшыру тантанасы узды. Россия хөкүмәте җитәкчесенең урынбасары Александр Новакның: «Хәзерге дөньяда энергетика социаль-икътисади үсешнең нигезенә әйләнде. Шуңа күрә бу өлкәдәге фәнни ачышлар безнең цивилизациянең алга таба үсешенә йогынты ясый. Бу яктан караганда, «Глобаль энергия» премиясе символик мәгънәгә ия. Ул ягулык-энергетика комплексының гына түгел, бәлки кешелекнең киләчәген билгели», – дигән сүзләре әлеге вакыйганың тарихи әһәмиятен күрсәтә. Россиядә фән һәм технологияләр елында бу мәртәбәле бүләккә татар галименең, Татарстан төбәге белән бәйле технологияләрнең лаек булуы зур горурлык уята.

Дөньяның иң мәшһүр премияләре исемлегенә кергән бу бүләкне икенче төрле «Россия Нобеле» дип тә йөртәләр. 2002 елны физика өлкәсендә Нобель премиясе лауреаты Жорес Алфёров инициативасы белән бирелә башлаган әлеге бүләккә энергетика өлкәсендә дөньякүләм билгеле ачышлар ясаган иң заманча технологияләрне уйлап табучылар һәм аларны гамәлгә кертүчеләр дәгъва итә. Мондый технологияләр энергия чыганакларын нәтиҗәле кулланырга мөмкинлек бирә һәм экологик куркынычсызлыкны арттыра.

2021 елгы конкурста 39 илдән 106 кандидат катнаша. 3 җиңүченең берсе Зинфер Исмәгыйлев – «Традицион энергетика» номинациясендә углерод материаллар химиясе, гетероген катализ һәм климат үзгәрү белән көрәшүгә фундаменталь өлеш кертү өчен олы бүләккә лаек дип табылган. Әлеге бүләкне игълан иткәндә, профессор Исмәгыйлевның бу ачышлары әйләнә-тирә табигатькә зыян салмыйча мотор ягулыгын чистартуның, радиоактив калдыкларны куркынычсыз зарарсызландыруның, күмерне энергия чыганагы буларак куллануның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлтелгәннәр дип ассызыкланды!

Лауреатның татарча сөйли башлавы алкышларга күмелде...

6 сентябрьдә узган җиңүчеләрне игълан итү тантанасында З.Исмәгыйлев татарча сөйли башлагач, бер мизгелгә дөньяның төрле телләренә тәрҗемә итеп утыручыларның эфирны тутырган шау-шуы тынып кала. Ул арада инглиз телен дә камил белгән Зинфер Ришат улының үз туган теленә хөрмәт күрсәтүе алкышларга күмелә...

Әлеге тантанада да, 2021 елның 30 сентябрендә Татарстан Фәннәр академиясенең 30 еллык юбилеенда чыгыш ясаганда да, Зинфер Ришат улы Татарстан белән күпьеллык хезмәттәшлеге, уртак эшнең гамәли нәтиҗәләргә һәм яңа технологияләр булдыруга китерүе турында сөйли. Ул уйлап тапкан ДИРОКС күкертле водородтан күкертне аерып алу технологиясенең чистарту нәтиҗәлелеге 99 процентка җитә, шуңа күрә дә ул Россиядә һәм чит илләрдә патентлана, күп кенә урыннарда шушы технологиягә нигезләнгән заводлар төзелә һәм составында күкертле водород күп булган нефть ятмаларыннан зур масштабларда нефть суыру һәм аны чистарту мөмкинлеге тудыра. Галим бу ачышның Татарстан галимнәре, Волжск углеводородлы чимал фәнни-тикшеренү институты (ВНИУС) генераль директоры, академик Әхмәт Мазһар улы Мазһаров, «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры академик Рафинат Самат улы Яруллин, «Татнефть» гаммәви акционерлык җәмгыяте хуплавы һәм ярдәме белән Татарстан өчен эшләнүен хәбәр итә. Хәзерге вакытта 2022 елда эшли башлаячак тагын ике җитештерү җайланмасы сынау уза дип, Татарстан белән хезмәттәшлекнең дәвамлылыгын тагын бер кат ассызыклый.

Зинфер Исмәгыйлев (уртада) «Глобаль энергия» премиясен тапшыру тантанасында. 2021 ел.

Кем соң ул – Зинфер Исмәгыйлев?

Зинфер Ришат улы Исмәгыйлев – Россия Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (академик), Россия Фәннәр академиясе Күмер һәм күмер химиясе Федераль үзәгенең фәнни җитәкчесе, Күмер химиясе һәм химия материаллары белеме институты директоры (Кемерово), химия фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы. Күп исемнәргә һәм күп бүләкләргә лаек булган галим, фәнне һәм сәнәгатьне оештыручы, җәмәгать эшлеклесе...

Зинфер Ришат улы гетероген катализы, нефть һәм күмер химиясе, углерод материаллары химиясе, функциональ наноматериаллар һәм сәнәгать экологиясе өлкәсендә тикшеренүләр белән шөгыльләнә. 1200дән артык фәнни хезмәт авторы булса, 4100 цитаталау саны әлеге хезмәтләрнең дөнья фәнендә гаять актуальлеге турында сөйли. Ул – Россия Федерациясенең һәм чит илләрнең 170тән артык авторлык таныклыгы һәм патентлары авторы һәм соавторы. З.Исмәгыйлев җитәкчелегендә 29 кандидатлык һәм 6 докторлык диссертациясе якланган.

Фәннең әлеге юнәлешен максатчан сайлап ала Зинфер Ришат улы. Ерак Башкортстаннан барып, 1969 елны Новосибирск дәүләт университетын «химия» белгечлеге буенча тәмамлый, 1972–1980 елларда СССР Фәннәр академиясенең Катализ институтында кече фәнни хезмәткәр булып эшли башлый. Озак та үтми, лаборатория җитәкли, хәтта 2010 елны Күмер химиясе һәм химия материаллары белеме институтына директор итеп билгеләнгәч тә, үзенең лабораториясен ташламый. 1974 елны шушында кандидатлык диссертациясен яклый. Россиянең төрле төбәкләрендә үз технологияләрен гамәлгә-җитештерүгә кертү белән шөгыльләнә.

«Телләр белгән илләр ачар», ди халык. Зинфер Ришат улы белән дә шулай килеп

чыга. Кызыклы фәнни хезмәтләрен күреп, яшь галимне Америкага, күренекле Райс университетына (Хьюстон, Техас) эшкә чакыралар. Бу карашларны киңәйтү мөмкинлеге бирә, фәнни эшенең перспектив нигезләрен барларга ярдәм итә, халыкара проектларга юл ача. 1988 елны докторлык диссертациясен яклап, Зинфер Ришат улы «Катализатор» тармакара фәнни-техник комплексның генераль директоры урынбасары (1988–1992) булып эшли башлый. Дөнья фәнендә абруе нығыганны 1992, 1994 елларда Франциянең Луи Пастер университетында, 1993 елны Американың Төньяк-Көнбатыш университетында һәм Тын океан төньяк-көнбатыш лабораториясендә (Ричленд, Вашингтон) «чакырылган профессор» булуы күрсәтеп тора.

Әлбәттә, чит илләр белән хезмәттәшлек туктаусыз гыйлем җыюны да таләп итә. З.Исмәгыйлев 1993 елда Америкада фәнне оештыру һәм җитәкчелек итү программасы буенча белем ала. Италия, Голландия кебек Европа илләрендә, Казакъстан, Азәрбайҗан һ.б. дәүләтләрнең 50дән артык вузларында һәм фәнни үзәкләрендә лекцияләр укый, күпсанлы халыкара проектлар белән җитәкчелек итә яки аларны гамәлгә ашыруда катнаша. Уртак фәнни эшләр алып барыла торган илләр арасында Америка (9 проект), Нидерланд (7), Япония (3) кебек дәүләтләр бар, 15 проект исә Азәрбайҗан, Беларусь, Казакъстан, Украина Фәннәр академияләре белән бергәләп башкарылган.

«Укытучылык гены» да үзен гел сиздереп тора: Зинфер Ришат улы 1976–1989 елларда үзе белем алган университетның физика химиясе кафедрасында укыта, вузның табигать фәннәре факультетында декан ярдәмчесе кебек оештыру вазифаларын да башкара. Бүген дә студентлар арасында: 2012 елның декабреннән хәзерге көнгә кадәр Т.Ф.Горбачев исемендәге Кузбасс дәүләт техник университетының профессоры, кафедра мөдире.

Әле генә күзәтеп узган сәхифәләр, әйтерсең лә, бер кеше гомеренеке генә булмыйча, берничә олпат шәхес турында сөйләгән кебек тәэсир калдыра. Моның сәбәбе, сере нидә? Күрәсең, нәселдәндер...

Исмәгыйлевлар нәселе

Исмәгыйлевлар – Башкортстанда танылган укытучылар династиясе, аларның гомуми педагогик стажы 700 елдан артып китә икән. Белем белән фән бергә үрелгән: укытучы хезмәте галимнәр династиясенә нигез булган!

Архив документларына караганда, нәселнең ерак бабасы Акбирде (1710 еллар тирәсе) хәзерге Башкортстанның Нуриман районына кергән Нимесләр авылына хәзерге Татарстаннан күченеп нигез салган 11 гаилә арасында булган. Аның улы Әхмәт, Әхмәтнең улы Сөендек, анысының улы Юмадил – барысы да шушы җирдә төпләнеп, тормыш алып барган, иген иккән, мал асраган, умарта тоткан, мәчеткә йөргән...

Юмадилның улы Исмәгыйль исә (1836-1919) муллалыкны сайлаган, аның җиде баласы да әтисе юлыннан киткәннәр. Исмәгыйльнең алтынчы улы Ибраһим, татар мәдәниятендә билгеле «Кыешкы», «Рәсүлия» (Троицк), Казан, Бохара мәдрәсәләрендә белем туплап, 1906 елда авылларында җәдит мәдрәсә ачып җибәрә, аның улы Салих – М.Гафуриның сабакташы, 1905-1918 елларда авылдагы җәдит мәдрәсә мөгаллиме, үз авылында беренче совет мәктәбен оештыручы. Сөргеннәрне кичеп, кабат туган авылына кайта.

Гыйлемле, зыялы Салихның бер кызы урта һөнәри белемле – җиде улының өчесе югары белем ала, педагоглык һөнәрен сайлый. Аларның һәрберсенең илгә багышланган тормышы, балалары һәм оныклары хакында күп сөйләп булыр иде.

Без сүз алып бара торган шәхес – Зинфер Исмәгыйлевнең әтисе, алтынчы бала булып үскән Ришат Салих улы Исмәгыйлев (1920-2020) гаять катлаулы тормыш юлы уза. 1930 елны әтисен мәзин буларак кулаклар санына кертеп, сөргенгә җибәрү, урамда туйдыручысыз калган зур гаиләдәге коточкыч ачлык-ялангачлык Ришатның укытучы

булу хыялын тормышка ашыруга киртә булып ята. Әмма ул үз юлыннан тайпылмый: кулак балаларына түләп укырга кушсалар да, мәктәпне дә, Кушнаренко педагогия училищесын да тәмамлый, 1940 елны Кызыл Армия сафларына алынып, хезмәткә Брест кирмәненә эләгә. Бөек Ватан сугышының иң фаҗигале тәүге сәхифәләре язылган шушы алышта радист егет каты яралана, әмма исән кала, күрсәткән батырлыгы өчен 2 дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. С.С.Смирнов «Брест крепосте» китабын язганда, соңрак А. Кот шул исемдәге фильм төшергәндә, Р.С.Исмәгыйлевның хатирәләре аларга нигез булып ята.

«Яраларын ямаштырып», туган авылына әйләнеп кайтуга, Ришат Салих улы сугыштагылар урынына баса: Нимесләр авылында укытучы, Укәрле мәктәбенең директоры вазифаларын башкара. 1945 елның июнендә аны күршедәге Байгелде җидееллык мәктәбенә директор итеп тәгаенлиләр. Үзе дә яралардан хәлләнеп җитмәгән яшь җитәкче тиз арада тирә-яктагы авыллардан килеп укучы балалар өчен интернат ачуга ирешә, башлангыч мәктәп өчен бина төзетә, җидееллыкны урта мәктәп итеп үзгәртә. 1961-1962 елларда районда беренче булып, мәктәпнең типовой бинасы салына, аннары 100 балага исәпләнгән яңа интернат сафка баса...Әйтерсең, яшь килеш үлем белән күзгә-күз очрашкан директорны тормышны тагын да матуррак итеп кору, үсеп килүче буынга зур юллар ачу омтылышы туктаусыз хезмәт итәргә, туктаусыз кайнап, кайтмый калганнарның вазифасын да үз җилкәсенә алып яшәргә өнди.

Ришат Салих улы мәктәпне СССР күләмендә үрнәк уку йорты итеп үстерергә тели һәм, гаять зур көч куеп, шушы максатына ирешә. Ул үзе 40 нчы еллар ахырында ук табигый фәннәрен укытуны җирлектәге авыл хуҗалыгы эшләре һәм хезмәт тәрбиясе белән бәйләү методикасын әзерли, 1956 елны мәктәптә, илдә иң беренчеләрдән булып, укучыларның җитештерү-производство бригадасы оеша, аның көче белән гаҗәеп бакча үсеп чыга. СССР Фәннәр академиясе башкорт филиалының Биология институты белән берлектә мәктәп яны тәҗрибә участогында һәм колхоз кырларында тәҗрибәләр уздырыла, сынаулар арасында төрле матдәләрне минераль ашламалар буларак кулланып карау, моның өчен күп кенә фәнни оешмалар белән хезмәттәшлек итү кебек үзенчәлекле юлны сайлауларын да әйтергә кирәк. Белем һәм тырышлык, фәнгә таяну һәм тир түгеп хезмәт итү нәтиҗәсендә югары күрсәткечләргә ирешәләр. Байгелде урта мәктәбе 23 тапкыр СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә (ВДНХ) катнаша, дипломнар, грамоталар белән бүләкләнә, күргәзмәнең Мактау китабына кертелә. Шундый ук бүләкләргә күп кенә укучылар һәм укытучылар лаек була. Ришат Салих улы үрнәге илгә тарала, Бөтенсоюз конференцияләрендә, семинарларда өйрәнелә. Гел яңалыкка, гыйлемгә, иҗатка тартылган Р.С. Исмәгыйлев төбәкне өйрәнүгә, фәнни-педагогик темаларга багышланган китаплар яза: «Нуриман районы тарихы турында очерклар», «Мәктәп директоры язмалары», «Акыл һәм талант белән», «Гомер буе белем алу, яки без барыбыз да Нимесләр мәктәбеннән»; 90 яшенә нуриманлыларның Бөек Ватан сугышындагы батырлыгы турында «Хәтер исән...», 95 яшенә «Хәтер» дигән истәлек китапларын язып бастыра.

Хезмәт тәрбиясе белән беррәттән, мәктәптә хәрби-патриотик тәрбия һәм спортны пропагандалау программасы әзерләнә. Мәктәптә 1950 еллар урталарында – музей бүлмәсе, 1963 елны музей эшли башлый. Ул республикадагы иң яхшы авыл музее булып танылa. Укучылар янына танылган язучылар, фикер ияләре, галимнәр һәрдаим кунакка килә... РСФСРның атказанган укытучысы Ришат Салих улы шушы мәктәптә 40 ел директор булып эшли, илкүләм билгеле педагог, уку-укытуны яңача оештыручы булып танылa, акыллы-зирәк дәвамчылар тәрбияли.

1943 елның ноябрендә госпитальдән кайтып, Ришат Салих улы күрше авылда укытучы кыз Сәрвә белән тормыш корып җибәрә. Бу гаиләдә үскән 5 малай һәм бер кызның гыйлемгә омтылуында, тәртипле, көчле рухлы шәхесләр булуында, шиксез, әниләре Сәрвә Газизовнаның да роле әйтеп бетергесез зур. Шушы зур гаилә өчен күңел

җылысы һәм илһам бирүче, теләсә нинди хәлдән чыгу юлын таба белгән тыйнак, эшчән һәм ярдәмчел әниләре дөнья буйлап сибелеп, үз юлларын эзләгән уллары-кызларына рухи маяк та, туган җирләре, татар теле һәм мәдәнияте белән бәйле үрнәк тә була.

Ришат Салих улы Исмәгыйлевнең фәннәр мәктәбе

Әлеге тырыш, акыллы, уңган гаиләдә 1944 елны олы уллары Флүр дөньяга килә. Мәктәпне тәмамлагач, Свердловскидагы тау-металлургия техникумында, Уфа авиация институтында укый, аннары да белем туплавын уңышлы дәвам итә. Исмәгыйлевларның нәсел шәҗәрәсенә салынган билгене – гыйлемгә омтылуны – әтиләреннән иң беренче булып олы уллары алып китә. Бүген Флүр Ришат улы – техник фәннәр докторы, профессор, Россия Федерациясе Югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре һәм башка бик күп мактаулы дәрәҗә-исемнәргә лаек остаз. Ул Уфа дәүләт авиация техник университетының электромеханика кафедрасы мөдире, профессор.

Аннары эстафетага 1947 елның 15 октябрендә туган Зинфер Ришат улы кушыла. Аның өчен абыйсының белем юлы үрнәк булгандыр.

1949 ел гаиләгә тагын бер малай – Фоатны бүләк итә. Ул да абыйларыннан калышырга теләми. Мәктәпне тәмамлауга, Башкорт дәүләт университетының химия факультетына укырга керә, диплом алгач, эшләү өчен фәнни-тикшеренү институтын сайлый: «НИИнефтехим»га килә. Төрле елларда Волга-Урал НИПИгаз, «Грознефтехим», «Текойл», «ГК Русгазинжиниринг» (Мәскәү) кебек күп кенә оешмаларда җитәкче урыннарда эшли, гаилә традицияләрен дәвам итеп, студентларга белем бирү белән дә шөгыльләнә. Бүген Фоат Ришат улы – техник фәннәр докторы, профессор. 1951 елны туган дүртенче малай – Рафаэль исә, күрәсең, әтисенең мәктәптәге эш-гамәлләреннән илһам алып, авыл хуҗалыгы юлын сайлый. Башкорт авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, Нуриман үсемлекләрне саклау станциясен җитәкли, аспирантура баскычын уза, Башкорт дәүләт аграр университетына килә, анда фәнни хезмәткәрдән кафедра мөдире, профессор дәрәҗәсенә ирешә. Бодай һәм арыш җитештерү технологияләре, алардан төрле продукцияләр җитештерү мәсьәләләре белән кызыксына. Рафаэль Ришат улы – «Ватан» һәм «Салават Юлаев» бодай, «Шихан» кукуруз сортлары авторларының берсе. Башкортстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы итеп сайлануы галимнең академик фәндә дәрәҗәсе зур булу хакында сөйли.

Дүрт абыйдан соң көтеп алынган кыз – Флюра Ришат кызы шулай ук фән юлыннан китә. Мәктәпне тәмамлап, Башкорт дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетында укый, кандидатлык диссертациясе яклый. Озак еллар Эчке эшләр министрлыгының Уфа юридик институтында укыта, чит телләр һәм рус теле кафедрасында мөдир була, фәнни хезмәтләр, дәреслекләр, уку-укыту ярдәмлекләре яза.

Төпчек ул – нигез сакчысы

Язмабыз Зинфер Ришат улына багышланган булса да, минем Салават Ришат улына кагылган өлешне аерып чыгарасым килде. Татар гаиләләрендәге матур традицияне дәвам итеп, йорт-нигезне саклаучы, әти-әниләренең эшен дәвам иткән бу ир-егет – 100 ел яшәгән, һәрчак үрнәк, киңәшче һәм ярдәмче булган әтиләрен югалтканнан соң Исмәгыйлевлар нәселе өчен рухи терәк булып калган кебек тоела. Башкорт дәүләт университетының тарих факультетында белем алып, үз мәктәбенә әйләнеп кайткан, 1985 елның августында әтисен алыштырган мәктәп директоры ул. Директорның да ниндие әле! Башкортстанда беренчеләрдән булып, 1993 елны Байгелде мәктәбе базасында авыл лицееен оештыра. Күптән түгел аңа Ришат Салих улы Исмәгыйлев исеме бирелде. Иҗади эшләүче, укучыларына белемгә һәм фәнгә юнәлеш бирә торган лицейны тәмамлаган 500дән артык укучының 400е югары һәм урта һөнәри уку

йортларына керүе, 73е алтын һәм көмеш медальләр белән билгеләнү – аның хезмәтенә иң югары бәядер, мөгаен.

Лицейда тарихи-төбәкне өйрәнү музее эшли, анда туган җир тарихы һәм этнографиясе буенча бай материал җыйналган.

Дәвамчанлык – иң күркәм сыйфаттыр

«Оясында ни күрсә, очканында шул булыр», ди халык. Исмәгыйлевлар гаиләсенә бигрәк тә туры килеп тора бу мәкаль. Ришат Салих улының кайсы оныгын алма – һәрберсе фән юлын сайлаган! Рөстәм Флүр улы – фән докторы, Калифорния технология университеты профессоры: химия, биология, биофизика, математика өлкәләрендә эшли! Яна Флүр кызы – юридик фәннәр кандидаты, доцент. Ильяс Зинфер улы – химия фәннәре кандидаты, әтисе юлыннан бара. Тимур Зинфер улы – Новосибирск милли тикшеренү дәүләт университетында укыта, аспирантура тәмамлаган. Салават Фоат улы Истанбул университетына барып, икътисад фәннәре буенча белем туплаган. Зөлфия Фоат кызы исә – техник фәннәр кандидаты. Ринат Рафаэль улы – химия фәннәре кандидаты, нефть-газ ятмаларында эшне оештыру проблемалары белән шөгыльләнә. Камил Рафаэль улы – икътисад фәннәре кандидаты, доцент. Флюраның кызы Нелли, улы Әнвәр – юридик фәннәр кандидатлары. Салаватның улы Таһир – техник фәннәр кандидаты, архитектор; тагын бер улы Нияз исә – физика-математика фәннәре кандидаты; кызы Зилә – Италиядәге Тренто университетында аспирантурада...

Шулай итеп, Ришат Салих улы Исмәгыйлевның балалары һәм оныклары арасында – 9 фән докторы, 12 фән кандидаты!

Саннарга күчкәнбез икән, тагын бер серне ачмыйча булмый: болар бит – нәсел шәҗәрәсенең бер тармагы гына. Ришат Салих улының 7 бертуганы гаиләләрендә дә фән докторлары, кандидатлары бар, шөкер!

Ахыргы сүз урынына

Күренекле татар галиме Зинфер Ришат улы Исмәгыйлев белән таныштыру кебек уйланылган иде бу язма. Әмма каләм үзеннән-үзе Башкортстанның гүзәл табигате кочагында яшәгән олы бер нәсел турында сөйләүгә алып кереп китте... Шулай булмый ни: үрнәк алырлык, сокланырлык, горурланырлык, акыллы, затлы шәхесләр, халкымның талантлы, тырыш, гыйлемгә омтылган уллары һәм кызлары бит алар! Кызыксынучанлыгы белән ерак төбәкләргә чыгып китүдән, әллә кай җирләрдән йөреп кайтудан өрекмәгән, шуңа күрә дә халыкта «Озын аяклар» дип кушамат алган киң карашлы Исмәгыйльнекеләр бит алар! Имәндәй нык, йөз яшәп, меңләгән укучыларына тормышта юл күрсәткән Ришатныкылар! Киләчәк буыннары да шуларга лаек булып яшәсеннәр.

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,
академик, филология фәннәре докторы.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, «Глобаль энергия» премиясен тапшыру тантанасын видеодан карый аласыз.

Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

ПРЕЗИДЕНТ ЮЛЛАМАСЫ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ТР Дәүләт Советына еллык Юллама белән мөрәҗәгать итте. Юллама халыкның яшәү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән иде, икътисад, сәнәгать, финанс мәсьәләләренә басым ясалды. Президент 2022 елның Цифрлаштыру елы булачагын җиткерде.

ҖАНИСӘП

Быелгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алу – Россиянең яңа тарихында өченче җанисәп. Моңа кадәр ул 2002, 2010 елларда үткәрелде. Хәзергесе алдынгы технологияләрне киң куллану белән аерылып тора. Анда исәпкә алучының традицион форматта өйгә килгәнен көтеп утырмыйча, ә мөстәкыйль рәвештә (Дәүләт хезмәтләре порталында, Күп функцияле үзәктә яки стационар исәпкә алу участокларында) катнашырга мөмкинлек тудырылды. Исәпкә алучыларга мәгълүматларны цифрлы форматта җыю һәм эшкәртүне җиңеләйтү өчен планшетлар бирелде.

ҖӘЛИЛГӘ БЮСТ АЧЫЛДЫ

Екатеринбургта каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә бюст ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья Татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев, өлкә җитәкчеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, биредә яшәүче милләттәшләребез, шагыйрь иҗатын яратучылар катнашты.

ФӘНИС ЯРУЛЛИН ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казанның Жуковский урамындагы 9 нчы йорт диварында Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин истәлегенә такта (авторы Фәнил Вәлиуллин) ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Хашимова, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Г.Камал театры артисты Равил Шәрәфиев, Казандагы Баулы якташлыгы җәмгыяте рәисе Нурислам Хәбипов, Татарстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, шагыйрә Асия Юнысова, шагыйрьнең хатыны Нурсөя ханым исеменнән сеңлесе Сәвия Хәкимова һ.б. чыгыш ясады.

БЕРЛЕК ГРАНТ ОТТЫ

Татарстан Язучылар берлеге «Үлемсез әдәби полк» проекты өчен Мәдәни инициативаларның Президент фонды грантын отты. Ул фронтовик язучыларны актив әдәби әйләнешкә кертү (китапларын барлау, электрон форматка күчерү, цифрлаштыру, контентны укучыга тарату) максатында бирелә. Грантның күләме 1 432 360, уртак финанслау акчасы белән бергә 2 844 790 сум.

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ НИ ХӘЛДӘ?

Татарстан Язучылар берлегендә Россия балалар китабы советының башкарма директоры Людмила Чижова белән очрашу һәм матбугат конференциясе булды. Кунак Россиядә балалар әдәбиятының бүгенге хәле, илкүләм уздырыла торган конкурслар, аларның шартлары, иҗади бәйгегә килгән әсәрләрнең гомуми проблемалары турында сөйләде.

ТҮБӘН НОВГОРОД ӨЛКӘСЕНӘ СӘФӘР

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары Рифат Җамал, язучы Хәбир Ибраһимов Түбән Новгород өлкәсенең Уразовка авылында булып, күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе Кави Нәҗминең тууына 120 ел тулуга багышланган чараларда катнаштылар.

КҮРГӘЗМӘ

Казандагы Татар китабы йортында шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, сәнәгатьче һәм хәйрияче Закир Рәмиевнең (Дәрдемәнд) тормышы һәм иҗатына багышланган күргәзмә ачылды.

ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булып узды. Аны идарә рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды. Утырышта берлекнең соңгы вакытта эшләгән эшләренә

хисап ясалды, җанисәп алу уңаеннан Бөтендөнья Татар конгрессы белән хезмәттәшлек итү, Әдәби тәрҗемә үзәге турында сөйләшү булды. Идарә Сирень Якупованы (2020 елда «Рухият» тарафыннан нәшер ителгән «Төшләремә яланаяк керәм» дигән шигырьләр җыентыгы өчен) – Һади Такташ, Нурислам Хәсәновны («Язмыш җиле», «Идел-Пресс», 2019) – Фатих Хөсни, Локман Закирны («ЖЗЛ», «Бриг» нәшрият-полиграфия фирмасы, 2020) – Гаяз Исхакый, Халисә Алишинаны («Булат Сулейманов и его наследие в отечественной культуре», Төмән, «Печатник», 2019) – Җамал Вәлиди, Эльмира Шәрифуллинаны («Ак бүре турында баллада», аудиокитап, «Китап» радиосы, 2021) – Абдулла Алиш, Айдар Сәхибзадәне («Проза», ТР Фәннәр академиясе нәшрияты, 2020) – Максим Горький, Равил Сабырны («Абага алмасы ачы була», 2020 елда Чаллы театрында куелды) Туфан Миңнуллин исемендәге әдәби премияләргә тәкъдим итте.

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиянең быелгы лауреатлары билгеле булды. Менә алар – Фәтхулла Абдуллин («Кемгә сөйлим серләремне» китабы өчен), Галина Булатова («Сильнее меня»), Лилия Гыйбадуллина («Кайту»). Кызыксындыру премиясенә Галия Гайнетдинова («Күңел бакча»), Лилия Фәттахова («Ишет мине»), Идият Әширов («Көзләр балкышы») лаек. Моннан тыш бер төркем студентлар Саҗидә Сөләйманова исемендәге стипендиягә ия булды. Бүләкләр Әлмәт Татар дәүләт драма театрында уздырылган тантанада тапшырылды.

ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ҺӘМ РӘССАМНАР ДЕСАНТЫ

ТР Яшьләр эшләре министрлыгы, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе һәм «Идел» яшьләр үзәге Буа шәһәрендәге М.Вахитов исемендәге гимназиядә, Биектау районы Әлдермеш, Әтнә районы Олы Әтнә, Арча районы Яңа Кырлай, Балтач районы Карадуган мәктәпләрендә «Тарих эзләреннән киләчәккә таба» дип аталган әдәбият-сәнгать кичәләре уздырды. Аларның максаты – республикабыз районнарында яшәүче яшьләрнең һәм балаларның игътибарын милләтебезнең тарихына, мәдәниятенә юнәлтү, аларда татар әдәбияты белән кызыксыну уяту, милли кыйммәтләр тәрбияләү.

Әлеге чара кысаларында «Иделем акчарлагы» конкурсында төрле елларда Гран-при алган һәм җиңү яулаган яшь шагыйрьләр (Рифат Сәлах, Фәнил Гыйләҗев, Ләйлә Хәбибуллина, Алсу Сәләхова, Алинә Хәбибуллина һ.б.) тамашачыга үз иҗатларын тәкъдим итте һәм «Тарих эзләреннән» бәйгесе җиңүчеләренең рәсемнәреннән торган күргәзмә оештырылды.

МИЛЛӘТТӘШЛӘР ЯНЫНДА

«Мәдәни җомга» газетасының, «Безнең мирас», «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре – Вахит Имамов, Ләбиб Лерон һәм Рөстәм Галиуллин Башкортстан Республикасында сәфәрдә булып кайтты. Алар Бишбүләк, Күгәрчен, Баймак, Белорет, Мәләвез, Стәрлебаш, Кушнаренко һ.б. районнарда милләттәшләр белән очрашулар уздырды, шулай ук китапханәләр, музейлар эшчәнлеге белән танышты, күренекле татар шәхесләренә бәйле истәлекле урыннарда булды, аларның каберләрен зиярәт итте.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен язучы **Марат Рафил улы Кәбировка** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Шәһәрне беренче төзүчеләрнең тарихи мирасын саклауга, милли мәдәниятне, сәнгатьне һәм халык традицияләрен, әдәби һәм журналистик иҗатны саклауга һәм үстерүгә, яшьләрдә әхлакый-рухи кыйммәтләр тәрбияләүгә зур өлеш керткәне өчен язучы **Фәтхулла Абдулла улы Абдуллинга** «Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданины» исеме бирелде.

2021 елның 10 октябрендә 86 нчы яшендә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, 1990 – 1999 елларда ТР Югары Советы, 1999 – 2003 елларда РФ Дәүләт Думасы депутаты булып торган **Фәндәс Шакир улы Сафиуллин** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы Курган зиратында җирләнде.

Сәхифәне **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман Р.РАХМАН «Татарка»; рассказы А.ХАНА «Одноклассники», Г.МИРХАДИ «Гитара»; стихи Э.ДЖАЛИЛОВОЙ, М.МИРЗЫ, Л.ЛЕРОНА, А.ХИСАМИЕВОЙ.
«К 100-летию журнала «Казан утлары»: статья Ф.БАЙРАМОВОЙ.
«Казан утлары» - в моей судьбе»: статья М.АМИРХАНОВА.
«Новые имена»: повесть И.БИЛАЛОВА «Гора Мадины»
«Литературный конкурс «Ах, милей родной народ!»: рассказ Х.РАЙХАН «Прасковья».
«Встречая юбилей»: фотоархив.
«Литературная критика»: статьи Т.ГАЛИУЛЛИНА, М.ХАБУТДИНОВОЙ.
«Свет далёких огней»: статья А.ХАЛИУЛЛИНОЙ.
«Литература родственных народов»: стихи Б.УКАЧИНА, Б.БЕДЮРОВА, К.ТЕПУКОВА в переводе Р.КУРБАНА, Р.ВАЛЕЕВА.
«Бесценные голоса»: статья к 120-летию М.Рахманкуловой и 130-летию М.Файзи. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
«Журналу «Чолбон» - 95: статья Р.КУРБАНА.
«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.

На наших обложках: Дворец Земледельцев (г.Казань); фото И.Абрамовой.
Поэтесса Лейла Хабибуллина.

IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by R.RAKHMAN «Tatar girl»; stories by A.KHAN «Classmates», G.MIRKHADI «Guitar»; poems by E.JALILOVA, M.MIRZA, L.LERON, A.KHISAMIEVA.
«To the 100th anniversary of the magazine «Kazan Utlary»: article by F.BAYRAMOVA.
«Kazan Utlary» is in my destiny»: article by M.AMIRKHANOV.
«New names»: novella by I.BILALOV «Madina Mountain»
«Literary contest «Ah, dear native people!»: story by H.RAYHAN «Praskovya».
«Meeting the anniversary»: photo archive.
«Literary criticism»: articles by T.GALIULLIN, M.KHABUTDINOVA.
«The light of distant fires»: article by A.KHALIULLINA.
«Literature of related peoples»: poems by B.UKACHIN, B.BEDYUROV, K.TEPUKOV translated by R.KURBAN, R.VALEEV.
«Priceless Voices»: article dedicated to the 120th anniversary of M.Rakhmankulova and the 130th anniversary of M.Fayzi.
The column is led by N.AKMAL.
«Cholbon» magazine is 95: article by R.KURBAN.
«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.
From the photo archive of the magazine.
Diary of social and cultural life.
On our covers: The Palace of Farmers (Kazan); photo by I.Abramova.
Poetess Leila Khabibullina.

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: Игенчеләр сарае.
И.Абрамова фотосы.

Тышлыкның дүртенче битендә: шагыйрә Ләйлә Хәбибуллина.